

# Казан утлары

1. 1983



## Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреатлары

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләрен бирү комитеты тәкъдимнәрен тикшергәннән соң, ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы премияләрне 1982 ел өчен түбәндәге коллективларга һәм кандидатураларга тапшырырга карар кабул итте:

Ленин комсомолы исемендәге **Яшь тамашачы театрына** — яшьләргә коммунистик тәрбия бирүдәге зур эшләре өчен;



**ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевичка** — язучы. «Яшисе килә» повесте һәм яшьләргә багышланган җырлар циклы өчен;



**МИҢНУЛЛИН Роберт Мөгаллимовичка** — балалар өчен язылган шигырь җыентыклары, телевидениедән әдәбиятны пропагандалаганы өчен.

# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1

1983

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## *Бу санда*

**Ә. БАЯНОВ.** Таш китап. Роман . . . . . . . 3
**И. ЮЗЕЕВ.** Мәңгелек белән очрашу. Шигъри трагедия . . . . . . . . . . . . . . 100

МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

**М. ЗАРИПОВ.** Отышлы әйләнеш. Очерк . . . . 123

ПУБЛИЦИСТИКА

**М. ГАЛИЕВ.** Лорка илендә . . . . . . . . 143

ИЛДАР ЮЗЕЕВКА 50 ЯШЬ

**Г. АХУНОВ.** Кыядагы бөркетләр . . . . . . . 148
**Р. ИГЪЛАМОВ.** Хакыйкатьне эзләү юлыннан . . 156

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. МӨХӘММӘДИЕВ.** Тормыш дәвам итә . . . 162

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

**Ф. САФИУЛЛИНА.** Хәзинәдә ниләр бар! . . . 171

ӘМИНӘ БИКЧӘНТӘЕВАГА 70 ЯШЬ

**Р. КУКУШКИН.** Сез бик кадерле безгә . . . . 179

ХӘКИМҖАН ХАЛИКОВКА 50 ЯШЬ

**Х. ХАЛИКОВ.** Рәхим итегез! Шигырьләр . . . 183

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Р. МИҢНУЛЛИН.** Канатлы малайлар, канатлы шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 185

БЕЗНЕҢ САФКА

Р. Кукушкин . . . . . . . . . . . 189
К. Латыйпов . . . . . . . . . . . 189

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

*«Казан утлары» журналының яңа тышлыгын Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов ясады.*


*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

Редколлегия: **ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ,** *җаваплы секретарь* **РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН,** *баш редактор урынбасары* **РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*



Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.



Производствога бирелде 21.09.82. Басарга кул куелды 20.12.82. ПФ 00062. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049 экз.
Заказ Ю-398. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1983 ел.

Әхсән Баянов

# ТАШ КИТАП

РОМАН

## Беренче бүлек



Баскычта Фәез адымнары. Салмак, талчыккан, әмма ышанычлы адымнар. Фәезнең хатыны аларны башкалар адымыннан аера, таный белә. Һәр кич саен көтеп ала. Ишек кыңгыравында кечкенә нокта чеңләп куюга ишек ачыла. Хатыны елмаеп каршылагач, ишек төбендә лампа кабынса-кабынмаса да, Фәезнең чыраена яктылык бөркелә. Чишенеп өлгергәч, хатыны астыртынрак карап тора да, кинәт... агач башына томырылган мәче тизлеге белән Фәезнең муенына асылына. Аяклары идәннән аерыла. Фәез аны юри генә төшермәкче була. Тегесе чынлап карыша, төшми. Юыну бүлмәсенә яки залга кергәч кенә, анда да көн буе мәхәббәткә сусаган иреннәре талчыга төшкәч кенә Фәезне иректә калдыра. Инде өч ел буе шулай. Соңгы көннәргә хәтле. Тик соңгы мәлдә хәл бераз үзгәрде. Арадан ятлар күләгәсе, ятлар хатирәсе узды...

— Син аны бүгенгә хәтле нишләп әйтми йөрдең?— дип үпкәләде Зәрия.— Әгәр читләрдән ишетмәгән булсам...

— Сиңа чаклы булган нәрсә.

— Хәзер дә, хәзер дә очрашасыз!

— Кем әйтте? Кемнәр?

— Исемсез кешеләр.

Бу хакта сүз кузгалгач, Фәез төн буе йоклый алмыйча, эшкә ял итмәгән хәлдә китте һәм көн буе, кыйналган кеше сыман, эленке-салынкы гына йөри алды. Ярый әле килешteләр шикелле. Кеше сүзенә түгел, үз күзләреңә генә ышанырга кирәклеген Фәез кабат-кабат тукылагач, Зәрия тынычлана язды кебек. Ләкин:

— Әгәр үз күзләрем белән күрсәм, Фәйрүзәне күтәрәм дә китәм,— дип янады һәм, ванна бүлмәсенә кереп, битен озак итеп юды. Чыкканда елмаерга азаплана иде. Фәез хатынының күзләреннән, битләреннән үбеп алды. Шулай да ишек катында муенга асылынулар сирәгәйде. Фәез кайтып кергәч, Зәрия аның күкрәгенә башын куя һәм ирен чәчләреннән сыйпагач, җәһәт кенә кухняга кереп китә. Керешли сөйләшмәскә кирәген аңлатып, иренена имән бармагын куя. Кухняда исә:

— Акырын сөйләшә белмисең, кызны уятасың,— дип, яратып орыша.

Кайбер көннәрдә караңгы чырай белән каршыласа, аның саф күңеленә әлеге дә баягы таныш күләгә төшкән булыр, Кама атлы кыз хати-

рәсе... Мондый чакта сүз белән мавыкмавың, бүтән шөгыль табуың хәерлерәк.

Чираттагы шундый көн: бу юлы Зәрия хәтта Фәезнең күкрәгенә башын да куймады. Бәхеткә каршы, күрешкәч үк әйтеп җибәрерлек яңалык белән кайткан иде Фәез. Ялгызлыкта куерып өлгергән шик сөремен таратыр өчен нәкъ әнә шуннан башлады да ул:

— Безгә яңа управляющий килә.

Зәрия башын күтәрде. Күзләрендә сагыш таралырга җыенмаса да бераз гына тормыш, кызыксыну галәмәте ялтырап куйды шикелле. Мәгәр аңладым дигән мәгънә белән керфек сирпүдән ары узмады. «Мөгаен, берәрсеннән тагы сүз ишеткән...»

Үзенең гаепсез икәнен аңлатып, Фәез ашаган чакта да баягы сүзен дәвам итте:

— Фамилиясе кызык — Агарков.

— Ә-ә, матур икән.

Өермәнең хәвефсез генә үтәчәгенә өметләнүдән, Фәез ихлас ук елмайды:

— Үзе нинди булыр.

— Башыгыздан сыйпар өчен чакырмаганнардыр.

Зәрия каладагы хәлләрне яхшы белә һәм шуңа күрә дөрес сиземли. Бүтән фаразларның мәҗбүрияте калмаганлыктан, Фәез хатынының күзләренә уңайсыз гына карап торды. Зәрия күзләрен йомгалагач, сүзне шаянга борырга җай килде.

— Син үз күзләреңнең нинди икәнен беләсеңме?

— Кара диләр.

— Моңарчы мин дә шулай дип йөри идем.

— Фикерең үзгәрдеме? Шулай була инде ул.

— Чү, салулама. Фикер түгел, синең күзләрең үзгәрә.

— Яратсаң — кара.

— Яратсаң — коңгырт. Ә мин бик каты яратсам, яшелгә әйләнә. Явар болыт төсле.

— Сөйләгәндә син бик оста анысы. Үзең...

— Без килештек бит — үз күзләрең белән күрмәгәнгә ышанмаска. Ә уйлап чыгару бөтенләй тыела.

— Нишләп уйлап чыгарыйм, булганы төшә искә... алары җитәрлек.

— Ә син уйлама. Уйласаң да без очрашкан чактан башлап кына... Булды, бетте, бүтән тыңламыйм.

Сүзсез генә чәй эчкәндә, ниһаять, Зәриянең күзләре коңгырт төсенә кайтты. Һәм ул тыныч кына:

— Сине бүген бер кеше эзләп килгән иде,— дип, яңа хәбәр әйтте.

— Кем?

— Сораган идем, әйтмәде. Исемсез кеше мин, ди.

— Тагын бер табышмак!

— Себердә, тайгада бергә эшләдек, ул мине хәтерләргә тиеш, ди.

— Без кемнәр белән генә бергә эшләмәгән! Каян белеп бетерәсең аларны. Җитмәсә, исемсезне!

— Кирәк булса, табар әле.

Өйдә гадәти тынычлык урнашты. Ләкин сүзнең тиешсез якка борылуына бөтенләй җай калдырмас өчен Фәез йокы бүлмәсенә хатыны бераз ойый төшкәч кенә керергә, эш бүлмәсендә китаплар карап утырырга булды. Кулына таныш томнарның берсен алды. Актаргалады. Тик уе һаман бер тирәдә әйләнеп, ул тирән көрсенде. «Эх, Кама, Кама! Сиңа бу өйгә, бу тормышка керү катгый тыела бит. Ишекләр, тәрәзәләр бикле, җиде кат йозак белән. Үзеңә генә түгел, хатирәңә, исемеңә дә. Ә син әрсезләнәсең. Ниһаять, җитте, бүтән килмә, бүтән бер дә килмә...»

Күңелгә житдирәк, хәвефсезрәк тойгылар килсен. Фәез аңа ирешә бeлә.

Китапның беренче битләрен укыгач, уйлар чынлап та янарды. Табигый рәвештә. Мәҗбүр иткәнгә күрә генә түгел. Фәез китаптагы сәхифәләр аша үз хатирәләренә күчте. Алар шулай ук күп — томнар, бер, ике, өч... Хәрефләр һәм юл аралары ут кайнарлыгы белән сулыш ала кебек. Андый вакытлар күп булды шул, артык күп булды. Җир өстенә кабат әнә шундый истәлекле чиллә килде.

*
* *

Чиллә үзенең бу хәтле дә кайнар була алуын соңгы дәвердә онытa язганлыктан, синоптиклар эсселекнең сәбәпләрен үзләренчә аңлатырга тырыштылар. Ләкин төп сәбәпне әйтмәделәр шикелле. Чын сәбәп, мөгаен, Мәскәүдән килгән белгечләр белән Казан кешеләре арасындагы бәхәстә булгандыр. Моңарчы үзенең масштаблары белән бер җирдә дә тиңе булмаган яңа төзелеш хакында бара иде сүз. Кайда, ничек төзергә?

Елъязмалар, ныклап уйласаң, шушы сораудан башлангандыр әле.

Соңгы вакытта гадәтләнүенчә, сөйләшүгә Лазарев Насыйбуллинны да алып барган иде. Тик фикер сорамаганлыктан, икесе дә шаһит сыйфатында гына утырдылар. Күзәтеп кенә.

Күзәтә торгач, тагын бер кешенең бәхәскә омтылмавы аерым-ачык күренде. Уртача гына буйлы, тыйнак кына кыяфәтле кеше. Хәтергә кереп калырга да ашыкмый кебек. Шулай да Фәез аның гадәти булмаган бер бизәген күрмичә калмады. Бу кешенең ике күзе ике төсле икән. Уң күзе — күгелҗем соры, икенчесе — коңгырт кара. Уң күзе белән караса, күңелгә ниндидер яктылык, җиңеллек иңә. Ә аныcын кыса төшеп, коңгырт күзе белән караса, күкрәк туры кызып, битнең кызарасы килә. Өстәвенә аның уң яңагында күзгә ташлана торган матур гына миңе дә бар икән. Шул рәвешле, кырыслык белән матур йомшаклык бер кеше кыяфәтендә бәхәсләшеп яши булса кирәк. Ә кырыслык һәрвакыт җиңәргә тырыша. Зәңгәрсу күзен кыса төшеп, коңгырт күзе белән сиңа текәлсә, бу кеше, үзе дә сизмәстән, яңагындагы сөйкемле миңен каплап, сыйпап тора.

Аның фамилиясе Агарков иде.

Шул көннән башлап, ул, нишләптер, Фәезнең хәтереннән һич чыга алмады. Коңгырт-кара күзен кысып, Фәезгә ул иң җайсыз чакларда да ышаныч сирпегәндәй тоелды. Сәбәбе мәгълүм түгел иде.

Әйе, Агарков, Мәскәүдән килгән делегация составында булса да, бәхәскә катнашмыйча, бәйсез тынычлык саклап утырды. Ә бәхәс сүрелергә теләмәде: Якты Ярга бирелгән уңай бәяләр белән бергә, тискәреләре дә бирешмәде. Уртак бер фикергә килә алмыйча интеккән шул мәлдә өлкә комитеты секретаре әңгәмәне шаянгарак борасы итте:

— Якты Ярның үзенә барсак, анда җил куәтле, һава чиста — шариклар тизрәк әйләнмәсме икән?

Мәскәүдән килгән иң өлкән кунак — министр бу сүзләрне дикъкатьсез калдырмыйча:

— Мең кабат бер үк сүзне тыңлап утыруга караганда, бер кабат күрү хәерлерәк, әлбәттә,— дигәч, башкалар да урындыклары белән арткарак чигенеп куйдылар.

— Үзебез тәкъдим иткән мәйданны тагын бер кабат күздән кичерсәк,— дип житдирәк елмаерга тырышты секретарь,— төзүчеләр, проектчылар да күрсә, бүтән вариантлар белән чагыштырса, барлык минуслар-плюслар үлчәнсә... Шулай түгелме? Беребез дә үкенмәс дип беләм.

— Аэропортка хәбәр итегез.— Министр секретарьга карап алды.— Шулаймы? Алайса, менә кайда тукталдык. Минемчә, автогигантны бер генә җирдә төзү — иң акыллы вариант. Якты Ярда инде зур төзелеш индустриясе тупланган. Энергетика проблемасы тумаячак — гидростанция төзелеп ята. Һәм... генподрядчы әзер. Шулай бит, иптәш Лазарев?

— Без солдатлар, иптәш министр. Иртәгә дисәгез, бүген эшкә керешәбез.

Секретарь министрны икенче яклап куәтләде:

— Якты Ярның географиясе уңайлы. Илнең барлык автомобиль предприятиеләре зур Идел бассейнында — Мәскәү, Ярославль, Горький, Ульяновск, Тольятти... Аларга Кама заводы кушылса, гигант комплекс — «Зур Идел детройты» барлыкка киләчәк. Икенчедән, Тольяттидагы төзелеш материалларын һәм Идел гидростанциясен төзүдән бушаган зур конструкцияләрне су юлы белән ташу җайлырак булачак. Шул ук шәһәрдәге төзүчеләрне күчерү дә мөмкин. Якын. Моннан тыш, су артериясе Якты Ярны Урал белән дә, Череповец металлургиясе белән дә, Идел-Дон каналы аркылы Украина металлургиясе белән дә бәйләгән. Меңнәрчә тонна металлны тимер юл белән генә түгел...

Мәскәүдән килгән баш эксперт аны бүлдерәсе итте:

— Якты Ярга барсак, анда тимер юлны күрә алырбызмы?

Белгеч — рационалист. Энтузиазмга бирелә торганнардан түгел. Аңа үзе кебек үк тимер логика китер. Секретарь шулай эшләргә тырышты да:

— Булачак. Якын киләчәктә. Гидростанция төзелеп ята. Металл ташырга да, әзер автомобильләргә дә юллар иркен, күп булыр. Тагын бер аргумент. Безнең республикада ел саен утыз мең кеше эш эзләп чит өлкәләргә китә. Авылның житештерүчән куәте үсү аркасында, эшче көчләр арта. Без ул көчне Якты Ярга бүләк итә алабыз. Ниһаять, әзер заводның үзенә Казан эшчеләр, белгечләр бирә алачак.

Икенче кеше сүз башлаганда, секретарь үз янында утырган ярдәмчесенә пышылдап кына нидер әйтүгә, тегесе тиз арада бүлмәдән чыгып китте. Ишек ябылуга эксперт комиссиясе җитәкчесе сүзгә кереште.

— Якты Ярда завод төзергә мөмкин. Ләкин бары тик завод кына, ә комплекс түгел. Без двигательләр заводы төзүне урынлы дип исәплибез. Автомобиль җитештерүнең үзен чимал чыккан тирәләрдә төзергә мөмкин. Бөтен дөньяда — шундый тәртип. Йөк ташуларга бер дә юкка дәүләт акчасын туздырасы түгел.

Секретарь ярдәмчесе урап кергән һәм секретарьга нидер пышылдаган чакта, министр киңәшмәгә йомгак ясагандай итте:

— Мәсьәлә ачык кала. Димәк, юлга?

— Самолет әзер,— дип, секретарь аягүрә басты.

Яп-якты ил күгенә «Ил-14» самолеты күтәрелде. Министр икенче як утыргычта гына урнашкан секретарьга борылды:

— Очкан арада уйлап бар — автозаводка нинди исем кушабыз?

Секретарь блокнот битләренә аерым-аерым: «Яңа заводны ничек атар идегез?»— дигән сорау язып, юлдашларының һәркайсына шул язуны җибәрде.

Самолетта Фәез махсус диярлек Агарков янына утырган иде. Агарков секретарьдан килгән язуны күрсәткәч, Фәез дә уйланырга кереште һәм, озак та үтмәстән, блокнот битенә үз атамасын язып куйды: Завод, гадәттә, үзе урнашкан шәһәр исеме белән атала. Газ, Маз, Краз... Якты Яр моның өчен җайсыз. Республика исеме белән атасаң, «Таз» булып чыга, яхшы түгел. Тольятти заводы шул сәбәптән «Ваз» булып китте. Сөземтәдә бер генә вариант кала: елга исеме белән атау.

Агарков кәгазе белән бергә, Фәез үзенекен җибәрде.

Ярты сәгать чамасы һәркем үзалдына уйланып баргач, секретарь арттарак утырганнарга кәгазьләрне кире җибәрүләрен үтенеп мөрәҗәгать итте дә, үз язуын министр кулына сузды:

— Кем варианты сезгә ошаса, шунысын сайларбыз.

Министр, секретарьдан алган кәгазьне карагач, елмаеп баш какты:

— Ярый.

Блокноттан ертылган сигез бит тә килеп җиткәч, аларны карарга керештеләр.

Ләкин шул вакыт самолет түбәнәя башлады да министр «соңрак» дигәнне аңлаткан ишарә белән канәгатьләнеп калды. Ул инде бүтән нәрсә хакында уйлый иде булса кирәк.

Фәез үрелеп җиргә карады. Самолет Иске Чурайның нәкъ түбәсендә янтаеп чайкала иде. «Рабига әби, мөгаен, шундадыр. Күрәме икән?»

*

* *

Әйе, күрә иде әби...

Бу чакта Якты Ярга Казаннан бер генә рейс самолет йөри, һәм ул Рабига әбиләр өе өстеннән чатырдап узганда, сәгать нәкъ уникe тула торган иде. Өй түбәсенә ышкылып диярлек самолет узгач, Рабига әби, ихатадагы теләсә нинди эшен ташлап, өйгә керә һәм аш тирәсендә булашырга керешә — казан кыра, юа, аш яки бәрәңге салып, ут тергезә. Аш кайнап чыгуга тракторчы оныгы — Рәшите, аннары килене Гөлниса кайтып җитә, аннары мич алдына самавыр килеп утыра. Рабига әбинең бәхете таша: нәкъ менә шушы гаилә җылысы җыйналып бөркелгән минутларда була яшәүнең иң олы мәгънәсе, шатлыгы һәм куанычы. Рәхәт була Рабига әбигә — рәхәт, күңелле. Тик менә соңгы ике елда шул бәхет юкка чыкты диярлек. Тракторчы оныгы китеп баргач, Фәез дигән матур ипле генә егет үгетләве аркасында, килене дә калага элдертте. Әбигә шәһәр фатиры почмак кызганмаса да җәйнең ямьле вакытларында ул ярты гомере узган шушы өйгә кайта, ташлый алмый балалар туып-үскән изге нигезне. Ташлый алачагы да юк. Кайвакыт: «Авыл су астында каласы, үзең йоклап ятканда кинәт су эчендә калып һәлак булырсың, әби,— дип өркетергә тырышсалар да әбиегез тыныч кала: «Үз диңгеземдә җан бирергә насыйп итсен, шуннан артыгы безгә кирәкми...»,— дип кенә куя.

Хәзер килене Гөлниса тәпиләре бу өй идәненә бөтенләй басмый диярлек, оныгы Рәшит хәл белергә атнага бер генә кайта. Самолет тавышы ишетелүгә, чебешләрен ашату, су эчертү кебек шөгылен калдырып, әби аягүрә басты да билләре языла төшкәнче йөренгәч, һавага күз атты. «Бигрәк тә яман гөрелди бүгенге күк арбасы. Әллә олырак та үзе. Вакыт иртәрәк тә кебек иде — мавыгыбрак кителгәндер инде. Әй, гомер — шулай сизелми дә уза да тора шул. Әй гомерләр! Инде алтмышны да тутырдык менә».

Самолет күздән югалгач, әби, өйгә кереп, гадәттәгечә казан тирәсендә мәшәкатьләнергә керешә. Үз-үзенә: «Хәзер, балам, син кайтып керүгә шаулап кына кайнап чыга ул аш. Чәй дә булыр. Бер оя, бер иш кенә, чөркелдәшә-чөркелдәшә сый рәхәте чигеп утырырбыз. Биргәненә шөкер, әйе, һич тә зарланырлык түгел, бәрәңгесе дә җитәрлек, оны, токмачы да. Рәшит каладан колбаса дигән кызыл ризык та алып кайткалый да, тик анысының ак мае күренеп тора, чучка мае диләр. Шуңа күрә, ходай үзе шаһит, нәфескә бирелми Рабига дигән колы, аллага шөкер. Насыйп итеп, урын оҗмахтан булыр, язган булса. Инде ул хакта уйларга бик тә вакыт. Күпме генә якты көннәр калгандыр.

Бердәнбер көнне гелт итәр дә мәңгелеккә сүнәр. Сүнәр дә Рабига дигән кеше өчен икенче тормыш башланыр. Каберстанда җеназа укылгач та Рабига әбиегез янына мөнкир-нәнкирләр килеп сорау алыр: «Исемең кем?» — «Рабига», «Өммәтең кем?» — «Өммәтем — Мөхәммәт», «Өммәтең Мөхәммәт икәнлеккә минем шигем бар» — «Синең шигең булса, минем шаһидем бар». «Шаһидең кем?»— «Шаһидем — бер алла».

— Лә илаһе иллалла, Мөхәммәде рәсүлулла.

Сорау алынганнан соң күпме вакыт икәнлеге билгесез арада Рабига әбиегез үзеннән киткән җанның кире кайтуын көтеп ятар. Дөнья бетеп, барлык җаннар теге дөньяга кайтып беткәч, ниһаять, Исрафил фәрештә сурын өрер һәм кыямәт, мәхшәр башланыр.

Исрафил сурын өргәй,
Барча җан тәнгә кергәй.

Рабига әби карлыккан тавыш белән шулай көйләп куйды.

— Лә илаһе иллалла, Мөхәммәде рәсүлулла. Оҗмахлы итәрсең, аллаһы боерса.

Ни хикмәт, Рабига әбиең күңеленә оҗмах балаларының каладагы өе сурәтендә күренә. Каладагы шул өйгә кил дә звонок төймәсенә бас. Шунда ук ишек ачалар...

Оныгы Рәшит нишләп кайтып керми соң әле? Самолет узып киткәнгә биш былтыр, ә малай дөбердәп кайтып керми дә керми. Юлда берәр алама хәлгә юлыкмасын тагы, «Раббым — бер алла. Үзең ярлыка барлык гөнаһлардан, сакла барча бәла-казалардан».

Аш пешеп, чәй кайнаганнан соң да күзләрне күгәртерлек вакыт узды инде — таныш тавыш ишетелмәде. Аптырагач, мич авызындагы күмерләрне әчкәрәк этеп куйгач, самавыр торбасын алып, олы мич кырыендагы тишеккә тыккач һәм бераздан янә күмер өстәгәч, урамга чыгып китте. Юк, оныгы анда да күренми иде. Ниндидер курку, шөбһәгә бирелеп, хәлсез йөрәге жуылдап куйды. Бер-ике ел элек кенә басу капкасы дип йөртелгән урынга чаклы барып та әйләнде. Шуннан соң кайгысыннан авыраеп, өйдә мендәргә сөялеп торган иде, бераз черем итеп алган булып чыкты. Уянып китсә, аның алтын багана мисалында йөргән баласы елмаеп басып тора.

— И, балам, балакаем! Кара кайгыларга саласың башымны.

— Нишләп алай дисең, дәү әни?

— Ашларым, чәйләрем суынып бетте инде.

— Иртәрәк салгансың.

— Самолет узып киткәч тә инде.

— Нишләп узып китсен ди самолет, әнә килә генә ләбаса.

Чынлап та самолет тавышы якынлаша иде.

— Менә инде, тагы... саташа башладым микән әллә? Бая узып киткән иде бит!..

— Төшеңдә генә ишеткәнсеңдер.

— Ашны да төштә пешердем микән?

Рәшит казанны ачса, мизгел эчендә тәнгә үк үтеп кергән тәмле куәт бөркелеп, борынны иркәләде.

— Юк, дәү әни, чынлап пешкән аш. Бүтән төрле самолет булгандыр ул.

— Ярый алайса, бүтән төрлесе булса, анда килгән кешеләргә дә иминлек бирсен. Бәхет-шатлыклары белән гомер сөрсеннәр.

Бу вакытта кемнәргә озын гомер һәм бәхет теләгәнен әби үзе дә, аның оныгы да белмиләр һәм Якты Ярда яңа шәһәр төзергәме, юкмы дигән сорауга җавап өстәп килгән делегацияне китергән самолет икәнлеген башларына да китерә алмадылар, әлбәттә.

* * *

Махсус самолетны каршы алырга шәһәр башлыклары, әлегә бердәнбер булган трест һәм дүрт данә төзү-монтаж идарәсенең байтак кешеләре килгән иде.

Якты Яр җиренә беренче булып өлкә комитеты секретаре аяк басты һәм шәһәр җитәкчеләре төркеменә кушылып, кунак каршылау йоласын башлап җибәрде. Министрга соры костюмлы, башына капрон эшләпә кигән, базык гәүдәле, утыз-утыз биш яшьләрдәге кешене тәкъдим итте.

— Менә бу — шәһәрнең һәм районның баш җитәкчесе.

Баш җитәкче дигәнебез үзенең фамилиясен ике куллап тапшырды:

— Аппаков.

Секретарь икенче иптәшне күрсәтте:

— Коровкин.

Аннары фамилиясез генә исәнләшүләр китте. Ул да булмады, арткы рәтләрдән туйга киенгәндәй ак киемле кызлар кулларына чәкчәк тотып килеп чыктылар.

— Кукурузмы бу?— дип сорады министр.

— Юк, чәкчәк,— дип аңлатты секретарь.— Рәхим итегез, кабып карагыз. Кая, кискәләгез әле.

Аппаков тарелкадагы кечкенә пычакны алып, чәкчәкне ашыгып кискәләргә керешә:

— Рәхим итегез, безнең иң кадерле кунакларны каршылый торган сыебыз — рәхим итегез.

Шулай да чәкчәкне беренче башлап өлкә комитеты секретаренең үзенә алырга туры килде.

Кукуруз дип уйлыйлар шул аны беренче күргәндә. Ләкин ул кукуруздан тәмлерәк, минемчә.

— Кайда үсә ул? Ничек итеп җыялар аны?— министрның чәкчәк күргәне булган, ахрысы. Үзенең юлдашын, баш экспертны котырткан гына икәнлеге мут күзләреннән аермачык беленә иде.

Мактый-мактый ризыктан авыз иткәндә танышу дәвам итте. Аппаков ул арада:

— Сезгә ошагач, безгә шуннан зур горурлык юк, рәхмәт,— дип пычакны тарелкага куйды.

— Булды, рәхмәт. Хәзер алып барыгыз инде мәйданга.

— Мәйдан фактта шушыннан башлана, хөрмәтле министр.

— Бу миңа аэропорт сыман күренгән иде.

— Аэропорт башка урынга күчәчәк.

— Кызык, безнең планнарны сез каян беләсез? Бу кешегез күрәзәчеме әллә?— Министр секретарьга көлемсерәп карады.

— Күз күрер. Сүзе чынга ашса, андый гына ланны җәлләмәбез.

Аппаковка активлык күрсәтергә җай тагын да арта төште.

— Сезнең расписание ничек соң? Юл кешесе, бераз ял итәсезме, әллә?..

Министр мәйданны әйләник дигәч, Аппаков кунакларны машиналарга чакырды. Башта арткы урынга министр белән өлкә комитеты секретаре, алгы утыргычка Аппаков, аннары бүтән машиналарга хуҗалар утырышкач, Минзәлә юлына таба кузгалдылар.

Юлларның ике ягыннан да кара-кучкылланып кабарган арыш, бодай, арпа дулкыннары кешеләрне күмеп китәрдәй булып чайкала иде. Сүз үзеннән-үзе булачак уңышны җыеп алу хакында, әйбәт көннәр, һавалар хакында куерып китте. Өлкә комитеты секретаре бик әсәрләнеп, әгәр һава хәлләре шәп торса, былтыргыга караганда ким дигәндә яртылаш артык алыначак уңыш турында сәнгатьле үк чыгыш

ясап ташлады. Аннары бүтәннәр аның чыгышын үз яшьлекләреннән калган истәлекләр белән дәвам иттеләр. Җәй, яшел кош алар теле белән сайрый иде. Аппаков ымы аркасында машина тукталгач та һәркайсы яшел диңгез дулкынлануын күздән кичерә-кичерә, күкрәгенә яшел дәрт сулады.

— Ах-ха-ха! Менә кайда икән ул оҗмах!..— дип куйды министр.

— Шушындый җирне актарып ташламакчы буласызмы?— дип гаҗәпләнде баш эксперт.— Болай да күпме болынныгызны, җәйләүләрегезне су күмәчәк. Минемчә, сез бу җирләрдә, бик зурдан кубасыгыз килсә, ниндидер гигант агро-кала төзергә тиешсез. Металл кою дигән, газ, химия дигән әйберләрне кертергә ярыймы икән шушы яшел дөньяга? Ә автогигантны кайдадыр уңыш бирми торган кара туфраксыз өлкәләрдә төзегәндә, акыллырак булмас идеме?

Беразга тынып калдылар. Өлкә комитеты секретаренең бу сорауга җавабы күптән әзер иде әзерлеккә. Ләкин ул Мәскәү кунагына капылт бәрелергә кыенсынды һәм ярдәм көткән караш белән министрга текәлде. Ә министр, билгеле, күптән Якты Яр тарафдары буларак, секретарьның карашын аңлады.

— Урынның матур булуы — бигрәк тә шәп. Матур табигать — төзүчегә дә, аннары шәһәрдә эшләячәк меңнәрчә кешеләргә дә ял итү, сәламәтлек ныгыту өчен менә дигән хәзинә булыр. Алар моңа муафыйк эш башкара алачаклар. Шуңа ышанырга кирәк.

— Лирикага бирелсәк, сезнең бу сүзләрдә мәгънә бик зур, Михаил Алексеевич.— Шулай дигәч, баш эксперт ихлас көлде.

Секретарь министрга җәһәт ярдәмгә килде:

— Шәһәрдә өч йөз илле мең кеше яшәр. Кара туфраксыз өлкәдә төзегәндә, азык проблемасы, өстәмә проблема туачак. Монда, үзегез күрәсез, яшел зона бүгеннән әзер... Индустриаль нигезгә корсак, башка өлкә, башка республикалардан ризык көтеп ятмаска мөмкин булыр. Минем шундый исәп:

Баш эксперт, бирешмәсә дә:

— Уйларга кирәк, әлбәттә,— дияргә мәҗбүр булды.

Тар юлдан сүзсез атладылар. Секретарь экспертлар тирәсенә күчеп, үзенең баягы фикерен шәрехләргә тырышты. Алар инде актан да, карадан да сүз әйтергә ашыкмыйлар иде. Секретарь, шуны сизеп, яңадан үзенең төп тарафдары булган министр янына килде. Килде дә... башкаларның гаҗәпсенүенә дикъкать итеп, алда ниндидер дөбердәү ишетте һәм шунда ук күзенә машиналар чалынды. Ул арада Аппаков барлык иптәшләрне шул тирәгә чакырды:

— Безнең кечкенә сюрприз бу, гафу итегез. Ә без аны сезнең карамакка тәкъдим итәбез.

Шулай дигәч, беренче булып машиналар тарафына ныклы адымнар белән үзе атлап китте.

Якында гына кран һәм экскаватор гөрләп утыра иде. Кран зур гына бетон конструкцияне җилтерәтеп алды да, әле генә казылган тирән чокыр авызы өстендә тирбәтергә керешә. Аппаков исә нәкъ малайларча мавыгып, шул тирәдә кайнаша башлады. Ә үзе кунакларны:

— Сабыр итегез, хөрмәтле иптәшләр, берничә минуттан без сезне үзебез дәшәрбез,— дип тынычландыра торды.

Ниһаять, кран кодрәте белән, бетон багана чокырга төшеп, агач өй дивары хәтле ак бетон плитә өске якта тип-тигез булып урнашты. Бетон дивар аклыгына кызыл хәрефләр белән: «Здесь будет построен Камский автомобильный батыр», дип язылган иде.

— Кызык сюрприз!— дип елмайды министр.

Секретарь Аппаковның җилкәсеннән кагып куйды. Ләкин сүз әйтмәде. Калын тавыш белән Лазарев:

— Мәйдан ачык, тәзелеш башланды!— дип игълан итәргә ашыкты.

— Иптәшләр, тарихи вакыйгага сезнең дә катнашуыгызны үтенәм. Механизм бездән башка да үти ала бу эшне, бик шәп итеп. Шулай да... Шулай да, иптәшләр, менә көрәкләр — үкенмәссез,— дия-дия Аппаков бер көрәкне министрга, икенчесен секретарьга бирде дә үзе өченче көрәкне иелеп алды һәм шул рәвешле кунаклар өмәгә катнашып китүләрен үзләре дә сизми калдылар. Тиз арада чокыр күмелеп тә бетте.

Фәез Насыйбуллин үзенә эләккән көрәкне баш экспертка бирде. Баш эксперт елмаерга һәм берничә көрәк балчык ташларга мәҗбүр булды. Эш бетәр алдыннан Фәез, сүзенең кемгә адресланганын үзе дә уйламастан:

— Хәзер инде каккан казыгыбыз да юк дия алмассыз. Беренче казык кагылды,— дигән белдерү ясады.

Фәез шул чакта үз сотрудникгы булган Хәмитовның да бер үк тирәдә, әйтергә кирәк, тарихның иң кирәкле төшендә кайнашуын шәйләп алды. Фәез аңа монда килергә кушмаган иде. Балчык беткәннән соң секретарь кулыннан көрәкне шул егет эләктерде.

— Бирегез миңа, урнаштырыйм,— дип, зифа гәүдә һәм озын кулы белән ихлас рәвештә сузылды.

Аннары шул ук кунакчыллыкны министрга күрсәтә алды. Шактый кыю егет. Көрәкләрне читкәрәк илтеп ташлагач, Аппаков янына барып, аның белән дә сөйләшерлек сүзләр тапты.

Кунаклар һәм хуҗалар министр белән секретарь тирәсенә җыелдылар. Министр шул вакыт үзеннән күз алмый торган Аппаковка карап:

— Бу иптәштә шактый көрәзәлек бар икән,— диде һәм аннары җитди сорау куйды.— Тәгаен карарга әле килгәнебез юк. Бу сезгә билгелеме?

Аппаков күз дә йоммады:

— Билгеле, әлбәттә, билгеле.

— Шулай да тарихны ашыктырырга, аннан узыбрак китәргә булдыгыз?

— Тарихның үз логикасы бар. Без шуңа исәп тоттык. Иптәшләрнең дә шуны сизгәнлеген чамаладык.— Шулай дип, Аппаков министрның үзенә һәм башка кунакларга кинаяләде.

— Ну, что ж. Карарбыз, күрербез. Шулай бит, Николай Яковлевич?

— Шулай,— дип баш какты баш эксперт.

— Митинг кору, тантаналы ачышларның кирәге чыкмас дип беләм.

— Шулай да...— секретарь Аппаковка ишарәләде.— Хуҗаларны тыңлыйк. Бәлки аларның сүзе бардыр?

— Сүз шул гына. Юлдан килгәч чәй дә эчмәдегез, ял итмәдегез. Монда күпме йөрелде. Бераз тамак ялгап алыйк. Аннары, фикер туса, кирәк булса, сезнең күздән, киңәшләрегездән качмабыз. Шулайдыр бит? Хәзер төшке аш көтә. Сезне шунда чакырабыз, рәхим итегез.

Машиналар гөрләп узганда, кырыйда ак диварга һәм андагы кызыл язуга тагын бер кабат игътибар иттеләр. Аппаков кычкырып укыды:

— «Здесь будет построен Камский автомобильный батыр». Шәп яңгырый бит, ә? Замечание ишетмәдек, беркемнән дә.

— Кай арада килеп чыкты соң шундый төгәл сүзләр?

Секретарь министр соравына каршы үз соравын куйды.

— Бер үк закон — табигыйлек, тормышның үз законы. Шуны сизә, күрә белсәк...

— Уңышка исәп тотарга мөмкин.

— Әлбәттә. Без дә шул уйда.

— Димәк, фикердәшләр,— дип Аппаков артка борылды һәм, мут кына итеп, ияген сыйпап куйды.

— Әгәр бүтән фикер өстенлек алса? Бүтән таба капыл борылса?

Андый ихтималлык та юк түгел бит. Аннары кая куярсыз ул истәлекле бетонны һәм андагы язуны? Әйтик, заводны башка җирдә дә сезнең кебек көтәләр? Ә?

— Анда да каксыннар шундый ук казык. Истәлеккә калыр, безнеке дә шулай, үкенечле хаклыгыбыз хакында сөйләп торган һәйкәл сыман торыр. Комачау итмәс ул беркемгә дә. Без шулай уйлыйбыз, гафу итегез.

— Җиңелү, ялгышу һәйкәле булып чыгудан да курыкмыйсыз?

— Курыкмыйбыз, иптәш министр, гафу итегез.

Шуннан соң министр секретарьдан сорады:

— Бу кеше монда күптәннән эшлиме?

— Ай чамасы бар инде.

— Һәм шул арада — Якты Яр патриоты.

— Республика патриоты,— дип Аппаков тагын артка борылды — Димәк, бөтен илнеке.

— Республика, ил масштабы... Якты Яр... кызык.

— Өстәмәгә бодай басулары, бытбылдыклар. Сез ишетмәдегез.— Баш экспертның һаман үз уйлары ныклы иде, күрәсең.

— Ишеттек. Мин ишеттем. Шулай да вакыт җитмәде. Тагын киләсе булыр.

— Рәхмәт, көтәрбез.

Пристань янында машиналардан төшкәч, әле генә күргәндәй итеп, министр Агарковка мөрәҗәгать итте:

— Игорь Дмитриевич, сез нишләп әле фикер яшерәсез? Туганлык кебек гигант кала торгызган практик ничегрәк уйлый, ә? Безнең өчен бу кызыклы булыр иде.

Агарков адымнарын акрынайтып, министр белән тигезләште.

— Нинди мәгънәдә?

— Мәгънә бер генә бит, Игорь Дмитриевич — кая төзергә дигән сорау тирәсендә. Сезгә, мәсәлән, төзелеш тапшырылса, сез аны кайда күрергә теләр идегез? Гигант автозаводны. Ә?

— Гигант автозаводны. Мин аны, иптәш министр, теләсәгез, айга, хәтта Марска илтеп сала алам. Тик бер генә нәрсә булсын.

— Тыңлыйбыз, Игорь Дмитриевич.

— Тик бер нәрсә: аның урыны һәм үзе экономик яктан тәмам өйрәнелгән, акланган булсын. Бу очракта...

— Аңладык, Игорь Дмитриевич.

Министр практик сүзенә ихтыярый кул изәве белән чик куйды. Һәм Агарков исә шуннан соң тагын актыкка чаклы ярты сүз, ымлык кына да чыгармады. Үзе дә, чырае да металлдан коелган шикелле иде.

Насыйбуллин үз күзәтүләреннән шундый нәтиҗә чыгарды. Министр — ихтыярның үзе. Аңа төзергә, төзергә — тизрәк, күбрәк төзергә кирәк. Кош очар өчен яратылган... Өлкә комитеты секретаре, Аппаков һәм башка хуҗалар — туган җир престижы белән яналар. Омтылыш законлы: республика данын янгырата һәм җирнең кыяфәтен заман рәвешенә кертерлек эшләр башкарырга кирәк. Ә баш эксперт? Аңа нәрсә җитми? Баш эксперт — саф рационализмның үзе. Ләкин ул битараф бугай. Энтузиазм аңа килешми дә кебек. Кайсы җиңәр? Битараф акылмы, әллә ихтыярлы омтылышмы?

Фәез чамалый. Башкалар да сизенә торгандыр, әлбәттә...

Дебаркадер аша катерга кереп утырдылар. Катер аларны Кама буйлата бераз түбәнгә таба алып китте һәм, сәгать тә узмастан, сөзәк ярга килеп борын төртте. Катердан кешеләр тугайга таба атладылар.

Насыйбуллинның истәлекле урыннары. Җәй көне моторлы көймәдә Кама, Гета, Борис белән, кышын җәяү яки чаңгыда... мылтык, ә кайтканда куян асып... Әйе, истәлекләр чәчләргә, йөзләргә куе җил, урман һавасы мисалында кагылдылар да бүгенге күренеш һәм хәлләргә урын

һәм җай бирү өчен нәзакатьле генә кире чигенделәр — үз вакытларына кайтып киттеләр. Ә бүгенге көннәнниләр калачак?

Пионерлар җәйләвенә барып җиткәндә, анда инде өстәлләр әзер, кунакларны көтәләр иде. Кунак каршылауның иң гүзәл галәмәте булып, өстәлләр тирәсендә ак башлык, зәңгәрсу күлмәкләрдән кызлар көлемсерәп тора иде. Кунаклар утырышкач та алар өстәлдәге «шифалы су» һәм утлы су шешәләрен ачарга керештеләр һәм утырган һәр кунакка елмаю бүләк итәргә иконнен дә онытмадылар. Ниһаять, табын әзер иде. Шул вакыт секретарь аягүрә басты. Беренче сүзе, әлеге дә баягы, кызларга юнәлгән иде.

— Рәхмәт сезгә, кызлар. Өстәлне искиткеч матур, зәвык белән бизәгәнсез. Инде безгә монда эш күп калмаган икән. Без инде үзебез генә, ирләр генә дә җиңеп чыгарбыз дип беләм. Бер сүз белән әйткәндә — кызларга бик зур рәхмәт. Аларга хәзер ял бирик. Артык чибәр булганыгыз өчен дә рәхмәт сезгә. Инде баягы үтенечне кабатлыйм: үзебезнең кунакларны без, ирләр генә җыйнаулашып сыйлыйк инде. Ә сезне, кызлар, шәһәргә катер илтеп куя. Тыныч кына ял итегез — тагын бер кабат рәхмәт.

Кызлар чылтыр-чылтыр көлештеләр дә, күз ярмас тизлек белән икенче якка чыгып та киттеләр. Ул арада Аппаков Хәмитовны үз янына чакырып нидер әйткәч, Хәмитов ишеккә таба ашыкты. Кызларны матур гына озатып куярга кушылды бугай аңа.

Тостлар башланды — кунаклар, хуҗалар исәнлегенә, алдагы уңышлар, хәерле ачышлар намына. Шул ук вакытта үз нәүбәте белән киләчәк төзелеш тә әңгәмәгә килеп кермичә калмады. Якты Ярның хәзерге кыяфәте бөтенләй үзгәреп бүтән шәһәргә әйләнәчәге телгә кергәч, кайсыдыр берсе, аңа икенче исем кушу ихтималын әйткән иде, тагын купты сүз, китте бәхәс. Түзә алмыйча, Фәез аягүрә басты:

— Хөрмәтле иптәшләр, минем дә сүзем бар иде, рөхсәт итмәссезме икән?

— Торып баскансың икән, давай выкладывай,— дип рөхсәт итте Аппаков.

— Мин — Фәез Насыйбуллин. Таныш булмаганнар өчен әйтүем. Абориген. Якты Ярның үз кешеләре тагын бардыр. Булмаса да, барыбер күбесе җирле кешеләргә әвереләчәк. Һәркемнең үз исеме бар, бүгенгесе көндә шунысы хак. Әйтәсе килгәнем шул. Менә без, бүгенге Якты Яр кешеләре, эш, төзелеш барышында үзебез дә үзгәрәчәкбез бит.

— Әйе, шәһәр белән бергә кешеләр дә үсәчәк.— Аппаков аңа ярдәмгә килде.

— Шунысы хак. Мәгәр мин болай уйлыйм: күпме генә үзгәрсәк тә, үз табигатебездән ерак китә алмабыз, шуңа күрә исемебезне алыштыру хаҗәте чыкмас. Мин, мәсәлән, Фәез булып, Насыйбуллин булып калырмын. Иптәш Аппаков та, башкалар да. Якты Яр да шулай, күпме генә үзгәрсә дә аның җире, табигый урыны, тарихы, бүгенгесе дигәндәй... Кешеләре, таулары, күлләре, урманнары, ниһаять, Кама суы... Әлегәчә калыр лабаса? Якты Яр нишләтсәң дә Якты Яр димәкче булам.— Фәез утырды. Дулкынлануын җиңәр өчен мөлдерәмә рюмканың тулы хәлендә башына җитте. Колагына секретарьның:

— Менә сезгә, рәхим итегез, патриотизмның шушындый рәвеше дә була,— дигән нәтиҗәсе һәм министрның:

— Мәгънәсе дә юк түгел,— дигән искәрмәләре йогып калды.

Шуннан соңгы сүзләрне Фәез гамәлдә ишетмәде. Таралышканда гына истә калырлык күренешкә тап булды. Күрде дә шаккатты Фәез. Гыйбрәтме, я мәзәкме итеп, шушы көнгәчә дуска-дошманга сөйли алганы юк.

Мәҗлес тәмам. Кунаклар урыннарыннан кузгалдылар. Кунаклар торып баскач ук, алар янына Аппаков һәм аңа сыенып кына, Айрат Хәмитов килеп житте. Ишеккә таба һәркем кунаклар артыннан нярсә, Хәмитов аларга алдан юл күрсәтә белде. Бер сүзсез — ым белән, хәрәкәт белән. Мәскәү һәм Казан кешеләре плащларын ишек катында, гардеробта калдырганнар икән. Айрат, тиз арада шунда кереп, өч плащ һәм эшләпә алды да барьер өстенә куйды. Куйды да җәһәт кенә бу якка чыкты. Кунаклар сүз белән мавыккан арада Айрат аларга плащларын тәкъдим итте: иң башлап министрга, аннары секретарьга, аннары баш экспертка һәм аннары — Аппаковка. Кунаклар игътибар иттеме, юкмы, ләкин Аппаков аның кунакчыллыгын күрде һәм ошатты:

— Молодец, хуҗа була беләсең икән,— дип, аркасыннан чәбәкләп куйды. Фәез боларны читтәнрәк күзәтте һәм күңелендә Айратка, аның әлеге гамәлләренә ниндидер дә бәя бирә алмыйча аптырады. Кунакчыллык — шәп нәрсә. Тик менә ул кунакчыллык нишләп әле күзгә бәрелде? Фәез үзе шундый була алыр идеме? Була алса, андый мөмкинлек аңа да бирелгән иде — өч плащ һәм эшләпәнең икесен, һич югы берсен генә эләктер дә — чык гардеробтан һәм тәкъдим ит олы ихтирамыңны... Ләкин Фәез моны эшли алмады, эшли алмый, эшли алмаячак. Әмма син булдыра алмаганга икенче берәүнең кулы бара икән, моңа ник гаҗәпләнергә?

Хуҗа була белү... Насыйбуллинда бу тойгы юк, ахрысы, һәм булса да бик зәгыйфьтер ул... Ярый, җитте, оныт. Инде пристань. Машиналарга төялделәр. Автомобильләр кабат аэропортка юнәлде. Һәм кунаклар көнне, җирне, һаваны мактый-мактый, самолетка утырдылар. Кул болгап яшел яланда дүрт кенә кеше калды: Аппаков, Лазарев, Хәмитов, Насыйбуллин.

Аппаков Лазаревны култыклагандай итте:

— Я, ничек, тәэсирләр?

— Әйбәт, хәтта бик яхшы дияр идем.

— Ничек хәл итәрләр дип уйлыйсыз?

— Ә безнең теге таш шактый авыр бит,— дип көлде Лазарев, көндез кырда калган бетон диварга һәм андагы язуга ишарәләп.— Минемчә, кузгата алмаслар.

— Минем дә яшь йөрәгем шулай дип тибә.

Кайтышлый Хәмитов — Аппаков машинасына, ә Фәез Лазарев машинасына утырды.

Лазарев бүген үзенә хас булмаганча тыйнаклык саклады. Алдагы зур эшләр, киң колачлар, тантаналар күңелен җилкеткәндәй итсә дә, ул эшләрнең җаваплылык, авырлык дигән өлешләре җилкәдә хәзер үк инде сизелә иде шикелле. Лазаревның гадәттән тыш тыйнаклыгын Фәез шуңа юрады. Тик менә үз халәтен аңлата алмый иде әле. Аның күңелендә бүген ни сәбәптәндер кимсенү, үкенү кебегрәк тоем гарьләнүгә табарак авыша һәм кечкенә генә, энә очы нәзеклегендәге соры төтен рәвешендә көйри башлаган кебек иде.

* * *

Самолетны Рабига әби күздән җуелганчы озатып калды. Анда нинди кешеләрнең нинди ниятләрдә йөрүен белмәсә дә:

— Хәерле сәгатьтә, ходай юлыгызны уң кылсын,— дип укына-укына, теләкләр теләде.— Самолет тәмам күмелгәч кенә каш өстеннән кулын алып, оныгы Рәшит янына, өйгә кереп китте.

Ә шуннан соң?

Ә шуннан соң елъязмаларның яңа томнары барлыкка килде.

*
* *

Фәез кулында шул томнарның берсе.
Каһарманнар.
Аларның да — беренчеләре.

Беренчеләр арасында — Павел Агафонов белән Фарук Сәхәбин исеме телләрдә күбрәк тәрләнгән чак. Хәзер уйласаң, хәтта бераз сәеррәк.

...Павел авыру сәбәпле, Сәхәбингә ике смена рәттән эшләргә туры килде. Соңыннан бөтен таныш-белеш кызык итеп сөйли торган мәзәк хәл нәкъ шул көнне башланды да инде. Ул көнне, олы начальниклыгын кече итеп, төзү идарәсе башлыгы Айрат Барневич Хәмитов Сәхәбин янына килде.

Арылган. Телгә — сүз, чырайга елмаю килерлек түгел. Шуңа күрә бугай, гадәттә төрткеле, ордылы-бәрделе начальникның май кояшы төсле көләп карьерга килүе хәтта аңлашылмаслык сыман иде. Олы начальниклыгын кече итеп килгән бит. Кабинадан төшәргә ым бирә. Башлык чакыргач, эшне туктатып тормыйча да ярамый.

Бүрек канатларын кагындыра-кагындыра, Хәмитов янына килде экскаваторчы. Начальник аның кулын кысып, тантаналы рәвештә яңалык игълан итте:

— Котлыйм сезне. Чын күңелдән. Сезнең хакта шәһәрнең иң югары комитетында сүз булды. Сезнең экипажны бик каты күтәргәннәр.

— Аны ничек күтәрергә мөмкин соң?

— Мөмкин икән. Сезнең экипаж башлыгына — сиңа, Сәхәбин, автозавод төзелешендә беренче чүмеч туфракны казып алуны ышанып тапшырдылар.— Фарукның сәерсенебрәк торуын абайлаганга, начальник үзе дә аптырабрак калды.— Аңламадың мәллә?

— Аңладым.

— Нәрсә аңладың?

— Икенче урынга күчәбез.

— Соң?

— Шул. Күчәбез, сез кушкач.

— Ә беренче чүмеч җир алу?

— Беренчесе дә, икенчесе дә булыр инде, бер керешкәч.

— Менә дивана. Аңлыйсыңмы син, автоград төзелешен тантаналы башлау дигән сүз бу — беренче чүмеч. Син үз экскаваторың белән бөтен халык каршында эшлисең шуны, белдеңме? Халык, халык җыела.

— Нәрсә, аларга эш беткәнмени? Ул халыкка дим.

— Кара әле, кемгә килеп бәйләделәр мине, ә?

— Без сине тотмыйбыз, иптәш начальник, алай, ул хәтле дигәч тә.

— Ә беренче чүмеч җирне, бөтен халык карап торганда, казып чыгара алырсыңмы?

— Мин түгел, аны экскаватор чыгара. Кая китсен, рас пультта кеше утыргач.

— Димәк, була.

— Булыр.

— У-уф! Рәхмәт. Шушы бер сүз өчен күпме җанымны кыйнадың. Ну, кеше дә син, Сәхәбин, ә? Ну, молодец. Аңладың. Котлыйм үзеңне. Тик тагын шунысын онытма: берәр корреспондент килеп, нинди дә булса сорау бирсә, бер дә каушамый гына сүз әйт. Үз эшең турында.

— Сүз? Анысы нигә? Балчыкка сүз кушыла димени?

— Тукта, тукта, Сәхәбин, салулый башлама тагы. Рас аларга кирәк, димәк, кирәк. Ни сорасалар, шуңа җавап бирерсең дисем.

— Сорасыннар.

— Молодец. Менә бит, сөйләшеп була бит синең белән адәмчә дә.

Инде тагы бер тәкә башы. Беренче чүмеч җирне син күтәреп автомашина әрҗәсенә салгач та мәйданда митинг башланачак. Синнән дә чыгыш көтелә.

Сәхәбиннең сөмсере җәһәт коелып төште. Начальник аның күзләренә бакса, бу минутта иң авыр фаҗига кичергәннән ямансурак караш белән очрашкан булыр иде. Уңышка ирешүенә шикләнә башлаганлыктан, начальникның үз кайгысы кайгы иде. Шунлыктан янә шәрехләргә кереште ул:

— Син куркып калма тагы, Сәхәбин. Чыгыш дигәч тә... Доклад түгел бит инде. Ике-өч сүзне... теләсәң, язып бирербез. Шуны укып кына бирерсең.

— Кеше язганнымы?

— Үз сүзләреңне әйтерсең. Бигрәк тә шәп.

— Булмый туган. Анысын көтмә.

— Ничек? Ничек дидең?— Начальник кулына алырга нинди дә булса әйбер эзләгәндәй иткәч, Сәхәбин чигенеп куйды.

— Булмый, мин әйтәм. Эшнең үз кешеләре бар, сүзнең — үз әһелләре. Лыгырдасыннар. Ә балчыкны казып чыгарам, күккә чөяргә дә булыр, тик сүз сөйлә дисәң, анысы юк. Юкны каян аласың?

Ким дигәндә ике-өч минут аптырап торганнан соң гына Хәмитов телгә килә алды.

— Дискуссияне туктаттык. Инде моны син эшләгән идарәнең башлыгы буларак бирелгән боерык дип кабул ит. Көне, сәгате төгәл әйтелер. Шул сәгатькә, шул минутка экскаваторың да, үзең дә төзек, нормаль хәлдә булыгыз. Монысы — приказ. Миңа гына буйсынырга теләмәсәң, миннән өстен инстанция әмеренең дә шул икәнен белеп тор. Сүзен дә әйтәсең, эшен дә үтисең. Ә мин яхшы сүзне үз телем белән әйтим, сөендерим дип киләм тагы. Ярый, бетте, хуш.

Эре-эре адымнар белән Хәмитов китеп баргач, экскаваторчы үз шөгыленә кереште. Ул, артык бәхәскә бирелеп, инде экскаватор янында берничә машина тезелеп басканын абайламый да калган икән. Шоферлар сукрануын, үзенең бөтен ачуын-заһәрен экскаваторга күчерә-күчерә, кичке караңгыга хәтле җир актарды. Теге фулса, җир дә мөгаен ризасызлык сиздерер, тетри, тузына башлар иде. Ләкин җир түзем.

Соңгы чүмечне тиешле әрҗәгә койгач, арган башын ухылдатып балчыкка орды да экскаватор шунда ук җансыз тынычлыкка бирелде. Хуҗасы аны бүген бөркәүгә илтмичә, коры елга үзәненә дә төшермичә, салкын, җилле, шыксыз төнгә япан кырда бер үзен генә калдырып китте. Кайткач бичәсе белән киңәшеп караган иде дә, анысы:

— Минем белән бәхәсләшкәндә сүзләрең бик йогышып тора лабаса, табарсың әле бер нотык,— дип кенә куйгач, аның белән дә бу теманы куерту җае калмады.

Ике-өч тәүлек борсалангач, түзмәде, идарә начальнигыннан өстенрәк оешмаларга таба юл тотты. Болай йөрү аның беренче һәм соңгы тәҗрибәсе иде. Ак тәүбә, кара тәүбә. Хәл шушы хәтле дә читен һәм аянычлы булмаса, Сәхәбин — югарыга бер адым атлый торган кеше түгел ул, һәм кагыйдә шундый булып калачак та. Мәгәр бу юлы гафу итсеннәр.

Автобус «Гэсэнергострой»ның баш идарәсе тирәсендәрәк туктагач, Сәхәбин төште. Баш идарәгә, баш управляющийга сугылмаска булды. «Эш буенча түгел бит, аңламаслар»,— дип уйлады Сәхәбин. Горком төбәгенә атлады. Һәм... шул урамнан барышлый ул керергә тиешле оешма исемен күреп алды: партком! Менә кая кереп, күңелдәге бөтен шик-шөбһәне ачып салырга. Анда Сәхәбинне аңламый калмаслар!

Ишектән керүгә — зур гына зал. Залда дүрт якка дүрт ишек. Дүрт ишеккә хуҗа булып бер секретарь кыз утыра, яшь кенә, чибәр генә

нәмәрсә. Картаела төшеп дөрес эшләнгән, югыйсә, гөнаһка, хатага батуың бик ихтимал. Аллага шөкер, бу җәһәттән җан тып-тыныч.
— Исәнмесез,— дип, кыз каршында бүреген салды Сәхәбин.
— Исәнмесез. Сез кемгә?
— Минме? Миңа секретарь иптәш кирәк иде.
— Кайсы?
— Иң зурысы.
— Аркадий Алексеевичмы?
— Әйе, шуның янына кертсәгез иде. Зинһар дип әйтәм.
Кыз, Сәхәбиннең кем булуын, кайда эшләвен сорагач, ишектән әчкә узды һәм тиз арада чыга-чыгышлый:
— Керегез, иптәш Сәхәбин, Аркадий Алексеевич сезне көтә,— дип тантаналы рәвештә белдерде.
Аркадий Алексеевич аягүрә басып исәнләште. Өстәл каршысындагы беренче урындыкны тәкъдим итте һәм янындагы иптәшләренә:
— Менә бу безнең атаклы экскаваторчыбыз Сәхәбин үзе, сез аны беләсез,— дип зурлады.
Сәхәбин, утыргач, кабинеттагыларга күтәрелеп карады, я хода, каршында үзе шикаять итәргә тиеш булган кеше Хәмитов һәм Насыйбуллин утыра түгелме!
Башта кызарып, аннан көп-көрән төскә кергән куәтле экскаваторчы нәкъ үзенең машина чүмечедәй борыны белән өстәл катылыгын казырдай хәлдә бөкрәюдән башка чара тапмады.
— Әйдә, сөйләп җибәр, Фарук Сабирович, хәлләр шәпме?
— Шәплеккә ярыйсы. Тик менә...
— Я, я, эш нәрсәдә?
Сәхәбин берничә генә сүз белән үзенә нинди үти алмаслык авыр эш йөкләнүе хакында сөйләп биргәннән соң:
— Мин мәктәптә дә шул сөйләү предметларыннан бик тә начар өлгердем. Кул белән тотып була торган әйберләр булса, пажалысты. Ә кулга эләкми торган әйберләр — минеке түгел. Пажалысты, бу көч җитмәс эштән мине коткарыгыз инде. Алла хакы өчен,— дип, гозерен аңлатты.
Аркадий Алексеевич елмаеп, Фәез Сәлимович сагышлы кыяфәт белән тыңласа, Хәмитов тавышы иң биек ноктага күтәрелде:
— Сез! Шундый үтенеч белән шушында килдегез?! Оят, тамаша!
— Әйе шул, бик үтенеп соравым...
— Сезгә шундый честь күрсәттек...
— Әйтәм ич, миңа тиешле чис түгел ул дип. Ник миңа башкалар өлеше? Кулга тотып була торган әйбер булса... пажалысты.— Фарук, ярдәм көтеп, Фәез Насыйбуллинга, аннары Аркадий Алексеевичның үзенә текәлде.— Пажалысты дип сорыйм бит.
Гаҗәпләнүе чыраена чыккан Аркадий Алексеевич, ниһаять, хәлне аңлады.
— Сезнең анда напарнигыгыз кем әле?
— Павел минем пардашым, Агафонов. Искиткеч шәп егет.
— Ул ничек — кулга тотып булмый торган әйберләр хакында фикерли беләме?
— Беләме дип... Тикшергәнем бер дә юк иде шул.
— Сез аның белән киңәшегез. Сез — атаклы экипаж. Икегезнең берегез, әлбәттә, сүз әйтсә, күңелле булыр. Ниһаять, ник кеше күзенә күренүдән куркырга? Гаепле кешеме сез, гарипләрме? Менә дигән чибәр, пакь намуслы кешеләр. Курыкмаска тырышып карагыз, өйрәнергә.
— Павел телне дә шәбрәк белә. Сез риза булсагыз, мин аннан сорармын. Дус кеше, салып таптамас.
— Рәхим итегез, сөйләшегез. Бүтән йомышыгыз, әйтәсе сүзегез, гомумән, эш буенча безгә дәгъваларыгыз юкмы?

— Тамак тук, өс бөтен дигәндәй. Дәгъва юк. Рәхмәттән башка.

— Сезнең кебек кешеләргә безнең дә шулай — рәхмәтләребез бик зур. Алда да бер-беребезне шатландыра алырлык булсын. Уңышлар телим сезгә, исән булыгыз, Фарук Сабирҗанович.

Аркадий Алексеевич Сәхәбинне ишек төбенәчә озата килде. Ишек ябылгач та Хәмитов шаккатып:

— Менә мужик! Менә сиңа чын мужик! Әкият!— дип сукрана бирде.

— Мондый мужиклар күбрәк булсын, Айрат Бариевич. Сез һич тә борчылмагыз,— дип, Аркадий Алексеевич яңадан үз урынына утырды.— Әйдәгез, төп мәсьәләгә әйләнеп кайтыйк. ‘

Бу вакытта Сәхәбин үзенең бүреген секретарь кыз өстәле янындагы урындыкта онытып калдырып чыгып бара иде. Кыз туктаткач кына исенә төште һәм бүреген алганда хушлашу сүзе әйтергә дә зиһене җитте.

Павел белән сөйләшүне озакка сузмады. Павликның сменадан кайтуына кесәсенә ярты кыстырып өенә барды да, мәсьәлә шунда җинел генә хәл ителде. Беренче балчыкны экскаватор белән Павел дус алырга һәм чыгыш ясарга да риза булды.

— Молодец, яхшылыгыңны онытмам,— дип аның кулын кысты Фарук.

Тантаналы көн галәмәте булып, платформа таккан йөк тракторы әйтелгән вакытта, дөбер-шатыр килеп тә җитте. Сәхәбин үзенең ярдәмчесе Агафонов белән экскаваторны шунда менгереп утыртты.

Караңгы төшеп килә иде.

Кара буранны яра-яра, трактор кыр юлы буйлап күзгә күренми торган билгесезлеккә — югарыга үрмәләде. Орловка дигән авыл артта калды. Аннары — очсыз-кырыйсыз кыр, ялан. Кырның бердәнбер һәм алыштыргысыз хуҗасы — буран. Карлы җил күз ачарга ирек бирми, битләрне, муеннарны чәнчеп ачыттыра. Ярый әле трактор бураннан һәм караңгылыктан көчлерәк — җил котыруын, төн төпсезлеген тонык утлары белән яра-яра, басулар буйлап алга атлыга — метрлап, карышлап чакрымнар җыя.

Ниһаять, кыр түрендә утлар җемелдәп күренде. Җиде җилнең тәгаен төйнәлгән төшендә бульдозеристлар инде килеп өлгергән икән. Аларга беренче төзелеш мәйданын кардан, туфрактан чистарту эшанып тапшырылган.

Экскаваторны бергәләп платформадан төшерделәр, һәм Фарук аны үз йөреше белән геодезистлар каккан беренче казык янына китереп куйды. Беренче мәйдан, беренче казык инде гражданлык хокукы алган. Бер-ике сәгать аръягында яңа мәгънә — беренче чүмеч дигән төшенчә туарга әзерләнә.

Экскаватор беренче казык янәшәсендә бер үзе генә калды. Фарук кабинадан төште дә читтән ямансулап карап торды. Аңа бу минутта, күпме гомер бергә эшләгән, җил-яңгырларны, бураннарны бергә кичкән дустыннан бөтенләйгә аерылгандай тоелып, йөрәген аңлашылмас җилкенүле сагыш кысып куйды. Билгеле вакыт җиткәнчегә хәтле Фарук үзенең өенә дә кайта алмас шикелле иде. Ә анда — хатын, балалар... Хәер, экскаватор эчендә, узган гомерне исәпкә алмасаң, бер нәрсә дә юк бугай бит.

Вак-төяк мәшәкать белән таң атканы сизелми дә калды. Яктыдан оялгандай, буран каядыр шым гына китеп качты. Мәгәр ул үзенең эзләрен яшерә алмаган иде. Күз күремен буран томалап торган арада янәшәдә генә төлке һәм куян арасында канлы бәхәс мәңгелеккә тәгәлләнгән. Ак кар өстендә сарылы-аклы мамыклар һәм тәпиләр ята...

Бу хәлне Фаруктан башка кеше күрмәде шикелле. Фарукның ни

өчен шунда аяклары белән кар өюенә дә игътибар итүче барлыгы сизелмәде.

Тракторлар, бульдозерлар, скреперлар, йөк машиналары, аннары җиңел машиналар җыйналды. Машиналарның берсеннән Фарукның дусты Павел Агафонов төште. Савыгып җитмәгәнгәме, әллә инде тантана аркасында дулкынланудан, йөзләре агарып, суырылып калган. Фарукны күргәч, елмаеп күз кысты. Тантана рәсмилеге ике дусны бер-берсеннән ераклаштыра алмады шикелле. Тик бу минутларда алар бер-берсенә һич тә якын килә алмыйлар инде.

Моторлар колак пәрдәләрен теткәләргә тырышкандай гүләргә тотынды. Бульдозерлар үкерә-үкерә туфрагы-ние белән кар эшерергә керештеләр. Фарук экскаваторы торган җирдән халык җыелган җиргә хәтле ара чистартылды.

Мәйдан инде кып-кызыл һәм хоккей уйнарлык дигәндәй такыр иде. Шул арада экскаватор каршына килеп баскан Хәмитовның:

— Иптәш Агафонов, башлагыз! — дигән командасы яңгырады.

Аның тавышын җөпләп, экскаватор чытырдап җибәрде һәм ук муенын күккә сузды да, йөзләрчә карашлар төбәлгән тарихи чүмеч үзенең барлык аппетитын җыеп авызын ачты, аннары, шулай бераз асылынып торды, дөп итеп җиргә бәрелде һәм авырткангa чыдаша алмыйча диярсең, тешләрен туң катылыкка батырды. Как балчык корыч тешләргә бирешәсе килмичә карышып маташса да, кирелек белән әллә ни кыра алмады. Алып тешләре аның саен үҗәтләшә барып, үзе ясаган чокырда ким дигәндә биш чүмечлек балчык әзерләп, шуны чүмеч эченә чүмәкәй тутырды да баш калкытты. Баш калкытты да салмак кына күтәрелә башлады. Мең күз озата барышлый, шул рәвешле югарыда асылынып калды чүмеч — тарихи чүмеч, беренче чүмеч!

Моторлар гүләвен аралап, фотоаппаратлар шыкылдады. Кул чабулар, тәбрикләр яңгырады. Беренче чүмечтән беренче балчык, беренче мәйданнан беренче йөк алып китәчәк самосвал әрҗәсенә коелгач та, идарә башлыгының кул изәвенә буйсынып, Павел Агафонов кабинадан төшкәч тә һәм ул тип-тигез кызыл келәм шикелле яткан такыр мәйдан аша автомашиналар әрҗәләреннән ясалган трибунага таба килгәндә дә кул чабулар, тәбрикләр яңгырап торды. Узып өлгермәгән чирдәнме, салкыннанмы, Агафоновның тезләре калтырана иде. Кемнәрдер каршылап Павликның кулларын кысты, нindидер ягымлы сүзләр әйтте. һәм шунда ук микрофон җебен сузып радио корреспонденты (я хода!) Павелга сораулар бирергә керешге:

— Әйтегез зинһар, менә шушы минутта сез нинди тойгы кичерәсез?

— Нинди тойгымы? — Павел бүреген күтәреп, күзләрен сөртеп куйды. — Бу минутта беренче тойгы — дулкынлану, әлбәттә.

«Беренче тойгы! Молодец, Павлик. Мин булсам...» — дигән сөенечле уй кичерде Сәхәбин.

— Дулкынлану, әлбәттә, тантана аркасында һәм сез үзегезне бәхетле хис итәсездер. Шулаймы?

— Әлбәттә, шулай. Зур эшнең башлануы, шул бөек эш башын үзенә ышанып тапшырулары чынлап та бәхет бит. Мин аны яшерүнең кирәге юктыр дип беләм. Аннары, икенче тойгы — ул горурлык. Үзебез белгән бик күп гади кешеләрнең, бөтен халыкның шушы зур эшкә алынулары, шушындый масштабларда уйлый һәм эшли алу сәләте горурлык хисе тудырмаска мөмкин түгел.

— Хөрмәтле Павел Сидорович, сезне бүген телевизор аша бөтен республика карый. Аларга сезнең әйтәсе сүзегез юкмы?

— Әйтәсе сүзем шул: без бөтен халыкның бу төбәк белән кызыксынуын, мөмкин кадәр ярдәм итәргә тырышуын сизеп яшибез. Мин

монда килеп эшләргә теләкләре булган һәр кешене шушы зур бәхеткә, тарихи төзелешкә чакырам.

Халык шаулатып кул чапты. Фарук үзенең дусты кем икәнне белмичә йөрүенә гаҗәпләнеп бетә алмады: «Менә кем, менә нинди зиһенле кеше икән бит минем напарник!»— Ә ул, Фарук, әлбәттә, болай булдыра алмаган булыр иде. Аның каравы шәп алкышлый белде. Кул чаба-чаба уч төпләре чатнады бугай, валлаһи.

Митинг шавы, моторлар гүелдәвенә кушылып, кырларга тарала торды. Якты Ярның барлык хуҗалык һәм оешма җитәкчеләре, Казаннан килгән җаваплы кешеләр чыгыш ясады. Иң соңыннан Лазарев тавышы дөбердәде, һәм азакта аның тиешле кешеләргә һәм оешмаларга әйтелгән рәхмәт сүзләрен бәйрәмнең чын хуҗалары — двигательләр үз гүләүләре белән еракка һәм озакка алып киттеләр.

Инде нишләргә — калыргамы, өйгә кайтыргамы дип уйланып торганда, дулкынланудан, ашыгудан кызарып беткән Хәмитов, бөтенләй башка кешегә әйләнгәндәй хисләнеп, Фарукны кочаклады һәм:

— Син, Сәхәбин, экскаваторны үз кулыңа ал инде. Павлик терелеп бетмәгән бит, үзең беләсең,— дип куйды.

Бу көнне Фарукка ике смена эшләргә туры килде. Карышмады, сукранмады ул.

*

* *

Елъязмалар шулай бер көй белән матур гына дәвам итә торды.

Яңа исемнәр, яңа каһарманнар. Эш һәркемгә җитәрлек. Үпкәләрлек түгел.

Көн артыннан көн. Көн тудымы, җыелыш. Таң аттымы, телефон. Кабинетта, өйдә — чакырулар, үтенүләр, янаулар. Урамда, машинада, мәйданнарда — ашыгу, каушау. Бурычлар — көнлек, атналык, айлык, еллык. Көннәр, атналар, айлар, һәм менә инде ничәмә еллар буе зур оештыручылар, җитәкчеләр, һәм, алар белән бергә, атказанган батырлар исеменә ияреп, кала даны илгә һәм дөньяга яңгырый.

Данлы кешеләрнең берсе — Лазарев. Шулай да ул үзе башлаган галәми зурлык белән хушлашырга тиеш булып чыкты. Ник?

— Фәез, иртәгә синең бәйрәмме әллә?

«Ник?»кә җавап урынына йокы бүлмәсеннән Зәрия тавышы белән бүгенге көн яңа сорау ташлый. Монысына сүз әйтү кыен түгел, әлбәттә.

— Бәйрәм түгел, Зәрия, җыелыш, авыр көн.

Һәм ут сүнә. Караңгы өйдән Фәез тышка күз салды. Яп-якты булып, ай мәңгелек тынычлык сибә.

Ай еректан матур, сихри. Гасырлар, дәверләр буе карап, айдан кешеләр үзләренең иң гүзәл җырларын тапканнар. Ай нурлары кеше күңеленә тылсымлы өмет, сагыш, мәхәббәт көче сыман сибелә килгән. Ә үз өстенә аяк басып, таптап йөргән кешеләр өчен ул җансыз таш, комнан гына гыйбарәт икән.

Ерактан караганда, Лазарев бер кеше иде, ә хәзер бөтенләй икенче булып күренде. Шулай кинәт үзгәрдеме? Әллә бер кеше ике кыяфәттә яшәгәнме? Кайсы чын, кайсы ялган? Әллә Фәез үзе ялгыш күрәме? Ни генә дисәң дә, Лазарев үзе дә, баш идарәдәге хәлләр дә тиз арада гына баш җитәрлек түгел сыман иде инде.

Баш идарәгә күчкәч, ныклап эшкә керешү нияте белән Фәез иң әүвәл барча документлар, планнар белән танышкан иде, күзләре шар булды. Бер актарды, өч актарды, тик хәл үзгәрергә җыенмады: планнар асылда кварталлап кына төзелә икән. Рәсми күрсәтмәләрнең бер

елдан алып күп елга исәпләнгәннәре очрый. Ләкин алар теоретик фикерләүләрдән, гомум бурычлардан гыйбарәт.

Атна-ун көн кәгазьләр диңгезендә адашып диңкегәч, барлык бүлек кешеләре белән киңәшкәннән соң, кулына кергән барлык фаразларны, мәгълүматларны берләштереп, Насыйбуллин программаларны конкрет производство планы кыяфәтенә кертергә тырышты. Баш инженерның — Григорий Никифорович Шарамыгинның ризалыгын алгач, Лазаревка сугылды.

— Молодец, әйбәт. Син калдыр аны,— дип куйды баш управляющий, кәгазьләргә өстән-өстән күз төшереп.— Тикшерербез. Ә хәзер миңа — киңәшмәгә.

Берничә көннән соң Лазарев Насыйбуллин тәкъдим иткән план-графикны тикшерү өчен баш идарә һәм бүтән бүлекчә җитәкчеләрен җыйды. План кайбер төзәтмәләр, өстәмәләр белән кабул ук ителде. Соңыннан баш управляющий Фәезгә чыкмый торырга кушты.

— План ярыйсы төзелгән. Ышандырырлык, реаль. Яза да беләсең икән. Шушы программа нигезендә миңа доклад ясарга туры киләчәк. Бер атна срок.

— Өлгерә алабызмы икән соң?

— Өлгерергә кирәк.

— Ешаеп китмәдеме икән киңәшмәләр, җыелышлар? Эшкә вакыт та калмый түгелме соң?

— Анысы бездән генә тормый, иптәш. Я, син миңа булышасыңмы? Идарәләрдәге үтәлешне барлап, чагыштырып... проект язып кертерсең... Бүтән эшләрдән сине азат итеп торырбыз. Шарамыгинга әйтермен. Булдымы?

— Булмый карасын! Баш управляющий әйтсен дә.

— Молодец! Бер атнадан миңа кертерсең.

Фәез Лазаревның хәлен аңларга тырыша, тик җыелышлар, трибуналарга күтәрелә-күтәрелә бирелгән предметсыз вәгъдәләр-күрсәтмәләрнең конкрет мәгънәсен генә күрә, таба алмый. Мондый шау-шуларны ул үзенең уйчан табигате, кичерешләргә артык күп көч бирүчән йөрәге аркасында кабул итә алмый бугай. Аллергия, икенче төрле әйткәндә. Бәс, шулай икән, җаның кабул күргәнне, зиһенең мөмкинлек биргәнне башкар — планнар, программалар төзе, докладлар яз.

Һәм язды Насыйбуллин менә дигән шәп доклад. Һәм укыды бөтен дөньяга ишетелерлек куәтле тавышы белән Лазарев аларны. Әсәренеп китеп, Насыйбуллин үзе дә алкышларга керешә иде хәтта. Сүз көче әнә нинди! Әкәмәт! Насыйбуллин үзенең шушы хәтле акыллы сүзләр яза алуына ышанмый башлый хәтта. Аның фикере, Фәезнең үзеннән аерылып, бүтән тормыш белән яши! Кызык!

Фәезнеке чагында, аны беркем ишетми, игътибар да итми. Насыйбуллинның үзеннән башка кешегә аның кирәге дә юк. Ә менә Лазарев тавышы белән берләшеп яңгыраса! Ул чакта инде бөтенләй бүтән эш! Бүтән мәгънә! Тирән, зур!

Доклад тыңлаучыларда, бигрәк тә президиумдагы иптәшләрдә әйбәт тәэсир калдырса, Лазарев, Насыйбуллинны тәнәфес вакытында әллә каян күреп, күз карашы белән иркәләп ала, ә начаррак чыкса, яныннан юри борелеп диярдәй узсаң да күрми. Икенче көнне бүтән бер сәбәп белән кабинетына чакырып, референтлык шөгыленә түгел, ә гомумән эшкә җитдирәк карауның әһәмияте хакында акыллы һәм дөрес искәрмәләр ясый. Мондый хәлләр сирәк, әлбәттә, бик тә очраклы була булуын.

Фәезнең затлы кеше булуын Лазарев таный, бәясез калдырмый — аңа ышаныч белән җавап кайтара. Чит шәһәрдә, үзәкләрдә җаваплырак сөйләшүме, җыелышмы булсын, үзе белән эксперт рәвешендә Фәезне дә ала. Казанда булган бик вәкаләтле бер җыелышта уңышка

нрешкәч, гостиницада Фәезне хәтта үз бүлмәсенә сөйләшеп утырырга да чакырды. Лазарев дигәч тә, баһадир дигәч тә, ул да кеше бит, гади тән, гади нервлар — аныкы да арый, талчыга. Фәез адресына матур сүзләр әйтә-әйтә ике-өч рюмка коньяк күтәргәннән соң телевизор карап утырдылар. Фәез күпмедер вакыттан абайласа, дивандагы мендәргә башын салып, Анатолий Самойлович татлы һәм тирән йокыга талган икән. Һәм ул нәрсә беләндер Фәезнең игътибарын телевизордан үзенә күчертә алды. Нииндидер мәзәк хәрәкәтләр ясый, нидер сөйли... Куллары күтәреп-күтәреп куя... Төш, төш күрә Лазарев! Һәм төшендә дә речь тота: сүзләре сәнгатьчә тәэсирле чыксын өчен тырышып, куллары белән, мимикасы белән ярдәм итә — коеп куйган пантомима!

Фәез урыныннан торды да телевизорны сүндерде. Түшәмдәге лампаны да сүндереп, өстәлдәге утны гына калдырды, Лазаревның кисәк-кисәк һаман кабатлана куйган баягы сәнгатеннән бигрәк, аның үзенә, мавыга белү сәләтенә сокланып, бәхетле чыраена, көчле гәүдәсенә хәтта көнләшүгә охшаш ярату белән озак кына карап торды һәм аяк очларына гына баса-баса, бүлмәдән чыгып китте. Үз бүлмәсендә сак-лык-тынычлыкны бозмыйча урын җәеп яткач, тиз арада йокыга да талды.

Көннәр артык хәвефләрсез генә уза торды. Билгеле, четреклерәк хәлләр дә чыккалый. Дөньяга баш идарә управляющие биеклегеннән карап яшәсә дә, күңеленнән Фәез Сәлимович барыбер су төзүчесе булып кала бит. Гидрострой өчен аның йөрәге ныграк көя иде. Башка бүлекчәләр дә аның карамагында булганлыктан, алар хакында да уйларга мәҗбүр һәм уйлый да Фәез. Ә менә ярату дигәндә... Ярату дигәндә, аның җаны һаман су ягында җил кебек йөри.

Соңгы вакытта Гидростройның хәлләре мөшкелләнде. Гидрострой җитәкчесе Коровкин һәм аның хезмәттәшләре, ни сәбәптәндер зарланмый. Хәер, зарланырга вакытлары юк аларның. Һәм уйларга да. Борис әйтмешли, алар — геройлар! Ләкин елмаюдан өстен, чын геройлар. Алар белән яшәп, эшләп карасаң, моны яхшы беләсең. Фәез шулай фикер итә хәзер. Сагына бугай. Тик аларга ничектер ярдәм итәсе иде. Ничек?

Баш вата торгач, әмәл табылды шикелле.

Гидрострой, барлык үз объектлары һәм торак йортлары белән бергә, бөтен каланы су белән тәэмин итәчәк водозабор дип йөртелә торган гаять зур станцияне төзи. Идарәнең үз эше булса да, ул хәзерге шартларда көчне таркатырлык дәрәҗәдәге ераклыкта.

Фәез телефон номеры җыйды.

— Әйе.— Коровкинның үз тавышы.

— Николай Трофимович? Исәнмесез, Насыйбуллин.

— Ә-ә! Фәез Сәлимович, сәлам! Син безне онытмадыңмыни әле?

— Онытып булмый бит. Сез гел минем йөрәктә. Һәм бавырда да бугай.

— Сухойны күп эчәсең син. Акны, акны гына ярат.

— Юк, минем бавырда бүтән төрле таш — аның исеме бүтән.

— Кызык, бүтән төрле таш та буламы бавырда? Алмаз? Сердолик?

— Водозабор дигән асыл таш.

— Ух, анысы алмаздан да катырак. Синең бавырда гына әле ул. Ә минем бугазга ук утырган.

— Йөткереп кара...

— Ничек итеп?

— Просто. Чак кына тамак кыр, ачуланыбрак.

— Давай, ярып сал.

— Котыл син аннан. Мин ярдәм итеп карыйм.

— Котыл? Котыласы да килми кебек.

— Шул тирәдә генә металлургия идарәләре, барлык базалары белән. Аларга якын һәм җайлы.
— Территориаль принцип. Логика бар.
— Йөткердекме?
— Шулай да кызганыч су үзәге... Күпме көч, күпме хис дигәндәй су төбенә төшеп яткан.
— Төкер син ул суга.
— Суга төкермәскә кушкан ата-баба.
Коровкин үз файдасына буласыны кабул итә алмагач, ник Фәез баш катырырга тиеш иде соң? Әмма идея орлыгы шыткан икән, теләсәң-теләмәсәң дә үсә башлый шул. Көннәрдән бер көнне фикер ак кәгазьгә үзлегеннән приказ проекты рәвешендә төште дә Фәез, аны баш идарәнең баш инженеры өстәленә кертеп салды. Шарамыгин кәгазьгә күз төшергәч тә баш калкытты.
— Аңладым. Коровкинга эш каламы соң?
— Гидростанция — үзе зур мәйдан. Аннары су әйләнеше блогы — алар төбәгендә, рәттән генә. Шуны аларга күчерергә мөмкин.
— Мөмкин. Һәм тагы — кою заводының компрессорлар станциясе төзелешен. Анысы да янәшәдә генә.
— Мөмкин.
— Шуны өстәгез дә — машинкага. Визаларга җибәрегез.
Бер атнадан тиешле бүлекләр һәм баш управляющий кул куйган приказның күчермәсе Насыйбуллин өстәленә килеп тә керде һәм шул ук көнне баш управляющий бүлмәсендә гауга да кузгалды.
— Бу ни дигән эш? Мин әйткән идем бит үземнең каршы икәнне? Без хәзер ничек итеп корыч эшенә керешик? Курслар ачыйкмы? Менә бит ничек, ә?
Сучыларга — металл, металлчыларга — су. Уйлап бетерә алмаган Насыйбуллин. Шул чакта турысын гына әйтмәкче булып авыз ачкач кына, Шарамыгин сөйләргә кереште. Ул тыныч кына приказның матур мәгънәләрен аңлатып бирде. Шулай да Коровкинның:
— Мин әйткән идем бит, әйткән идем! — дип ачыргалануын туктата алмады.
Ниһаять, речетативка Анатолий Самойлович игътибар итте:
— Кемгә әйткән идегез?
— Насыйбуллинга.
— Нишләп әле Насыйбуллинга әйтәсең, миңа түгел?
— Мондый нәрсә зурга китәр дип кемнең башына килсен. Уйламадым да.
— Уйламый яшисез — бөтен хикмәт шунда, уйламыйсыз.
— Кайвакыт уйлауның файдасы тия,— дип акыл бирде Лазаревны җөпләгән баш инженер.
Коровкин аптырагач бирешә башлады.
— Ярый инде, нишлисең. Сыерга нәр кидертәбез. Җайлы түгел. Атлардан сөт фермасы ясадык. Ярый.
— Гафу ит, сыер һәм атларның монда катнашы юк сыман,— дип көлгән булды Фәез.
— Сыерны дагалап карарга уйладыгыз.
Әңгәмә бераз гына шаян төс алып, күзләрдәге курку кими төште дә аннары тынлык урнашты. Шуннан файдаланып, Лазарев нәтиҗә ясады:
— Эш мәйданнарының ерак булуыннан күз яшьләре коя-коя зарландыгыз, хәтерем ялгышмаса.
— Зарландык.
— Крокодил яшьләре идемени алар?
— Адәм яшьләре.

— Шулай булгач? Соң? Мена без сезгә ярдәм итәргә уйладык.

— Рәхмәт. Шулай да бит, мин әйткән идем... Сыерга камыт кирәкмәгән лешми дип.

Элекке Лазарев икенче төрле иде, ул кирәк икән, әллә нинди зур чигенүләргә бара ала иде. Уйлый белә иде, моңа аның вакыты да житә иде. Ә хәзер вакыты житми — киңәшмәләр, конференцияләр, жыелышлар, делегация каршылаулар, банкетлар, речьләр, докладлар... тагын әллә нәрсәләр.

Мәйдан артык киңәйсә, колач житми башлый. Колачың житмәгәнне кочарга тырышма, диләр. Артык биек күтәрелсәң, жир өсте тоташ күксел төскә әйләнә — матур, ләкин дөнья җанын җуя...

Калага егерме тугыз кешелек комиссия, дәүләт комиссиясе килеп төште. Председателе — СССР министры...

Мәскәү һәм Казанның зур белгечләре, план, проектчы вәкилләре, күзәтүчеләр атна буе баш идарәнең барлык бүлекләрендә кәгазь актарып утырдылар, житәкчеләр белән бәхәсләштеләр, киңәштеләр һәм экскурсияләр ясадылар. Аларның гидлары сыйфатында кемнәрне дигәндә, Айрат Хәмитовның үзен, Рәхилә һәм... Кама исемле кызларны күрергә мөмкин иде.

Ике-өч көн элек кенә Аппаков бүлмәсендә тар даирәле киңәшмә җыелып, анда баш идарәнең баш инженеры урынына Фәез дә чакырылды.

Аппаков — төзелешкә тулаем уңай бәя биргәннән соң, кыенлыклар хакында каты-каты сүзләр әйтте. Гидростанциягә исә, боларыннан да усалрак атамалар белән бәя бирде.

Лазарев, чәчми-түкми диярлек, Фәез язып биргән сүзләрне кабатлап, вакыт ягыннан икеләтә озын чыгыш тотты. Әмма нәтиҗәләре хак иде:

«Булган һәм туктаусыз килеп торган материалларга караганда, планда каралган эшләр һаман күбрәк булып кала. Геройлыкларны киметүнең хаҗәте юк, әмма объектларның төзелү срогы кичектерелә бара».

Лазарев бу сүзләрне әйтеп бетергәндә, ишек ачылып, аннан Рәхиләгә охшаганрак бер кыз белән Кама килеп керде. «Гафу итегез» дип адрессыз пышылдаганнан соң кыю гына алга уздылар. Каршы як тәрәзә буенда буш урыннар күбрәк иде, Рәхиләгә тарткан кыз туры шунда юнәлде. Ә Кама Аппаков каршындагы бердәнбер урынны сайлады. Шуннан соң Аппаков та, аннары бүтәннәр дә нинди дә акыллы сүзләр сөйләде бугай да, тик алар Фәезнең бер колагыннан кереп, озак тоткарланмыйча тиз үк икенчесеннән чыга да тордылар. Фәезнең күзләре һәм зиһене Кама тирәсендә буталды. Күз салмыйча да калырлык түгел шул: әнә бит, аягын аякка куйган да, сул кулы белән ияген тотып, эчендә җаны булган һәр адәмне алгысытырлык итеп, томыраеп утыра. Татлы кыяфәте мең вәгъдә биргән моң белән өретелгән. Чак кына элегрәк булса, бу сурәт гүзәллек тантанасы шикелле чыңлар һәм хыялны мең катлы зәңгәр бөеклеккә күтәреп китәр иде. Тик бу юлы... һәрчак оста чыгыш ясый торган Аппаков булып Аппаковның иң кирәкле төштә теле тотлыксын әле! Шуннан соң ни диясе кала? Аппаков, житди нотыгын бүлеп, чак кына чигенү ясарга мәҗбүр булды. Камадан күзен алалмыйча, ирексездән елмаеп, бөтенләй көтелмәгән якка сөрлегеп куйды:

— Беләсезме, иптәшләр, бу минем якташым, Кама Сафарова. Хәтерлисездер, Якты Ярда гына түгел, Казанда да матур чыгышлар ясаганы бар. Ярыйсы гына инженер иде, ә хәзер шәп журналист. Ул, актив җәмәгать эшлеклесе буларак, үзен тапты. Без алар авылындагы мәктәпкә йөргәндә, күзгә күренергә дә ояла торган бала иде. Шуның аркасында, аңа игътибар итмичә, зур хата җибәргәнмен. Үкенерлек хәл, тик

нишлисең... соңгарак калынган. Тик ул барыбер безнең тирәдә. Бу комиссия эшенә дә булышлык күрсәтте. Без моны киләчәктә искә алырбыз. Сез, Сафарова, минем янга теләсә кайчан, ишек шакымыйча керә аласыз.

Барысы да — ирләр сокланып, хатын-кыз җәмәгате көнләшеп — карашлары белән аңа ябырылдылар. Оялчан кыз тыйнак кына елмая иде, кызармыйча гына...

Комиссия председателенең дә ындыр табагы чаклы маңгаеннан уртәлү сырлары юкка чыгып, йөзе түгәрәк ай сыман нурланып китте. Проект заданиеләренең чынлыктагы хәлгә бөтенләй диярлек туры килмәвен әйтсә дә, кайбер объектив сәбәпләрнең аңлашылуын онытмады. Үзгәрешсез калган кеше булса, ул мөгаен бердәнбер булгандыр — Лазарев соңгы сүзләрен һич тотлыкмыйча тәмамлады.

— Эшләр катлаулы, әлбәттә. Барлык ресурсларны, шулай ук кешеләрне төп объектларга ташладык. Хәтта административ-көнкүреш йортларын санга сукмаска мәҗбүрбез. Гидростанция үги бала хәлендә. Хәзер аңа да ныклап тотынырга чират җитә. Хәл шундый. Аннан паникасыз чыгу юлы бердәнбер — фронтны тизләтү. Шуңа ирешсәк кенә, җиңүгә исәп тотарга мөмкин.

Киңәшмә бетеп, кешеләр таралыша башлагач ук, Аппаков, урыныннан җәһәт кубып, Кама янына килде. Фәез акрынрак атласа да, алар бусага тирәсендә бергәрәк туры килделәр. Фәезнең колагына шундый сүзләр кереп калды.

— Киләсе атна башында мине табарсың, мин сиңа яңалык әйтермен,— диде Аппаков,— Булдымы?

Кама елмаеп баш какты. Ул арада Аппаков өстәл башында калган Лазарев белән комиссия председателе янына ашыкты.

Ишектән чыккач, Кама, бөтенләй икенче төрлегә әйләнеп, Фәезгә елмайды... Күз алдына шул елмаюны китергән Фәез йокы бүлмәсенә керешли: «Эх, Кама, Кама!»— дип көрсенде.

*

* *

Иртәгә җыелыш. Якты Яр кешеләре белән бергә, кунаклар — Казаннан, Мәскәүдән. Сөт сатучы һәм министр, слесарь һәм идарә башлыклары, баш управляющийлар белән бергә, участок мастерлары, прораблар. Шулар арасында Фәез Насыйбуллин. Ул кем бүгенгесе көндә?

Аны кешеләр баш идарә вәкиленә исәпләп, йомыш әйтә. Фәез нәрсәләрнедер хәл дә итә. Ә чынлыкта... чынлыкта ул — бүтән кеше. Чынлык белән тышкы рәвеш тәңгәл килмәү кызык тоела. Икейөзлелек шәхеснең икегә бүленүеннән башланмыймыни?

Культура сарае төбендә ыгы-зыгы.

Кырмыскалардай кайнашкан халык арасында бер абзый ак козгын мисалында аерылып тора. Фәез аңа игътибар белән карап узды. Ишектән кергәч артына борылып караса, теге абзыйның да керәсе килә икән, ә чакыру билетлары тикшереп торган, беләкләренә кызыл тасма бәйләгән егетләр рөхсәт итмиләр. Иелә, бөгелә төшеп, астан өскә карап, куллары белән нидер аңлата-аңлата озак ялынгач, ахры, түзмәделәр, бар алайса, дигән мәгънәдә кул селтәп, тәки уздырдылар. Фәез китап сәүдәсе оешкан төштә чират торган җирдән абзыйның яңа үтенеч белән, бер кешедән китеп, икенче кешегә сүз кушуын шәйләде. Аның соравына рәтле җавап бирүче булмавын абайлап, Фәез абзый янына үзе килде һәм аңа ни кирәге белән кызыксынды.

— Улым, миңа Рәхилә атлы кыз кирәк иде. Өенә барсам, бикле, эшләгән төшенә килсәм, монда шушында диделәр. Кырык чакрым тиңкә җирдән аны күрергә килдем.

— Рәхилә исемле дидегезме?

— Әйе шул, Рәхилә, фамилиясе дә бар — Низамова анысы. Син аны беләсеңме әллә? Ишшугы ишеткәнең булса...

— Бар, абый, ишеткәнем дә, күргәнем дә бар. Әйдә, эзләп карыйк.

— Әйдәле, балам, савaплы булырсың. Бик ерактан сәфәр кылдым бит. Юлаучыга ярдәм иткән кеше догалы була ул.

Шул рәвешле, алар китап сатылган тирәдән, гардероблардан, буфетлардан әйләнделәр. Күзгә чалынмады Рәхилә. Инде өмет сүнде дигәндә, Фәез барьерга сөялеп торган ике егет белән бер кызга текәлеп калды. Кызның сөйләшүен тыңлап караса, чак кына шаркылдап көлеп җибәрмәде: әлеге кыз кайчандыр Фәез белән якын ук диярлек таныш булган Рәхилә үзе бит. Ләкин ул асылда бөтән Рәхилә, мәгәр барыбер — Рәхилә! Ни булган, нинди үзгәреш шушы хәтле танымас хәлгә китергән аны?

Рәхилә йөзенә пластик операция ясаткан икән. Элек борынында шактый ук күренекле бөкересе булса, хәзер кызның борыны — төп-төз, гүзәл борын. Җыйнак кына прическасы да колакларын каплап, матурлыгын искәртеп тора. Тагын бер үзгәреш күзгә ташланмыйча калмады: элек Рәхиләнең чәчләре кара булып, көксел соры күзләренә ярашып бетмәсә, хәзер ул чәчләр саф алтын төсендә нур чәчеп яна. Фәез баягы абзыйга кызны күрсәтте:

— Абый, менә Рәхиләң шушы синең,— дип янына ук чакырып китерде.

Әмма хикмәт диген, я алла!— диген. Мондый могҗизага тап булганын күпме генә хәтерләргә тырышса да, Фәез исенә төшерә алмас иде. Ни булдымы? Менә ни булды.

Шактый ук таушалган бишмәт, җәйге куян сорылыгына күчеп уңган колакчын бүрек һәм галошлы пима кигән абзый каршыларына килеп баскач, ике егет тә авызларын ачып, ни дияргә белми катып калдылар. Ә Рәхиләнең ап-ак чырае кызарып кабынды да, тиз арада көл төсенә керде. Ләкин бер сүз дә эндәшмәскә көч таба алды Рәхилә. Җибеттәге чибәр манекен рәвешле тора бирде. Ә атасы, аның тирәли ким дигәндә биш-алты тапкыр әйләнеп чыкса да, баласына кызым дип эндәшергә җөрьәт итә алмады.

— Азрак төсмере бар да кебек, юк та шикелле шунда,— дип ыңгырашкан, сызлангандай итеп, һаман борсаланып йөренде карт.

— Синең кызың бу. Шушы.

— Төсмерләгән дә кебекмен, түгел дә...

— Рәхилә инде, Низамова. Синең кыз.

— Минем кыз да кебек, түгел дә.

— Рәхилә, әтиең килгән бит, энә.

Рәхиләнең күзләре чын нәфрәт белән Фәезгә кадалды. Иреннәре калтырап, карашыннан да катырак сүзләр ыргытмакчы иде бугай, тик ул тагын түзде. Һәм, нишләргә белмичә, тагын бераз торгач, капыл кузгалып, инде барьерга таба борылып баскан баягы егетләргә дә берни әйтмичә, залга — кешеләрнең иң кайнап, буталып торган төшенә кереп китте.

— Хәлләр менә шушылай, абый, кызыңны табып бирә алмадым, гафу ит. Югалды синең кыз, бетте. Бусы синеке түгел.

— Гафу инде, гафу анысы, ярый үзең үпкәләмә.

Абзый, кызын эзләп, кайнап торган кешеләр арасыннан танырга тырышып, тагын бераз йөренде дә, лап-лоп атлап, киң вестибюльне иңләп, ишеккә таба атлады. Кызы белән күрешү бәхетенә ирешә алмыйча, кырык чакрымны тагын үзе генә узар ул. Шулай да хатынына, авылдашларына ни күзе белән күренер ул? Якты Яр кебек кечкенә калада бердәнбер кызын таба алмаган кеше!

Фәезгә, нишләптер, ул инде кызның өенә барып, бүтән эзләмәс, авылына кайтып китәр, дигән ныклы уй килде. Йөрәге өзгәләнсә дә, сәбәбен беркемгә әйтмәс. Бәлки әле карчыгына да. Кызны тапмый кайтканы өчен мыскыллασалар да, үртәлмәс, үртәлсә дә түзәр, тешен кысып булса да.

Менә шушындый хәлләр, абзый, кичер. Синең белән генә түгел, башкалар белән дә килеп чыккалый мондый сәер алмашыну һәм аймылышлар...

Киң залларны тар итеп Лазарев йөри — һәркем белән элеккечә сөйләшә, шаяра, көлә, житди киңәшләр, хәтта вәгъдәләр бирә. Һәр кеше Лазаревны баш идарә управляющие дип исәпли. Казан һәм Мәскәүдән килгән зур житәкчеләр белән бергә президиум өстәленә узганда, аннары шунда олпат кыяфәт белән утырганда да тыңлаучылар карашында — ул һаман баш управляющий. Баш идарәдәге хәлләр хакында сөйләгәндә, һәркем диярлек аның ишетеп торуын, ниндидер мәсьәләләрне һәм төзәтелергә тиешле җайсызлыкларны колагына салып куюын белеп сөйли — ярдәм, эш, чара көтә.

Тәнәфес вакытында Фәез Лазарев янына килде. Анатолий Самойловичның чыраенда ниндидер бүтән сызыклар, ят чалымнар шәүләләнә иде.

Җыелыштан соң, кая сугылырга белмичә аптыраган бер мәлдә, «Мөһим нәрсә хакында киңәшәсе бар», дип, Фәезне Шарамыгин үз бүлмәсенә алып китте. Озак кына, тәрәзәдән урамга карап, янәшә басып тордылар.

Урамда — ыгы-зыгы: машиналарның берсе китә, икенчесе аның урынына килә тора. Танышлар төшә, ятлар. Барсының да баш идарәгә юлы терәлгән яки шуннан башлана. Кешеләр һәм әйберләр вакыт һәм аралык үзгәрешләре кичерәләр. Әнә машинадан Аппаков чыкты да, салмак адымнар белән килеп, идарә баскычларына аяк басты. Аны күрүгә, Григорий Никифорович үз алдына елмаеп куйды. Башта игътибар итмәгәндәй тоелса да Фәез бераздан:

— Ниндидер кызык бармы? — дип сорамыйча булдыра алмады. — Баш житәкчегә кагылышлы?

— Аңа микән? Хәер, беренче чиратта...

— Нәрсә соң?

— Үзгәрешләр төрле яклап булырга тора әле.

— Нинди үзгәрешләр?

— Син Рәхилә Низамова дигән кызны беләсеңдер?

— Аны кем белми?

— Якыннан укмы?

— Бәхеткә каршы, ерактан.

— Алайса, хәбәр синең өчен дә кызыклы булачак. Әйе. Шул кызны шәһәрнең баш тәрбиячесе итеп куячаклар. Иртәгесе форумда...

— Тукта әле, син кем беләндер бутыйсың бугай.

— Дөнья бу!

— Бар икән күрәселәр.

Фәез тәрәзә яныннан китте. Бераз йөренгәч, үз урынына утырып өлгергән Шарамыгинга текәлеп:

— Минем дә сиңа әйтәсе кызык хәбәрем бар, — дип елмаерга тырышты. Мәгәр аның кыяфәте рәнҗетелгән кешенекеннән аермаслык иде.

— Моннан да кызыграгы тиз генә ишетелмәс дип куркам.

— Ихтимал, син хаклыдыр. Тик барыбер...

— Соң әйтеп кара, көләргә тырышыйк.

— Баш идарәдән мин дә китәргә булдым.

— Югарыга — житлләр оясынамы?

— ГЭСка — элекке урыныма.

— Үзең теләп, түбәнгә?
— Үзем теләп — үзәнгә.
Селекторда Алевтина Федоровна тавышы:
— Иптәшләр, сезне Игорь Дмитриевич Агарков көтә.

*
* *

Якты Яр язмышы хәл ителгәндә фәнни дәлил таләп иткән Агарковны җыелышта күрәчәгенә Фәез ышанып ук барган иде. Шулай булып чыкты, чөнки фикер һәм вакыйгалар, сметалар һәм мөнәсәбәтләр шундый шәхесне таләп итте. Моңарчы җиңүләр яулап килгән ихтыярлы тойгы ялгышын нәкъ әнә фәнни җитәкчелек төзәтә алачак!

Фәез җыелышта Агарковныерактан күреп таныса да, ничектер, хәзер якыннан карап нәтиҗә ясыйсы килде. Ахыргача ышанып җитми иде, күрәсең. Нәрсәдер тагын көтте. Кабинетка шул ният белән керде.

Ләкин Алевтина Федоровна Агарков сезне көтә дисә дә, монда иң югары башлыклар әле күренми икән. Баш идарәнең җаваплы әһелләре — бүлекчә җитәкчеләре генә утыра.

Мондый киңәшмәләр гадәти хәл. Тик бүген шундый аерма күзгә ташлана: кайбер мәсьәләләрне баш управляющийга хәтле үк хәл итә тору, бәхәсле шау-шу юк. Җәмәгать — тын, көтә...

Баш управляющийның ял итү бүлмәсеннән Аппаков, министр һәм Лазарев күренгәч, тынлык сагаюгарак охшап куйды шикелле. Лазарев беренче тапкыр читкә, почмакка урнашты. Министр белән Аппаков өстәлнең ике ягына килеп өлгергән мәлдә үз ишегеннән Агарков чыкты. Чыкты да... утырыр алдыннан карашы кемгәдер тукталды, кемнедер ул танырга җыенган иде бугай, аның карашы тукталган кеше, әлбәттә, үзе дә сизмәстән, тотты да аягүрә басты. Кинәт килеп чыккан бу хәлгә гаҗәпсенгәндәй, Агарков бүтәннәргә дә күз салган иде... берәмберәм бүтәннәр дә укучы балалардай баса тордылар. Министр белән Аппаков кына ихлас елмайган хәлдә утыра бирделәр. Соңыннан абайлавынча, Фәез үзе дә яңа җитәкчене, сүзсез генә, ләкин барыбер аягүрә басып олылый, сәламли икән.

— Исәнмесез, хөрмәтле иптәшләр.
— Исәнмесез, Игорь Дмитриевич.

Җавап та дәррәү бирелде, Агарков үз урынын алгач кына бүтәннәр дә утырыштылар. Шунда гына елмаюын тыеп, Аппаков торып басты. Яңа гына төгәлләнгән җыелыштан соң Агарковның кем икәнен аңлатып торуның хаҗәте юклыгын әйткәч:

— Яңа баш управляющийның төзелеш тәҗрибәсе зур,— дип канәгатьләнү белдерде.— Ул — Туганлык кебек зур каланы юктан бар иткән кеше. Ерак Себердә, тайгада. Без аның монда да шундый ук уңышлар яулаячагына ышанабыз. Ышанабыз, фатиха бирәбез, көтәбез.

Шушы ук мәгънәләрне башка сүзләр белән министр кабатлагач, баш управляющийны котлап куллар да чабылды. Башкаларга ияреп-ме, хәтта Лазарев та кул шапылдатып куйды. Гәрчә Фәездән башка кеше аңа күз салмады шикелле...

Әйе, Агарков — Фәез көткән кеше. Сүз хәзер анык. Хәзер, котлаулар өчен рәхмәт әйтеп бетергәч тә, ул төзелештәге өзеклекнең сәбәпләре, аннан чыгу мөмкинлекләре хакында тиешле бүлекчә җитәкчеләреннән фикер сорар, бәяләр бирер, бурычлар куяр...

Тик Фәез каты ялгышты. Агарков теленнән әзер нәтиҗәләр генә ишетелде. Гаҗәпләнми хәлең юк!

— Козьма Прутков кочагың җитмәгәнне кочакларга тырышмаска киңәш иткән. Ә без кочак җиткерергә тырышып интегәбез.— Тенор

белән баритон арасындагы тавышы йомшак, ягымлы. Бу тавыш белән лирик җырлар җырлау мәслихәтрәк булыр иде. Ә ул сатирага керде...

— Дистәләрчә төзү идарәләренә баш идарә конкрет барып житә алмый. Алар баш идарәгә тиешле җепләр белән тоташмаган. Шулай. Сезнең һәркайсыгыз бәләкәй булып караган. Җеп бәйләнгән гимнаст курчакны хәтерлисездер. Ике кулдагы җепнең ничек тартылуына яраш-лы рәвештә, гимнаст тиешле хәрәкәтләр ясый. Әйе, кайсы җепне ничек тартуга карап. Ә безнең баш идарә җепләрне ничек кенә, ничә куллап кына тарткаламасын, кайбер бүлекчәләр тәпиләрен дә селкетмиләр. Әйе шул, көлкеле хәл. Тик һәр шаярту нигезендә дөреслек ята. Анысын да беләсез. Бүлекчәләрне агач гимнаст хәленә тиңләмәстән, аларның төгәл механизм кебек эшләргә тиешлеген таныйк. Шуңа күрә тәкъдим итәм: төзү объектларының үзләренә карап, махсус трестлар булды-рырга. Асылда тәртипләре чуалган, әллә нинди комплекслар белән тимгелләнгән төрле зурлыктагы идарәләргә тигезлек биреп, аларны өч оешмага буйсындырырга — металлургия биналары төзелеше, автоза-вод төзелеше, гидростанция төзелеше трестларына. Бу трестларны булдыру өчен, документлар, биналар кадрлар белән конкрет эшләү өчен җаваплы кешеләр билгеләргә. Автозавод төзелешенә — бүгенге көнгә хәтле баш идарәнең баш инженеры булган иптәш Шарамыгинны, металлургия төзелешенә аның урынбасары булган иптәш Насыйбул-линны билгеләргә. Гидростанциядә иптәш Коровкин үзе кала. Эшнең барышы хакында бу иптәшләр көн саен миңа рапорт бирәчәкләр. Со-раулар булмаса, шушының белән бетте.

Фәез үзенең гидростанциягә кайтырга теләге барын әйтергә тел әйләндерә алмады.

— Уңышлар телим, кадерле иптәшләр.— Беренче җылы сүз.

Соңгысы булмасын. Бәлки бүтәннәр дә шундый фикер белән тара-лышкандыр. Фәез көткәнчә килеп чыкмады бугай...

Чыгышлый Фәезне Шарамыгин тагын үз бүлмәсенә чакырды һәм инде башлык буларак түгел, иптәшләрчә, Насыйбуллинга урынбасар итеп Хәмитовны тәкъдим итте.

— Ә сез аны үзегезгә алыгыз, Григорий Никифорович, ычкын-дырмагыз.

— Хәмитов сине якынрак күрә. Аппаков та шундый фикердә.

Фәезгә баш кагып җилкә җыеру җае гына калды.

Иртәгесен трест урнашачак бинага тәүге тапкыр эшкә килгәндә исә аны иң беренче булып каршылаган кеше Хәмитов булды. Тышкы ишек төбенә үк чыккан да:

— Котлыйм сезне, Фәез Сәлимович, яңа вазифа белән!— дип, пар кулын сузган.— Берга-берга эшләрбез.

Шул көннән соң икенче төрле тормыш башланды. Гәрчә анысы да Фәез фаразлаганча түгел иде.

*
* *

Урамда февраль.

Урамда кышкы чиллә. Битләрне өтәрдәй шундый көннәрнең бер-сендә Фәезне баш идарәгә чакырып алдылар. Аны Агарков һәм министр көтә икән. Сүзне министр башлады.

Таныш соры күзләр, карчыга борын... Хәтсездән таныш булса да бүген үзгәрәк төсле иде бу кыяфәт, тагын кемнедер хәтерләтә кебек иде. Кемне? Кемне соң әле? Искә төште — Лебедев. Ул да онытылмый. Әйе. Лебедев бик үк каты томшыклы булып чыкмады, ә монысы бүтән. Монысына эләксәң!

Эләкте дә бугай Насыйбуллин.

Министр Агарков урынында утыра иде. Кунак булып килмәгәнлеген күрсәтер өчендер, Агарков, аның уң кулына терәлеп диярлек, каш астыннан карый. Кырый урындыкларда да кемнәрдер утыра, ләкин анда күз төшерергә вакыт бирмәделәр.

— Эшләр ничек бара?— диде министр, көн саен бергә эшли торган кеше кебек гади генә.

— Әлегә начар. Бик тә начар.

— Сәбәп?

— Сәбәп — бер генә. Үзебез сала торган биналарның проекты кирәк. Хәзер үк.

Министр корыч тавышы һәм җиңелчә кул изәве белән сәбәп һәм өметне бер юлы себереп төшерде:

— Проектлар белән сабыр итәргә туры киләчәк.

Бу чакта вакыт тарлыгы белән бөтен нәрсәне аклап була. Мәгәр технология дигән нәрсә хәтта министрга да буйсына белми бит. Насыйбуллин хаклы. Тик проектчыларның өлгермәячәген туп-туры әйтүе белән министр да ялгышмый иде. Хәл үзе шәфкатьсез иде.

— Мин анда күз бәйләш уены уйнарга җыенмыйм,— диде, ниһаять, Фәез зиһенен җыеп.

— Шартлар өлгергәнче, фронтны башка җиргә күчереп торырга туры килә.

— Хәзергә аңламадым.

— Аңлат, Игорь Дмитриевич.

Агарков зәңгәр күзеннән ике-өч тамчы нур чәчрәтте:

— Җылылык трассасын...

— Безнең профиль түгел.

— Шуның бер участогын сезнең карамакка бирү хакында сүз бара. Икенче кышка барлык заводларга, шул исәптән сезнең литейныйга җылылык керергә тиеш.

— Мин балачакта экиятләрне күп укыган кеше. Шулай да... Юк биналарга, юк җылылык...

— Срок фантастикага тартым, үзебез дә беләбез,— дип тынычландырмакчы итте министр.— Көтелмәгән комачаулар чыгуы да ихтимал... Соңга калсак... Кышкы суыклар безне гафу итмәячәк.

— Һәм без үзебезне бернинди объектив сәбәпләр белән дә аклый алмаячакбыз.— Агарков битендәге миңен капшап, зәңгәр күзен кыса төшеп, сары каш астыннан бакты.

— Шулай да сез үзегезне бернинди объектив сәбәпләр белән дә аклый алмаячаксыз.

— Рәхмәт.— Фәез аптыраштан елмая гына алды.

Сары кашлар астыннан караган коңгырт күзләрдә дә сизелерсизелмәс елмаю галәмәте шәйләнде:

— Моннан да мактаулырак бүтән бурычны табу кыен.

— Инде дә...

— Сез аңа сүзсез риза.

Фәез министрга да, Агарковка да күтәрелеп карады. Шаярту галәмәтләре сизелми иде.

— Ә нишләп... нәкъ менә мин риза булырга тиеш?— дип сорады Фәез.

— Монысы инде — безнең эш. Шулай бит, Игорь Дмитриевич?

— Шулай.

Насыйбуллин тиз генә капланып төшмәде, тартышты, карышты. Ләкин соңыннан бәхәс йомшара язды. Ниһаять, Фәез кулын өстәлгә җәеп салды:

— Ярый, беткән баш беткән.

Министр баягыдан да катгыйрак итеп:

— Шуны кабатлап әйтәм. Берничек тә аклана алмаячаксың. Үзең беләсең, кыш... Кыштан барыбер алданрак өлгерергә кирәк.

— Ә мин ашыга төшәрмен.

— То есть?— министрның күзләре бернинди кызгану галәмәте вәгъдә итми иде.

— Утызынчы ноябрьга кою заводына җылы пар кирәчәк.

Кырый урындыкларда утыручылардан берәү, заказчылар вәкиле бугай:

— Һе, ул шаярта, мыскыл итә!— дип куйды.

Министр тагын кырысланып сорады:

— Нишләп?

— Китерә алмаячак. Утызынчы ноябрьга түгел, утызынчы декабрьга, утызынчы январьга да китереп җиткерә алмаячак.

— Ә мин аның белән үзем эш итәчәкмен. Ә минем таләп,— министр заказчыга ымлады.— Минем таләп... икенче төсле булыр. Аңлашыламы?

— Аңлашылды.

— Димәк, бу эшкә алынасың.

Башын кискәгә салганын Насыйбуллин сизә иде, билгеле. Ләкин җылылык килмәсә, төзелешнең ким дигәндә ярты елга артта калачагын да белә иде. Бер баш киселә икән, киселсен. Әгәр ул җылылык иҗат итәргә сәләтле булса, бәлки әле кисмәсләр дә. Ә иҗат итә алмый торган баш икән, киселүе хәерле...

— Димәк, алынам.

Ике як кырыйда сулышлар аһылдады. Аның каравы министр белән Агарков җиңел сулап аягүрә бастылар. Министр кул сузды:

— Сезгә уңыш телибез.

— Рәхмәт.

Әңгәмә шуның белән тәгалләнде.

Шул минутлардан башлап Фәез Насыйбуллин күз алдында алакола йолкыш ноябрь тере кеше сыман булып, торып басты. Аралар әлегә ерак. Әмма һәр көн, һәр сәгать аны якынайтачак. Ихтимал, дию белән алышкан әкият батыры кебек, аларга да алышырга, соңгы тамчы канга чаклы сугышырга туры киләчәк.

Бурыч: Фәез Насыйбуллин тресты, чынында нульдән башлап, завод биналарын юктан бар итәргә һәм аларга җылылык та кертергә тиеш. Бәгъзе кешеләр көлде, кайберәүләр кызганып читкә борылдылар.

Хатыны Зәрия ялынып-ялварып бу эштән Фәезнең баш тартуын сорады. Ләкин Фәез үзенчә кабул итте. Күңелдә рәхәт җилкенү, колакларда — җил сызгыруы... Ул гүя ярдан баштүбән оча...

Фәез вакыт-вакыт газиз башының түмәр өстендә ятканын күз алдына китерә. Ләкин әле, шөкер, муен исән. Балта күзгә күренми шикелле. Төштә генә күренсә... Тик хәерлегә каршы, төш күрергә вакыт калмый.

Барлык хәлләр өндә булды.

Министрдан кайткач та үз кабинетына керешли үк секретарьга әйтеп, үзенең производство буенча урынбасары Хәмитовны, баш инженер Глазовны һәм бүлек мөдирләрен чакырып кертте. Агарков кабинетындагы сөйләшүне кыскача хәбәр итте дә:

— Бурыч аңлашыламы? — дип, иптәшләрен берәм-берәм күздән кичерде.

Нәрсә әйтсен, нәкъ Фәезнең үзе шикелле, фантастика дип, бәяләделәр. Ләкин эш — чынбарлык. Аннан качу, котылу юк. Бары тик үтәргә генә мөмкин.

— Бары тик үтәргә генә рөхсәт. Көнен, сәгатен билгеләп график төзисез. Һәркем үз башыннан шуны кичерсен: һәр кеше, гомум задание үтәүдән тыш, лично үзе шул файдага нишли ала. Яңа техник алым,

ачышлар хакында әйтүем. Иҗади эш диюебез монда тулысынча туры килә. Фантазиягә — чикләнмәгән мөмкинлек.

— Һәм кулларга,— дип шаярырга тырышты Хәмитов.— Һәм аякларга.

— Берсе дә тыелган алымнар түгел. Ирекне күбрәк бирү ягында мин. Килештекме? Килештек. Ә хәзер — мәйданнарга.

Урамда — кыш. Ак чиллә — киләсе кыштан хәбәр, чәнечкеле буранnары белән йөрәкнең үз эчендә жуылдый, чыдамасаң, тешләреңне шыкылдат.

Фәез һәм аның иптәшләре ике машинага төялеп, кырга юл алдылар.

Мәйдан дигәннәре — кар диңгезе. Ак диңгездә калган зәгыйфь бер эздән машина үкерә-үкерә шактый озак барды. Ә иң үр басуларның түрендә — истәлекле таш дивар... «Здесь будет построен Камский автомобильный батыр».

— Өч ел...— дип Хәмитов диварга аягын куйды,— бу таш моңаеп тормаска тиеш иде бит. Төзек бина тәрәзәләреннән яктылык төшеп, елмая башласа да гаҗәпләнмәс идек. Ә монда...

Фәез нигезләргә якын ук килеп басты:

— Таш елмаерлык көн китерү безгә тапшырылды. Шул исәптән сиңа, Айрат Бариевич.

Кайсыдыр бер тилесе фотоаппарат белән килгән икән. Фәез нәкъ әлеге сүзләрен әйтеп торганда, сурәткә төшереп алдылар. Аппарат чыкылдап куйгач кына абайлады Фәез. Газеталарның берсендә тантаналы кыяфәт белән басып торырлар. Әлегә... дип өстик.

Фәезнең кәефе кырылды. Шушы бит инде кою заводы дигәннәре — казулардан мәгънә килеп чыкмаган буш чокырлар, котлованнар, димәсәң, үпкәләүләре бар тагы... Тар чокырларга тоташтан тимер-бетон плитәләр салынган. Краннар иләмсез авыр конструкцияләр күтәреп интегә, көчәнә, ыңгыраша, сызлана. Берсе туң балчык тавының лепкәсенә менеп утырган да шуннан, муенын сузып, теше үтмәстәй каты чикләвекләр эләктерә. Эләктерә дә теше үтмәгәнгә күрә, яратмагандай, икенче урынга сузылып ыргыта.

Күптән түгел генә аргы котлованнар эчендә кыр казлары һәм бүтән кошлар чума-чума уйнаганлыгын чамаларга мөмкин. Хәзер бу күлләрдә конькичылар ярышы оештырыр өчен кем дә кем рөхсәт сорый килсә, Насыйбуллин андый рөхсәтне һич кыенсынмый бирәчәк. Тиздән, боз авырлыгыннан, боз катылыгыннан котылгач, искән әкрен җил белән дулкыннар кузгалачак һәм эш тукталачак. Аннары җәйне көт...

Үзләренчә изге һәм сыналган традицияләргә ябышып, проектчыларның ычкына алмыйча интегүләре шушы мәйданда барча буталчыклары, иләмсезлекләре белән актарып ташланган, чакрымнарга сузылган бушлык рәвешендә җәйрәп ята. Ә бит кайдадыр бораулап коела торган свайлар даны шаулый һәм ул Якты Ярга да ишетелә тора!

Насыйбуллин шушы хакта баш идарәдә сүз кузгатачагын төшенеп, Глазовтан:

— Сергей Николаевич, син бу мәйданда стажлырак кеше. Бу җирнең геологик картасын караганыгыз булгандыр. Ничегрәк монда катламнар? — дип сорады.

— Минем караганым юк, Фәез Сәлимович.— Фәез тузына башлаячакны сизеп, аңлатырга ашыкты.— Чөнки андый карталар бездә юк.

— Шунсыз төзергә керештегез?

— Дәвам дә итәбез.

— Бүтәнчә болай ярамый. Далада күз бәйләп кая барганыңны, кайда буталуыңны белмичә күпме йөрергә мөмкин?

— Бу сорауга беркем дә җавап бирә алмый, Фәез Сәлимович.

— Бирергә тиеш.

Насыйбуллин мәйданнан кайтып үз кабинетына керү белән телефон

трубкасына ябышты һәм баш идарә баш инженерының техника буенча эшләгән урынбасарыннан әлеге картаны сорады.

— Юк андый карта,— дигән кыю тавыш ишетелде.

— Ә нишләп шунсыз эшкә керешкәннәр?

— Күрсәтмә булгандыр, боерык. Син үзең дә әле генә шушында идең — күрсәтмәләр биреп яттың. Болай ук тиз онытмаска иде.

— Ләкин бит карталар эшләнгән булырга тиеш! Кайдадыр ята бит алар? Мәйданга геологлар килгәндер, ә?

— Бәлки килгәннәрдер, бәлки бардыр. Кирәксә, эзләп тап.

Ун-унбиш көннән соң гына тарихи ачыш ясый алды Фәез. Кызларга күчтәнәчләр куя-куя һәм мең вәгъдәләр бирә-бирә архивка салынган кәгазь арасыннан эзли торгач, геологик карта тирән катламнар эченнән килеп чыкты. Шулар була торып, шушы көнгә хәтле эшләгәннәр — сукыр килеш!

Ниһаять, карталарны машинкада күчереп баскач, Фәез аларны үзенең яңа кабинеты стенасына элеп куйды. Аларда котлованнар, завод биналарының контурлы сурәтләрен сызгалады. Җир катламнарын тикшерде. Җир асты сулары кай тирәдә? Ел фасылларында аларның биеклек, тирәнлек чикләре кайда? Боз астындагы бу күлләр каян килеп чыккан?

Тикшерә торгач, ачык күренде: кою заводы нигезләре җир асты суларының уртасына ук чумып утырган икән. Тигез җирдәгеләре генә түгел, хәтта калкурак урында салынганнары да.

Проектчыларның шул чаклы хәтерләре калды! Кабат-кабат таләп итүләргә карамастан, баш идарә геологик карталарны аларга җибәрергә вакыт тапмаган икән! Чөнки аларны җир актарырга ашыктырганнар...

Кызыксынып, Насыйбуллин Якты Ярга кайткан проект документларының томнарын исәпләп карамакчы иде... Бу җиңел генә эш түгел икән. Заводның УКСлары һәм ОКСлары үзләренең фондында йөзәр меңнәрчә томнар һәм альбомнар саклый — гигант китапханә! Томнарны үлчәүгә салсаң, алар йөзләгән тонна тартыр иде... Күпме кешенең ми куәте аларда!

Телефоннан Агарковка, хәлне ачыклап, киңәш төсендә хәбәр иткән иде, баш управляющий: «Сезгә җаваптан качу өчен кирәкме минем киңәш?» — дип өлгергәч тә Фәез, гафу үтенеп, рычагка басты. Трубкада кыска гына: пип-пип-пип... Моннан да аңлаешлырак сигнал булмас: «Трестның үз башы бар — уйласын. Уйламаса, бүрегең бәреп төшерербез».

Үзенең иң якын ярдәмчеләрен — урынбасары Хәмитовны, баш инженер Глазов белән заказчы вәкилләрен чакырып, Фәез кабинет стеналарын бизәгән гүзәл карталарның су астында калачак мәгънәләре һәм мәгънәсезлекләре хакында хәбәр итте.

— Үзебезне фаш итмичә, төзелешне шушы килеш дәвам итәргә мөмкин, әлбәттә. Ләкин без каз-үрдәк фермасы төземибез бит. Әзер заводта эшләүчеләр киләчәктә безнең өрәкләрне таптап йөрсеннәрме?!

— Ләкин сроклар? — дип кисәтергә тиеш булды Хәмитов.

— Әйе, сроклар. Әйбәтрәк фикерегез бармы әллә?

Хәмитов бу мәйданда элегрәк эшләгән кешеләрне, шул исәптән Глазовның да җаваплы булуы хакында сөйләсә дә нишләргә икәнен Фәезнең үзенә калдырды.

— Агарков, минемчә, министр белән икәүләп, срокларны беренче чиратта синнән сораячак.— диде ул.

— Глазов, сез...

Глазов акланырга тырышмады, геологик карталарны күрмәве аркасында уртак шаукымга ияреп таныды һәм:

— Тиешле җәзагызны бирерсез,— дип, баш иде.

Заказчы фикерен сорап тормастан, Фәез нәтиҗә ясады:

— Хәлне аңлатып, баш идарәгә докладной язгыгыз. Заказчының техник контроле белән актлар төзегез — брак! — Эндәшүче булмагач, актыгын әйтте.— Салынган стеналарны җимертү өчен техника әзерләгез. Минем бетте, сездә булмаса — эшкә.

Мәйданда бульдозерлар, скреперлар, экскаваторлар җыйналды һәм башланды яңа мәхшәр — дөбердәү, шатырдау, акыру, тиргәшү. Фәез моңа гаҗәпләнмәде. Мондыйны әлегрәк күргәне бар иде шикелле. Кайчан әле? Әйе, берничә ел элек. Лазарев шушы рәвешле Лебедев күтәрә башлаган агач каланы җимереп аткан иде. Агач кала түбәсе — зәңгәр гөмбәзнең үзе кебек гөрселдәп төште. Бу юлы түбә юк. Ләкин нигезләр шартлап җимерелә... Теге вакытта Фәез баш идарә тәрәзәсеннән өстәнрәк күрсә, бу юлы түбәннән, ләкин тирәнрәк күрә бугай.

Шулай бөтен дөньяны тиргәп йөргәндә, Фәезне таныптыр, күрәсең, зәңгәр штормовка кигән бер егет ниндидер кәгазь сузды:

— Менә, заявка бирелгән, килешенгән иде бульдозер алырга. Бирмәделәр.

— Соң?

— Шалтыратып алмассызмы диюем иде.

— Ә? Нишләп миңа килдегез?

— Ә кемгә соң бүтән?

— Баш управляющийга, өлкә комитеты секретарена, яки Мәскәүгә, министрга.

Бульдозерчы, сүз куертмыйча, китеп барды. Насыйбуллин да ары атлады.

Вак-төяккә катнашырга яратмый Фәез Сәлимович, чөнки вак дигәне, гадәттә, башкалар вазифасы. Һәркем үз эшен, үз урынын төгәл белергә тиеш. Бигрәк тә менә шушындый төзелештә. Ә ник әлеге егет бульдозерны Фәездән сорады? Бульдозер китерү эше тапшырылган махсус кеше бар. Фәез җитәкчелегендә, билгеле. Аның эшен Фәез хәл итә ала: трубканы гына кулга аласы... Мәсьәләнең шулай җиңел хәл ителү мөмкинлеген зәңгәр штормовка белә. Мәгәр Фәез моны эшләми һәм эшләмәячәк. Чөнки, беренчедән, механизация бүлегенең дәрәҗәсе түбәнәя. Икенчедән, бүлек эшләмәскә өйрәнә, катлаулырак мәсьәләләрне югарыдагы иптәшләр җилкәсенә күчерергә күнегә. Үзләре күтәрсен, эшләреннән ләззәт тә алсын. Ә трест җитәкчесенең үз шөгыльләре житәрлек: эш фронты булдыра тору, материаллар, кешеләр туплау. Коллективка вакытында дөрес юнәлеш күрсәтү. Иң соңгысы — шушы гомум бурычларны үтәгәндә килеп чыккан кыенлыкларны тиз арада хәл итә бару.

Тайпылышларга юл куймаска тырыш! Төзелеш — машина кебек, чак кына ялгыш борсаң, кюветка тәгәрәргә тора, кешеләрне харап итә ала... Һәм дәүләт байлыгын...

Шаулы мәйданга Агарков, аннары Аппаков килеп җиттеләр. Фәез тупас, усал сүзләр көткәнлектән, боларның чама белән тыныч калуларына гаҗәпсенә язды. Елмаюын ук тыеп түгелме икән әле, Агарков:

— Шәп җимерәсең. Ә төзүгә килсәк? Нишләргә җыенасыз? — диң, битендәге миңен сыйпады.

— Бер генә юл — субайлар. Аларны бораулап кою — иң дөресе.

— Иң яңасы. Шул техниканы китертә аласызмы?

— Китертә алмасам, гади субайлар кага башлыйбыз. Колакларыгыз тонса, бәлки ярдәм итәрсез.— Шул сүзләр белән Фәез җитәкчеләрнең икесенә дә текәлеп карады.

Аппаков:

— Уйларга кирәк, кирәк, әлбәттә,— дигән фараздан соң, Агарковка шаяргандай әйтте.— Эксперимент төсендә уздыру җиңелрәк булмасмы? Соңыннан киң юлга чыгу өчен. Ә?

— Тырышып карарбыз.

Аппаков шуннан соң ачык ук көлемсерәде:

— Мин үз рычагларымны кузгатып карыйм.— Һәм Фәезгә туп-туры карап: — Ну, Насыйбуллин, егет икәнсең, кара, ахыргача егет бул,— дип машинасына таба китте.

Бораулап свайлар ясау, мең бәхәсләрдән соң, шул рәвешле җиргә берегә башлады. Бульдозерлар, скреперлар җыйналды. Яңадан футбол тубы тибәрлек булып чистарган мәйданнарга бораулау машиналары килеп басты.

*

* *

Бәхете кимесә дә, Фәезнең акылы арта төшкәндер: кемгә тәгаен тапшырылган дип тормастан, ул көн саен барлык объектларны үз күзеннән кичерә, көн саен, сәгать саен эшнең барышына күз сала.

Биналарда, ниһаять, тәртип урнашты дияргә була. Кичә беренче тапкыр задание үтәлде. Бүген дә карарлык үзгәрешләр юк түгел. Насыйбуллин шуларны күңеленә беркетә бара. Каршысына зәңгәр штормовкалы таныш егет — Макаров килә. Бригадир. Гадәттәгечә, күзләрен кыса төшеп елмая Макаров — перемычкалар, плитәләр килгән, димәк. Шулай да зарланачак. Ләкин теге көндәгечә бульдозер сорамаячак...

— Я, хәлләр ничек, Алеша?

— Ярыйсы безнең хәлләр, тик...

Зарланмыйча түзә алмый Алеша — гадәте шундый аның. Материал ни хәтле генә җитешле булмасын, хәтта уңышка ирешсен, барыбер, нәрсәдәндер риза булмаячак. Монысына түзәргә мөмкин. Иң кирәклесе — үз башы белән йөри, юкны бар итә, төзи, стеналар калка.

— Тагы нәрсә, Алеша?

— Теге якта дренаж каналларын көрәк белән казырга туры килде, экскаватор җибәрмәделәр...

— Казымаска иде. Мин кушмадым ич?

— Проект. Аны нишләтим?

Җавантан Черных килеп коткара. Идарә башлыгы. Бетон нигезләр шартлаткан көннәрдә күрше идарәдән күчерде аны Насыйбуллин. Кешеләргә ярый белүе бар, ахрысы... Ләкин Хәмитовча түгел. Үткерлек белән түгел, изгелек эшләп. Әнә бит, бригадирның начальство белән ярамаганрак темага сөйләшәчәген абайлап, җәһәт кенә бу таба борылды. Юл уңаен эшкә әйләндерә белде: кемгәдер искәрмә ясады, икенчесенә нәрсәнедер эшләп күрсәтте, хәтта опалубка өстенә менеп китте — монысы яшьлек галәмәте. Салмакланыр, тормыш үзе өйрәтер.

Черных килеп җитте. Тик кул кысышканда ук анысы да зарланудан башлады:

— Фәез Сәлимович, сезнең вариантны уздырып булмады бит әле — проектчылар аяк терәде.— Фәез стеналар озынлыгын бераз үзгәрткән иде.

— Ә сез үзегез, инженер буларак, хаклы икәнлегегезгә ышанасызмы соң?

— Ышанабыз. Шулай бит? — Черных Макаровка күз ташлады.

Ә анысы:

— Проектчы үзе дә риза кебек. Ләкин хәл кылырга курка, Мәскәүдән фикер сорамакчы,— дип, үзенә зарлану өчен җай тудырды.

Фәез аннан өлгеррәк:

— Ә без үзебез нәрсәдән куркабыз? Менә син, Макаров? Син, Черных? Куркасың бит?

— Анысы да хак,— дип килешмичә булдыра алмады Черных.

«Куркуын яшерми. Димәк, аңа исәп тотарга мөмкин»,— дип уйлап, Фәез:

— Мөстәкыйль хәл итәргә хакыгыз бар. Хәтта шулай эшләү — сезнең бурычыгыз,— диде.

— Идея сезнеке булгач, Фәез Сәлимович, сездән катырак сүз көттек бугай.

— Шулаймы? — Фәез Макаровка текәлде.

— Дөресен әйтергә тәвәккәллек җитмәде.

«Моңысы да үзен җайсыз хәлгә куюдан курыкмый. Димәк, бүтән чакта курыкмавы да ихтимал».

— Володя, син карта уйныйсыңмы? Дурак калудан курыкмыйча, карта уйный аласыз. Ә менә монда... андый куркыныч янамаган урында куркып калгансыз. Килешми бит алай, ә? — Шулай диде дә, егетләрнең кулларын кысып, Насыйбуллин китеп барды. Бригадир һәм идарә башлыгы баскан җирләрендә сөйләшеп калдылар. Мөгаен, үз өстеңә җаваплылык ала белү хакындадыр. Ярый, зыян юк, тора-бара анысына да өйрәнерләр. Конкрет эш эшләргә күнеккән кеше, хәйләгә, дипломатиягә мәйдан бирмәс.

Машина ялан җирдән бераз баргач, авыл урамына керде. Авылның тап уртасыннан югары вольтлы электр мачталары атлап бара. Җылылык узачак юан торбалар сузылып ята. Аларның кара, төпсез авызлары бу агач өйләрне йотар шикелле. Әмма торбалар хәрәкәтсез. Һәм шул хәрәкәтсезлек Фәезне үрти дә инде. Фәез башын кискәгә салган икән, бу торбалар тиешле урыннарында ятарга тиеш.

Барак тибындагы агач бина.

Фәезне каршыларга идарә башлыгы ишек төбенә үк чыкты. Ләкин Насыйбуллин аның белән исәнләшкәнче үк:

— Бер атна... үзгәреш күрмим. Күрсәт, зинһар,— дип шундый тыныч әйтте, шуңа күрәдер, начальник сагаеп калды. Бераздан соң гына Фәезнең тавышыннан да йомшаграк итеп:

— Кран юк бит,— дип куйды.

— Кран булачак. Юл аңа әзерме? — һаман да шул яратып эндәшкәндәге кебек тавыш.

— Ике көн эчендә эшләп бетерәбез.

— Ике көннән кран булыр. Ә яктылык ягы, ут ягы ничек?

— Безнең монда... авылга килгән ут...— дип начальник аклана башлагач кына Фәез үз тавышына металл чыңы кушасы итте:

— Промсанитария ягыннан караганда, бу — мескенлек кенә түгел, корткычлык. Бәлки сезгә шуны аңлатыр өчен махсус курс ачаргадыр? Бәлки ликбез? Кайда субподрядчиклар? Ник алар күренми?

— Алар... ну... материал җибәрелмәгән дип сөйләнделәр.

Насыйбуллин сүзсез генә, чокып ташланган, балчык сибелеп яткан төшкә килде.

— Тиздән кар яки яңгыр койса... Монда сез ни кылмакчы буласыз?

— Ну, бер көн яуганнан...

— Каян беләсең... бер көн? Ә бер атна, ике атна койса? Апрельгә прогноз шундый — белеп әйтүем. Я?

Начальник җавап бирә алмады.

— Сез бит ул чакта дүрт аяклап балчык эчендә буталачаксыз, судагы тараканнар рәвешендә. Бүген үк үзегезгә дә, субподрядчикка да юл салыгыз. Бүген!

Насыйбуллин тагын бераз атлагач:

— Менә бит, машиналар буксовать итсен өчен махсус әзерләнгән урын. Кызык итеп, мәзәк карап тормакчы буласызмы?

Иртәгә прорабка әйләнәчәк начальник, баш иеп, тыңлап торуны дөресрәк тапты бугай. Ризалашуы шул булгандыр бәлки.

— Кул астындагы кешеләр алдында кызартмыйм әлегә. Үзеңә генә әйтәм: синең чир алкоголизмга тартым — бүген ихлас тәүбә итәсең дә иртәгә тагын үзеңчә дәвам итәсең. Ә яңгыр ява башлагач, бармакларың белән гравий актарырга керешерсең. Вакыт та, материал да өч-ләтә күбрәк китәчәк — изеп, таптап, балчык белән бутап, чәчеп бетерәчәксез. Бетон плитәләр ваткаларга керешерсең. Анысы да соң булыр. Ә син аны хәзер тап — түшә корыда. Аннан соң инде, «субчиклар» ял-кау дип, эшләмиләр дип бугаз ертылганчы акырсаң да килешер. Ә хәзер... әйтәсең бит, фронт юк дип килмиләр. Син юлны да, аларның авызын да бишмәтеңне салып булса да томала. Җәй асфальт урынына. Ә хәзер алар хаклы. Булдымы? Ярдәм кирәкме?

— Кешеләр җитми, тиз арада...

— Тиз арада бөтен литейный кешеләр күтә. Ә мин ут мәсьәләсендә сөйләшермен, Сорокин белән. Мин аны кичә кич караңгы объектлар буйлап йөрттем дә. Синекенә дә алып килермен. Караңгыда маңгайга маңгай бәрелешсәгез, чатнап дөнья яктырып китмәсме.

Көн саен шулай. Көн саен, сәгать саен — айлар буе. Эш киметәм дип йөргәндә, ул арта бирә. «Гидростройның» элек Хәмитов җитәкләгән идарәсендә — су чистарту станциясе һәм водозабор төзелешендә — нинди тәртипсезлек була алуын Фәез үз күзе белән күрде! Югыйсә ышанмас иде.

Бригадалар саны хәзер Насыйбуллин җитәкчелек иткән бөтен тресттагы санга тигез — кечкенә генә эш мәйданында хәтта махсус һөнәр бригадалары бар иде. Бүтән эш кушсаң, тәкәббер генә баш тарталар: без — фәлән белгечләр! — дип куялар. Берсенә дә эш фронты әзерләнмәгән. Нәтиҗәсе дә күз алдында — бер елга бер миллион сум югалту! Тиз арада үзгәртеп кору мәҗбүри иде. Бригадаларны зурайтып, комплекслы итеп үзгәртте Насыйбуллин. Ә эш күтәп тик ята торган отделочникларны бөтенләй таркатып, ул эшкә биналарга даими җылылык кертелгәч кенә тотынырга күрсәтмә бирде. Фронт күтәп яткан бригадаларга бүтән эш табылды, табылмаган очракта кешеләр бүтән идарәгә үк күчерелде.

Шулай да эш бер көйгә салынып бетми әле һаман...

Насыйбуллинның мәшәкатьләре бүтән идарәләрдә дә җитәрлек. Шофер кая барырга икәнен сүзсез белә. Сорамыйча алып китте.

— Көненә ничә километр узыла икән машинада?

— Өч йөз, өч йөз илле,— диде шофер.

Кою заводында кечкенә якта чәчне үрә торгызырлык хәл сизелмәгәч, Насыйбуллин үз кабинетына кайтты. Узышлый ук:

— Таня, миңа Сорокинны чакыр, зинһар,— дип әмер бирде дә, эчкә кергәч тә, телефон номерын җыярга керешге.

— Мин — кран хакында. Әйе. Ике көннән. Дусларча очрашырлык булсын. Рәхмәт.

Бүтән номер.

— Син машинаны җибәрмәгәнсең бит. Әйе, җылылык трассасы... Әйе, ул да безгә карый... берни эшли алмыйсың — үтәргә туры килә. Молодец. Хуш, рәхмәт, онытмам.

Олы яшьтәге, калын гәүдәле, зур гына башлы абзый килеп керде — Сорокин.

— Утырыгыз, Олег Витальевич. Блокнотыгызга иртәгә эшләргә дип языгыз, пожалуйста: җылылык трассасының хәзер эш барган һәм барачак участокларында... Юпитерлар куярга.

— Анда бар бит ут.

— Төнлә күчмә лампалар белән эшлиләр. Фонарьга күчәргә җыенмыйсызмы тагы?

— Төнлә дә эшлиләрмени?
— Син ничек уйлыйсың?
— Мин белмәгән идем.
— Хәзер менә белдең. Ничә көн сиңа?
— Өч, дүрттер...
— Ике көн.— Сорокин уйлаган арада өстәде.— Ике көн — шәп срок. Исән булып торыгыз.

Сорокин чыккач, секретарь кыз керде:
— Сезгә анда приемга килгәннәр.
— Бүген прием көнемени?
— Түгел дә... бик сорыйлар.
— Ничә кеше?
— Дүрт. Барысы да квартир хакында.

Насыйбуллин чак кына уйлана калды. Ләкин соңыннан сукранусыз тавыш белән ризалык белдерде һәм блокнотын шуыштырып китерде дә тиз-тиз язарга кереште:

«Без сугыш хәлендә яшибез. Дошман — аяусыз, беркайчан да чигенә белми, туктаусыз алга, алга атлыга. Дошман дигәнебез — вакыт. Аны җиңү өчен бер генә ысул бар — үзеңнән тизрәк өлгерү. Вакыт белән билгеләнгән эшне күбрәк, тизрәк башкару. Вакыттан алда, вакыттан алда!»

Насыйбуллин иртәгә кою заводы җыелышында үзенең чыгышын шушы сүзләр белән тәгалләячәк.

*
* *

Үзгәрешләр — көн саен, сәгать саен. Үзгәрешләрнең кыяфәте, ап-ак диварлар булып, инде кою заводында гына түгел, башка заводларда да күренеп тора. Мартның чалт аяз зәңгәрлегендә диварлар фарфордан ясалган җиңел уенчыклар сыман тоела.

Якты Ярны җил ярата. Җил чак кына ял итә дә, шул кыя-диварларга өермәләр сыйфатында кагылып, аударырга, күтәреп китәргә азаплана. Ләкин өйләр, биналар нык — җил тырышлыгына көлемсерәп ялтырый бирәләр.

Җил һәм эфир дулкыннары Якты Ярның барлык тарафларына сүзләр тарата — көн саен, сәгать саен.

— Дамир! Заһретдинов! Сиңа бетонны кай төшкә җибәрик? Әйдә, минем яшь күңелем йомшак чакта, хатаңны төзәт. Теләсәң нишләт. Бер дә булмаса күлмәк изүеңә тутыр. Үзегез гаепле — иртән арматураларыгыз әзер булмаган, машиналар сәгать ярым тик торган. Агарков мине үтерәчәк — моннан соң мондый хәл кабатланмасын. Заявкаларны гына түгел, отказны да язмача гына кабул итәбез. Ишетсен колагың. Хәзер тизрәк уйлагыз — яңа адрес бирегез — кая?

Элегрәк болай сөйләшеп торулар ишетелми иде. Килгән җирдә автомашина бетонны түгәр дә китәр иде. Беркем дә җавап бирмәс иде. Хәзер Заһретдинов баш тартса, башы белән үк димәсәң дә, эш хакы белән җавап бирәчәк! Диспетчерлыктан тимерчыбыклар һәм чыбыксыз телефоннар аша килеп җиткән яңгыравыклы матур тавышларның мәгънәсе шулдыр. Кызлар тавышы. Уйланмас җиреңнән уйланырсың.

Агарков эшкә керешкән көнендә үк шундый приказ бирде: смена эчендә дүрт йөз кубометр бетон кабул иткән ике диспетчер йөз сум бүләк ала... Ни хәтле генә юмарт тоелмасын, аңа әле бер пар — Людмила Георгиевна белән Галия Сабировна гына ирешә алды. Заһретдинов адресына бөтен шәһәр ишетерлек итеп кычкырган тавыш — нәкъ менә шул Людмила тавышы да инде.

Моннан дүрт кенә ай элек Агарковның килеп керүен кызлар һич тә оныта алмас. Һәм кызлар гына да түгелдер. Ул чакта диспетчерлык палаткада урнашкан иде.

Килеп керде Агарков диспетчерлыкка. Беренче тапкыр. Сәгать иртәнге алты. Бер сәгатьтән икенче смена башланачак. Дымлы җил палатка брезентларын умырмакчы — тарткалый, селкетә. Агарков, башын ия төшеп, эчкә узды, һәм баскан җирендә катты да калды.

Людмила Георгиевна да, Галия Сабировна да аның нәрсәгә шаккатканын тиз сизделәр. Баш диспетчер Валерий Шадрин аягүрә баскан хәлдә аның белән ике-өч тапкыр исәнләшсә дә, Агарков җавап бирергә җыенмады. Аның күзләре бүтәндә иде.

Балчык укмашып тапталган такта идән уртасында ике өстәл берсе-берсенә сыенып тора. Өстәлләрдә төрле кәгазь өемнәре. Түшәмнән озын шнурга тагылган шәп-шәрә лампочка асылынган. Бер телефон. Бернечә каналлы хәзерге телефон, телетайп, рация кебек аппаратлар күрергә теләгәндер Агарков. Аның салкын күз карашыннан бүлмә эчендә шыксыз тынлык куера барды.

Баш управляющий, хәтта кызлар белән дә исәнләшмичә, өстәл янына узды. Битендәге миңен каплап, шуны сыйпый-сыйпый, диспетчерлык журналындагы язмаларны укырга кереште — төн дәвамында мәйданнарда нәрсәләр эшләнгән... Аның һәр эш көне диспетчерлыктан башланачагын кызлар әле белми иде.

Агарковның кашлары өлгергән бодай кылчыгы төсле озын һәм сары. Валерийга илтифат итмәстән, шул кашлары ышыгыннан Людмила Георгиевнага сыңар күз белән карап куйды да укуын дәвам итте. Аның нәрсә укыганын Людмила күрде: «Икенче сменада объектларга ком китерелде...».

— Күпме?

— Билгесез. Участоклардан...

Мәгълүмат бирелмәгән икән, мастерлар исәпне ихтирам итми дигән сүз.

Агарковның коңгырт күзе ут чәчкәндәй тоелды. Арпа чуклары сыман керфекләре җиз тимерчыбыкларга әйләнеп тырпайдылар да, аннары авыраеп, яңадан тынычландылар.

«Төнге сәгать бердә машиналарга отказ бирелде. Сәбәп: көчле яңгыр аркасында котлованнар янына узу мөмкин түгел».

Шул сүзләрне укыгач, тагын бер кабат идәнгә карады да, ниһаять, баш диспетчерга күз ташлады:

— Сезнең монда гөмбәләр үсмиме?

— Кайда?

— Кайда. Сезнең... сез җитәкләгән диспетчерлык идәнендә. Салкын көздә бүтән кайда үсә алсын? Бу елларда мондый хәлдә чучкаларны да асрамыйлар.

Людмила:

— Хәзер, хәзер без...— дип кузгалса да, Агарков аны кул ымы белән генә җәһәт туктатты.

— Сабыр.

Агарков бүтән кәгазьләрне кулдан кичерергә кереште. Күпмедер вакыттан соң күтәрелеп, сул кулы белән битен янә ышкып куйды.

— Сез — баш диспетчермы?— аның тавышында мәсхәрә чалымы юк түгел иде.

— Б-б-бүгенгә хәтле.— Шулай үз гомерендә беренче тапкыр тотлыкты Валерий.

— Сез суккан штамп бер сум акча бәясенә тормый икән, сез менә шушы палатканы саклый торган төнге һәм көндезге каравылчылар булып калачаксыз. Йөк төялгән машиналар башта сездә тамга алырга тиешле. Ә мәйданга баргач, путевкага мастер штамп суга. Шул

штамп булмаган путевкалар кабул ителми. Шушыны аңлау өчен баш диспетчер булу да мәҗбүри түгел, җыештыручы апа моны аңлый. Ә мин сезгә аңлатырга мәҗбүр.

— Моңарчы... моңарчы тәртип шушындый иде.

«Чыраена, сүз әйтүенә һәм ояла белүенә караганда, Валерий — әйбәт күңелле, тәрбияле кеше. Әмма монда икенчерәк тәрбия һәм холык кирәк шул».

— Кеше эшләмәскә күнеккән икән, бернинди тәртип ярдәм итми. Яңа гадәтләр табарга — вакыт аз.— Шулай дип, Агарков чыгып китте. Үз кабинетына керәп өстәл янына утыргач та беренче чакырып керткән кешесе үзенең производство буенча урынбасары һәм аңа бирелгән боерык шундый иде:

— Теләсә кайсы бүлекне палаткага чыгарып, диспетчерлыкны элекке урынына кайтарыгыз.

— Әйе, ерагайгач, анда эш начарланды.

— Тагын да ныграк начарланды,— дип төзәтте ул урынбасарын, каш астыннан карап.— Баш управляющийдан түгел, баш диспетчерлыктан башлана төзелеш. Булдымы?

— Булды...

Икенче көнне эшкә килгәндә, тагын беренче башлап «Диспетчерлык хезмәте» бүлегенә керде. Бүлек Агарковның үз бүлмәсе янәшәсендә генә иде...

Идәннәргә линолеум җәелгән, кешеләр, урамнан кергән аяк киемнәрен ишек катында калдырып, аякларына чешка-башмак элә. Идән, шуңа карамастан, көнгә ике кабат юыла...

Бүлмәдә хатын-кызлар гына. Кичәге баш диспетчер килмәгән... Агарков ул кайда дип сорамады. Өченче керүендә өстәл башында яшь кенә егет утыра иде. Аннан сорады:

— Син баш диспетчермы?

— Куйдыгыз бит. Минем анда ни гаебем бар? — дип елмайды егет.

«Моның кулыннан эш килүе ихтимал».

— Исемеңне онытып җибәрдем.

— Валерий.

— Кичәге Валерий түгелме?

— Түгел шул. Фамилиям бүтән — Малков.

— Яле, карыйк, Малков.— Агарков тагын укырга кереште.

Бүлектә дүрт бүлем — телетайп бүлмәсе, баш диспетчер кабинеты, диспетчерлык үзе һәм көтү залы. Залга диспетчерлыктан тәрәзә карый. Аның ачылуын көтеп, шоферлар бутала. Тәрәзә ачыла — смена башлана, ябыла — смена бетә, ачыла — тагын ябыла, тагын ачыла... Көннәр, еллар буе шулай ачылып ябылачак.

Бүлмәләргә, телетайп һәм рациядән тыш, туры элемтә — селектор челтәре куелды. Лазарев урынына хәзер үзенең малайлыктан әле генә чыккан тавышы белән Валерий Малков акыра, гүзәл тавышлы кызлар кычкыра. Үзләренә дә аһәңле сүзләр килә:

— Людмила Георгиевна! Чибәркәй, хәлең ничек?

Людмила Георгиевна кулында — ике бетон заводыннан чыгып, Якты Яр юллары буйлап агылган барча бетон. Бөтенесе аның аша уза. Бетон — Людмила Георгиевнаның башында граммына хәтле исәптә. Людмила уйлап та тормый:

— Икенче РБЗдан ыргыта алам. Ишетәсеңме, Заһретдинов? Инструментальный баш тартты. Кай төшкә синең? Ничек керергә, кай юлдан? Каршылагыз, машиналар хәзер китә. Кичкә таба үзем сугылырмын, чәчкәләр сатып ал.

Людмила җавап ишетелгәнче үк, заводка күчә:

— Виталик, синең бар бит анда. Давай, чап — алтынчы участок, литейный. Әйе. Молодец! — Инде шул арада баягы дустына кычкыра:

— Заһретдинов, Заһретдинов! Дамир! Дамирчик! Син сораган идең бит? Заявкасыз бирәбез — ал. Савыт әзерли беләсең. Синнән моны көтмәгән идем. Молодец! Пожалуйста. Эх-х, тагын кемне сөендерим икән?

Рация трубкасын куйгач та, Людмила тәрәзә төбендә торган электр чәйнеген тоташтырды: иртәнге һөҗүм җиңү белән тәгәлләнде — машиналарга заявкалар белән тәгаенләнгән бетон бүленеп бетте.

Людмила шунысын да сизә: Агарков бәйләнер җай тапмас. Юкка гына, каш астыннан карап, баш диспетчер ягына узды. Әмма озак тормыйча гына, миңен ышкымый-нитми генә ике күзе белән дә тигез караган хәлдә чыгып китте.

Ул киткәч, Людмила кәндезгелек өчен бәрәңге әрчергә кереште. Тиз арада бүлмәләргә җылы, тәмле пар күтәреләчәк.

Баш диспетчер кызларга сүз әйтми — күрмәмешкә генә салыша. Агарков хәзер иртәнге якта гына сугылып чыга. Шулай да бер көнне... көн уртасында килде керде дөбердәп. Бәрәңгене тәлинкәгә аударып кына торган чакта.

Аны күргә, баш һәм яшь диспетчерның чәчләре үрә торды — кызларның күзләренә кадалырдай карап, алалы-колалы тавыш белән ысылдады Валерий:

— Сез нәрсә монда кухня оештырдыгыз, ә? — Әйтерсең, беренче кабат күрә.

Людмила Георгиевна телдән һәм чырайдан язды. Аның ярдәмчесе булган үсмер кыз ярдәмгә килмәсә, хәл бөтенләй куркыныч иде шикелле. Ярый әле кызлар ир-аттан бик өрекми торган була. Каушаган булып, ләкин бер авазны да йотмыйча гына Агарковка үз сүзен ярып салды Галия Сабировна:

— Без бит, Игорь Дмитриевич, үзегез беләсез, диспетчерскийны бер минутка да калдырып чыга алмыйбыз. Көндез генә түгел, төнлә дә. Телефон туктаусыз чылтырый — барысы да ашыга — пожар диярсең. Пожарның чынлап та чыгуы бар, алла сакласын.

— Алайса инде һич югы бүтән бүлмәдә...— дип ысылдый бирә яшь диспетчер...

— Кайсы бүлмәне әйтәсез?

Валерий — ык-мык. Күзләре — Агарковта.

Гади кеше күләргә, я тиргәргә тиеш иде мондый чакта. Агарков исә, ничек керсә, шул хәлендә калып:

— Куй, эшлеләргә кагылма,— дип кенә куйды да янә баш диспетчер бүлмәсенә узды. Биш-ун минуттан соң чыгышлый хәтта елмайды:

— Молодцы, кызлар. Пожар чыгара күрмәгез, хәзер таш та яна.

Диспетчерлык эшенең абруе күтәрелгәч, Кама Сафарова радиодан тапшыру оештырырга килде. Иртәгесен шәһәргә радио аша баш диспетчерлыктан репортаж яңгырады. Тапшыруны Кама:

— Кызларга чынлап та сүз әйтмәле түгел. Бер минут та вакыт әрәм итмиләр. Алар бөтен Якты Яр күләмендә диспетчерлык хезмәтен оештыруның алдынгы ысулларын уйлап чыгаралар. Рәхмәт безнең кызларга!— диган сүзләр белән тәмамлады.

Кызлар күп санлы путевкаларны, талоннарны тикшерәләр. Сәгать тавышы ишетелә. Тәрәзәләргә яктылык ина. Сыек, тыныч яктылык кызларның арган, талчыккан чырайларына матурлык булып өстәлә. Ник дисәң, заявкалардагы саннар белән алынган бетон күләме тәңгәл килә...

Кичке җиде туларга егерме минут. Коридорда аяк тавышлары. Агарков түгелдер? Юк, ишек ачылып, аннан яшь кенә егет оялып кына керде.

— Исәнмесез.— Кепкасын бөтәрләп ишек төбендә тукталып калды.
— Әйдә, бала, түргә уз. Ни йомыш?
— Миңа Люда исемле кыз кирәк иде.
— Бездә Люда исемле кыз эшлимени?
— Нишләп эшләмәсен ди? Эшли.

Людмила Георгиевна егеткә кызыксынып карады да төнге ялга китәр алдыннан бераз тынычланыр өчен генә үз өстәле янына килеп утырды һәм «Аврора» сигаретын алып кабызды.

— Сиңа нәкъ менә Люда исемле кыз кирәкме?
— Әйе. Люда кирәк. Үзе.
— Сез аның белән танышмы соң?
— Таныш. Таныш дип...

Людмила Георгиевна кызыклы вәгъдә чамалап:

— Танышмы, түгелме? — дип төпченәсе итте.
— Таныш дип... Тавышы таныш.
— Сез кем соң?
— Заһретдинов!

Рәхәтләнеп, кычкырып җибәрде Людмила Георгиевна:

— Ник башта ук шулай димисең аны. Утыр, Заһретдинов, утыр, кадерлем минем! Дамирчик!
— Сез кем соң, гафу итегез.
— Мин — Люда.

Егетнең сөмсере челпәрәмә коелды да төште.

— Сез?.. Сез... Сезме Люда?
— Әйтеп торам ич.
— Әһе, алай икән.— Егет, кулындагы чәчәкләрен яшереп, әкренәкрен артка таба чигенә башлады.— Сез... сез мине гафу итегез. Сезнең тавышыгызны гел ишетә торгач, үзегезне күрәсе килгән иде... Гафу итегез.
— Чәчәкне соң, чәчәкне! — дип кычкырды Галия Сабировна.

Шулай да Заһретдинов чыгып китте. Ул чыккач, Людмила Георгиевна тәмәкесен каты-каты суырып куйды һәм шактый вакыт сүзсез йөренде. Шуннан соң гына кычкырып көлеп җибәрде:

— Менә бит ничек, Заһретдинов белән мин гел җылы итеп сөйләшә идем... Менә бит кешене ничек бутарга мөмкиннәр!

Людмила Георгиевнаның ярдәмчесе Галия офтанып әйтте:

— Сезнең тавышыгыз яшь, матур. Мөгаен, шуңа гашыйк булган инде ул.

— Очрашырга килгән. Ниләр генә уйламагандыр, нинди генә матур төсләр, буяулар белән бизәмәгәндер үземне... Тормышта да шундый булсаң икән, их-их!

— Тәмәкедә, тәмәкедә хикмәт. «Аврора» кирәк булмаган, сигара тартырга кирәк булган. Аның болыттай төтененнән башы әйләнеп, егет сразы алдына авачак иде.

— Тавышым шәп, үзем алама. Ходаем, ник мине шулай мәңге яшь итеп яратмадың икән?! Ходаем!
— Я, я, тилермә...
— У-уф! Заһретдинов! Хуш, минем яшь мәхәббәтем, хуш!

Шул сүзләр белән Георгиевна тәмәке утына үртәлеп төкеренде.

Җитмәсә, берничә көннән, Насыйбуллиннан: «Ник минем диспетчерны бозасыз? Мәхәббәтен сез кире какканга үч итеп, һуштан язганчы аракы чөмергән дә ике көн эшкә чыга алмады», дигән үкенечле шелтә дә әлекте әле.

Моңарчы төзелеш атлы Алыпның башы бер җирдә, ә кул-аяклары һәм гәүдәсе бүтән җирләрдә кыймылдап яткан икән. Ниһаять, үзгәрешләрдән укмашып, ул үз йөреше белән атлап китте. Үз каһарманын, үз

тылсымчысын көткән икән. Агарковны. Төзелеш Агарковның үзе кебек үк эшчән иргә әйләнде — җыелышларсыз, алардагы кайнар, калын тавыш күкрәүләреннән тыш. Һәм яңача күкрәргә кереште.

Тик Насыйбуллинның баш өстендә — айбалта — Агарков кабинетында министр белән очрашу... Насыйбуллин нәрсә хакынадыр үз башын корбан итәргә тәвәккәлләде. Йөз мөмкинлектән бер мөмкинлек— җиңү! Әнә шуның хакына! Куркыныч күцелне сәер чымырдата — йөрәктә ләззәтле сулкылдау... Якты Яр җиренең тагын бер кат асты өскә килде шикелле. Мәгәр монысы инде бик күпләр күзенә күренми торган хәрәкәт иде. Шәһәр белән бергә Фәез дә туктаусыз үзгәрешләр кичерә бугай. Үзгәрешсез нәрсә генә калды икән? Мәхәббәт? Юктыр, анысы хәзер бөтенләй юкка чыкты — шау-шу, ыгы-зыгы, шатырдау, дөбердәү, чыелдау аны мәңгелеккә күмеп ташлагандыр, мөгаен...



### Икенче бүлек

Экскаватор саескандай көн саен җир чукый. Чукмарлы борыны җиргә батып керә дә яңадан калка. Саескан-пәһлеван көнозын, бертуктаусыз балчык ташый — балчыкны үз янына чиратлашып килә торган автомашина әрҗәләренә муенын суза-суза, талпына-талпына коя. Әрҗәләр тулуга, гайрәт чәчә-чәчә, машиналар үз юллары белән китә тора, бушаган урынга бүтәннәре килеп баса.

Көн саен шулай, сәгать саен. Җәен дә, кышын да һәм... бураннар, яшенле яңгырлар да бу хәрәкәт-шөгыльләрне туктата алмый. Чүмечбашның уйнак талпынуы сменалар алмашканда гына һәм бик тә каранғы төшкәндә генә күренми тора.

Менә бүген дә, гайрәтле муены читкәрәк сузылып, башы әрҗә өстендә бераз чайкалгач, кинәт авызы ачылгандай булды да, авырлык артканнан автомашина сыгылып, ыңгырашып куйды һәм, житте дигәндәй, шул рәвешле канәгатьлек сиздереп, аннары төтен йомгаклары чыгарып төчкерә-төчкерә, олы юлга таба үрмәләде.

Чиратта машиналар беткән иде. Экскаватор, чүмеч башын кызыл яр күкрәгенә салып, беразга оеп калды. Шул рәвеш белән ул кешеләргә дә черем итеп алырга мөмкин дигәнне аңлата иде.

Өлкән машинист двигательне сүндерде дә сусыз күлнең тапталулардан такырайган саргылт мәйданына таба атлады. Барышлый бераз үзенә охшаган урта яшьләрдәге ялгыз имән төбендә тукталды.

Бу төштән караганда, Кама үзенең барча матурлыклары белән күз күремена сыеп, җәйрәп ята. Кулыңны каш өстенә куй да түбәнгә кара: зәп-зәңгәр, яп-якты дәрья, болын-әрәмәләре белән бергә синең аяк астында боргалана. Уңда офык белән ара якынрак. Анда каралҗым чаршауга сирпелгән сыек зәңгәрлек аша, яшькелтем бизәкләр инде күзгә күренер-күренмәс хәлдәге мәхәббәт хәбәрләрен сиздерә. Шундый төсләрне аралый-аралый, бире якка олы юл килә — Минзәлә юлы.

Машинист, барган җиреннән бераз каерылып, юлга табарак атлады. Бераз баргач, калкурак төшкә утырып, аякларын сузды. Аның тирәсендә төсләр тагын әйлән-бәйлән уйнарга кереште.

Барча төсләр күзне иркәли. Шундый ул — Минзәлә юлы, юри купшыланып, күңелне алгысындыра — үткән бәхетләргә чакыра. Бераз гына арырак атласаң, көрәнсу-кара сызыкларны офыкка терәп кышка калдырган һәм җәйгә тоташтырган басуларга барып чыгачаксың. Төсләр сыекланувы, яңалары хасил булуы — яшелле-сарылы дулкыннар чабышуы... Барысы, барысы олы юлның аргы очында — якын, бик тә якында гына. Шуннан ары — туган йорт, жил капкалар, каен-имәннәр, шомырт һәм сәрби куаклары. Күк зәңгәрлеге белән кушылырга ашыккан тыныч, туры төтен...

Тәсләр җемелдәп җилсендергән күзләреннән тирле сагышны сыпырып төшерде машинист. Торып басты да, майланып беткән бушлатын җилкәсенә салып, бер бармагы белән генә элгеченнән тоткан хәлдә кирегә, бүгенге көненә таба китте — тирән чокыр ягына. Аннан ары — Иске шәһәр. Шунда ук яңа йортлар. Бу якларга илнең әллә кайсы төбәкләреннән килгән сан-исәпсез кешеләр арасында Фарук исемле машинист яши. Аның бүгенге тормышы менә шушы гыйфрит мисалындагы зур экскаваторга һәм иске каладагы яңа йортларга шулай ук күзгә күренмәслек җепләр белән бәйләнгән бугай. Ул үзенең, узганнарын калдырып, ничек тиз арада күченүен сизми дә калды һәм хәзер дә аңлап бетерми әле. Әйттеләр, кирәк диделәр, һәм ул китте. Сәбәпләрне тикшереп торуның кирәген күрмәде Фарук — экскаваторга утырды да менә шушы төбәккә — Коры елга дигән мәйданга, ким дигәндә егерме метр чамасы тирәнлектәге тигезлеккә, коры елга төбенә юл тотты.

Икенче яклап шушындый ук сусыз елга сузыла. Ике елга кушылган төштә — тигез үзән. Фарук, шул үзәнгә карап, нәрсәнедер аңларга, күреп төшенергә тырыша. Монда инде дистәләрчә, йөзләрчә корылма — агачтан һәм тимердән. Үзе бер шәһәр диярсең. Нәрсәнең ни икәнен чамалау һич тә җайлы түгел.

Участок алачыгы янында Фарукныкы кебек үк ике экскаватор басып тора. Шунда ук — идарә башлыгы, Аркадий Иванович Тимофеев белән трест управляющие урынбасары Хәмитов. Тәмәке кабызгач та Фарук алардан: заводка да, гидростанциягә дә әверелмәячәк урында шушы хәтле авыл барлыкка килүнең сәбәбен сорады.

— Кызык кеше булып каласың син, Сәхәбин,— диде Хәмитов гаҗәпсенеп.— Үзең эшләгән эшнең мәгънәсен дә белмисеңме?

— Белсәм сорамас идем бит.

— Менә, Фарук туган, бу төшләргә без дамба өябез. Син җибәргән балчыктан, дип бел. Дамбалар өстенә җылылык торбалары сузылып ятачак. Теге калку төшне күрәсеңме? Чокырлар арасында... Син җибәргән балчык...

— Тауны икенче урынга күчерәбез булып чыга.

— Менә шул, син — тау күчерүче баһадир.

— Үзем дә шул тау сыман җиргә береккән идем дә, күчелде бит...

— Торба салучылар безнең дамбаларга килделәр дә инде. Заводлар, йөзләгән яңа йортлар файдалануга тапшырыла. Аларга җылы кирәк.

— Алай. Менә белдем — җылы кирәк.

Фарук шул сүз белән такта ашханәгә ашыгып керде дә шулай ук ашыгыч капкалап, яңадан үз урынына менеп китте. Экскаватор чүмеченең сирәк, әмма каты тешләрен кызыл яр балчыгына батыргач, үзле балчыкның әчкелт тәмен үзенең каты кысылудан авырткан теш төпләре белән тойды. «Кешеләргә җылы кирәк».

Шул көннән алып, Фарукның ямансу күзләре Минзәлә юлына сирәгрәк карый башлады. Чүмеч тешләре табылган мәгънәне көннән-көн күбрәк казып чыгара һәм экскаватор үзе дә акыллырак була бара кебек иде. Акылы арта барган машинаны үзеннән соң эшли торган Павел Васильевич Агафоновка тапшырганда, Сәхәбин арган, талчыккан, әмма чиксез бәхетле хәлдә, дустының кулын кыса һәм машина белән алда тулы бер смена эшләячәк кешегә чак кына көнләшебрәк карап тора. Ләкин, Павелның иртәгә Фарукның үзенә дә шулай кызыгыбрак караячагын белгәнгә күрә, тынычланып өенә тыраклый.

Машина көйсезләнеп куйса да, кәефләре кырылмый. Андый чакта, икесе бергә калып, теге яки бу ватык детальне бергә эзләп, бергә



*Виктор Аршинов рәсеме*

табалар, бергә төзәтәләр. Күз тимәсен, машина бераз гына ютәлләп тора да хуҗаларга тимер тавышы белән рәхмәт әйтә-әйтә, калтырамаска тырышып, каз аякларына охшаш тәпиләрен җиргә тери, янә муенын суза, янә башын дөп итеп җиргә бәрә дә янә тешләрен каты, кызыл балчыкка батыра.

Соңгы көннәрдә, кала урамнарының баш идарәдән ерак булмаган күргәзмәсендә Фарук Сабирович Сәхәбин белән Павел Васильевич Агафоновның рәсемнәре узган-барганнарга җитди карап торыр биеклеккә менеп кунаклады. Коры елга да үзгәрде — бөтенләй бүтән кыяфәткә керде. Аның төбен бульдозерлар сөзә-сөзә, аннары мең машина юл уңаеннан таптый-таптый тигезләгәч, дамбалар өстендә эченнән тегенди-мондый гына автомобильләр эһ тә итмичә гөжелдәп узып китмәле илаһи юан торбалар аунап ята башлады.

Яз якынлаша — яңгырлар ешая, җәяү йөрүләр кыенлаша. Экскаватор кабинасына исән генә узып үрмәләр өчен кунычы бот төбенә җитмәле итекләр сатып алырга туры килде. Коры елгадан өскә менеп утыз-кырык метрлы җирне узган арада дөньяның бәйрәм белән алыштыргысыз яңалыклары тоныклана төшсә дә, өстәге бушлатка сибелгән тыныч тамчылар алда матур тойгыларның күплеген, якты көннәрнең шулай ук бихисап икәнлеген аңлаталар — шыбыр-шыбыр, шыбыр-шыбыр...

Кабина түбәсеннән үтмиме су, үтми — шул җитеп арткан. Машиналар, балчыктан туймыйча, әле дә килә аламы, ала — җан тыныч. Экскаваторның ак тешләре кызыл балчыкны кимерә һәм чүмеч саранланмыйча машиналар өстенә каплана тора. Моторлар тигез гөрли, яңгыр җепләре чаршауга охшап китә дә аның артыннан әлҗе-мөлҗе генә янә яшь тормыш төсмерләнә. Күз алдында — ындыр. Яп-якты кояшлы көздә, Фарук дигән шул малай, көрәк белән бәрәңге җире казый. Әнисе, сеңелләре, энеләре ак чың тараткан чиләкләргә ишелеп уңган бәрәңгене тутыра. Чиләкләр тулган саен, бәрәңгене, бер тирәгә илтеп, кибә төшсенгә, таратыбрак салалар. Кечкә табан исә капчыклар белән аны өйгә ташып, базга коялар. Әнисе көянтә-чиләк аскан, ә улы Фарук, аркасына капчык салган да бакча сукмакларыннан ашыгыпмы ашыга. Фарук бәлки ашыкмас та иде, тик эре бәрәңге арканы каклый, тизрәк капчыкны ыргытасы килә. Шулай да юри сөйләр өчен генә дә ямьсез бер күз дә хәтердә калмаган. Ә яз хакында әйтәсе дә түгел. Хатирәләре белән дә, бүгенге көннәре белән дә Фарукның бөтен гомере гел шатлык-куанычлардан гына гыйбарәт диярсең.

Дөрес, дөрес, дөрес дип, экскаватор чүмече гөрселди бирә һәм, балчыкны алагаем тутырып, түзем генә көткән самосвал әрҗәсенә сузыла.

Хатирәләргә күренмәс төтен бөркеп, казылудан кызыл төскә кергән киңлек уртасына соры машина үрмәләп чыкты. Тиз арада тукталып, аннан бер кеше төште. Үз теләге белән шушындый пычрак далага килеп чыгучы кем булыр икән?

Кеше, үләнлерәк, карлы-бозлырак урыннарны сайлый-сайлый гына, тәки якынлашты һәм, Фарукны үз янына чакырып, кул изәде. Фарук рычаглардан кулын алды да кабинадан чыкты. Фарукның арматура тимеренә охшашлы кытыршы бармакларында җан әсәре бармы-юкмы икәнне ачыкларга теләптер, Насыйбуллин каты итеп аның куын кысты. Хуҗа сүз юктан сүз булсын өченгә генә гадәти сораудан башлады:

— Оясыннан эт чыкмас көнне... Шушы пычрак дөньяда батмыйча, курыкмыйча йөрибез диген, ә?

— Йөрми хәлең дә юк — күрәсе, беләсе килә бит адәм баласының.

— Безнең инде монда әллә ни белем алмассың, Фәез Сәлимович.

— Беләсе килгәнем шул, Фарук Сабирович.— Фәез, утырасы килгәндәй, түмгәкне тотып караган иде — юеш. Баскан көе дәвам итте.— Тәңгелеккә машиналарны кайда калдырасыз?

— Кайда дип... Шунда инде, Коры елга төбендә.
— Шулайдыр дигән идем аны.
— Ник? Ярамыймыни?
— Ярамый, һич тә. Бүгеннән башлап, алай эшләмәскә тырышыгыз. Килештекме?

Моның сәбәбен тикшереп тору, нишләптер, Фарукның башына да килмәде, начальник кеше белми сөйләмәс дигән уй белән ризалык бирде:

— Ярый соң. Шулай тиеш икән рас, шулай эшләрбез.

— Напарнигыңа да, участок начальнигына да әйт. Коры елга төбендә бернинди техника тотмасыннар. Булдымы?

— Колакларына киртеп куярмын.

Дусларча елмаешу, кул кысышу. Шуннан соң Фарук тиз үк кабинасына үрмәләде.

Кирәк икән рас, шулай эшләрбез!— дип кул болгады да яңадан эшенә тотынды.

Фарук, әлбәттә, Фәезнең юл уңаеннан биреп киткән боерыгын участок башлыгына да, Павел дустына да җиткерде. Мәгәр начальник шаярыбрак, әмма һавалы рәвештә:

— Ул монда кабат тикшерергә килгәндә, без инде башка җирләр айкый башлаган булырбыз,— дип кул селтәде.

Ә Павел исә:

— Ничек кушсалар, шулай эшләрбез,— дип, икеле-микеле җавап белән канәгатьләнде.

Шулай да Фарук кичке сменада эшләгән көннәрдә экскаваторны елга төбенә төшермичә, кайчандыр ашлык сугулардан калган ярым җимерек бөркәү астында калдыра торган булды. Авылда машиналар кыш килгәнне шулай тыныч кына көтәләр иде бит. экскаваторны да кисәкләп ташымаслар әле. Мәгәр участок башлыгы моны башбаштаклык дип, экипаж башлыгы булган Фарук Сәхәбин битенә кәгазьгә язылмый торган ике-өч сүзне ыргыткалый торды. Фарукның эшлим дигән эшеннән экскаватор белән дә каерып, куптарып булмый торган кеше икәнлеген ул электән үк белә иде, хәзер инде ныклап инанды. «Була бит шундый да кире беткән бәндәләр!»

Беркөнне Фарук таң белән йокыдан бер дә юкка борчылып уянды. Күңелендә әллә нинди тынгысыз бөҗәкләр сикергәли, тешләшә сыман... Чак кына уйланып, тыңлап яткач, бер дә юкка түгеллеген аңлап алды. Сәбәп бар икән. Сәбәп — тәрәзә артында гына. Җил, яңгыр. Чиләкләп коя. Хәер, моның галәмәтләре кичтән үк сизелгән иде бит.

Юынуы — юыну, ашавы ашау булмады. Бичәсенең гаҗәпләнүенә һәм ай-вайларына колак салмастан, Павелга чапты. Пардаш дусты йоклый иде әле. Пычрак итекләрен күтәрмә төбенә ыргыткач, Фарук түргә атлады. Дустын яңакларына суккалап уятты. Аларган күзләрен ачкалый-йомгалый, тегесе сикереп торды.

— Ни бар? Котырдыңмы әллә?!
— Син машинаны чокырда калдырдыңмы?
— Нәрсә булган?
— Чокырда калдырдыңмы, бөркәү астындамы?
— Барыбер түгелме сиңа?!
— Аста, елга төбендә калдыргансың. Шулай бит?
— Калдырса? Менә инде, дөнья беткән диярсең. Шуның өчен минем тәмле төшемнән аердың. Кара син, коты очкан!

«Дөрес сукалый түгелме дус кеше? Ник шул хәтле күтәрелеп бәрелергә? Дөньяда яңгыр яумый торамы соң?»

Ләкин оялуын яшерү җае буларак, шул ук ашыгычлык белән тәрәзәгә баш какты:

— Соң әллә син чукракмы? Ишетмисеңме?

— Нәрсә ишетергә?

— Яңгыр коя.

— Коя бирсен. Ялкауга — ял. Өенә кайт та яңадан җылы түшәгенә чум. Хатының хакына дәрман җый, файдалы гамәлгә яраклы бул.

— Башыңны җүләрлеккә саласың ла...

Тиргәшә башлаудан куркып, Фарук тыйлыкты. Бит-күзләрен угалагач, хәлне ачыклап бетерү ягын карады:

— Әйдә, тор. Барып карыйк. Ишетәсеңме?

— Юк, мин чукрак. Үзең әйттең — бик дөрес.

— Мин чынлап сөйләшәм, Павлик.

— Ә мин шаярудан узарлык сәбәп күрмим. Мин начальник кушканча эшләдем, кирәк тапса, ул каушасын синең белән бергәләп.

— Ну, ярый, йокла. Мәгәр тиз арада күзләрең ачылыр да күргәнеңә ышанмый торырсың, тик соң булыр.

Павел тагын нидер әйтеп көлсә дә, Фарукның инде колаклары андый өннәр өчен саңгырау иде. Ах-ух килеп итекләрен элде дә куәтен киметергә һич исәп тотмаган җилле яңгыр эченә чумды. Кая барганын төшенеп җитмәстән, бер машинадан икенчесенә күчеп, аннары, йорттүбәсез яланда нинди дә булса машина күренүгә өметен җуйгач, лаплоп атлап, соры бушлыкны яра-яра бер ялгызы атлады. Пенсионер яшендәге карт шикелле, вакыт-вакыт йөрәген уып торырга мәҗбүр булды. Аннары, ниһаять, Коры елга ярына җитеп, түбән караса... Үз күзләренә үзе ышана алмады. Ул, хәлен тәмам җуеп, лычкылдап торган пычрак җиргә утырды. Тиз үк аягүрә басты һәм тагын аска күз атты. Коры елганы бөтенләй танырлык түгел, коры елга, чын дәрьяга әверелгән дә, үзенең көчен агымсу шаулары белән исбатлый һәм бәйрәм итеп ята иде. «Әйе, мин юк булып, кибеп яшәдем, гомер буе сусыйм, тик минем дә була менә шушындый тантана кылган чакларым! Менә күрегез, мин дә елга! Мин дә бәхетле була алам! Ә сез ниләр генә сөйләми идегез?! Имеш, юк мин, беткәнмен. Ләкин хәзер елга мин, алкын сулы елга! Моннан соң кимсетсәгез дә, исем китми, тынлыкны сабыр гына кичерү өчен тагын кибәрмен, әмма горур булырмын!»

Коры елганың сап-сары куәте үз эчендәге барлык тимер-томыр, таш-түмәрләр белән бергә барлык корылма һәм машиналарны күмгән. «Коткарыгыз, йолып алыгыз!»— дигән сыман, краннар һәм экскаваторларның уклары күтәрелгән куллардай тырпаеп тора...

Арлы-бирле йөренсә дә, суга төшкән тавык кебек күшегүдән башка берни дә кыла алмыйча, Фарук бөркәүгә әйләнеп килде. Үз машинасын шунда итеп күз алдына китерергә тырышты. Ләкин барны юк итәргә мөмкин, ә юкны бар итә алмый теләк. Язмышка буйсынып кул күтәргән машиналарның берсе — аныкы...

Бөркәү астында әз-мәз ышык, тыныч сыман. Әмма Фарук өчен түгел. Аның өчен юешлек, көчсезлек, мәгънәсез теләкләр баскан җир өстен. Бөркәү астыннан тавышсыз шом төсле үтәли җил сөяк эчендәге җилекләрне өтеп ала.

Кайчандыр кап-кара туфрак булган, хәзер исә соп-соры пычрак — таш, тимер, бетон, балчык буталып изгәләнгән мең күлдәмәле юл белән озак, бик озак атлады Фарук иптәш. Гомерлеккә сузылган кебек ялыктыргыч сәфәр бетмәс, каладагы җылы өйгә кайтып җитү мөмкин булмас сыман иде. Мәгәр ул атлавын белде. Атлый торгач, кайтып та җитте.

Өй ишеген ачып җибәрүгә мәктәбеннән кайтып өлгергән кече кызы: «Әләй, әтием, нишләдең?!»— дип чарылдаса да, күшеккән Фарук мондый гына хафа сигналларына җавап биреп вакланмады. Гадәттәгечә:

— Ярый, кызым, әйбәт булган. Инде сабакларыңны кара,— дип кенә куя алды һәм, көч-хәл белән чишенгәч, юынгандай итте. Кухня ягына чыгып, бер йомыры аракы тондыргач, йокы бүлмәсенә керде, аннан-моннан урын җәеп, түшәккә баганадай ауды. Павлик дөресен әйткән ләбаса, шайтан алгыры. Йөрүен йөрсә, йөгерүен йөгерсә дә, Фарук беркемгә, хәтта үзенә, вөҗданына да игелек күрсәтә алмады. Акыл кермәс ахрысы сиңа, Фарук дус, керә алмас. Бәс шулай икән, дөньяда рәхәт тә күрә алмассың. Соңгы елларың шуны күрсәтә. Алама баш аякларга маза бирми. Куәтеңнән килә алса, акыллырак булу ягын кара. Килә алмаса, ялкаулана калсаң да ярый. Ялкауның бәхете йокламый, диләр, хак булса.

Хәмер хикмәтеннәнме, акыл ярдәм иттеме, Фарук бик үк азапланмыйча йоклап та китте. Ләкин йоклау беләнмени — ләззәт урынына соп-соры һәм эсселе-суыклы төшләр белән интеккәч. Бөтен дөнья соры, хәтта төштә дә... Коры елга таша, хәтта төштә дә. Сары елга машина астына керә дә изелә, изелә дә җан бирә алмыйча чупырдарга, буталырга керешә. Аның белән бергә Фарук үзе борсалана. Экскаватор чылбыры астыннан ычкынырга, шул мәлдә сары дәрья баткаклыгыннан да котылырга, йөзеп чыгарга азаплана-азаплана хәлдән тая Фарук, мескен, һәм, тыны-көне бетеп, уянып китә. Янә йокыга тала. Сары төс һәм төссез мәгънәсезлекләр белән көрәшә-көрәшә булса да, шулай да төнгә хәтле йокланылган иде. Бичәсе дөбердәп кайткач һәм бүлмәгә кыштырдап кергәч, тиз үк күзләрен ачты.

Хатын берни белми һәм шуның белән бәхетле иде. Явым аркасында эшкә бармыйча ял иткән дип, иренә көнләшкәндәйрәк сүзләр әйткәләде, хәтта иренең битен, күзләрен сыйпады:

— Молодис да инде үзең, яши беләсең.

— Синең анда... тәртиптер бит?

— Тәртип. Үз урынында. Арылды гына. Җыелышлар тия теңкәгә.

— Ә минем экскаватор су астында калган.

— Экскаватор? Ничек алай?

— Пашка — дивана, коры елга төбендә калдырып киткән дә...

— Пашканы итәрсең дивана.— Шул сүзләрдән ире кинәт сикереп торгач, хатын, нидер аңлагандай, аны тынычландырырга тырышты.— Соң, син дә күтәрелеп бәрелмә, шул хәтле тимер өемен агызып китмәгәндер әле.

— Китмәгән дип...

— Дөнья бетмәгән ул хәтле. Бер авызыгыз пешкәч, өреп кабарсыз икенче.

Фарук бераз тынычланды. Әгәр иртә таңда бу хәбәрне хатыны белән бергә ишетсә, соңра бергә күрсәләр, бәлки талчыгу-бәргәләнүләрнең әсәре дә булмаган булыр иде. Ирләр көчле, әлбәттә, мәгәр тылында рәтле хатын-кыз торса гына көчле ул...

Икенче көнне яңгыр туктагач, Павел эшкә, Фарук дустын алыштырмак булып барса, Фарук алай ук тиле түгеллекне ул бик тиз төшенгән. Нишләргә дип, төшлектә инде үзе Фарукка киңәшкә килгән.

— Тыныч кына кайтып, түшәгеңә чум,— диде аңа Фарук, елмаерга тырышып.

— Начальство күзләрне тиз ачтырмасмы соң?

— Ачарсың да карарсың.

— Мастер да, Хәмитов та җөпләмәгән иде бит үзеңне. Ә син алдагын алардан шәбрәк күргәнсең булып чыкты.

— Мин түгел, Насыйбуллин күргән иде моны. Узып барышлый күзе төшкән. Ә без әйткәнне дә эшли белмәдек.

— Шуңа күрә управляющий итмиләр бит безне.

— Бер машинага баш була белсәк, җитеп арткан.

Су кимегәч, дүртенчеме, бишенчеме көнне, берничә кешелек махсус ярдәмче звено оештырып, балчык астына муеннан күмелгән машиналарны казып, Фәез Насыйбуллин күрсәткән урынга, бөркәү эргәсенә өстерәтеп чыгардылар. Аннары тагын берничә көн машиналарны чистартып, ремонтлап узды. Яңгыр койган, коры елга котырган көннәрдәгедән дә ныграк пычрандылар кешеләр — ләмгә, балчыкка, суга батып беттеләр. Шуңарга өстәмә рәвештә тагын бер төрле ләм чәпәлде Фарук Сабирович Сәхәбинга һәм аның пардашы Павел Сидорович Агафоновка — машиналарны кушылган урынга, ягъни бөркәүлеккә куймаганнары һәм шуның аркасында производство эшен ун көнгә туктатып торганнары өчен бик каты кисәтергә дигән приказ чыкты. Приказ язуы пыялалы рам эчендә — яңгыр да тиз генә юып төшерә алмас.

Тоткарлыктан соң беренче көнне үк смена вакытында Павел:

— Син приказны күрдеңме? — дип сорагач, Фарук кул гына селтәде:

— Чукынсыннар ла.— Һәм стартерга басты. Павел, хушлашканда кул болгап куйгач, җай гына атлап китте.

Яңадан яңгыр яварга кереште. Ашыгычлык белән диярсең, болытлар күкнең соңгы кыйпылчыкларынача яңадан томалап, ялыктыргыч көйгә эреле-ваклы салкын тамчыларны сибә, чәчә, түгә тордылар. Әле генә ләмнән, чүп-чардан арындырылган коры елга түбәнлеге яңадан баткакка, аннары янә, агымсуга, елгага әйләнергә азаплана башлады. Идарәдә яңа приказ чыкты: Коры елганың эш барган мәйданына югарыдан аккан су төшеп җыйналмасын өчен өскерәк урында буа ясап куярга һәм шул рәвешле уңай эш шартлары тудырырга.

«Эшне нәкъ менә шуннан башларга кирәк тә иде,— дип уйлады Сәхәбин, эштән кайтышлый участокка сугылган бер көнендә.— Әгәр монысы да ялгыш булып чыкса, кемгә шелтә эләгер икән? Ләкин идарә башлыгына да, управляющий урынбасарына да булмаячак».

Мәйданда — хезмәт шавы һич тынып тормый. Торбаларны сала башларга вакыт. Хәер, куәтле яңгырлар аркасында, төзек чокырлар тигезләнеп, бөтенесен яңадан казырга туры килде. Нишлисең, табигать белән алышу, су белән көрәшү — уен түгел ул. Озакламыйча, эш утка... ябыштыр электр көче белән һәм акрын-акрын ары уз. Җылылык трассасы дигәннәре шулай ялгана башлады. Әлбәттә, бу гыйфритләр масштабындагы хезмәтне башкару кешене дә шул масштабларга якынайтырга тырыша. Гәүдәсен булмаса, җанын зурайта.

Фарук бер көнне югарыдан караса, коры елгаларның икесе берьюлы элекке еллардагы саф Агыйдел шикелле булып, ялтырап ята. Чиста күк зәңгәрлеген үзенә сыйдырган да балкыпмы балкый адәм кулы иҗат иткән гүзәллек. Тик акыллы кулларммы? Шул хакта гына уйлый төшәсе, ачыклап бетерәсе калган, мөгаен.

Фарук буа янына килде. Су норма итеп куелган билгегә җиткән инде. Төп-төгәл шул биеклеккә менгән. Икенче елга ярына барып бакты — анда да шул ук хәл. Манзара Фарукның кәефен җимерде. Мөгаен, мәкерле гүзәллек бу. Аңа чак кына яңгыр өстәлсә... ни белән бетәсен чамалау мөмкин бугай.

Аста — мәйдан, төзелеш кыры. Салынган һәм салынырга чират көтеп яткан, атлы арба сыймалы торбалар, дистәләрчә машиналар һәм кешеләр. Өстән афәт булып шарламалар кайчан ыргылачагын каян беләсең? Бәлки ул зур җиңүләр, тантаналар хакында, бәлки шуннан

һич ким булмаган башка тойгылар хакында киләчәк очрашулар, узган бәхетләр һәм бүтән төр гүзәллекләр хакында уйланган меңнәрчә баш һәм йөрәкләрнең механизмнар гөрелтесенә әйләнеп шаулаган иң илаһи вакытларында ташланыр? Түгелгән көч, вакыт, акча һәм материаллар кыйммәте... Шуларның бөтенесен сары су йотса? Җан няләрен акырта-акырта, бума елан шикелле йотса?

Фарук калтыранып куйды — тәне буйлата күзгә күренми торган эсселе-суыклы бөҗәкләр тырмашып узды. Бәхеткә каршы, әле смена башланырга ярты сәгать чамасы вакыт бар. Шул арада берәр эш кылып булмасмы.

Фарук эш урынына чапты. Тиз арада кабинага менде. Двигательне кабызды да, үзенә кушылган эшне калдырып, елга ярларына таба юл тотты.

Фарук хәтерли: моннан өч-дүрт йөз метр югары күтәрелгәч, бөтенләй икенче якка таба сузылган тагын бер коры елга бар. Шул төштә боларыннан аны нибары йөз, йөз илле метр гына җир аерып тора. Берниндн уйсыз диярлек, Фарук такта кисәге табып, шоферлар өчен: «Погрузка производится несколько выше по оврагу» дигән язу калдырды да утрау сыман җиргә килде һәм экскаватор чүмечен туфракка батырды.

Акрынлап су ягына якынлашу нияте белән эшне сусыз чокыр ягыннан башлады. Бер-ике көн эчендә теләгенә ирешәчәгенә шикләнми, ләкин комачау гына итмәсеннәр.

Бәхеткә каршыдыр, шоферлар күп күренмәде. Килгәннәренә шушыннан алып кына төяде. Аскырак катламда ком яраклы булырга тиеш... Смена тәгәлләнгәнче, двигательгә һәм үзенә артык кызып китәргә ирек бирмәс өчен генә ялга туктый-туктый, кушылмаган чокыр казуны дәвам итте. Смена азагында ул артта калдырган кызыл балчык өемнәре ун метрдан да ким сузылмагандыр. Әгәр сүз тыңлап, көн буе Павел да казыса, иртәгә, берсекөнгә су биеклеген бер тигезлектә сакларлык канал әзер булачак.

Павел килеп җиткәндер инде һәм машинаны эзлидер...

Ләкин алай булып чыкмады. Павел килгән, экскаватор урынын да караган, әмма эзләү кадәресенә керешмәгән. Буа астындагы мәйданга төшеп, кем туры килсә, шуның белән гәп корып вакыт үткәргән. Фарук күренгәч тә күтәрелеп бәрелмәде:

— Син нишләптер анда күренмәдең,— дип кенә куйды ул.

— Әйдә әле, Павлик.

— Нәрсә бар?

— Сөйләшик әле, әйдә. Ну, үзебезнең экскаватор янына.

— Экскаваторны бит җир йоткан.

Павел шул сүз белән тәмәкесен сүндерде дә җайлап утырган төштән иренеп кенә кузгалды. Экскаватор эшләргә тиеш урынга хәтле сүзсез генә бардылар. Анда машина күренмәүгә Павлик инде гаҗәпләнү, юксыну галәмәте сиздермәде. Килеп җиткәч кенә Фарукка борылды:

— Ни уйлап чыгардың тагын?

— Тегендә кара син, Павлик, елгага.

— Шуннан?

— Отметкага кара син, буа алдындагы сызыкка. Күмелә язганмы?

— Язган.

— Тагын бераз арта төшсә?

— Су буа өстеннән ага башлаячак.

— Шулай булгач?

— Ә минем нинди катнашым бар анда?

— Соң, астагыларның хәле ничек булыр?

— Минем ни катнашым бар дим мин. Алар бит аста, алар да уй-

ларга тиешләр. Ә безнең урын коры, өч елга ташса да, селкенерлек түгел.

Фарук аптырабрак калды. Чынында шушылайрак уйлау да мөмкин ич. Ни өчен башкалар эшенә Фарук тыгылды? Барысыннан да ул акыллыракмы әллә? Аңа гына кирәкме? Уйлый төшсәң, кирәк тә түгел. Тик шулай да... шулай да...

— Шулай да, Павлик, ашыгырга кирәк. Афәт бик якын бит... ташланырга тора.

— Димәк, тревога куптарырга кирәк. Начальствога әйтергә, бүтән кешеләргә, эшчеләргә. Карасыннар. Үз хәлләрен аңларлык кына башлары бардыр.

— Анысы хак. Шулай да син теге каналны казый бир инде, яме.

— Кушылганны туктатыпмы? Яраксыз ком җибәрергә? Шуңа рәхмәт әйтерләр дисеңме?

— Әйтерләр, Павлик, әйтми булмас.

— Менә нәрсә, син минем башны катырма, яме. Минем семьям бар, аллага шөкер...

— Минем дә бар анысы... Эшләдем бит әнә... көн буе. Комы да яраклы булырга тиеш.

— Ну и дивана. Кем кушкан сиңа? Сиңа шулай тиеш. Әнә өч машина килгән дә инде. Бар, ком урынына балчык төяп кара...

— Син, димәк, бармыйсың. Ярый, алайса, синең сменаны да үзем эшлим.

Фарук чокыр төбендәге кешеләрнең тыныч кына һәм шул ук вакытта бер көй белән мавыгып эшләүләрен яр башыннан карап торды-торды да аптырабрак калды. Җилкәсен кашыды, кепкасы белән киңәш корып бакты. Менә бу кешеләр — дөньяларын онытып эшләгән бәндәләр арасында паника куптару нинди максатка туры килә? Ярый, шау-шу купты ди, кешеләр дәррәү кузгалды да ди. Ләкин шул вакыт алар нишләргә тиеш? Күрәк күтәреп җир казырга? Шулай тиештер, ләкин көрәкләргә ышаныч шул чаклы гына.

Фарук туп-туры идарәгә юл тотты.

Начальник янында кемнәрдер утыра һәм нииндидер бер мөһим нәрсә хакында сызымнарга карый-карый бәхәсләшәләр иде. Телефоннан да шундый ук кискен сүзләр килә бугай, начальник трубкага каты-каты җаваплар бирә. Нәрсә хакында сүз баруын башта белмәгәнгәме, әллә техника теленең үз белемена караганда катлаулырак булуыннанмы, әллә юкса, үз максаты, үз уйлары белән артык мәшгуль булгангамы, тыңлап-тыңлап торса да, Фарук мондагы чәнечкеле, ботаклы сүзләрдән рәтле мәгънә чыгара алмады. Бердәнбер теләк шул: начальник Фарукны күрсә һәм ник килгәнлеге белән кызыксынса иде. Әмма Фарук, күз алдында тырпаеп утырамы, юкмы — начальник өчен барыбер. Фарук дигән кеше дөньяда булмаса да, гамь тудырмас иде кебек. Шуңа күрә, сабыр гына көтте-көтте дә Фарук атакага күчмәкче итте.

— Исәнме, начальник.

— Ә-ә, Сәхәбин. Нишләп йөрү?

— Менә сменадан кайтып килеш.

— Сине анда шоферлар югалткан иде. Ком юк дип...

— Төяп җибәрдем инде. Башка урыннан.

— Яңа карьер ачтыңмы?

— Анда буаларда су актык отметкага җиткән дә...

— Җитсә ни?

— Соң, үзең беләсең ич ни буласын.

— Бар, Сәхәбин, дәвам ит, казый бир карьерыңны. Дәүләт тарафыннан тапшырылган мактаулы бурычыңны үтә. Ударник дигән даныңны ычкындырма, яулаган биеклектән төшмә. Ә калганын уйлар өчен бүтән ке-

шеләр акча ала. Белдеңме? Алар өлешенә кермә, хәтерләрен калдыруың мөмкин. Хуш, Сәхәбин.

Ык-мык итте Сәхәбин, торып баскач та шаяртмыймы дигәндәй борылып, текәлеп карады. Ләкин инде начальник аны оныткан һәм баягы кайнар бәхәсенә кайткан иде:

— Липецк заводы җибәрәме, юкмы, безнең эшебез кечкенә. Без сезне беләбез, без сездән генә сорыйбыз. Белдегезме? Безгә эш фронты житкелекле булсын. Әгәр шул хәлдә башкара алмасак, анда инде карарбыз.

Сәхәбин, бу проблеманың су басу куркынычыннан ашыгычрак дип уйламаса да, алачыкны хуҗаларына калдырудан башка җай күрмәде. Димәк, кабат барырга, анда комга килгән шоферларны Павлик янына җибәреп торырга туры килә. Башбаштаклык булса да, нишлисең. Начальникның күзләре якындагы әйберләрне генә күрә икән, Сәхәбин тагы ни кылсын?

Китешли, ашханәгә кереп, кәбестә ашы белән ипи капкалады да югарыга тыраклады. Павлик каналга китмәсә, карьердагы белдерүне тикшергәч, экскаваторга янадан үзе утырмакчы иде. Мәгәр, тау башына менеп, бераз атлагач, тиз үк күренде... Фарук казый башлаган туптуры юнәлеш белән Павлик балчык өемнәрен ишәйтеп дөберди иде.

Шулай да икенче көнне идарә алачыгында яшен яшьнәмичә кала алмады. Сәхәбин эшләгән сменада, җирнең өске катламын ачкан чакта, күпмедер машина йөксез киткәләгән, имеш, һәм хәбәр трестка житкән. Хәмитовтан шелтә алган идарә башлыгы, Фарук белән Павликны малайлар хәленә төшереп тиргәү белән генә тынычланмыйча, приказлар тактасына янә шелтә кәгазе чыгарып элдерде.

— Тәүбә, тәүбә, моннан ары үземә кушылганнан гайрегә тотынмам, янгыр түгел, таш яуса да,— дип адарынды Сәхәбин приказлар тактасы янында.

Павлик исә елмаеп аның аркасыннан гына какты:

— Артык хафалана торган кеше син, Сәхәбин. Бөтен нәрсәне шушылай күңеленә якын алсаң, озак яшәмәссең, белеп тор.

Аның каравы атна-ун көннән соң күк гөмбәзеннән яшендәй ялтырап күңелле хәбәр килде. Койды гына яңгыр — чиләклəп-чиләклəп койды. Тиешле отметкага житкән сулар, кире чигенә-чигенә, уңга таба борылып, өченче коры елга төбенә чабышырга керештеләр. Теге чакта задание үтәлеп житмәгән өчен пыр туздырып тиргәгән, шелтә элдергән идарә башлыгы яңгырга илтифат итмәгән хәлдә, егетләрне бүгенге эшләре өчен мактады. Бернинди каршы сүз әйтмичә генә тыңладылар. Уй-фикерләре, яңа канал шикеллерәк, бүтән якка гөрелдәп узып китте.

Инде шуны өстәргә кирәктер: Насыйбуллин Хәмитовтан әлеге коры елга буаларының хәлен сорашкач, һәм урынбасар ул мәсьәләнең үз инициативасы — Хәмитов инициативасы белән — өстәмә канал казу ысулы белән хәл ителгәнлеген әйткәч, управляющий чак кына гаҗәпләнеп куйды һәм планерка вакытында бүтәннәр ишетми калмаслык итеп, Хәмитовны мактады. Хәмитов, исә, тыйнаклык аркасында кызара төшеп, трест житәкчесенә игътибарлы булганы өчен рәхмәт әйтте. Менә бит алдан күрә белүнең нинди матур өстенлекләре бар! Гәрчә Айрат Бариевич бу хактагы якты фикерләрен Сәхәбингә һәм Агафоновка димәстән, һич югы идарә башлыгына да житкерергә вакыт тапмады...

Бөтен нәрсә үз чираты белән дәвам итте. Ниһаять, коры елга буйлап һәм аннары тигезлекләр аша су җыйнагыч тимер-бетон торбалар суздылар, дамба салдылар. Ноябрьның уртасында — билгеләнгән вакытта җылылык трассасы файдалануга тапшырылачак, дигән ышаныч туды.

Фарук Сәхәбин белән Павел Агафонов хакында «Алсу таңнар» дигән шәһәр газетасында мәкаләләр чыккалый торды. Теге чактагы зи-

рәклеге өчен управляющий урынбасары Хәмитов белән идарә башлыгы кабат-кабат телгә алынды. Олы бер җыелышта аларны: «Иҗади сизгерлек, чын хуҗа булу хисе күрсәттеләр», дип, хәтта Аппаков та зурлагач, Фарук белән Павлик көлешеп, бер-берсенең кулбашларына сизелерлек каты суккалап алдылар:

— Менә шулай, Агафонов!

— Дөнья бу, Сәхәбин, белеп яшә!

Шуннан соң Сәхәбин эш урынын алыштырырга булды.

*
* *

Насыйбуллин дөньяга һәм кешеләргә каушамыйча карый һәм яши башлады. Баш өстендәге айбалта читкәрәк тайпылды. Мәгәр... көтмәгән чакта һәм бөтенләй уйламаган яктан килеп, яшен сукты — ап-аяз көнне, матур бер таңда... йокыдан аны телефон чылтырап уятты. Хәмитов тавышы. Фәез тиз арада машина чакыртты. Күзләрен угалап, юынгандай итте дә, аннан-моннан капкалап, мәйданга юл тотты.

Җир өстендә — коры яз. Чыпчыклар бәйрәм итә, песнәкләр. Яңа нигезләр өстендә — шомлы тынычлык...

Котлованнар буйлап атлады Фәез. Җимерелмәс нигез буласы дигән бөтен нәрсә файдасыз тауга әйләнгән: бетон да, түгелгән акча һәм беләкләр көче дә. Гадәттә, ташны ташка орсаң, ут чыга, очкын чәчри. Ә монда башны башка бәрсәң генә чыгуы ихтимал... Бу эшкә Хәмитов җитәкчелек итте...

Хәмитовның идарә башлыгы алачыгында утырганын Насыйбуллин белә. Анда кереп, барысын бергә туздырып чыгарга мөмкин. Әмма Насыйбуллин алай эшләмәскә булды. Насыйбуллин тыныч кына гөрелдәп утырган автомобиленә яңадан утырды да үз кабинетына кайтып керде. Хәмитовны һәм идарә башлыгын шунда чакыртты. Хәмитовның чырайенда үзгәреш бар, әлбәттә, ләкин артык каушау сизелми иде.

— Рәхмәт, сөендердегез,— диде Насыйбуллин шатлык галәмәтләре сиздергән рәвештә.— Бу сезгә бик хас.

— Шулай булып чыкты, нишләтәсең — кышкы эш, суык... Заказчы кабул итмәде,— дип, Хәмитов сүзне тыныч җыпкыга төшерергә тырышкандай итте. Шулай ул идарә башлыгының хәлен җиңеләйтә, янәсе, үзенекен түгел...

— Күрсәтергә оятыгыз җиттеме?

— Аңламыйм, нишләп әле миңа карыйсың?

— Аңлыйсың. Давылдан күз йомып котылмакчы буласың.

— Ә мин причем?! Идарә бар, кыш, суык...

— Алай... Ходайны эшеннән алырга туры килә һәм тагын кайберәүләрне. Җылырак урын сайлау мөмкинлеге килеп чыкты.

— Монысын янау дип кабул итикме?

— Тәкъдим дип.

— Кемгә нинди тәкъдим булыр әле, карарбыз.

Насыйбуллин сискәнеп китте. Колакларына ышанмыйча, кабатлап сорарга мәҗбүр булды:

— Нәрсә дидең?

— Ишеткәнеңне.

«Килеп җиттек. Мин белеп җиткермәгән нидер бар монда. Ачыкларга кирәк, тикшерә, уйлана төшәргә».

Шул фикер белән үзен тынычландырып, Фәез дусларча тавыш белән урынбасарына карарын белдерде:

— Яхшы. Син сүзеңне әйттең. Ә мин җавап бирергә әзер түгел. Ярты сәгатьтән соң Глазов белән икәү керерсез. Хәзергә бетте.

Секретарь кызга: «Мин берничә минут объектларда булам»,— дигәч, ял бүлмәсенә кереп, диванга чалкан ятты...

*
* *

Фәезнең төзү-монтаж идарәсендә баш инженер булып эшләгән чагы иде. Аның бүлмәсенә күптән түгел генә производство-техника бүлегенә инженер итеп алынган яшь егет Айрат Хәмитов килеп керде. Эшли башлаганлыгына өч кенә ай чамасы үтсә дә, үз эшен тырышып үтәвәге һәм үсәчәге ачык булганга күрә, табигый рәвештә, ул мөдир вазифаларын да үтәргә кереште һәм сәләте-аңы белән ул эшкә туры килгәнлеген исбатлый алды.

Нәзек, ләкин нык гәүдәле, әйбәт мөнәсәбәттәге кешеләр өчен чибәр үк дияргә мөмкин булган егет кабинетка керде дә ишек төбендәрәк басып калды. Көндәлек мәшәкатьләр белән бәйләнгән кешеләр мөнәсәбәте өчен сәеррәк тоелды бу. Шунлыктан Фәез гаҗәпләнебрәк карап торды. Сары йөгертелгән йөзенә күркәм тыйнаклык, озынчарак төз борынына дөрес биеклек сайларга мөмкинлек биргән таман зурлыктагы кара күзләр ихтирам сирпеп карыйлар һәм нәрсәдер әйтәләр иде шикелле. Фәезнең вакыты кыска, әлбәттә, уйлап тормастан, ул:

— Уз, Айрат, эш нәрсәдә? — дип кенә куйды һәм оялып азапланган егеткә утырырга кушты.

Егет, ихтирам белән сугарылган якты караш сирпеп, тагын бераз торды һәм сүз әйтмичә генә килеп утырды.

— Нәрсә, Айрат, өйләнергә фатиха сорыйсыңмы әллә? Мин риза. Белеп тор.

— Өйләнү хакында түгел, көйләнү хакындарак иде шул сүзем.

— Соң, нәрсә комачау итә?

— Нәрсә түгел, кем.

— Конкрет әйтсәк?

— Начальник.

— Нишләп?

— Приказ юк бит һаман. Эш бар, хакы булмаса да.

— Менә хәзер аңлашылды.

Фәез телефонга тотынды:

— Валя, Николай Трофимович үзендәме? Әһә, булды, әйбәт.— Сикереп диярлек торды да ишеккә таба атлады.

Шундый ук ашыгычлык белән начальник бүлмәсенә узды, һәм, Айрат ишекне йомшак кына ябып азапланганда, ул инде начальникның кулын каты итеп кысарга һәм, алдагы урындыкка утырып, сорау ташларга да өлгергән иде:

— Бу егет белән эшне хәл итәргә кирәктер бит?

— Нинди хәл? Каян чыккан проблема? — Коровкин бу сүзләрне ашыкмыйча, тыныч кына әйтте.

Кама белән үпкәләшүе аркасындамы, Фәез ул көнне иртәдән үк кискенлеккә, ашыгуга көйләнгән иде. Начальникның тынычлыгы аны тагын да үрти төште. Фәезнең сүзләре тагынботаклы булып чыкты:

— Проблема юк, ләкин гамьсезлек тә юк димәс идем.

— Нәрсә син... Кирегә сукалыйсың?

— Бу егет ай буе бүлек мөдире эшен башкарды, ә приказ һаман бирелмәгән.

— Ә, менә нәрсә!

— Приказга кул куймагансыз.

— Анда уйлап бетерәсе бар, үлчәп бетерәсе — аранга сыямы, юкмы?

— Нәрсә үлчәргә? Нинди аран? Ул бит кеше, сыер түгел.

Николай Трофимовичны, әйтерсең, корт чакты. Фәезгә гүя уйлап бетерергә вакыт бирер өчен туп-туры итеп, җитди караш белән озак кына карап торды. Аннары аягүрә басты. Үзенә игътибар көтеп зарыккан һәм утырырга кыймаган Айрат, булачак давылны сизеп булса кирәк, аяк очларына гына баса-баса, ике арада чыгып тайды. Фәез дә кузгалды, тик бу хәлдә чыгып китәргә ярамаганын ул дөрес чамалады.

Николай Трофимович—Якты Юлга терлек симертү хуҗалыгы директоры булып эшләгән җиреннән җибәрелгән кеше. Башта төзү-монтаж идарәсендә, аннары баш идарәдә кадрлар бүлеге начальнигы булып эшләде. Читтән торып, дүрт ел эчендә төзелеш техникумын бетергәч, хәзер исә институтка керде. Дөресен әйткәндә, кемдер кушканны түгел, күңеле кушканны тыңлый иде ул. Ветеринарлык һөнәреннән тиз генә ваз кичеп, нишләп шулай тырыша-тырмаша биналар корылышына керешеп киткәндер, утыз бишкә җиткәч, системалы белем алган инженерларга бил бирмәскә тырышып, ник үҗәтләнә-үҗәтләнә яшәмәктәдер, анысын Фәез белми. Ныклап төпченсәң, Коровкин моны үзе дә тәгәл генә аңлата алмас, бары тик терлекләр хакында гына сөйләр иде, һәм сүзләре хак, чын булыр иде. Терлек симертү хуҗалыгыннан киткәненә ярты дистә ел узуга карамастан, аның теленнән һаман әле хайваннарга гына туры килә торган тәгъбирләр ычкына иде шул. Айратны «үлчәргә» керешүе дә иске гадәт дәвамы иде.

— Үзең атланасы аргамакны син дөрес сайламагансың,— диде ул җитдилекнең чын рәвешен алып.

— Начар булса да, ат үгезгә караганда яхшырак.

— Ә син, минемчә, үгезгә дә тап булмагансың, хәтта ишәккә дә түгел, ә дуңгызга! Һәм шуны аргамак булып үсәр дип уйлыйсың, Фәез Сәлимович, ничек кенә үстерсәң, ни хәтле генә симертсәң дә, чучка баласы аргамак булып җитлекми. Чучка баласы нәкъ олы дуңгызның үзе булып симерә дә, күккә бакмыйча, җир тырный-тырный ертлашуын белә. Бүтән нәрсәгә өйрәнә алмый ул. Күккә карый алмаганлыктан, һаман үз лепкәсенә күк терәлеп тора дип фараз итә. Күк биек, кояш көлә, йолдызлар җемелди дигәнгә ышанмыйча, ул һаман синең яман якларыңны, алама мәгълүматларыңны эзләп казына.

— Сезне, Николай Трофимович, аңларга тырышып карарга мөмкин. Тик бер дә конкрет фактлар сайламадыгыз бит, артык гомуми, һәм... гафу итегез... Айрат Хәмитов хакында сез нәрсә беләсез?

— Сез белгәннән күбрәк.

— Ә нишләп миннән яшерәсез?

— Аны бит сез куйдыгыз мөдир итеп. Нишләп башта тикшермәдегез? Ник хәзер генә белергә тырышасыз? Соңрак түгелме? Уйлагыз, барыгыз.

Бүлмәдән чыгып кит дигән сүз иде монысы. Шуны Фәез янә кимсетү, мыскыл диебрәк кабул итте һәм тагын усаллаша куйды:

— Мин кешеләрчә генә яши беләм. Терлек нормалары, сезнең кагыйдәләр миңа таныш түгел, гафу итегез,— дип ычкындырды һәм, начальник характеристикасын яман яктан шактый тулыландырырлык сүзләр өстәде.— Минә нәрсә, Трофимович, шуны белеп тор. Мин кешеләргә аларның ат яки сыер була аламы, дигән позициядән түгел, бүтәнрәк позициядән карыйм. Мине аларның ата-бабалары, кода-кодагыйлары кызыксындырмый. Мине бер генә нәрсә кызыксындыра — төзүчеме ул, әллә терлекчеме, менә шул!

Николай Трофимович сикерергә әзерләнгән ерткыч мисалында сак һәм тыныч торды. Үз өстенә ташланачагын, һич югы имән бармагын ишеккә төбәячәген сизгән килеш, Фәез бөтенесе белән ризалашкан тыныч кыяфәткә керде. Алай гынамы, баштагы үртәлүләре үк начальникның тәмәке төтенедәй, хәтта аңардан да тизрәк юкка чыкты. Ә тәмәке төтене Фәезнең баш өстендә бөтерелә генә башлады але...

Нәрсә уйлаганын, ни кичергәнен кем белсен, әмма Николай Трофимович, ишеккә бармак күрсәтмәде. Киресенчә, кай арада тынычланып, үз урынына утырды да приказлар папкасын актарырга кереште. Кирәкле кәгазьне табып, аны үз алдына шуыштырып, папканы исә өстәл читенә этәрде. Ике данә кәгазьгә имза салгач, стенадагы сәдәфләрнең берсенә басты һәм тиз арада кергән секретарь кызга бирде. Максатына ирешүен Фәез, әлбәттә, начальникның баягы хәрәкәтеннән үк сизгән иде. Мәгәр аңгамәгә нокта куелганын ахыргача көтте һәм Николай Трофимович тудырган имин шарттан шунда ук файдалана да белде. Торып басты да:

— Проблема чынлап та юк иде бит, ә? Сәбәпсезгә күпме каурый йолкындым,— дип куйды.— Гафу итегез.

— Сез дә гафу итегез.

Бүлмәгә кеше кыяфәтендә керсә дә, бүтән рәвештә чыгачагына ышана язган Фәез өчен бу хәл көтелмәгән яхшылык сыман тоелды. Һәм имән бармакка буйсынуга караганда үз теләгең белән чыгуның күңеллерәк икәнен тойган хәлдә, ишек ачып, аны шундый ук саклык белән япты да. Ишек төбендәге урындыкта Айрат утыра, мөгаен, баягы ямьсезлекне ишетеп торган булырга тиеш. Егет, әлбәттә, шат. Фәез чыгуга аягүрә басып, кызара-кызара елмайды:

— Рәхмәт инде, сезгә, Фәез Сәлимович, бик зур рәхмәт.

— Эшегезне көн кушканча үтәсәгез, рәхмәт шул булыр.— Шулай дип Фәез чыкты, ләкин Айрат Бариевич күз алдында тылсымлы приказлардан күз куптара алмыйча утыра калды. Мөгаен, начальникка кереп, аңа да рәхмәт әйтер. Тәртипле бала, һәрхәлдә олыраклардан әдәплерәк булып чыкты. Хәерлегә юрыйк.

Фәез үз бүлмәсенә кергәч тә берничә минут вакытын шул әйбәт теләккә багышлады. Күңелендә әллә нинди аңлаешсыз сагыш хасыйл булды. Балачак, әти-әнисе хәтергә килде дә, Коровкинны рәнҗетүе белән ул үз нәселенә хыянәт иткән сыманрак тойгы кичерде...

Ахрысы, кемдер аркага сукты... Юк, гади авырту икән. Монысы — күптәннән бирле арттан калмыйча иярә килгән бәла. Соңгы елларда ул баш миен кинәт авырттыру һәм сискәндерүдән гыйбарәт булса, элегрәк кан китү белән беткән чаклары да булгалый иде...

Фәез икенче курста укыганда, аның бер танышы, сер ачкан кебек кенә итеп, тимер юл станциясенә эшкә чакырды. Акчаның кирәклеген әйтәсе түгел. Берсүзсез ризалашты Фәез. Иртән иртүк торып, дусты артыннан иярде. Станциягә килеп җиткәч үк аны калымчылар бригадирына күрсәттеләр. Бригадир өстән генә карап:

— Сынауны узса, карарбыз, кеше кирәк безгә,— диде һәм,— әзерләгез,— дип боерды.

Аптырабрак калган Фәезгә иптәш малае исә:

— Шунсыз булмый инде, ритуал,— дип, начальник сүзен җөпләде.

Әзерләү дигәннәрен тиз тоттылар, күпмедер минуттан соң ук түгәрәк уртасына үзен генә бастырып куйдылар да:

— Без сиңа авыр-авыр сүзләр әйтербез, ә син егылмаска тырыш,— диделәр.— Аңлашылдымы?

— Ә егылсам?

— Егылсаң, дүрт ягың — кыйбла, ләкин безнең бригада барын онытасың.

Фәез, уртада ни буласын белмичә, бу хәлнең мыскыллаумы-түгелме икәнен аңларга тырышып торган мәлдә аркасына кинәтниндидер таш белән ордылар да, ул, сыны катып, күз алдында җемелдәшкән йолдызларны санарга азапланган уйсыз-тойгысыз мизгелдә, тагын шундый ук дөпелдәү... һәм шул аның сүнә язган зиһенен кире урынына кагып куйды шикелле. Фәез артка борылды. Караса... таш түгел, аяк астында нәрсәдер салынган капчык ята. Соңыннан белүенчә, иллеме, утызмы

килограмм чамасы ком тутырылган капчык икән. Шуның белән органга чыдаса гына станциядә эшли ала бәндә дигәнең.

Егетләрнең йөзләре соң дәрәҗәдә җитди икәнлеген күреп, Фәез үзен шаяртмаган, мыскылламаганнарын «ә» дигәнче төшенеп алды да тагын тиешле якка борылды һәм тагын җилкәгә баягы ком тутырылган капчык килеп бәрелде. Фәез егылмады. Бу инде сынауның тәгәлләнүен күрсәткән фал иде. Ул үзен бригада члены итеп тоя язган иде инде, ләкин, гөнаһ шомлыгы, шул мизгелдә аның борыныннан кан саркып чыкты да, ул аны кулъяулык белән капларга мәҗбүр булды. Әйе, сынауны бәхәссез уза алмады Фәез. Алыргамы, юкмы дигән әңгәмә кузгалды. Шулай да аны чакырган дусты яклашты:

— Моңарчы мондый хәлнең булганы юк иде бит. Безнең уставта юк бу хакта искәрмә,— дигәч, һәм,— кабул итмәскә безнең хакыбыз юк,— дип тә өстәгәч, бригадир:

— Ярый, эшләсен әйдә,— дип кул селтәде.

Шул рәвешле, Фәез калымчылар бригадасы члены итеп алынды һәм кала урамында иске, тишек чалбар, үкчәсе ашалып кыекланган туфлиләр киеп йөгерүдән котылып, ашау-эчү җәһәтеннән дә адәмчә яшәү мәртәбәсенә иреште. Ләкин шул вакыйгадан соң борыннан кан китү гадәте барлыкка килде һәм абайламаганда аркага әллә ничек, күренмәгән кешеләр еш кына дөп итеп ком тулы капчык белән китереп оралар шикелле иде. Дөрес, соңгы елларда бик тә сирәгәйде бу хәл. Әмма юк дигәндә дә, сирәк булса да, кабатлана килә шул. Николай Трофимович бүлмәсеннән чыгышлый, Фәез, шулай сискәнеп, кинәт артка борылды. Хәмитов та, секретарь кыз да гаҗәпсенеп куйдылар. Тик эшнең нәрсәдә икәнен аңламадылар һәм аңламаслар да. Тиз үк онытырлар. Фәез үзе, бүтән чакта моңа артык дикъкать итми торган булса да, әллә нишләп, шуны махсус диярлек уйлап йөрде.

Фәезгә укыганда ярдәм итте бу хәл: тимер юл станцияләрендә, пристаньнарда цемент, таш, тимер, агач авырлыгын кәгазьдә исәпләп кенә түгел, Фәез үз мускуллары белән тоеп белде. Соңыннан үзе үк бригадир-начальник булып үрләгәч, шкиперлар, диспетчерлар телефоннан туп-туры аның үзенә шалтырата торган булдылар. Икешәр тәүлек буе баржа бушаткан көннәрдә баш мие уку хакында хәтта оныта иде. Әйе, үз икмәген үзе табарга күнекте Фәез... цементны, ташны, агачны һәм тимерне бүтән җилкәләргә күчерү мөмкинлеген башына да китермәскә гадәтләнде...

Әрепләшкән көнне үк, эштән кайтышлый, Николай Трофимович белән туры килделәр дә, Фәезнең зиһене бик тиз төшенеп алды. Николай Трофимовичның, күрмичә узарга тырышуына караганда, рәнҗүе хак иде. Фәезнең исә күңелендә энә очы хәтле дә ачуы калмаган. Ул читкә төбәлгән карашны үзенә бик җиңел кайтара алды.

— Николай Трофимович! — Начальникның игътибарсыз кала алмавыннан файдаланып, Фәез җылы сүз әйтергә ашыкты.— Бая безнең нервлар бер дә юкка уйнап ташлады бугай. Әйдә, без аларга бик ирек бирмик, ә?

— Мин тыныч сөйләштем шикелле.

— Ләкин барыбер бик үк матур килеп чыкмады: зурайтмыйк, әйдә, мә бишне.

Бик кыска гына вакытка икеләнеп торгач, Коровкин Фәезнең ихлас елмаюына каршы тора алмыйча, үзе дә ярып китте.

— Мә соң, ун булсын.

Коридордан бергә атлап, баскычтан да бергә төштеләр. Шул рәвешле каршылык төенләнми калды, аллага шөкер, дип уйлап өлгергән иде дә... Фәез ашыга төшкән булып чыкты.

Бер атналык командировкадан кайтса, аны шул көнне Аппаковка

дәшеп алдылар. Аппаков маңгаен сыпырып куйды да вак-төяк сүздән соң туп-туры сорау куйды:

— Сезнең анда нәрсә чыкты Коровкин белән?

— Безнең анда тәртип, минемчә.

— Харап, синеңчә тәртип. Ләкин дөнья икенче төрлерәк шаулый.

— Дөнья? Дөньяны шаулатырлык эш кырган юк бит әле.

— Алда нинди генә җайсыз, авыр хәлләр килеп чыкмас. Болай булгач, сезгә ничек ышаныйк? Ә?

— Без аның белән чак кына бәхәсләшеп алдык та кул кысышып килештек. Менә сиңа ир кеше. Шуннан соң да ул жалоба белән килдеме?

— Сүз аның хакында түгел, синең хакта! Нишләп әле...

— Болай бармый, болай җитди түгел, Ислам Мөдәррисович, мин мондыйга күнекмәгән, гафу итегез. Мин андый кеше белән эшли алмыйм. Без бит кул кысышып килешкән идек!

Ислам Мөдәррисович бик кыска вакытка гына аптырабрак калды да (ул Фәез акланырга тырышыр дип уйлаган иде булса кирәк) ике кулы белән колагын каплап, урындыгының артына ук сөялеп торды һәм тыныч, ләкин шактый ук кискен рәвештә алда торган бурычларның зурлыгы хакында озак кына речь сөйләп ташлады һәм житәкче кешеләр арасында мондый мөнәсәбәткә юл куймау зарурияте белән тәгәлләде.

— Дөрес, мин дә нәкъ шулай уйладым. Каным карыша минем мондыйга, мин аның белән хәзер эшләү түгел, сөйләшә дә алмаячакмын.

— Ул хәтле кискен куймаска тырышыгыз.

— Соңгы кабат әйтүем, Ислам Мөдәррисович.

— Я ул, я син?

— Алай ук әйтмим. Шулай да...

— Ну что ж, Лазарев белән киңәшербез.

— Рәхмәт.

Ни өчен рәхмәт әйткәнен ул аңлап бетермәсә дә, сүзнең тәгәлләнүе аның өчен хәерлерәк сыман иде. Фәез хәзер эш урынына бара алмаячагын төшенеп, туп-туры баш идарәгә юл тотты. Һәм берничә көннән соң Насыйбуллин баш идарәнең баш инженеры урынбасары булып эшли башлады.

Лазарев ярдәме аркасында Коровкин белән каршылык хәерле тәгәлләнсә дә: «Нишләп әле шундый олпат кеше түбәнлеккә — доноска бара алды?» — дигән уй аның күңеленә гел килә торган булды. Хәзер генә аңлашылды: сизгерлек житмәгән Фәездә! Ул чакта шик белдергән булсаң, Коровкин: «Ак эт бәласен кара эткә якма әле»,— дияр иде...

Соң булса да, аңлау хәерле.

Берничә минуттан Насыйбуллин үз кабинетына чыкты да урындыкка утырганчы ук Глазовка гына карап:

— Безнең трестта батырлар күбәеп китте бит әле, нишләргә икән? — дип мөрәҗәгать итте.

— Дусты аю булса, куян да батырая.

— Мин дә нәкъ шуны әйтмәкче идем. Тыңлап тор, Айрат Бариевич. Эш менә болай. Әгәр синең стиль белән хәрәкәт итсәк, без, Аппаков тирәсендә бөтерелеп, пальто кидергәндә, бер тапкыр аның гаҗәп тә акыллы икәнен, икенче юлы гаять зур ихтирам белән сугарылганыбызны аңлатыр идек. Өченче тапкыр пальто кидергәндә, синең кемлегеңне әләкләп аңлатыр идек. Әйе. Синең ярдәм белән аның башында безгә карата яман фикер укмашты. Кызганыч хәл. Ләкин без сине түбәнлеккә төшә алмыйбыз. Монысы үзебез өчен мөһим. Иптәш Аппаков, иртәме-соңмы, кемнең кем икәнен чын төсендә үзе күрер, үзе төшенер, дип ышанабыз. Шулай бит, Глазов?

— Әлбәттә, шулай. Тик... болай тычкан филне җиңә килә бит.
— Бер нишләп булмый. Без тычканнарча яши белмибез.
— Ә кемдер белә, андыйларның бөтен көче — тычканлыкта.
Күзләре алара язган Хәмитов шул чак:
— Ялагай! Тырышып кал! — дип барлык ачуын Глазовка күчергән иде, Фәез дустына ярдәмгә ашыкты:
— Синнән уздыра алмый ул, курыкма.
Ләкин Хәмитовның бирешергә нияте юк иде. Зәһәрләнүен дәвам итте:
— Тырышып калыгыз. Мыскыллагыз, гәрчә вакытлыча. Без түзәбез,— дип, өстәл тактасын җиңе белән ышкыды.
— Кабатлап әйтәм, иптәш Хәмитов. Исән калган котлованнарда нигезләр салу, контрольлек итү сиңа махсус тапшырылган иде. Синең зирәк җитәкчелектә...
— Ә син? Син кайда идең?
Ачу белән әйтелгән шушы соравына җавап көтмичә, зифа гәүдәсен төп-төз тоткан хәлдә, Хәмитов чыгып та китте. Насыйбуллин исә, производство бүлеге мөдирен чакыртып, котлованнар хакында актлар төзергә һәм инстанцияләр өчен рапорт язарга кушты.
Тагын башланды йокысыз төннәр һәм саташулы төшләр.
Яудан трест управляющие Фәез Сәлимович Насыйбуллин каты шелтә белән котылса, шул хәтле бетонны туңдырганы өчен Айрат Бариевич Хәмитов исә Фәезнең телдән әйткән һәм әйтмәгән кисәтү-янауларын, өскә ябышкан кар бөртекләре сыман итеп, сыпырып кына төшерде.
Шуннан соң Насыйбуллинның бу кеше белән эшләргә нияте һич кала алмады. Аның Хәмитов белән бер түбә астында утырасы, бер коридор буйлап йөрисе, планеркаларда бәхәсләшәсе, бәлки әле бер үк кала урамнарын да таптыйсы килмәгәндер. Ләкин... бу кешенең билгеле сәбәп аркасында Фәезнең үзеннән көчлерәк икәнлеге сизелә бирде.

*
* *

Сәхәбингә иләмсез зур дип исәпләнгән экскаваторыннан да биеккә — кран кабинасына күчеп утырырга куштылар. Егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз дип, Насыйбуллин үзе үтенгәч, ялындырмый гына ризалашты Фарук. Аны Германия Демократик Республикасыннан килгән «Эберсвальд» дигән порталлы кран экипажына кабул иттеләр.
Кранны чуен кою заводы котлованына төшереп монтажладылар.
Эшкә керешергә җыенганда гына, торып торыгыз, дигән хәбәр китерделәр. Проектчылар һәм төзүчеләр ялгышы буенча тантаналы рәвештә салынган «беренче нигезләр» үзләренә тиешле урыннардан шактый ук еракка таешкан булып чыкты. Бөтенесен тагы өр-яңадан башларга кирәк... Беренчеләр урынына икенче нигезләр салырга туры килде.
Порталлы кран хата төзәтергә килешле булып, Сәхәбин унике метрлы биеклектән дөньяны тагын да киңрәк күрә башлады. Тегендә, ак балачакка чакырган Минзәлә юлы тагын да озынайды. Ә якында чылбырлы, дизельле краннар ябышкак пычракта алга бара алмыйча, боргалана-боргалана, пошкыра-пошкыра азапланалар, еш кына тончыгып куялар. Боларның эш кыен. Алар, биектәге Сәхәбингә көнләшептер, күз чөяләр. Ап-ачык кырда һәркемгә күренеп җилнеңә: чылбырлы кран бетончыларга бер бадья измә биргәнче, Фарук икене, өчне җилтерәтеп китерә. Ә бадьялары нинди диген!
Бетон булып каткан нигез тасмалары алга табан шулчаклы тиз озаеп сузылды ки, Фаруклар кранына тимер рельсларны көчкә салып өл-

герә тордылар. Аларның җитез хәрәкәтләрен рекорд дип атадылар. «Алсу таңнар» газетасы битләреннән монтажчыларның калын-калын битле йөзләре көн саен диярлек кин елмаю аша карый иде. Моңа Фарукның бик исе китми: елмайсыннар — кош — очар өчен, адәм баласы уңышлар өчен яратылган лабаса!

Ә ни дисәң дә, биектә — бәхетнең зуррагы, чөнки анда беркемгә дә аңлаешлы булып бетмәгән манзара күзләрне чагылдыра. Ул сер — Минзәлә ягы... Күпме генә көннәр үтсә дә, ерагая белми Минзәлә, якыная гына...

Таш җәеп тапталган киңлеккә озын-озын ак баганалар тезелеп ятты. Бораулап казылган тирән чокырларга шуларны күтәреп бастырырга монтажниклар килде. Һәм Сәхәбин краны, пәһлеван фил бүрәнә күтәргәндәй, ничәмә тонналы колоннаны җилтерәтеп кенә алды. Сары каскалы егетләр аңа каш чөйделәр.

Беренче багана (беренче!) башын кран биеклегеннән дә уздырырга тырышып, тураеп басты. Тимер-бетон шәм дигән багана, колоннага әйләнде — беренче колоннага. Кырлар киңлегендә чәчелеп утырачак заводның беренче терәгенә! Тигез рәтләргә тезеләчәк ишләре белән бергәләп, ул — биленә корыч кыршау буган Антей — күк гөмбәзе хәтле завод түбәсен күтәрешеп, механизмнарны гына түгел, адәм балаларын да кар-яңгырдан, төрле афәтләрдән саклап, мәңге торачак.

*
* *

Кою заводы төзелеше дә шулай колонна адымнары белән кыю атлап китте. Көннәр, атналар, айлар шул адымнар белән бара торгач, ниһаять, финиш дигән кызыл көнгә якынлашты. Колонналар, диварлар өстенә Техника дигән пәһлеван, җирдә укмашкан, чакрымнарга сузылган тоташ түбәне һавага күтәреп җәйгәч исә, төрле шау-шулардан кайнап-гөрләп торган кала бер мәлгә үзе дә тынып калгандай булды. Үзе кылган могҗизага үзе сокланып, тел шартлатты Кеше дигән пәһлеван. Ә Табигать атлы пәһлеван, эндәшмәү ысулы белән аның эшләренә ризалык белдерде.

Өч великан: Кеше, Техника, Табигать күк гөмбәзен җилкәләрендә күтәргән хәлдә, киләчәккә горур атлый бирделәр.

*
* *

Ниһаять, көннәрдән бер көнне Насыйбуллин күк гөмбәзедәй зур түбә астына кергән кою заводы түренә кунак сыман узды. Кою системасы монтаждан соң бөтенләй икенче кыяфәткә кергән иде.

Кою агрегаты алып арбасыдай олы булып күз алдына килсә, үзе бер дә коточкыч нәрсә түгел икән. Биеклегенә кул сузсаң, кул җитә, озынлыгы да дүрт метр чамасы гына. Керешли сул якта — идарә итү пульты, уңда — цилиндр рәвешле зур мич...

Булачак эшчеләр — киләчәк вәкилләре — киләчәк төзүчеләр һәм монтажчылар иҗат иткән дөньяда үзләрен чын хуҗаларча, иркен тоталар. Насыйбуллинга караучы да юк. Бөтен күзләре — Сәгыйт дигән дежур егеттә. Анысы, шартлы смена башлануга, машинаны җылытырга кереште. Үз янына килгән икенче егеткә сүз кушты:

— Яле, Вадим, карап карыйк.

Анысы — коючы егет. Ул кагылуга, мич ачылды китте. Һәм аннан тыгыз эсселек күтәрелеп, металл сулышы битләргә бәрелде. Металл үзе — алсу, утә күренмәле сыеклык... Шул буладыр алюминий. Наладчик егет, бер дә кирәкмәсә дә, төп-төзек машинаның һәр приборын күз-

дән кичерә, блокнотына нидер яза. Насыйбуллин, үз әсәренә үзе сокланган бөек рәссамдай, тын ләззәт кичерә. «Исәнме, таныш түгел буын! Сезгә хәерле сәгатьләр, тыныч еллар!»

Битләренә металл кызылы күчкән Сәгыйдулла селектордан завод директорына эндәшә:

— Николай Яковлевич, пресс-формалар кызды. Эшкә керешикме?

Ясалма тантаналыктан ычкына алмаган директор мөмкин кадәр тавышын калынайтып, салмак кына:

— Жи-бәре-гез! — дип боера.

Боерыкны дежурный наладчикка җиткерә:

— Җибәрегез!

Коючы шул ук команданы икенче төрлегә әйләндерә:

— Машинаны тикшереп чыгыгыз... Суны ачыгыз... Һава...

Наладчик, күкрәгеп кирәк дәрәҗәдә калку тотып, тиешле сәдәфкә басты. Бер дә тәэсире булмас сыман юк кына хәрәкәткә буйсынып, ямьяшел чатыр — мич түбәсе — өскәрәк күтәрелеп җаелде дә, аннары машинаның корыч корсагы киңәеп, кулына кәкре трубка тоткан наладчикка эчкәрәк керергә юл ачылды. Егет тиз арада трубкадан пресс-формаларга кысылган һава өрдерергә тотынды. Коючы телевизор выключателенә охшаш ачкычны борды. Аны тыңлап, өлешләп бүлү приборы үзенең чүмечле кулы белән тарату мичена таба ашыкмый гына сузылды, чүмечне алсу сыеклыкка батырды да, шуны алагаем чумырып алгач, иплэп кенә күтәрде, машина янына китерде һәм аның өстендәге бүрәнкәгә — пресс-агрегат стаканына агызырга тотынды. Эсселеккә түзә алмагандай дерелдәп, машина пресс-форманы шудыра, үзе, көчәнүдән диярсең, ухылдый, ахылдый. Формалар каплангач, аларга басым көче өретелә — йөз кырык атмосфера... Түбә чатыры шул көчнең ялгыш шаяруына юлны тәмам бикләр өчен төшеп мич өстен томалый. Кызыл ут ургылып, бәреп чыга алмый — мич ышанычлы, коючы тыныч. Аста — матрица белән клэймә сугучы капчык арасында — пресс-форма эчендә деталь инде әзер... Озакламый фәлән хәтле басым астыннан шундый сүзләр килеп чыгачак:

— Якты Яр автомобиль комплексының кою заводында беренче деталь коелды! Беренче! Беренче деталь!

Ләкин әле җиңү күзгә күренми, ул әле һаман эчтә... Йөз кырык атмосфералы басым астында. Ул әле — сер... Саклык чатыры һәм машина миче тибрәнми дә... Куркыныч һәм сер тышка бәреп чыкмаячак...

Ниһаять, ачкыч яңадан борылды. Чатыр янә итэгать белән күтәрелгәч, корыч кул мич эченә сузылды да әзер детальне эләктерде. Һәм аны тиз арада, әллә каян чыгып баскан корыч өстәлгә җайлап куйды. Өстәл детальне суга ыргытты. Аннан исә транспортер инде суынган детальне кисү прессына өстерәде. Деталь, тиешле озынлыкта кискәләнгәч, бүтән адрес белән ары җибәреләчәк.

Машинаның ачык авызына дүрт почмактан да майлы сыекча агып керә дә — металл гыйфрит — ажгырып, ысылдый һәм тагын пар бөркә башлый. Гыйфрит диясең килмәсә, паровоз диген. Ничек кенә атасаң да, мәгънәсе бер — менә дигән машина!

Ул арада завод директоры үзе дә кереп җиткән икән. Хәзер аның икенче командасы яңгырады:

— Автоматикага күчәбез!..

Коючы егет икенче ачкычны борды һәм берничә адым янгарак тайпылды да читтән күзәтә башлады. Машина нәкъ баягыча эшли башлады.

Кинәт... машина чыелдарга кереште. Дежурный пультка ташланды. Прибордагы циферблатка текәлеп, күзләре кысылды... Алтын каймалы супер-модалы күзлекләр дә күзләр тынгысызлыгын яшерә алмый калды.

— Ни диде машина? Ярдәм сорыймы?

Директорның бу соравына наладчик җавап бирде:

— Технологиядән кичкенә генә тайпылыш...— Һәм үз сүзләренең дөреслеген пульттагы сызмалардан карап тикшерде.— Әйе, юри эшләдек. Шулай да зыян юк. Бу детальләрне яңадан коярга була.

Слесарь да, наладчик та нәрсәнедер карый, төзәтә. Машина чыелдаудан туктый, тынычлана һәм баягыча көндәм хәленә кайта. «Нинди акыллы машина! — дип уйлый Насыйбуллин.— Моның белән эш итәргә була. Әгәр бөтен кешеләр дә шулай дөреслеккә сизгер булсалар!.. Үз эшен бу машина төгәл үти, ә үти алмый башласа, ялган горурлыкка бирелми, гарьлек санамый — ярдәм сорап кычкыра... Аның, әлбәттә, хәл җиңелрәк — ярдәмгә ашыгучы кешеләр янда гына...»

Директор:

— Теориягез сирена кычкыртты,— дип көлде дә беренче төзек детальне кулына алды.

Каяндыр фотограф килеп чыкты һәм, Гайнуллинга беренче алюмин детальне тоттырып, аның янына директор белән башка егетләрне чакыргач, чалт-чолт аппаратын баскалады. Егермеләп эшче, уртада Гайнуллин белән директор, сурәткә әверелеп, тарихта, музейларда калачак... Насыйбуллин заводның нигезен салган көннәрдә болай шатлана алмаган иде... Аның бәйрәме менә бүген килде — башкалар тантанасы рәвешендә... Киләчәк көн рәвешендә.

Уртада — Гайнуллин, кулында — беренче деталь!

Беренче деталь икенче көнне директор бүлмәсенең түренә менеп утырды. Аңа беркетелгән җиз калайга кай арада «Беренче» дигән олы мәгънәле язу сырланган иде...

* * *

Сәгать сукты. Кою заводы төзелеп бетте. Аны хәзер тулысынча — рәсми рәвештә — файдалануга тапшырырга кирәк. Болай булгач, тапшыру җиңел булыр, һәм министрга чакырылгач, Фәез Сәлимович Насыйбуллин да вәгъдәсендә торуы хакында, ниһаять, мөмкин кадәр тантаналы итеп хәбәр салыр!

Директор кабинетында тиешле кешеләр җыелды. Зур, иркен бүлмә — көн яктысы сирпелгән лампалар, агачтан эшләнгән стеналар күзне иркәләп, хатирәләргә этәрә кебек. Хәмитов та матурлыкка хәйран калып:

— Без эшләдек микән моны?! — дип Насыйбуллинга борылды.

— Сез, сез,— дип елмайды Насыйбуллин, ирониясен яшерергә тырышмаган хәлдә.

Директор һәм, аңа ияреп, урынбасары, тагын берничә кеше — заказчылар делегациясе керде. Директорның дүрт кырлы шакмактан гыйбарәт булган аксыл чырае, кая, кемгә караганы ачык беленеп тормаган битараф карашы шәфкать вәгъдә итми иде. Ә аның урынбасары исә чегәнгәме, гарәпкәме охшаган кара-кучкыл йөзе белән үртәгеч кырыслык чәчкәли иде. Насыйбуллин, көрәшнең каты булачагын сиземләп, хәтта елмаеп куйды.

Төзүчеләр делегациясе дүрт кешедән — трест управляющие Насыйбуллин, аның урынбасары Хәмитов, баш инженер Глазов, төзү-монтаж идарәсе начальнигы Черных һәм рәсми хокукы булган тагын берничә белгеч.

Ике «илчелек» зур озын өстәлнең ике ягына кара-каршы, күзгә-күз карап утырдылар. Әмма урынбасар бу җайны артык санап:

— Бөтенесен урында карарга кирәк бит, монда утырудан ни файда? — дип куйды.

Насыйбуллин гаҗәпләнде:

— Нәрсә карыйсыгыз килә?

— Нәрсә тапшырасыз — бөтен нәрсәне.

— Илле мең квадрат метрлы мәйданны? Берьюлы?

— Безнең бит монтажларга керешәсе бар. Кәгазьдә эш бетми.

— Сезнекеләр инде кәгазьдә түгел, минемчә, күптән биналар эчендә монтажлый. Зарланучы юк,— диде Глазов.

— Монтажлыйлармы? — дип тагын гаҗәпләнгән булды Насыйбуллин.— Син әле металлны коеп карадылар дип тә мактанырсың. Сиңа ышансаң... һәм кәгазьгә...

Директор иронияга дикъкать итмәде.

— Мәйданнар... Мин аларны бер атна элек йөреп чыккан идем. Эш шактый калган иде. Бер атна эчендә бөтенесе тәртипкә килгәндер дип һич тә ышанасы килми.

— Бер атнадан соң караган кешеләр менә... Монда кул куйдылар.— Идарә башлыгы Черных өстәлдәге кәгазьләрнең кайберләрен директор тарафына шудырды.

— Субподрядчылар? Кул куйдылармы?

— Бернинди искәрмәсез.

— Яле, карыйк әле...

— Ә менә монда... Кичә күрдем, буялмаган, бер метр да.

— Буйыйбыз аны... Унбишенә хәтле бетерәбез...

— Алайса күрсәтәбез — унбишенче ноябрьга хәтле. Искәрмә итеп яздык.

Тәрәзә яныннан Насыйбуллин карый: әйтерсең, полководец сугыш кырын күзәтә. Югарыдан яхшырак күренәдер. Ләкин, Хәмитов сизүенчә, син, иптәш, кайбер бик якындагы нәрсәләрне күреп җиткермисеңдер. Зурракларын ычкындырасың...

Насыйбуллин урынбасарының нәрсә уйлаганын, үзенең нинди хәлдә икәнен белми һәм ул әле — бәхетле. Хәмитовка игътибарсыз. Хәрәкәтләре иркен, үзе көләч. Имеш, эшнең уңышлы барып чыгачагына ул шикләнеп тә карамый. Ләкин чынлыкта аның эче тулы ут, ул курка — төзелеш бетсә дә, рәсми төгәлләнмәгән булып чыгуы бар... Һәм бүгениртәгә — министр чакырып алачак. Вәгъдә срогы бетте... Вакыт җитте... «Мин сездән сорый белермен...» Шуңа күрә, бүген рәсми тапшырып бетерү — мәҗбүри. Шаян, күңелле роль уйнау нервыга суга... Җилкә сызлый, күз авырта... Һәм урынбасарның чамадан тыш куәтле аваз белән:

— Без кисәттек, карашыбызны игълан иттек! — дигән белдерүенә каршы:

— Сез Берләшкән Милләтләр Оешмасында түгел бит. Игъланнарсыз, кисәтүләрсез генә булмыймы соң? — дип үртәлмичә кала алмады ул.

Бәхәс тагы куера, тойгылар тагын да катырак тартыла төште.

Бәхәс арасында Фәез Агарковның секретарена шалтыратып, министр килдеме әле дип сорарга да өлгерде. Телефоннан килгән тавышны, нишләптер бик ишетәсе килеп, бу минутта Айрат колакларын торгызды. Фәез сүзләреннән берни аңламыйча, сәбәпсезгә кызара төшеп:

— Ничек? Килгәнме? — дип сорамый булдыра алмады.

Кәефе әйбәтләнә төшкәнлектән, «Сиңа барыбер түгелмени?» дип куясы урынга, Фәез:

— Килгән,— дип тыныч кына җавап бирде.

Килгән. Хәзер төшке ашка киткәннәр. Димәк, озакламый Насыйбуллинны чакыртачаклар. Үзе сораячак министр. Сорый беләчәк. Ләкин Фәез калтырап тормас. Болай булгач, үзен тота да, сөйләшә дә беләчәк. Аның табан астында, таяна торган урыннарында — таш, бетон...

Тик менә заказчылар чак кына артыграк иркәләнәләр, юри сузалар диярсең.

Министр белән тыныч, нык сөйләшер өчен Фәезгә дә ашханәгә барып, чак кына ял итеп алырга кирәк. Шушы фикер тугач та ул өстәл янына килеп утырды.

— Я, ничә метрны чигереп торуыбызны үтенәсез? Чигерегез курыккан кадәре. Без үлмәбез. Ничә? Мең метрмы? Алып ташлагыз. Унбиш мең метр. Ләкин юри тоткарлавыгызны иптәшләргә аңлатсак, сезгә дә җиңел булмас. Килештекме шулай?

Ләкин Черных андый ук ташламага риза түгел әле.

— Ничек килешик, Фәез Сәлимович — егерме мең бит! Черки дә борын тыга алмаслык дәрәҗәдә шома эшкәртелгән метрны нишләп алай ансат кына ыргытып бәрим мин?

Директор, бераз гына йомшара төшкәнен сиздереп, кузгалып куйды:

— Килештек. Бише-ние белән кабул итәрбез. Ләкин башта карап, йөреп чыгыйк. Шуннан соң кабат җыелырбыз.

Ягымлы кыяфәткә кергән директор ишеккә таба атлады һәм Насыйбуллинга кул ымы белән хәзергә хушлашуын аңлатты.

Насыйбуллин шулай ук кул һәм күз ишарәләре белән янына үз кешеләрен җыйды:

— Мине төштән соң министрга чакырулары бар. Калган өлешне үзегез хәл итеп бетерерсез. Глазов, Хәмитов, Черных. Сез — җаваплы. Калган иптәшләр дә. Килештекме?

Ризалашып баш кактылар.

— Алай-болай кирәгем чыкса, мин хәзер ашханәдә булам. Шалтыратырсыз.

Шул рәвешле ничәмә көнлек тәнәфессез буталчык чабышлардан соң Фәез көндезге ашны иркенләп, адәмчә ашар өчен, ресторанга юл тотты. Машинадан рация-телефон аша үзенең секретарена да: «Әгәр министрга ашыгыч чакыра калсалар, миңа тиз генә шалтыратырсыз»,— дип, кайда икәнлеген хәбәр итте.

Мәһабәт Җәлил проспекты. Күзгә күренеп барлыкка килде, үсте ул. Ләкин шуның матурлыгына бер генә минут карап сокланырга да вакыт тигәне булмады. Вакыт хәзер дә юк. Шулай да бүген Фәез үзенә бәйрәм бирергә хаклы санады. Берничә сәгатьтән соң — завод цехлары, җылылык торбалары белән егерме ике мең метр мәйдан тапшырылып бетәчәк. Кул куячаклары инде аермачык беленде. Я, барып карасын директор күпмедер калган бәхәсле мәйданны. Күзләре күргәнгә ышанса, риза булачак. Димәк, трест управляющие Фәез Сәлимович Насыйбуллин үтәлгән задание хакында министрга тантаналы рапорт бирәчәк. Җәлил урамы буйлап матурлыкка, киңлеккә соклану нияте белән җәяү атлаган Фәезнең шундый уйлар күзләрен каплаган иде. Күзләр нигездә күрмәскә әйләнгән инде. Күңел тыныч түгел, нигәдер ул һаман көйрәп тора. Сәреме дә юк микән әле. Югыйсә, баш ник авырта дисең? Шул сөрем исе капканнан түгелмени?

— Фәез! Исәнме, Фәез!

Яннан гына Кама узып бара.

— Исәнме.

Шулай дип кенә узмакчы иде Фәез, ләкин Кама аның азга гына тукталуын үтенде:

— Безгә сөйләшергә кирәк.

— Ни хакында?

— Киңәшәсе бар, бик кирәк. Әйтәсе сүзләрем...

— Соң... Берничә көннән минем күзләр бераз ачылыр кебек. Сөйләшербез.

— Мин... бүген үк... Менә хәзер кирәк иде.

— Минем бит хәзер обедка барышым.

— Бигрәк тә шәп. Бергәләп ашарбыз. Минем акчам бар...

Фәез елмаерга мәҗбүр булды. Шуны Кама ризалашуга исәпләде һәм:

— Алайса мин горкомга кереп кенә чыгыйм инде, заказ бирә тор. Мин бик тиз,— дип, китеп тә барды.

Фәез үзе генә атлый торырга тиеш булды.

Ләкин хәтердә алар икәү атлыйлар иде... Тик атлый торгач, мәңге аерылмаска дип тотынышкан куллар, нидәндер сискәнгән шикелле, кинәт ычкынды да куйды. Әйбәт кенә барган җирдән... Ничек әле?

Ерак таң шәфәгы, тәрәзәдә озак көтелгән яңалык төсле, Каманың болай да кабарынкы чәчләренә, аннары керфекләренә кагылды да... ул кинәт күзләрен ачты. Кама күзләрен ачкач, әле генә офык нурлары кагылган керфекләрне, чәчләрне Фәез кулы белән сыйпап куйды. Чын иде кыз, хыял гына түгел иде. Чын кыз — аның өендә... Шулай да бәхеткә ышану кыен. Нәрсәдер кинәт үзгәрер дә, ул юкка чыгар кебек. Кама, әкият илчесе, чак кына ялгыш кагылсаң, зәңгәр кошка әверелер дә тәрәзәдән үк очып югалыр кебек. Кыз йокыдан арынып та җитмәгән елтыр күзләре белән дә, сүзләре белән дә таңны тизләтә, ашыктыра куйды:

— Ай, соңга калганбыз!

Бу сүз колак төбендә әле дә ишетелеп тора. Әнә ул көн якын гына!

Фәезнең чигә чәчләрен сыйпап куя да Кама сикереп тора һәм күз ачып йомган арада бүтән бүлмәгә кереп китә. Фәезне тагын курку били: кыз үзенең каядыр җыеп куйган канатларын кабат кияр дә сыегаеп барган шәфәкъ артыннан очар сыман. Юри генә кыз рәвешенә кергән коштыр ул дип шикләнә Фәез. Юыну бүлмәсеннән шыбырдап су акканы, нәрсәнеңдер ишетелер-ишетелмәс шакылдап куйганы гына Каманың әле һаман кеше рәвешендә икәнлеген һәм әле дә Фәез өендә кала бирүен сиздерә. Аннары бигрәк тә — кухня ягында савыт-саба шалтырый башлавы җир мәшәкатьләрен үк хәтергә китерә.

Фәез урынын җыйгач, ике-өч төрле хәрәкәт белән зарядка дигәнен ясап куя, юыну бүлмәсенә керә. Болары, әлбәттә, хыялдан якынрак, түбәндәрәк. Шунлыктан бугай, кухняга ашыга Фәез. Анда төн кыскалыгы аркасында җитми калган шатлык көтә — үзләре дә аңлап өлгергәнче үк кочаклашырга ташлану, битләр, чәчләр йомшаклыгы китергән сөенечләр. Тик иреннәр Фәездән тиз качасы иттеләр.

— Фәез, соңга калганбыз, тиз!

Кама чәй кайнатып өлгергән. Калган ризыкны барлаганнан соң күзләр белән генә яратышып чәй эчтеләр дә, җәһәт киенеп, урамга ташландылар. Бер бүлмәдә узган бер төнлек бәхетләр эчтә бикләнеп калды. Үзләренә дә әйтеп бетерә алмаслык сер...

Аерылганда, Фәез, сүзләренең мәгънәсенә үзе дә төшенеп бетмәстән:

— Кама, син миңа нәрсәнедер аңлатырга, сөйләргә тиеш бугай,— дип куйды һәм шуның белән кызны таң шәфәгыннан алсурак төскә керттe. Тиз арада күзләрен яшерде, берара тораташтай тик торды да — ялт. Болан баласыдай урамның икенче ягына томырылып, үз дөньясына юл тотты. Фәез кул болгап караса да, кыз инде күзләрен сирпеп тә карамады — эшкә ашыккан мең кеше арасына чумып юкка чыкты. Мөгаен, трамвайларның берсендә ул яңа калага таба барадыр — Фәездән еraграк, еракка, читкәрәк...

Бетон багана белән парлашып, катып калды Фәез. Шактый озак кузгала алмады. Узган төннең мәгънәсен аңлыйсы килә, тик күңелгә зиһен кайтмый. Буталчык, күңел кабул итмәстәй шикләр, сизенүләр, иртәнге салкынча җил сыман, тәнне чымырдата. Фәез калтырый ук башлады бугай. Һәм шунда гына, эшкә соңаруы кабат искә төшкәч кенә, идарәгә таба атлады.

Ә Кама шуннан соң чынлап та күзгә күренмәс булды. Моңарчы күздән югалса, ул Кама елгасы рәвешендә яши башлый иде. Күптән түгел генә шулай була торган иде. Фәез инде су керә торган җирдән арырак, тынрак җиргә барып утырса да, анда да Кама исемле елга белән Кама атлы кызның икесе ике нәрсә икәнлеккә ныграк ышана барды. Җитмәсә, елга гел саф мәхәббәт шикелле ялтырап кына тормый — җил искәндә ямьсез үк шадралана, үртәлә дә белә икән. Һәм ул сафмы икән әле? Чишмә суы белән чагыштырсаң?

Юк, саф түгел, кая ул сафлык, Кама шактый ук болганчык икән лә. Төсе дә шуңа күрәдер ак түгел, соргылт аның. Теләсә кем кереп коена ала Камада, теләсә кем аңа теләсә нәрсә ташлый, ыргыта. Ә Кама-су барын да кабул итә. Үзен шадраландырып башта үртәлсә дә, тиз үк яңадан үзенең гадәти хәленә кайта... Тып-тыныч соры төс. Ак түгел...

Тукта, житте! Үзең дә әллә, тәрбиясез кешеләрдәй, су өстенә ярамаган нәрсә, чүп ыргыта аласыңмы? Ашыкма, сабыр ит. Сабыр төбе — сары алтын.

Ә шулай да ник күзгә күренми Кама атлы кыз? Нидән курыкты? «Нәрсәдер хакында сөйләргә тиешсең» дигәннәнме? Сөйләргә, ачыкларга теләмичә, сер булып калмакчымы? Күңелне тырный, җәрәхәтли торган сер булыпмы?

Ә нәрсә хакында сөйләргә тиеш иде соң ул? Монысын Фәез хәтта үз-үзенә әйтергә дә курка. Исемсез калсын бу шик — һич югы мәҗбүрияте чыкканчыга хәтле. Нәрсә ул шик дигәне, нәрсә соң ул ләкин? Ник бәйләнчек фикер булып әверелде? Ник кавышу көнендә үк яралды? Бүтән җан яралырга ихтимал булган иң бәхетле, мәңге онытылмас хатирәгә әйләнеп каласы төндә яралды ул! Ник?

Сабыр ит. Исемсез калса калсын, бәхетсез үк итмәсен. Хыялдан чынлык тормышка күчмәсен, бетсен, югалсын.

Ләкин шик нәрсәдән башланды? Анысы мәнә шушы бугай: ни өчен, нинди хокук белән Лазаревның ак күлмәгенә ал шәрап сибә алды әле Кама? Борисны яклап. Анысы хактыр. Ә бит Фәез дә яклады Борисны. Мәгәр андый ук кыланышка, кискенлеккә бара алмады. Җитмәсә, Анатолий Самойловичның үзенең дә моңа чәчләре үрә тормады. Ник? Шул сорау: әлбәттә, алар Фәез белмәгән нинди дә булса бер нәрсәне әйбәтрәк беләләр... Чынында ничек алай була ала ул?

Көннәр суына барса да күңел сүрелүдән ераграк иде. Киресенчә, башны диванага сабыштырырлык зурайды сәбәп. Сәбәп шул: бер кеше ике төрле кыяфәткә кереп бутала. Беренчесе: Кама — әүлиядәй пакь, чибәр, чая, җәйнең иң сихри чакларында таңда җәйрәп яткан Кама суы. Яр белән сөйләшкән дулкын төсле... Тугай күлендә барлык гүзәллек рәвешен үзенә җыйган төнбоек чәчәге шикелле. Җил көче, агым тылсымы белән берләшеп, чылтырапмы чылтырый:

— Чын күңелдән якын күреп, моңарчы таныш булмаган ашкыну, талпыну белән мин сиңа тартылам, тик яр белән дулкын, тик дулкын белән яр мәңге кавыша алмаган кебек, без дә бергә була алмыйча тилмерербез кебек. Нәрсәдер эшләргә кирәк — син үзең уйла. Син үзең акыллы. Икебезгә дә әйбәт булырлык карарга кил! Соңга калма, ялгышма! Ялгыша гына күрмә!

Кама кинәт икенче кыяфәткә керә. Дөрес, әүвәлгечә тере, көләч, елгыр булып кала ул, тик чаялыгы чибәрлегенә ниндидер күләгә булып төшә, билгесез шик кебек. Бер нәрсәне дә гөнаһ дип исәпләмәстән, барлык кешеләргә елмая, һәм ул елмаю бик кыйбат та тоелмый кебек, теләсә кемгә бушлай бүләк итела кебек. Мөгаен болай түгелдер, Фәезнең үз кешелеге шикледер — нинди изге кызны, фәрештәне начар суга манып алырга тайчанмаган бәләкәйрәк җанлы адәмдер үзе. Үз җаны вак кеше бүтәннәр хакында түбән уйга бирелүчәнрәк була. Үз бозыклыгы дәрәҗәсен бүтәннәргә дә күчерергә ярата, үз ишләрен кү-

бәйтергә тырыша. Фәез үзен шундый аламага чыгарып еш кына үз-үзен тирги. Шул чакта Кама элекке рәвешендә гөнаһсыз моң сирпеп елмаерга керешә.

Шулай да ул Фәезнең берничә кабат чакыруына каршы, телефоннан үзенең көрсенүле сулышларын гына җибәрә торды.

— Кама, ишетәсеңме, Кама! Мин сине үләрдәй булып сагындым.

— Мин дә.

— Кайчан күрешәбез?

— Ник?

— Уф! Сагынуың рас түгел, алайса.

— Рас сагынуым, сөюем да рас.

— Син көт, хәзер үк барам яныңа! Көт! Ишетәсеңме?

— Килмә, Фәез, тынычлан, оныт!

— Тукта, мин синең янга чаптым. Көт, ишетәсеңме?

— Ишетәм.

Трубканы куйды да, аста торган машинасына утырып, Каманың эшләгән җиренә томырылды. Ике атлыйсын бер генә атлап, тыны-көне бетеп керсә, иптәш кызлары гаҗәпләнеп, шаккатып торалар. Күзләрендә — әйтергә ярамый торган хәбәр.

— Әле шушында иде Кама, бик ашыгып каядыр китте,— диделәр кызлар.

— Кайчан киләм диде?

— Бер сүз дә әйтмәде.

— Көтеп карыйм микән?

— Ихтыярыгыз.

Ярты сәгать чамасы көтте Фәез. Ләкин сабырлыгын җуеп, хәтере калып, тәмам үпкәләп, кызлар белән саубуллашмыйча да китеп барды. Бүтән ул аңа шалтыратмады да, эзләмәде дә. Ләкин урамдагы, кайда да булса берәр кыз очраса, ул аңа ерактан ук «Кама бугай» дип текәлә торган булды. Кызлар — күп, ә ул — юк. Хыялдагы Кама юкка чыкты. Кама хәзер җир тузанын битеннән сөртеп торган кыяфәттә күз алдына килә. Килә дә кемнеңдер ап-ак күлмәгенә ал шәрап бөрки. Ә үзе елмая, көлә. Ул инде яңа Кама, бүтән Кама... Инде хыялдагы Кама ерактан сирәк кенә көлемсерәп карый... Кайсы чын боларның, ә кайсы ялган? Кайсына ышанырга?

Беткесез яңгырлары, атаклы юлсызлыклары белән Кама киңлекләренә шыксыз көз килә. Тизрәк кыш, кыш килсен иде ичмаса. Барлык гөнаһ-гаепләрне, шик-шөбһәләрне салкын, өшеткеч булса да чиста аклыгы белән күмеп китсен иде.

Ә бүтәннәргә барыбер. Бүтәннәр тоташ бәхетле, бүтәннәргә чик-чамасыз мәшәкатьләр, ялгышулар, тартышлар ачылыгын алмаштырып, җиңүләр шатлыгы килә тора. Бәйрәмнәр, тантаналар белән чиратлаша. Истәлекле бер көн, чираттагы тантана. Соңыннан банкетка да чакырдылар.

Кама аръягындагы пионерлар җәйләвенә һәркем үз автомобиле белән барды. Фәез, шоферны мәшәкатьлисе килмәгәнлектән, руль артына үзе утырды. Элегрәк булса, ул Каманы чакырыр иде үз янына, рәттән утырырлар иде. Ә болай ул кайдадыр ялгыз моңаячак... Ләкин Фәез ялгыш уйда иде. Ул үзенең ялгышын бик тиз аңлады.

Җәйләүнең җылытылган бүлмәләре зур түгел, бер-берсеннән ишекләр белән генә аерылып тора, һәм, аларны ачып куйгач, тар гына озын бүлмә хасил була. Иң дәрәҗәле кунаклар түр бүлмәгә утырган. Фәез кергәндә, Аппаков сөйләргә дә керешкән иде инде. Соңгарак калып керүчеләрне дә үзенә комачау дип кабул итмичә, тантана белән җиңүчеләрне котлавын дәвам итте. Фәез исә беренче күзгә ташланган буш урынга килеп йомылды. Тирә-юньгә берничә минуттан соң гына карый алды. Фәезнең нәкъ каршында... өстәлнең икенче ягыннан гына Кама

карап утыра иде. Карашлар очрашкач, күзләрен үзенең нәфис, озын бармаклары белән капларга тырышты. Фәез үрнәгенә иярепме, чигәләрен угалады, тик барыбер, теләсә-теләмәсә дә, чынлыкны күрергә дучар иде. Әйе, күр, Кама, ышан, каршыңда — сөекле кешең! Ә ник шулай булгач сөенмәскә, шатланып исәнләшмәскә һәм башка матурлыклар эшләмәскә? Син бит дөньядагы иң әйбәт сүзләрне тагын да гүзәлләтеп әйтә беләсең, я, кабатла шуларны яисә яңаларын тап. Елмаеп кара да яктылык өстә дөньяга. Һәр әйтелгән сүз бөек мәгънә алсын.

Ә Кама каушый, Кама кызара. Фәезнең:

— Исәнме, Кама! — дигәненә каршы да баш кына кагып куя. Янындагы таныш түгел ир алда торган бокалларга шәрап койгач, рәхмәт әйтер өчен генә телгә килә.

Фәез өчен шул минутта дөнья берсүзсез үзгәрде дә китте. Иң башта төсләр алмашынды. Зәңгәр төсләрнең кинәт тоныклануы — күзгә ташланган беренче үзгәреш...

Бер сәбәпсез Миңлекәев Рәшит белән беренче очрашу күз алдына килде. Миңлекәевнең биленнән үз каешын алып чажылдатканда, егетнең үрсәләнеп кычкыруы, кыйналуының сәбәбен белергә тырышып инәлүе, сикергәләве, ниһаять, күзләрендәге усаллык-зәһәрлекнең кызгандыргыч ялыну белән алышынуы хәтердә кабат яңарды. Һәм ул чакта Миңлекәев дигән егетнең Кама атлы кыз белән алмашынуы киләчәкнең мәҗбүри сурәте хәлендә укмашып куйды. Ләкин бары тик өмет, хыялның гына тасвирламасы иде бу. Кама, бераз уңайсызлануын яшереп, тыебрак булса да, асылда тыныч утыра. Хәлбуки, Фәез Рәшитне кыйнаган чактагыдан артыграк ярсыды, артыграк арыды, тик кешеләр генә моны сизми иде. Күршесе янында урындык буш булганлыктан, Фәез ул кешегә шунда күчеп утыра алмассызмы, яки минем урынга күчмәссезме дип үтенгән иде, әлеге иптәш, уйлап та тормастан, Кама каршына ук шуышып утырды һәм җитмәсә Камага баш кагып:

— Кайбер иптәшләрнең матурлыктан күзләре чагыла,— дип шаяртасы да итте.

Кама чәнечке һәм пычагын гына зеңгелдәтеп куйды. Читтәнрәк күзәтү җиңелрәк иде, Фәезнең гүя муенын кыскан бау чак кына бушады, кулбашлары языла төшкәндәй итте. Каманың үз ягына караганын сабыр гына көтәргә тырышты. Кызганычка каршы, алгы бүлмәләрдән тостлар ишетелә торып, Камага шуларны тыңлап утырырга һәм артка борылып карамаска җай бар иде. Речьләрнең чираттагысы төгәлләнгәч, Фәез үрелебрәк Кама рюмкасына да, үзенә дә шактый тутырып коньяк койды да тагын Кама күзләрен ауларга керешгә. Ниһаять, алдындагы бокалга күзе төшеп, кыз гаҗәпләнмичә һәм бу якка карамыйча булдыра алмады. Ни хикмәт, карашлар очрашкач, тән буйлап электр агымы төслерәк таныш чымырдау узды да Фәез янә тотлыга калды. Муенны авырттыра торган зәһәр хиснең янә кузгалуын сизде. Куллар, янә теге онытылган, еракта калган каешны эзләп, һавада буталып куйдылар. Кама бу хәрәкәтләргә гаҗәпләнми булдыра алмады һәм шулай Фәезгә теләгән форсатны китерде дә. Фәез әүвәл баш кагып, соңыннан исә сүз белән үк кызның үз янына күчеп утыруын үтенде. Кама ялындырмыйча гына күчеп тә куйды. Ләкин рәттән утыргач, әйтәсе килгән усал сүзләр әллә кая очтылар да киттеләр, һәм шактый вакыт баягыдан да җайсызрак киеренкелек комачаулап торды. Якынлыкның яңәшәлеккә әверелүе бик мөмкин иде. Аннары бөтенесе бетте, дигән сүз. Әмма бөтенесен дә капылт кына югалтасы килми, әле ачыклыйсы нинди дә булса мөмкинлек калгандыр кебек иде. Өметкә тартым шундый теләк үз авазын ишеттергәч, Фәез әле генә каеш эзләгән кул белән үз рюмкасын күтәрде дә бая Кама өчен махсус салган рюмкага һәм, анысын кабул итмәсә дип, коры шәрап салынган бокалга ым какты:

— Җиңүчеләрне без дә котлыйк... Бәйрәм онытылмаслык хатирәгә әйләнсен. Тарихи көн белән!

Кама бокалны алып, читтән чәкешкән сыман итте дә кире куйды. Шунда Фәез, ниһаять:

— Ни булды сиңа? — дип кискен итеп сораганын сизми дә калды.

Кама җәһәт кенә күзләрен алгы якка борды — тыңлый, янәсе.

— Кама, я, кыланма инде.

— Ничек инде ул, кыланма? — Аның күзләрендә кырыслык галәмәтләре бермә-бер кимегән иде.

— Туп-туры мәгънәсендә.

— Барыбер аңлашылмый.

— Әйдә, аңлашылсын өчен шушыны күтәреп куябыз.

— Проблемалар үзләреннән үзләре...

— Бернинди проблема юк һәм... булмасын өчен.

— Мин риза.

— Киттек.

Шуннан соң, аз-маз ризык капкалаганда, киеренкелек күзгә күренеп кимеде. Сүзсез генә булса да көлемсерәп, юкны да җөпләгән ымлыклар ясап утырдылар. Озак та тормастан түр бүлмәдән яңа тост килеп җитте:

— Безнең эшләрнең барысы да кешеләр өчен. Безнең эшләр кешеләрнең киләчәгенә багышланган. Гомер буе бер-берсен эзләп тә, үз тиңнәрен моңарчы тапмаган меңнәрчә кешеләр бездә бер-берсен таптылар. Тостның мәгънәсе шул: тапканнар югалтмасын, югалтканнар тапсын. Югалтышлар түгел, табышлар өчен, дуслар!

Фәез тостны җөпләп Камага шуны үзенчә кабатлады:

— Әйдә, тапканнар югалтмасын — эшен дә, үзен дә, кешесен дә...

— Бәхетен...

— Мәхәббәтен дә.

— Мәхәббәтен дә.

— Молодец, Кама!

Тагын нидер әйтмәкче иде Фәез, тик нәрсә икәнен сүз белән әйтү әлегә мөмкин булмаганлыктан, ихлас чәкешү белән канәгатьләнеп калды. Бер дә юктан кырт киселгән ара бер дә юктан җилемсез ябышып та куйды, тагын ни теләргә? Ә бит әле кич озын, кич җитмәсә, төн бар, алда бөтен бер гомер!

Гомер, яшь гомер! Бөтенесен дөрес кенә хәл итә алырсыңмы? Иң зирәк карарларны иң тиле чак — яшьлек таба белергә тиеш. Акыллы дигән картлык бары тик аның уңышларын саклый һәм ишәйтә, ул кабызган кояшта бил-арка кыздыра. Ялгышма, кешенең дә, үзеңнең дә — тормышның, бөтен дөньяның чын аслын таба, күрә бел! Югалта күрмә!

Тәнәфескә Кама белән Фәез бергә чыктылар. Икәүдән-икәү генә беренче эзләрне калдырып, якын тирәдәге урман эчендә йөрделәр. Иреннәр кайнарлыгын һәм сафлыгын аңлаган ай да ап-ак каурый болытлар аша: «Сез элеккечә, сез элеккечә якыннар» — дип, шатлыктан чайкала иде. Бәйрәмнең шунда гына мәгънәсе аңлашылып, җиңүнең максаты шунда гына табылгандыр кебек тоелды. «Бөтен нәрсә — кеше өчен, үзебез өчен! Табылганны югалтма, сакла, кадерли бел!» — Телдән әйтелмәгән шушы уйлар белән шаярып, шул уйлар белән каеннарга, усакларга сөялеп, күкрәкләргә ташлана-ташлана йөри торгач, җәйләү тирәсендә сөйләшүләр тынганны абайлап, яңадан йорт эченә керделәр. Ләкин, ни хикмәттер, өй эченә әллә нинди кара-кучкыл төсләр кереп урнашкан кебек иде. Монысын Фәез, әлбәттә, Камага сиздермәскә тырышты һәм ул максатына ирешәчәк тә иде. Инде утырышып беткәндә генә — Айрат. Каян килеп чыкты диген, мигә фикер килеп өлгермәс җәһәтлек белән Фәезгә карап:

— Гафу,— диде дә Каманың терсәгеннән тартып куйды.— Безнең анда эш бар, хәл итәсе нәрсә. Сезне аерам инде хәзергә.

Кама урынына Фәез гаҗәпләнде:

— Мәҗлестә нинди эш?

— Кама белә. Шулай бит? — Кама эндәшмәгәч, кыставын дәвам итте.— Шулай кирәк, үзең беләсең. Әйдә, әйдә, киттек.

— Ярый, Фәез. Моңаймаска тырыш.

Шул рәвешле Каманы йолкып алып киттеләр. Фәез калды буш урынны саклап. Бая гына язылган җилкә мускуллары яңадан кысарга керешкәч, нигәдер күзләре әчетә башлады. Авыртуны басарга тырышу нияте белән ул берничә рюмканы рәттән күтәрде. Тик ачу һәм шик алай гына ычкындырырга теләмичә, барча бауларны тагын да тыгызлабрак тарта бирде.

Каманымы, Айратнымы, әллә үзен гаепләргә һәм тиргәргәме икәнен хәл итә алмыйча озак кына баш ватты Фәез. Уйлаган саен фикерләре ныграк чиямлана, ә кәефе караңгылана барды. Чынында — уйлануның кирәге юк иде. Айрат кебек эшләргә генә кирәк иде. Бәлки хәзер дә соң түгелдер? Әмма түр бүлмәдә — житәкче иптәшләр. Кама шунда.

Дөрес, Каманың Айрат белән шикле бәйләнешкә тартым бернинди мөнәсәбәт сиздергәне юк. Бая тәнәфескә чыгып барганда, Айрат үзенә кадалыбрак карап калгач, Кама:

— Яратмыйм шушы кешене, бите-чырае уголовникнныкына охшаган,— дип куйган иде. Чыннан та, Айратның карашы да читкә борыласын китерә торганча әрсез, кырыс, хәйләкәр. Ләкин Фәез моңарчы бу кешегә, нәкъ менә шушы кичәдәгечә, һич тә кискенлек күрсәтә алмый. Юк, курыкмый. Куркырга хакы юк. Мәҗлеснең түгәрәкләнә баруы сизелгәч, түр бүлмә ишегенә килеп, Фәез Каманы ым белән үз янына чакырды. Тик кыз берни эшли алмыйм, дигәнне ишарәләү белән генә чикләнде. Шунда ачуы кубып, Фәез тиз-тиз урамга чыгып китүдән башка чара тапмады. Үзе дә төшенмәстән, күптән түгел генә икәүләп калдырган эзләрне таптап йөрде. Пар эзләр, тезек, көйле эзләр бозыла калды. Күпмедер йөргәч, яңадан ишек катына килсә, ишек инде ачылып-ябылып торудан туктаган, кешеләр сирәгәйгән иде. Автомобильләр янына арырак узып, анда җыйналган төркемнәрне танырга тырышып тагын бераз йөренгәч, эче жуылдап китте: «Кама кайда?»

Яңадан өй эченә кереп, бүлмәләр аша түргә, бая Кама калган ишек төбенә житте. Кама шунда иде. Башның тәмам йөдәве, томалануыннан бигрәк, Каманы күреп алудан артык сөенүе аркасында, Фәез, үзен белештермичә, туп-туры аның каршысына килеп басты. Кама тыныч утыра иде. Артык тыныч. Фәез күренүгә шатланасы урынга чак кына сәерсенгәндәй карап куйды. Кыек-мыек сүзләрнең инде кодрәте жуелганга исәпләп, Фәез туп-туры карап:

— Син мине яратасыңмы? — дип сорады.

Кама шулай ук озак уйлап тормады:

— Мин сине яратам.— диде.

— Алайса киттек.

— Кая?

— Жир читенә.

— Анда ни бар?

— Яратам дисең бит?

— Ләкин бит алар да мине ярата.

Шунда гына ул Каманың шактый исергән булуын абайлады. Күтәрелеп караса, өстәлнең икенче ягында гына Хәмитов утыра икән.

— Шушы кешеме?

— Алар! Алар!

Мондый хәлдә Каманы ташлап китү гөнаһ булыр иде. Фәез аны

кулыннан алып торгызмакчы иде, ялгышты. Кама кузгалырга җыенмады да. Аптырагач, Фәез ярсынып:

— Кемнәрне тагын яратасың? Кемнәр алар?!

Кама өстәл ягына кабат ымлагач, ныклабрак караса, бүлмә артында тагын бер бүлмә барлыгы күзгә чалынды. Һәм анда, ишек артында, таныш тавышлар ишетелеп куйды. Фәез аларны таныды, ләкин исемнәрен атарга теләмәде. Ә каеш? Кайда иде соң куллар баядан бирле эзләгән каеш? Анысы юк иде, бар эш кулларның үзләренә тиеш. Фәез Каманың ике терсәгеннән берьюлы күтәреп торгызды, ләкин ихтыярсызлыкны хәмергә сылтарга тырышкан кыяфәттә Кама озак тора алмады. Фәез, ахыр чиккәчә үртәлү, гарьләнүгә чыдамыйча, аны көчләп диярлек яңадан үз урынына утыртты да, тегесе гаепсез күзләр белән мәхәббәт сирпеп караган бер мәлдә каеш сагынган уч төпләре чатнаган аваз чыгарып, Каманың гүзәл бите белән кавыша да куйды. Яңаклар яратып сыйпаудан алай чатнамый торгандыр...

Шул чак ишек артында да кискен сораулар ишетелде һәм шул тавышлар боерыгы белән, ерткыч җәнлектәй сикереп, Хәмитов бу якка чыкты:

— Бу ни? Тагы сез... Үзегезнең кайда икәнегезне беләсезме?

Айрат Фәез дустына шулай «сез» дип эндәшә башладымыни инде?

— Гафу итегез.

— Сезне кичермәсләр моның өчен.

— Беләм.

Монда калу мөмкин түгел иде инде. Бүлмәдә бүтән өмет һәм теләк, урын һәм иптәш тә калмаганлыктан, үзен кыйналгандай тоеп, хәлсезләнеп, авыртмаган битләрен учлап, каядыр йөзгән төслерәк булып, Фәез ишеккә, бүлмәләр аша урамга таба атлады. Соңгы ишекне ябыйм дигәндә кинәт тукталырга мәҗбүр булды.

— Фәез! — җилкәгә таныш тавыш бәрелде.

— Кама?

— Чак кына сабыр ит, Фәез!

— Нишләп син?..

— Гаҗәпләнмә. Хәзер аңлатам.

Тышка, салкынга чыктылар. Кама шунда ук калтырый да башлады. Үзе Фәезне салкыннан саклагандай кочып, аны бала сөйгәндәй иркәләргә кереште. Фәезне маңгаеннан, битләреннән үбә, һәм үзе тәкърарлый торды:

— Дустым бул, Фәез, акыллы бул, ачуланма, ялгышма. Мин барыбер — синеке, синең белән... тик бүген генә синең белән кайта алмыйм. Монда мин болай гына. Юк, яратмыйм беркемне, тик сине. Монда мин кирәк булганга гына — эш өчен, синең өчен дә. Тик әле барын да әйтеп булмый. Теге чакта, иң бәхетле, иң истәлекле төнебездән соң да берни дә сөйли алмадым. Яратсаң шушы хәлемдә ярат...

— Юк, мин яраткан Кама — бүтән... Син мине алдадың, Кама. Син бөтенләй бүтән кеше. Мин белгән Кама түгел.

— Мин генә түгел, бөтен дөнья син күргәнчә түгел, күзләреңне ачыбрак кара, Фәез! Шулкадәр беркатлы, көчсез, сабый булырга ярыймыни! Шушы заманда! Шушы заманда!

— Үз бозыклыгыңны заманга якма!

— Фәез! Ни сөйлисең?

— Белгәнемне, күргәнемне.

— Ә син мине шушы хәлемдә ярат, чын хәлемдә. Бәлки әле мине аңлау да мөмкиндер, уйла. Яратмасаң, ачуланмыйм, хакым юк. Ә минем өчен синнән дә назлы, синнән дә кадерле кеше юк. Шуны белеп яшә.

Кама шулай тагын күпме өзгәләнер иде, әйтү кыен. Фәез баганадай селкенми-кузгалмыйча, ни эшләргә һәм уйларга белмичә күпме газап-

ланыр иде — билгесез. Ишектән хатын-кыз шәүләсе чыкты да башта пышылдабрак, соңыннан ачык ук ишетелерлек итеп нәрсәләрдер әйтте һәм тагын да соңрак кычкырып та җибәрде:

— Кама, ишетәсеңме, җүләр! Акылыңа кил! Сине көтәләр, бөтен эшне харап итәсең бит!

— Булдыра алмыйм, Рая, ачуланма.

Фәез шунда гына кызның Рәхилә икәнен аңлады. Ишек төбендә тагын бер шәүлә барлыкка килде. Монысы, һичшиксез, Айрат булырга тиеш. Аны күрүгә Фәез Каманың кулларын үзеннән ычкындырды да кискен, әмма тупасланмыйча әйтте:

— Бар, Кама, сине көтәләр. Син барын да булдыра аласың. Тагын да зуррак уңышларга ирешәчәксең. Алдагы тантаналар хөрмәтенә яңа тостлар күтәрегез, бар, тизрәк бул.

Алдагы көннәрдә генә түгел, бәлки гомер буе үкенер өчендер, бәлки һичнигә карамыйча җитәкләп үзе белән алып китәргә тиешле гөнаһлы мәхәббәтен калдырып, бүтән бу якка карамау гына түгел, хәтта колак та салмыйча, Фәез машинасына таба китте. Машинаның тыныч гөрелдәве исә күңелне үз көенә ияртә язды.

Нәкъ Кама әйткәнчә, күзләре ачылды Фәезнең. Дөнья яңа төстә, үз төсендә күренә башлады. Ай... Ай да әллә нишләде, үзгәрде.

Айның күзенә ак төште...

Ләкин...

Хыяллары Каманы мең төрле гөнаһ өчен тиргәсә, гаепләсә дә, элекке зәңгәр төсләр меңгә теткәләнсә дә, кимсетелгән, хурланган мәхәббәт бөтенләй үк үләргә, бетәргә һич теләмәде. Үзе белгән элекке Каманы кире кайтарыр өчен мең-мең догалар укыса, ялынса, үз тормышына чакыра-чакыра тилмерсә дә, урамнан уза барган һәр чибәрне Кама түгелме дип сискәнсә, танырга тырышса, ымсынып күңеле кырылса да, чын күрешүдән курка да иде. Ул Камага шалтыратырга җыенып беткәч, трубкасын яңадан шап итеп куя, саннар җыйса, телефон гудок биргәнче рычагка баса торды. Кешеләрдән дә сорашмады. Ләкин үзе, ничектер, аның хакында хәбәр көтә, телефон шалтыравы көтә, аның үзен көтә бирде. Башта бу тормыш түзә алмаслык җәза булса, эшкә дә хәтсез үк зыян китерсә дә, соңыннан, көннәр суына барган кебек, сагышлар да үз җыпкысына төштеләр шикелле. Көндәлек шөгыльләргә үрелгән салмак сагыну тыныч зарыгуга әверелде. Хәтта чибәрләр елмайганы, шаяртып сөйләшкәне күзгә күренә, ишетелә, аңлашыла башлады.

Мәгәр дөнья элекке төсенә кире кайта алмады. Айның күзенә ак төште.

Ничәдер елдан соң күзгә-күз карап ресторанда утырганда да Каманың йөзендә айдагы сыман сүрән таплар шәүләләнеп куя иде. Чын Кама югалды, табылмады.

*
* *

Кама сүзендә торды. Официант заказ алып китүгә елмаеп килеп тә керде.

— О, урыныңның шәбе туры килгән — тәрәзә яны, яп-якты, молодец. Әйбәт вино да бар дигәннәр иде.

— Ә мин курыктым.

— Нәрсәдән?

— Тәрәзә яктылыгын вино киметә бит.

— Ә-ә! Зыян юк. Коры шараптан әллә ни эшләмәс. Бигрәк тә безнең соңгы очрашу хакына.

— Дөнья — кысан. Шәһәр әллә ни зур түгел әле.

— Эш дөньяда түгел, безнең үзебездә. Очрашкан юк бит менә. Ничә ел инде?

— Санамадым.

— Бәхетле син!

— Әйе, бик бәхетле.

— Мин сине котладым шикелле?

— Нәрсә белән?

— Законлы никах белән дә, аннары... Менә бит бар монда нинди шәп вино — «Старый замок» тибында. Аннары нәсел үрчетә башлавыгыз белән.— Кама күзләрен кыса төшеп елмайды, башын да уйнатып куйды. Ә официант кыз аш китергәч, аңа да елмайды.— Минем кавалерым онытып кагн. Бер генә шешә коры шәрап китерегез, пожалуйста.

Официант кыз килгәнче, Кама бер сүз дә дәшми торды. Ә Фәезнең сүзсезлеге һаман да шул министр һәм кабул итү комиссиясе белән бәйләнгән иде. «Тиздән, бик тиздән телефонга чакырачаклар...»

Официант кыз бокалларга ярый әле үзе койды. Кавалер тагын бер кисәтү алачак иде. Ә бокалны башлап кулга алуны Каманың горурлыгы күтәрә ала.

— Соңгы очрашу хакына, Фәез.

Шул сүзләрдән дөньяга кайткан Фәез баягы соравын кабатлаудан уза алмыйча:

— Бер шәһәрдә яшәп тә бер дә очрашмау мөмкинмени? — дип куйды.

— Мин ул мәгънәдә түгел...

— Нинди мәгънәдә? Без бүтән мәгънәдә чынлап та очрашкан юк бит.

— Ә мин моңарчысы турында түгел, киләчәктә очрашмау хакында. Без моннан соң беркайчан да очрашмаячакбыз.

— Соң... ярый.

Каманың бераз гына хәтере калгандай тоелды. Яңалыкларыннан керфекләре төсле нәзек һәм озынча күләгә ялтырап узды. Тик хәл тиз үзгәрде, тынычланды Кама һәм сүзен дәвам итте:

— Мин инде синең хакта уйлаудан туктадым.

— Ә мин уйлаштырам, гәрчә вакыт юк, үзең беләсең.

— Хәер лә... бер очрашу мөмкин... Кагыйдәдән чыгарма буларак. Син хәтерлисеңме, теге төнне?

— Хәтерләмичә.

— Шул төнне кабатларга мөмкин. Әгәр син әйтсәң... Мин каршы тора алмаячакмын.

— Мин инде, теге вакыйгалардан соң, алай эшли алмамдыр шул.

— Алырсың... Мин сине рәнҗетмәдем, алдамадым. Шулай булгач...

— Мин үзем алдандым... Фәрештә дип...

— Запаста шул төнне калдырабыз...

Фәез моңа каршы нәрсә әйтергә — баягы тискәре җавапны кабатларгамы, юкмы дип, аптырабрак утырганда, официант кыз аны телефонга чакыруларын килеп әйтте. Министр? Юктыр, чак кына иртәрәк. Ашыга төште микән? Фәез хәзер телефоннан ук: «Сезнең заданиегез үтәлде, иптәш министр»,— дип тантаналы төстә рапорт бирә алачак. Гәрчә документлар бер-ике сәгатьтән соң гына әзер булса да. Ярый, барыбер эш төгәлләнүе хак бит — Фәезнең йөзе, вөҗданы барыбер ак. Чакыртсыннар, барыр ул, әйтер.

Ләкин звонок кою заводыннан гына иде. Глазов шалтырата. Фәез аннан хәлне сорарга ашыкты:

— Ничек, әллә бетте дәме?

— Юк шул, Фәез Сәлимович...

— Нәрсә, ватык-җимерекләр табылдымы?
— Юк, карап чыктык, анысы — болай ярый торган.
— Ну?
— Директор безнең белән сөйләшми. Сезне көтә.
— Ничек мине? Ну мөһим җирләрен бергә хәл иттек бит инде. Ә боларына урынбасар калды...
— Урынбасар китте бит.
— Кая?
— Әйтеп тә тормады, китте дә барды.
— Ну, әлегә аңа болай булгач. Ярый, килеп җитәрмен.

Калган ризыкка күз салмыйча, Кама белән ашыгыч хушлашып, яңадан кою заводына томырылды Фәез. Иртәнге яктагыча ук булмаса да, барыбер шома гына, бәхәссез генә узмады. Ахыргача килешеп куллар кую да тантаналы рәвеш ала алмады. Шулай да кичке сәгать сигезләрдә эш бетте. Инде соң — министр чакыра алмас...

Шул хакта хәбәр итүче булмадымы дип, секретарена шалтыраткан иде, анысы киткән булып чыкты. Өйгә шалтыратмадыларммы дип белешмәкче иде,— хатыны да трубканы алмады.

Фәез иптәшләре белән кул кысышып аерылгач та, бүтән мәйданнарга сугылмыйча, туп-туры өенә кайтты. Звонок бирде, ачучы булмады. Үз кесәсендәге ачкыч белән ачып керде. Зәрия дә, бала да өйдә юк. Урамга йөрергә чыкканнардыр. Бүтән көннәрдә Фәез бит соңрак кайта. Шуңа күрә ашыкмыйча, иркенләп йөриләрдер. Аларны көтеп тормастан, чәй җылытып, аннан-моннан капкалады да, ишектән ачкычны алып, Зәрия кайтса, уятып тормасын, үзе ачып керсен дип, Фәез йокларга ятты һәм шунда ук үлгән кешедәй, каты йокыга талды. Баһадирларча йокласа да, уяныр алдыннан хәтта төш күрде. Имештер, узган ел дәүләт эше тапшырганда министр Фәезне Агарков кабинетына чакыртып китергән дә нәкъ шул чактагы җитдилек белән, тик инде бу юлы дәүләткүләм әһәмияте зур булган бурычны намуслы үтәп чыккан өчен, котлап кулын кыса, тәвәккәллек күрсәткән өчен, башын кискәгә салгач та курыкмыйча фикерли, эшли алганы өчен мактый, ил исеменнән рәхмәт белдерә, мәгәр барлык сүзләрен нәкъ теге вакыттагыча усал, хәтта рәхимсез кырыс итеп әйтә. «Нәрсәдер монда бәйләнми, нәрсәдер дөрес түгел,— дип уйлый Насыйбуллин.— Кемдер министрга нәрсәнедер бутап тапшырган бугай, механизмны төзәтергә алынган кеше яңа, төзек деталь урынына ватык деталь куеп җибәргән төсле».

Буталчык тантана, якты шатлык тойгысы белән уянып китсә,— янында хатыны юк. Җәһәт торып бала караватына сузылса, караватэче дә буш... Фәез буш аклыкны мәгънәсез хәрәкәтләр белән кабат-кабат актарса да берни таба, күрә алмады. Күңелендәге шундый ук бушлыкның көзге төн сыман жуылдавын тыңлап, дивана кешедәй күпмедер катып торгач кына, әкрен-әкрен генә зиһен кайта башлады бугай. Шунда гына хәлнең хәерсез икәнен аңышып, кинәт җилкәсендә утлы авырту тойды. Фәез башта, чигәләрен учлап, якындагы урындыкка утырды, алай да көч җитмәгәч, караватка чалкан ятты.

— Ззың, зың, зың... Чч-ың-ччың...

Колаклардагы зәһәр сулкылдау яшәүгә янаудан башка мәгънә белән дә чыңлый иде: «Киткән! Хатын киткән!» Шунда ук: «Ник?»— дигән сорау чыңгылдарга керешә. «Ник? Ник? Ник?» Ә җавабы бернинди өн ярдәмендә дә килергә җыенмады. Сорау артык та көтелмәгән булганлыктан, җавап килеп җитәренә өметләнү мөмкин түгел иде. Шулай да — ник? Моңарчы ялгыш кына да бит телгә килешкәннәре булмады. Гәрчә, хәтерне бераз киерә төшсәң, Зәриягә нясе билгесез шалтыратулар булгалаганын искә төшерергә мөмкин икән. Имеш, аңа Фәез хыянәт итә... Зәрия моңарчы акыллы булды. Яла яккан иясез тавышлар-

га сөенечле хафа өстәмичә, иренең тыныч аңлатуларына ышанып, матур гына яши белде. Хәзер өйгә шундый ук тавыш кергән булуы ихтимал. Ләкин бер нәрсә аңлашылмый: Зәрия бу юлы ничек ышана алды икән?

Көтелмәгән очрашу һәм аннан тизрәк аерылышу... Бәлки табигый чишелештер бу?

Тиз килгән әйбер тиз китә... Ләкин тиз генә ышанасы килми.

Фәез, дивана кеше шикелле, өйнең һәр урынын — балконын, ванна, туалет бүлмәләрен, шкафларны ача-ача эзләнде, аннары телефонга тотынып, каядыр шалтыратып маташты, ләкин ниндидер саташкан авазлар гына ишетә алды. Дөресрәге, ул үзе саташкан, ул үзе кая шалтыратырга тиешле икәнен дә белми әле. Шәһәрдә Зәриянең беркеме дә юк, әти-әниләре авылда... Иптәш кызларына, тулай торакка гына киткән булуы ихтимал. Һәм Фәез, үз табышыннан әсәрләнеп, каушый-каушый шунда шалтыратты һәм ялгышмады.

— Телефонга Фәнисә исемле кызны чакырыгыз, пожалуйста,— дип ялынды.

Тавышы артык та хәвефле ишетелгәндер, мөгаен, әле бик иртә дип зарланмыйча гына, Фәнисәне чакырырга киттеләр. «Мөгаен — шунда, бүтән җирдә булуы мөмкин түгел». Ике-өч минуттан соң — онытыла язган таныш тавыш.

— Алье! Кем бу?

— Мин бу, Фәез Насыйбуллин. Әйт әле, пожалуйста, Зәрия сездәме?— Тавыш юк.— Сездә бит? Фәнисә, әйт, акыллым, куркытма, сездә бит?

— Бездә булса?

— Рәхмәт әйтермен.

— Нәрсәгә рәхмәт?

Фәнисәнең тавышы шактый дорфа сыманрак ишетелсә дә Фәезнең эченә җылы кергәндәй булды:

— Нишләп ул сезгә китәргә булды икән?

— Анысын инде үзеннән сорарсыз.

— Чакырыгыз әле аны телефонга...

— Килмәс шул...

— Ә сез чакырыгыз, килсен. Бик ныклап чакыра, диегез, шаяра торган чак түгел, акыллырак булсын, үкенерлек булмасын. Барыгыз, Фәнисә, аңлатып карагыз, пожалуйста.

— Монда телефонга кешеләр җыелды...

-- Барыгыз, Фәнисә, миңа үзе шалтыратсын, трубканы куеп торам. Алдый күрмәгез, көтәм. Ярыймы? Килештек?

— Мин ни... барып карыйм...— Кыз шулай дип трубканы куйды.

Бүлмәдән бүлмәгә йөренә-йөренә көтте Фәез. Ванна бүлмәсенә керде, юынды — фикерләре бераз үз урыннарына кайтып утыра башлагандай тоелды. «Исәннәр икән, анысы әйбәт. Ә калганы... Калганы хәл ителәчәк. Тормыш үзе бит хәл ителмәгән проблемаларның хәл ителә баруыннан гыйбарәт. Тәртипкә салынмаган нәрсә булмас. Башланган чакта ук өметсез ашкынулардан башланган иде... Шулай да матур гына ике ел яшәделәр лә, һич кимсенерлек түгел.»

Чынлап та хәзер ул вакытларны елмаеп кына хәтерләргә мөмкиндер. Әйе, шулайдыр. Әмма ул чакта...

Кич иде. Баш идарә йортыннан Фәез җәяүләп чыкты. Гидростройчылар урамы белән бераз өскә таба атлады да, гостиница төбәгендәрәк икенче якка чыкты. Тротуар буйлап йөзләрчә кешеләрнең берсе сыйфатында атлады. Асылда беркемгә дикъкать итмичә. Ләкин бер мәлне тукталып калды. Автомобиль юлы белән тротуарны аерган тимер барьерга сөялеп, ике кыз тора иде. Йөзләренә карагач, алар янында тук-

талмау мөмкин түгеллеге күзгә чалынды. Чырайлары шул хәтле ямансу, шул чаклы кызганыч иде, керфекләрендәге яшь бөртекләре кибеп тә өлгермәгән, битләрендә яшь эзләре.

— Исәнмесез, кызлар... Хәерле кич.

Кызлар, икесе дә читкә борылып, күзләрен, битләрен сөртkәләделәр. Тиз генә баш күтәреп карарга ашыкмадылар, Фәез сүз кушар да узып китәр дип уйладылар бугай. Юк, Фәез алай эшли алмады һәм җыенмый да иде. Шуны сизгәнлектән, кызлар чак кына елмаерга тырышкан хәлдә Фәезгә карамыйча булдыра алмадылар. Нечкә генә, озынча төз гәүдәсен берсе хәтта горуррак кыяфәткә кертергә дә тырышмады микән әле. Шуңа күрә Фәез кызларның ябайрагына — кыскарак буйлы, түгәрәгрәк йөзле чибәргә сүз кушты:

— Нишләп болай бик моңаеп калдыгыз, әллә егетләрегез ташлап качтымы?

— Егетләрне анысы без үзебез дә ташлый беләбез.

— Соң? Нинди уңышсызлык алайса?

— Уңыш зур — искитмәле.

— Ә дөресе?

— Дөресе шул — ал да гөл.

— Эшлисезме, укыйсызмы, дигәндәй.

Кызлар шушы сүздән янә үзгәрен, җитди кыяфәткә кермичә булдыра алмадылар. Инде нәзек гәүдәле чибәр телгә килде:

— Эшкә урнашмакчы идек тә...

— Сон?

— Соң... Соңга калганбыз. Отдел кадров бикле.

— Шул гынамы фаҗига?

— Җитмәгәнме?

— Хәзер нишлисез инде?

— Нишләргә икәнен белсәк...

Кызларның хәле аңлашылды.

— Димәк, отдел кадровка соңга калдыгыз, ә кая барырга белмисез — танышларыгыз юк.

— Әйе шул.

— Кай төбәктән килеп чыктыгыз?

— Актаныш районы.

— Куркырлык бер нәрсә дә юк. Эшләрегез рәтле булачак. Теләсәгез, эшкә үзем урнаштырырмын.— Фәез үзенең исем-фамилиясен, кайда эшләгәнен әйткәч, кызлардан да сорады.— Ә сез?

— Мин — Фәнисә Халитова,— диде түгәрәк чибәр.

— Мин — Зәрия Мияссәрова,— диде нәзек сылу.

— Булды, бик тә шәп. Болай булгач, мин сезгә ярдәм итә алам. Үзебезнең кызлар икән... белемегез ун класс. Быел бетердегез. Шулаймы?

— Әйе, сез аны каян беләсез?

— Әүлия бит мин. Әйе, хәзер сезгә кунар урын кирәк.

— Сез чынлап әүлия бугай,— дип Фәнисә чын күңелдән елмайды.

— Кунар җиребез чынлап та юк шул,— диде Зәрия, тәкәбберлеген киметергә тырышкан өчен генә кабатлап.

— Соң, курыкмасагыз, минем өйгә киттек. Киресенчә, кызлардан үзем куркам мин. Обижать итмәссез бит?

Кызлар инде, ихлас елмаеп, рәнҗетмәскә вәгъдә сиздерделәр.

— Сүз бетте, алайса. Тик безгә хәзер әнә теге яктагы кибеткә чыгып, нәрсәдер алырга кирәк була. Хәмер әле сезгә ярамый — сөттер, ипидер...

— Анысын гына инде үзебез булдырырбыз.

— Бүген сез — кунак. Мин сезне сыйлыйм. Киттек.

Киттеләр дә, өйгә дә кайттылар. Өйдә кызлар пычакны Фәез кулыннан алып, үзләре бәрәңге әрчеп пешерделәр. Авылдан килгән вак-төяк күчтәнәчне өстәлгә чыгаргач һәм холодильник берничә кабат ачылып ябылгач, өстәл бәйрәмгә үк әйләнде. Алдан килешенгәнчә, бәйрәмнең иң югары сые итеп сөтләп ясаган чәйне бал белән эчү исәпләнергә тиештер.

Бик кыстаса да, кызларны Фәез караватка яткыра алмады. Алар зал ягындагы диванны артыграк күрделәр һәм кочаклашып шунда йокладылар.

Билгеле, иң кирәкле нәрсәләр чәй янында хәл ителгән иде. Биргән вәгъдәсен һәм үз тәкъдимен тормышка ашырып, Фәез Зәрия белән Фәнисәне дизайнерлар курсына урнаштырды.

— Укып чыккач, минем өйне дә фән кушканча бизәрсез.

— Без моны ук өмет итеп килмәгән идек тә...— дип куйды нәзек Зәрия.

— Без ул хыялны калада бераз чирканчык алгач, буыннар чыныга төшкәчкә калдырмакчы идек тә,— дигән булды түгәрәк Фәнисә.

— Өйләрне шактый күп төзедек, инде матурлык, бизәүләр көн тәртибенә куелды. Сез бик вакытлы килеп җиттегез, молодцы.

Шулай итеп, кичәге авыл кызлары — таңда шәһәр кешеләренә әверелде. Кызлар рәхмәт йөзеннән көн саен Фәезнең өен җыештырып торырга рөхсәт сорадылар. Фәез риза булды, ләкин:

— Килешерме соң? Сезгә акча түләп торасы була ич алай,— дип карышкандай итте. Кызларның сөмсерләре коелды:

— Безне алай ук кимсетмәгез инде, Фәез абый, начальник булдым дигәч тә...

Бәхәс шуннан ары китмәде. Кызлар көн саен диярлек Фәез эштән кайтуга килеп җитәләр дә ярты сәгать чамасы вакытны бәйрәмгә әйләндерәләр иде. Ялга каршы көннәрдә кухня тирәсендә дә эшне җиренә җиткереп китәләр иде. Ләкин акча алу түгел, Фәез чакырса, аның исәбенә киного барырга да теләмәделәр. Алар шул рәвешле абый белән сеңелләргә тартым булып куйдылар шикелле. Һәрхәлдә күрешетирә шулай дип белә иде. Билгеле бер вакытка тикле... Ә бер көнне... Хәер, кистереп үк әйтергә ярамыйдыр. Кызларның үзләренчә әйтсәк, ашыкмый төшик, ашка пешмик. Ә шулай да вакыт үзе темп таләп итә иде. Ашыккан вакыт бәйләнешләрне тиз арада шулкадәр якынайтты, хәтта бер көнне кызлар рөхсәтсез-нисез Фәезнең керләрен уып, эчке киемнәренә хәтле юып куйганнар иде. Фәез уңайсызланып кызарынды:

— Кайсыгыз эше бу?— дип төпченгән булды.

— Без түгел, без түгел,— дигән булып котылдылар кызлар.

Ә Фәез, нишләптер, икесеннән үк димәстән, берсеннән — Зәриядән шикләнә иде. Сизелүенчә, Зәриянең күзләрендә туганлык якынлыгы гына сирпелми, ә тыйнаграк хәлдәге бүтән хис төсмерләре очкынлана, көйри шикелле. Бу төсләрне Фәез тоя да, күрә дә, тик ышанырга әллә теләми, әллә җөрьәт итми әле. Ә вакыт һаман алга чаба һәм, Фәезнең үзенең дә кайбер нәрсәләргә соңгарак калуын искәртеп, ашыгырга куша, тәвәккәллеккә өнди сыман. Фәез ашыгыр иде, кыюлыгы җитми.

Вакыт, ниһаять, Фәез өенә яңа бәйрәм булып, кызлар шатлыгы булып керде. Звонок.

— Әйдәгез, кызлар.

Бу юлы Фәез кызлар кулын сизелерлек каты һәм озаграк кысып торды.

— Безне котла, Фәез абый,— диде Зәрия керфекләреннән иң ихлас мәхәббәт нурлары чәчкәләп.

— Фәез абый, укулар тәмам, эшкә күчәбез,— диде Фәнисәсе иптәшеннән уздырып һәм Фәез абыйсының кулбашына үз тиңе итеп сугып куйды.

Аякларын салгач та тиз үк түргә уздылар да өстәлгә иң башта укуны тәмамлаулары хакындагы шаһәдәтнамәләрен ыргыттылар:

— Әнә кара, Фәез абый, чын, бер ялгансыз.

— Чын, чын! Кызлар, сез просто молодцы. Ну, котлыйм, ихлас котлыйм.

Кызларның аркаларыннан кагып аларны юри баласытып куйды Фәез. Тик алар моңа илтифат итмәгән сыман бөтерелеп алдылар да Фәезгә күзләрен йомып торырга боердылар.

— Нык итеп йом, Фәез абый, менә шушылай,— дигән булып Зәрия хәтта Фәезнең күзләрен куллары белән үк каплаган иде, Фәнисәсе иреннәрен бүлтәйткән булды һәм:

— Я инде, Зәрия, мине көнләштермә. Мин юкта кыланырсың,— дип шаяртты.

Егет күңеле бу сүзләрнең шаяру гына түгеллеген чамаларга тырышты, билгеле. Аңа шулай булуы әйбәтрәк, ләззәтлерәк иде.

— Күзләреңне йомдың, шуңа күрә ундың, Фәез абый, менә ул — безнең сезгә рәхмәтебез билгесе. Безнең исәнлеккә, үзегезнең җорлыкка, бәхетләрегез зурлыкка — рәхәтен күрегез.— Монысы да Фәнисә такмагы.

— Ну инде, кызлар, алай ук зурларга ярамый бит кешене, масайтып куюыгыз бар бит, узындырып.

— Масайсагыз да урынында, Фәез абый. Сезнең кебек кеше булмый ул дөньяда. Бүтән юк та ул.

— Булмасын, кирәге дә юк.

— Булсын — безгә кирәк! Шулай бит, Зәрия?

— Әйе шул, безгә...

Зәрия кызарып куйды. Фәез монысын да әйбәт фалга юрады. Һәм үзе сизгәнне сиздермәс өчен сүзне тиз арада икенчегә борып, кулына шешә алды.

— Беләсезме — без моны нишләтәбез — бүтән юлы...

— Юк, юк, бүтән юлы бүтәне табылыр.

Зәрия сүзләренә ышанмаганга, Фәез Фәнисәгә борылган иде, анысы да:

— Анда тагын саталар... Без эшли башлыйбыз бит.

— Ярый, сез мине тәмам егып салдыгыз, аркам — идәндә,— дип көлүдән башка чарасы калмады егетнең.

Өстәл янында шул яңалык та беленде: кызлар бүтән тулай торакка күчкәннәр икән. Монда сирәгрәк киләчәкләр. Аның каравы, Фәез үзе баргаларга сүз бирде. Ул кичтә юк-бардан кызык табып көлешә-көлешә озак кына утыргач, Фәез тәкъдиме белән киногa барып кайттылар.

Шуннан соң бер айлап вакыт узгандыр. Ләкин Фәез кызлар янына бара алмады. Тагын күпмедер узгач кына хат җибәрде. Хат бер генә кешегә, Зәриягә адресланган һәм анда күрешү урыны, шулай ук вакыты билгеләнгән иде: яңа кала, Мәскәү проспекты...

Озак көттермәде Зәрия. Елмая, кызара, сүзгә дә юмартрак... Үзе генә чакырылганга гаҗәпләнү сиздергән булды. Фәнисә көнләшә дигәнне әйтергә дә тиеш тапты, мәгәр үзе гадәттәгедән ягымлырак, чибәррәк иде. Җилдән чәчләре дулкынланып кабара, аларны җайлап үз урынына куйганда, иркә көлемсерәп, Фәез күзләренә текәлә.

— Икенче вакыт икебезне дә чакыр, яме... Син мине болай дус кызымнан аерасың бит.

— Аерам шул.

Фәез көлми иде. Җитдилеге Зәриягә дә күчә барды.

— Мин шаярып сөйләшкәнгә ачуланма, Фәез абый.

— Ә мин чынлап.

— Кызык, Фәез абый.

— Чын кызык әйтергә килдем.
— Алай булса, әйт тә куй, бергәләп көлик.
— Син безнең өйгә бөтенләйгә күчеп кил, Зәрия, ә?
— Ничек бөтенләйгә?
— Аңламыйсыңмы?
— Аңламыйм шул, Фәез абый.
— Моннан соң Фәез абый димәскә ярый.
— Нишләп?

Почта ишеге тирәсендә кешеләр күп узуны сәбәп итеп, Фәез сүзсез торды. Сүз җае эзләде. Ләкин күпме азапланса да, тапмый аптырагач:

— Зәрия, әйдә, язылышырга гариза бирәбез,— дип турыдан китмичә булдыра алмады.

— Әләй, Фәез абый... син... я лә, шаяртма ла...

— Чынлап. Чынлап, Зәрия.

— Болай ук кинәт булыр димәгән идем... Яратканыңны сиздергәнең дә юк.

— Егетләрнең чын яратуы язылышу гаризасында әйтелә бит. Шулай булгач, шаяртмыймдыр, Зәрия, чынлап.

— Мин дә...

— Риза. Ризамы?

— Әйе, беренче күргәннән бирле.

Фәез Зәрияне сак кына кочаклап, маңгаеннан үпте. Таныш түгел кешеләр елмаеп узганны алар сизмәделәр, әлбәттә.

— Фәнисә көнләшер инде, үпкәләр.

— Эх, җүләр син, просто ул дә кит.

«Кама икенче төрлерәк сөйләшер иде...»

Бергә яшәп, бер ел узгач, тагын шул чактагы кебегрәк күтелмәгән хәл килеп чыкты. Ишек шакыды Фәез, әмма җавап бирүче булмады, ишекне үз ачкычы белән ачып, кап-караңгы өйгә керде. Күңелгә дә бик тиз шундый ук караңгылык үрмәләп өлгерде бугай... Ут кабызгач та йөрәк әчетеп тибүеннән арына алмады. Ярый әле күзләре өстәлдәге язуга төште.

«Миңа ашыгыч ярдәм чакырырга туры килде. Сине озаграк көттем бугай.

Зәрия».

Өсләрен чишенмәстән, Фәез телефон трубкасына тотынды. «Әлбәттә шунда, әлбәттә шунда!». Номерлар җыеп-җыеп караса да, тик әллә нинди оешмаларга, квартираларга эләгеп бетте, ә тиешлесенә юлыга алмады. «Шәһәрдә гинекология больницасы берәү генә. Әлбәттә шунда!».

Ишеген бикләдеме-юкмы, анысын хәтеренә дә алмыйча, җан-фәрманга чыгып чапты. Мөмкин урыннардан гел йөгереп кенә узды. «Ә ишекне бикләмәдем бугай?» Ачкыч кесәдә — бикләгән, димәк. Шушы хәл аңа көч өстәгәндәй тоелып, Фәез тагын да тизрәк йөгерергә керешә. Больницага якынлашканда ул инде бер аласы сулышын ике тапкыр ала, шабыр тиргә чумган һәм үзе һаман ашыга иде. Тик болай дивана бәндәдәй килеп керү уңайсыз дип, больница тирәли ике тапкыр әйләнеп чыкты. Берничә урында абынды, бер урында ниндидер каты тимер чыбыкка эләгеп, туфлиен шактый ук сыдырып чыгарды... «Ярый әле, төнлә аякка карамаслар». Ә үзе шул ук секундта тирләгән керфекләрен, кашларын сөртеп: «Эх, Кама, Кама!»— дип авыр сулыш алды.

Кабул итү бүлмәсендә җан иясе барлыгы сизелми иде. Эчкәрге ишекне шакыгач, юан гына бер апа чыгып:

— Ник шул чаклы дөбердәтәсең, кәҗүнни ишек бар мәллә?— дип жикерсә дә, хәтере калмады Насыйбуллинның. Киресенчә, җанында мөмкин булган барлык җылылыгын җыйнап:

— Апа җаным, әйтегезче, Насыйбуллина Зәрия сездәме? Хәле ничек икән? Әйтегез, зинһар, апа җаным,— дип ялварганын үзе дә сизмәде.
— Насыйбуллина Зәрия? Списокта юкмыни?
— Нинди список?
— Соң әнә бит, диварга эленгән.
— Гафу, апа, гафу итегез. Хәзер карыйм.
Ишек янындагы исемлекләрне күздән кичерсә дә анда үз хатыны исемен күрә алмады.
— Апа, апа дим, юк анда минеке... Юк Зәрия.
— Фамилиясе ничек диден әле?
— Насыйбуллина, исеме Зәрия.
— Менә син, ә? Нишләп юк икән? Яңа гына килде микәнни? Хәзер мин карап килим инде алайса.
— Зинһар апа, мәңге онытмам.
Апа озак көттермәде һәм гомергә җитәрлек яңалык белән килде. Фәезнең хатыны Насыйбуллина Зәрия шушында — кыз баласы бар...
— Кыз бала?
— Син ир бала көткәнсең инде.
— Әйе, ну, ярый болай да. Шәп. Исән алайса?
— Икесе дә исәннәр. Бар, тиле кешедәй буталма. Иртәгә килерсең. Күчтәнәч китер, кефир, булка.
— Китерәм, апакаем, китерәм. Тыныч бул, хуш, исән булып тор, тау чаклы рәхмәт үзеңә.
— Ярый, балам, рәхмәтеңә рәхмәт. Бар.
Дөнья ярыйсы гына матур хәлгә килде. Утлар балкый. Урамнардан урамнарга атлар-атламас кына килеп чыга торды Фәез. Баш — моңарчы булган вак мәшәкатьләрдәнме, ашыгыч хәбәрләрдәнме — ахыр чиккәчә буталып каткан. Уй дигәнен уй димәссең, мәгънә дигәннең очына чыга алмассың. Ләкин башта нәрсәдер һаман әйләнә. Бушка зырылдаган турбина калаклары диярсең. Ә мәгънә юк, ә генератор ут эшләп чыгара алмый, әйтерсең ки, баш мие...
Өйгә кайтып җиткәндә ул шундый хәлдә иде. Өй эче баягыча ук ямьсез һәм караңгы түгел икән. Урам баганаларыннан төшкән яктылыкта да яшәп ятарга мөмкинлек зур икән. Шулай дя Фәез ут кабызды. Кухняга узды. Анда байлык зур иде. Зәрия, ни буласын сизенеп, ким дигәндә атнага җитәрлек ризык әзерләп киткән.
Газ өстендәге кастрюль суынып өлгермәгән әле. Газ кабызып Фәез чәйнек куйды. Тиз-тиз капкалап чәй эчкәндәй иткәч, ямьле-ямьсез уйлардан котыла язган хәлдә башын мендәргә терәде.
Иртән дөнья яңадан барлыкка килгәндә — кояш яктылыгы күзләргә төшеп әчеттерерлек көчкә ия иде инде. Үз гомерендә беренче тапкыр бу көнне Фәез эшкә соңга калган иде. Сикереп тә торды — телефонга ябышты:
— Ало, Алевтина Федоровна, хәерле иртә.
— Хәерле көн, Фәез Сәлимович.
— Сез анда сораучылар булса әйтегез әле, минем хатын роддомда. Мин хәзер шунда ашыгам. Аңлашылдымы?
— Хәле ничек? Кеме бар? Ир баламы, кызмы?
— Кыз, Алевтина Федоровна.
— Котлыйм, Фәез Сәлимович! И бәхетле дә кеше инде сез! Молодцы прямо!
— Рәхмәт. Агарков сораса, әйт минем кайда икәнне. Булдымы?
— Булмыйча соң инде, Фәез Сәлимович.
— Вакыты җиткәч үзем күренермен.
Дежурный апа әйткәнне үтәп, алган әйберләрен газетка төреп, челтәр сумкага салгач, кечкенә генә хат язды:

«Зәрия! Котлыйм! Бик шатмын. Исәнлегең өчен — бигрәк тә.

Фәез».

Җавап язарга көч тапкан иде Зәрия. Әти кешене котлаган һәм исем эзләргә кушкан. Кыз балага исемне әни кеше таба дигәннәрен ишеткәне бар иде Фәезнең. Кечкенә кебек тоелган шушы горефнең асылы хакында уйлагач, анысының да әйбәт гадәт икәнлеге ачыкланды. Нинди зирәклек халыкта — балага бернинди чит хатирә күләгәсе төшәрлек булмасын!

Һәм Фәез икенче килүендә күчтәнәчкә өстәп: «Зәрия! Минем баш әле эшләми! Исем эзләмим. Кызыбызны табарга зирәклегең җиткәч, исемен генә табарсың»,— дигән язу кертеп җибәрде.

Атна-ун көннән соң килгәч, якын кешегә әйләнгән апа: «Менә, ата кеше, Фәйрүзә атлы яңа кеше бүләк итәм сиңа!»— дип Фәез кулына ап-ак биләүгә биләнгән баланы тоттырды. Фәез ялгызы гына да түгел иде. Күрше кызлары белән килгән иде. Һәм буш кул белән дә түгел. Әни кешегә дә, дежур апага да чәчәкләрне ул үз кулы белән бирде. Шуннан соң кызлар да бәхетле анага чәчәк суздылар, чуп-чуп үптеләр. Шуларга өстәп, Фәез кесәсеннән нәрсәдер чыгарды да кызын күршеләрнең берсенә биреп, дежур апа иңенә алсу бизәкле ак яулык салды. Апаның кылган догалары, рәхмәтләре шулай ук бөтен гомергә җитәрлек иде:

— Игелекле бала икәнсең, рәхмәт яусын. Үзең дә бәхетле булырсың, аллаһы боерса. Мине болай сөендергән өчен ходай сине шатландырыр. Хатының да менә дигән, балаңны да ходай сөеп кенә бирде. Бергә-бергә картаерга язсын, тигез, тату тормыш бирсен сезгә ходаем!— дип ишек төбенәчә озата килде.

Өйгә кайткач көн буе диярлек телефон шалтырап торды — котлаулар...

Зәрияне бүтәннәр исеменнән котлап, үбәргә өлгергәнче, тагын звонок. Бу юлы... бу юлы Фәез, ни өчендер, бик үк ачык сөйләшә алмады. Бу юлы — котлаган кешенең исемен дә кабатлый алмады Фәез. Өйдә исеме ишетелә алмый торган кеше... Кама иде... Анысы уйда гына яңгырады:

«Кама, Кама, Кама, Кама!».

*

* *

— Алье! Фәез абый, сезме?
— Фәнисә? Нәрсә, килмимени Зәрия?
— Килми шул.
— Нишләп?
— Нишләп дип ни... Үзе белә инде.
— Өйгә кайтырга җыенамы, юкмы?
— Яраткан кешесе белән торсын, ди.
— Нинди яраткан кеше?
— Анысын үзегез беләсездер инде...
— Кара әле, Фәнисә, җүләрләнмәсен, әйт Зәриягә. Тиз арада өйгә кайтсын. Югыйсә, мин дә бит үпкәли беләм.
— Гулять итә дә беләсезме?
— Белмим. Дивана сүз сөйләмәгез, әйт Зәриягә — аңламый-нитми дөнья җимергәнче, белеп эшләсен, сөйләшкәч, күргәч, эшнең бөтенләй ул уйлаганча түгеллеген аңлар да үзе үк оялыр.
— Сез ояла беләсезме?
— Нәрсәдән?

— Зәрия үзе ояла белә инде.
— Уф! Ну ярый, соңгы сүзем — мин аны көтәм. Бүген мин кайтуга өйдә булсын. Әйт, минем тамчы да гаебем юк. Ничек икәнен беләсе килсә, кайтсын. Булдымы?
— Бәлки килеп алырсыз?
— Сүземне, пожалуйста, җиткерегез аңа.
— Ярый, әйтермен.
— Рәхмәт.

*
* *

Кайгы пар канатлары белән очып килде дә өйнең иң түренә оя корды. Өй сагыш белән тулды. Сагатьләп, минутлап көтте Фәез хатынын — аяк тавышлары ишетелмәде. Эштән өйгә сәгатенә сигез тапкыр шалтыратса да, трубкага кагылучы булмады. Шундый ук түземсезлек һәм каушау белән ул Агарков секретареннан чакыру хәбәре көтте. Сәгатьләп, минутлап көтте — Фәезне күрергә теләү галәмәте шулай ук сизелмәде. Аптырагач, секретарьга үзе шалтыратты:
— Алевтина Федоровна. Мине югалтмадыгызмы?
— Югалтмадык әлегә. Ник алай дисез?
— Миңа кемдер шалтыраткан — сез түгелме дип беләсем килгән иде.
— Юк, Фәез Сәлимович, эзләмәдем әлегә.
— Агарков үзендәме?
— Үзендә. Биримме әллә?
— Юк, юк. Ә министр?
— Министр да анда.
— Безнең трестка, ну, литейныйга килеп чыгасылары килмиме икән?
— Юктыр инде. Министр бүген китә бит. Аны озатырга җыеналар.
— Рәхмәт, Алевтина Федоровна, минем бетте.
Нәрсә беткәнне Насыйбуллин чынлыкта үзе дә белми иде әле. Мәгәр нәрсәдер тәгәлләнде. Монысын җанның әллә кайдагы, төпкелендәге бер күзәнәге ерак йолдыз җемелдәгәндәй сулкылдап хәбәр итә иде: бетте, бетте, бетте...
Нәрсә бетте? Фәез бүлмәсендә йөренә — ерак күзәнәк, ерак йолдыз сулкылдавы әйтеп җиткерә алмаган сорауга җавап көтә. Җавап күктән дә, җирдән дә иңми, чөнки Фәез кайбер нәрсәләрне белеп бетерми, ахрысы...
Министр киләсе көнне заказчыга мәйданнар тапшырып утырганда, нишләптер, Хәмитов, Фәез үрнәгенә ияреп, берничә кабат, Алевтина Федоровнага шалтыратты: — «Министр килеп җитмәдеме әле?» дип сораганнан соң: «Хәзер алар кайда?» дип тә өстәгән иде. Айратның ул көнге белешүләрен Фәез әйбәткә юрады — директор алдында трест җитәкчелегенең абруен күтәрергә тырыша, янәсе. Имештер, әйтергә теләп: вакланмый гына кабул иттегез, югыйсә, министрның үзе белән эшегез төшүе бар!
Хәмитовның нинди мәнфәгать белән мавыкканын Фәез хәзер чамалый, әлбәттә. Ләкин хәзер дә чамалый гына. Насыйбуллин секретарена звонок бирде, ишек ачылгач та:
— Хәмитовны чакырыгыз, пожалуйста, — дип боерды.
— Хәмитов китте бит, — диде Людмила.
— Кая?
— Министрны озатырга.
— Министрны? Озатырга?
Фәез гаҗәпләнүен ачу өянәге дип атау дөресрәк булгандыр. Чөнки секретарь кызның аптырабрак калганыннан, бүтән ни әйтергә белмичә

көтеп торып та бераздан акыртын гына ишек ябып чыгуыннан шундыйрак сөземтә ясарга мөмкин иде.

Фәез, үзен-үзе белештермәстән, тагын бер кабат Алевтина Федоровна номерын яртылаш җыйды да, трубканы дөпелдәтеп кире куйды. Җилкәсе гадәттәгечә кызып, йөрәкне ниндидер үткер металл ватыгы тырный, аяк астында ниндидер элмәк төенләнеп тартылырга азаплана. Ирек куйсаң, буарга керешер сыман. Фәез ирек куя алмый. Ул урыныннан тора да йөренә башлый. Әмма тынычлану алай да килергә чамаламый. Сорау бик катгый һәм туры: Ник? Ник үзе биргән заданиенең үтәлгәнен тикшермичә китте министр? Юк, үзе куйган бурычның үтәлгәне өчен рәхмәт әйтү дә түгел, һич югы тикшерергә, кызыксынырга тиеш иде бит? Гомумән эшнең ничек барганы белән кызыксынырга? Насыйбуллин дигән кеше барын, теге вакытта аны үз күзләре белән күреп, өстәлгә үз куллары белән сугып бурыч куйганын оныткан да, ди, шулай фаразларга тырышып та булсын, ди. Ләкин кою заводының төзелеп бетүе яки бетмәвен министр онытырга, оныта алырга тиеш түгел иде ләбаса? Онытмаган да ул аны. Кызыксынган, сорашкан да ул аны. Ләкин ничек болай Насыйбуллинсыз? Эшне башкарган кешенең үзеннән башка?

Министрның самолеты һавада икәнен белгәч тә Хәмитов Аппаков янына килеп җитте. Тегесе аэропортка җыена иде инде.

— Ислам Мөдәррисович, аэропортка мин дә барсам, килешерме икән?

— Нишләп килешмәсен, китәбез хәзер.— Аппаков күпканаллы телефонның бер сәдәфенә басты.— Игорь Дмитриевич Агарков! Без кузгалабыз. Әйе. Аэропортта очрашабыз. Булды.

Аппаков тиз генә киенүгә, чыгып та киттеләр.

Аэропорт, самолет, шатлыклы каршылау. Яңадан Якты Яр юлы. Аннары Агарков бүлмәсендә тар даирәле киңәшмә: министр, Агарков, Аппаков һәм... Хәмитов.

Министр бу юлы түр кәнәфигә утырмады, озын өстәлнең беренче урындыгына урнашты. Агарков, үз урынын буш калдырып, аның каршысына утырды. Аппаков министрның сул кулбашын якынрак күрде. Бәхетнең артык зурлыгыннан Хәмитов кына үзен кая куярга белмичәрәк азапланды. Шунлыктан Аппаков аңа үз яныннан урын күрсәтергә мәҗбүр булды. Ләкин егетнең билгеле микъдарда каушавын һәм чырае аллануын ихтирам дәрәҗәсе белән аңлатырга мөмкин иде — аэропортта министрның портфелен сорап алганда, кабинетка кереп, портфельне гардероб янына куйгач, кунакның киемнәрен кабул иткәндә һәм элгәндә, мөхтәрәм житәкчеләр арасында үзенә тиң урын таба алмыйча тыйнаклыгы аркасында җайсызрак хәлдә калганда һәм менә хәзер олы ихтирам тулы күзләр белән өч кешенең һәркайсына вакытын белеп кенә сокланып, баш ымы белән сүзләрен дөреслэп утырганда да — барысы, барысы да әдәпкә буйсындырылган галәмәтләр иде.

Агарков, төзелештәге хәлләр белән таныштыру йөзеннән, унбишегерме минутлык информация ясады. Азакта кою цехының нәкъ билгеләнгән вакытка төзелеп бетүен әйткәч, министр ихлас елмайды. Шул чакта Аппаков:

— Иптәш министр, бу хакта җавап бирүне гаепле кешеләрнең үзләреннән лично сорарга вәгъдә иткән идегез. Хәзер бәлки аларны тыңларбыз?— дип сүз кушкан иде, Агарков сөйләүдән тукталып:

— Анысы бәлки икенче юлы?— дигән сорау белән министрга карады.— Кешесе юк бит.

Ләкин Аппаков аны җөпләмичә:

— Минемчә, тиешле кешеләр барыбыз да монда,— дип, Хәмитовка ишарәләде.— Трест управляющиеның урынбасары — Хәмитов Айрат Бариевич.

Айрат Бариевичны тиешле микъдардан артыграк кызартып, министр:

— Ә нишләп управляющий үзе юк? — дип, ана туп-туры карады.

— Аның... Аның белән җайсызрак хәл килеп чыкты шул.

— Эш нәрсәдә?

Уңайсызлыктан Хәмитов боргаланса да җайсыз хәбәрне яшерә алмаган рәвештә әйтергә тиеш булды:

— Хатыны белән шунда...

— Ни булган? — дип Аппаков дөреслекне ашыктырасы итте.

— Насыйбуллинның хатыны белән... кызлар арасында скандал килеп чыкты. Аерылышып йөриләр. Шул мәшәкать аркасында...

— Нинди җавапсызлык! Шушындый вакытта! — Агарковның, да министрның да бу хәбәргә исләре бик китмичә утыруы аркасында килеп чыккан бушлыкны тутыру өчен Аппаков тагын дәвам итәргә тиеш тапты. — Каһарманнарча килеп чыкмаган. Әйдә, үзең докладывай. Игорь Дмитриевич, шулай дөрес булыр бит?

Агарковның да, министрның да сүзсез ризалыгыннан соң кул ишарәсе белән Хәмитовны урыныннан торып басарга мәҗбүр итте. Хәмитов, баягы каушавын тиз онытып, тигез дулкынлану белән сөйләргә керешә.

— Хөрмәтле иптәш министр, сезнең лично үзегез куйган гаять авыр, ләкин мактаулы бурычны уңышлы үтәү өчен без бөтен коллективның барлык көчен, тырышлыгын тупларга тырыштык. Бурычның кем тарафыннан куелганлыгын, аның партия карарларын тормышка ашыру юлындагы әһәмиятен һәр бүлекчәдә аңлаттык. Үзегездән киңәш, ярдәм сораган чакларыбыз булды — ярдәмегездән мәхрүм итмәгән өчен, аталарча кайгыртуыгыз өчен зур рәхмәт әйтәбез сезгә. Иптәш Агарков белән иптәш Аппаков безнең эшкә көне-сәгате белән исәпләшмичә, оештыру эшендә безгә ярдәм иттеләр. Коллектив тырышлыгы әрәмгә китмәде. Бүген без зур канәгатьләнү хисе белән сезгә рапорт бирәбез: билгеләнгән задание, сез куйган бурыч тулысы белән үтәлде. Без барыбыз бергәләп: зур җиңүгә ирештек, дип белдерә алабыз. Сезне, хөрмәтле җитәкчеләр, шул җиңү белән котларга рөхсәт итегез.

Җитәкчеләр, әлбәттә, елмаебрак булса да, рәхмәт әйттеләр. Сөйләшүнең дөрес барачагын тойган Аппаков, бүлмәне вакытлыча калдырып, мөһим эшләре буенча каядыр шалтыратып керде. Ул югында да югалып калмыйча, Хәмитов ул кергәч тә чыгышын ярыйсы гына матур төгәлләде.

— Кыенлыклар, әлбәттә, булды, хәтта бик күп булды дияр идем. Ләкин аларны без җиңеп чыга алдык. Аларны без киләчәктә дә истә тотарбыз. Нәтиҗәләр ясарбыз. Тәҗрибә киләчәк уңышларга юл ачар, дип уйлыйм. Кайбер теләкләр, күрсәтмәләр сездә бардыр. Без аларны игътибарга алырбыз. Ә хәзер, хөрмәтле җитәкчеләр, коллективның олы җиңүен вакламыйча, зур көенчә сезгә тапшырам. Кабул итегез — кою заводы әзер!

Хәмитов, җитәкчеләрнең өчесенә дә ихлас ихтирам белән елмаеп утырды да чигәләрен, чәчләрен сыйпап куйды. Минут чамасы гына булып алган тынлыктан соң министр телгә килде.

— Ну что же. Яхшы, иптәш Агарков, хәтта бик тә яхшы. Йөзне кызартмадыгыз — молодцы. Меңнәрчә кешелек коллективта хезмәте икърар ителмәгән бер генә кеше дә калмас дип ышанам. Конкрет кешеләр хезмәтен ачыклап куегыз. Ташламалар ясамыйча, гадел рәвештә. Һәркемне үз өлешенчә теге яки бу формада билгеләп үтү булыр — тантаналы шартларда. Вакытын эш барышында киңәшербез, дип беләм. Шулай бит?

— Шулай, әлбәттә, шулай,— дип җөпләде аны Аппаков.— Монысы безнең җаваплылыкта... киңәшербез, уйлашырбыз. Киләчәктә яңа бурычлар хәл иткәндә дә сынатмаска тырышырбыз.

— Булды, аңлашылды. Сезнең, Агарков?

— Хәзергә җитеп торыр, ахрысы,— диде Агарков.— Кирәк булса, тагын киңәшербез. Чиратта эшләр күп, яңа заводлар...

Җитәкчеләр бераз утыргач та предприятиеләрдәге эшләрне үз күзләре белән күрер өчен калага һәм далаларга юл алдылар. Хәмитов аларны баш идарә алдында озата калды. Машиналар арасында шактый вакыт уйсыз басып торганын абайлап, ә башына зиһен килгәч, тәмам арганын тоеп, шунда барча йончулардан берьюлы котылыр өчен иң якын кибеттән бер шешә коньяк белән ризыклар алды да өенә ашыкты. Көн буе үзе теләгәнчә ял иткәч, икенче көнне тыныч һәм ышанычлы адымнар белән трестка килде, сагая төшеп үз кабинетына керде. Насыйбуллинның күзгә чалынмавы хәерлерәк сыман тоелды.

Кабинет ишеген гадәттәгедән катырак япкач исә әлеге хис юкка чыкты. Газеталар кулга эләгүгә хәтта күңелне тантанага охшаш җиңеллек биләп алды. Кала газеталары турында әйтеп тә тормастан, республиканың һәммә газеталары кою заводының файдалануга бирелүе хакында хәбәрләр, фотографияләр бастырып чыгарганнар иде. Тарихта калачак беренче сурәт: дистәгә якын кеше арасында кою заводының смена башлыгы Сәгыйдулла Гайнуллин, төзелеп беткән яңа заводта коелган беренче детальне кулында тотып, киләчәккә елмая... Шундый ук елмаю тарихта калачак икенче сурәттә: министр, Агарков һәм Аппаков. Алар янында басып торган Айрат Бариевич Хәмитов чыраена чор бөеклеге яктылык шәүләсе булып төшкән...

Сурәтләрдә дә, хәбәрләрдә дә Насыйбуллинның исеме-төсе юк. Кәгазьләрдә аңа урын җитмәгән булса кирәк...

Уйларны сискәндереп, телефон шалтырады.

— Управляющийда планерка.

Бүлмәдә беркем булмаса да, Айрат Бариевич кызарып куйганын, тәне буйлап эссе чымырдау узганын сизде. Иртәнге җил искәндә тыныч күл өсте шул рәвештә чуарлана торгандыр. Зыян юк, һәр нәрсә башта гына сәер тоела, соңыннан барыбер, хәтта гайре табигый сыман тоелган хәлләргә дә күнегәсең. «Эшләр рәтле безнең. Җиңүчеләр кыю булырга тиеш».

Гәүдәсен туры тотып, Хәмитов управляющий кабинетына керде. Гадәттәгечә, бүлмәдә — ун-унбиш кеше. Гадәттәгечә, сүз кичәге эшләргә бәя бирүдән башланды. Мәгәр Насыйбуллинның кыяфәте гадәттәгедән нык аерыла иде. Күзләре кызарган, чырае чирле кешенеке төслерәк агарып калган. Тавышы да элеккечә кискен түгел, шактый ук көчсезләнгән. Бу үзгәрешне, мөгаен, сизсә Хәмитов кына сизә, күрә торгандыр.

Әзер мәйданнарны заказчыларга тапшыруның уңышлы төгәлләнүен хәбәр иткәннән соң, управляющий картинаны төгәлрәк тасвирлау өчен баш инженерга сүз бирде. Глазов:

— Фәез Сәлимович әйткәнчә, гомумән, бер максатка ирештек,— дип кенә куйды да, шунда ук кыенлыклар, аларның ничек җиңелә баруын тәфсилләп сөйләргә кереште.

Хәмитов кичә зуррак категорияләр белән эш иткән иде. Масштаблар — җир белән күк арасы! Ваклыклар белән мавыгып, кешеләр зурны ычкындыра. Болай ярамый, болай тиеш түгел: олы мәгънә — зур эшләрдә, шулар хакында уйларга, бигрәк тә сөйли белергә кирәк. Насыйбуллинча түгел, бигрәк тә Глазовча түгел. Булып узган вак кытыршылыклар хакында, җитмәсә, Глазов әнә ничек кайнарлана бит. Бушка, кирәкмәгәнгә, файдасызга. Ә бит эшләнәсе инде эшләнгән, беткән...

— Шуның өстәвенә,— дип тәмамлады сүзен Глазов,— кайбер иптәшләр үзләрен азакка кадәр егетләрчә тота алмады.— Бу минутта Хәмитовның колаклары үрә торды.— Управляющий урынбасары иптәш Хәмитов, мәсәлән, үзенә управляющий йөкләп калдырган вазифаны, мактаулы бурычны — заказчыга әзер мәйданнарны тапшырып бетерүне ташлап китте дә каядыр юкка чыкты.

«Кем югалгандыр әле, карарбыз!» — дигән бәяне бирде моңа каршы Хәмитов. Ләкин колаклары теләккә туры килмәгән сүзләр ишетә биреп, йөзе карала төште.

— Бу эштә Хәмитов үзен нәкъ чит кешеләрчә тотты. Күзәтүче хәлендә. Мин иптәш Хәмитовны, гомумән, төзелешкә файда китергән, зур өлеш керткән дип исәпләмим. Моны мин аның сәләте бәләкәйлектән дип кичерергә тырыша идем. Ләкин эш җитдирәк тоела башлады. Кичәге поступогын ул үзе ничек аңлатыр, минемчә, хәзер аны тыңларга кирәк.

«Газеталарны, алардагы хәбәр һәм сурәтләрне күрмәгән, әлбәттә. Болай кылана алмас иде. Әнә бит, Насыйбуллин...»

Насыйбуллин тыныч кына утырган иптәшләргә күз йөртеп чыкты:

— Тагын кем сөйләргә тели?

Кичәге зур җиңүдән соң да сүзгә күчәргә атлыгучы күренмәде. Димәк, алар Глазовча фикер йөртә.

Насыйбуллинның карашы Хәмитовка төбәлде. Хәмитов исә секундны да әрәм итмәс өчен шунда ук кул изәде — сөйләргә теләге бар.

— Хәмитов. Тыңлыйбыз,— дип кырыс кына игълан итте Насыйбуллин.

Гадәттә планерка вакытында утырган килеш кенә сөйләүне артыграк күргән Хәмитов бу юлы аягүрә басты. Дулкынлануы күзләрен кызартып өлгергән, һәм күңеленнән тышка бәреп чыгарга ашыккан басым көченә аның тыярга теләге юк иде. Шул ук вакытта вакланырга ярамаганны да бөтен тәне белән сизә иде. «Мөмкин кадәр — кичәгечә, кичәгечә!— дигән өнсез бисмилладан башлады Хәмитов.— Иман кешегә көч бирә».

— Әйе, без бу җиңүгә ел буе зур тырышлык белән атлап килдек. Барчабызның тырышлыгы, коллектив каһарманлык дияргә кирәк, әйе, шуның аркасында килгән олы җиңү бу. Әйе, тыйнаклык уйнау бүген урынсыз. Без үзебезнең бу җиңүебезне чын горурлык белән телгә алабыз икән, безне һичкем гаепли алмас. Кичә, мәсәлән, югары оешмаларда, безне аңладылар. Әйе, җиңү, олы җиңү. Безнең хөрмәтле җитәкчеләребез дә аны шулай бәяләделәр. Мин сезне министр, баш идарә управляющие Агарков һәм Аппаков исеменнән ихлас күңелдән котлыйм.

Мәҗлес халкын телсез калдырып, Хәмитов моңарчы һич күрсәтә алмаган олпатлык белән, салмак кына атеп, үз урынына утырды. Глазов Насыйбуллиннан күз аера алмый, Насыйбуллин — аннан. Бүтәннәр исә бер Хәмитовка, бер управляющий белән Глазовка күз текәп, ни әйтергә белмичә аптырый калдылар. Бар да Насыйбуллиннан сүз көтә иде. Әмма Фәез бу мәлдә ни дә булса әйтерлек хәлдә түгел иде шул. Фәез бу мәлдә колаклары ишеткәнгә ышана алмыйча газап чигә иде. Шуңа күрә:

— Дәвам итегез, Хәмитов,— дип, үтә дә кыюсыз, бәлки әле мәгънәсез үк сүз кушкач, иптәшләрнең гаҗәпләнүе арта гына төште бугай. Карашлар ихтыярыннан ычкына алмыйча, Хәмитов яңадан торырга мәҗбүр булды.

— Тагын ни әйтергә мөмкин? Әйттем ич?

«Әһә, хәзер эшкә күчәргә мөмкин».— Шундый фикер белән Фәез, уртәлүен нәзакатьлек кыяфәтенә төреп, Хәмитовтан көтелгән җавапны кабат искәртергә тиеш тапты:

— Әйтеп бетермәдегез, Айрат Бариевич. Глазов сезгә шактый житди замечание ясады. Иң хәлиткеч мәлдә эш урыныгызны ташлап киттегез, дип гаепләде. Әйтергә кирәк, бик зур гаеп. Моның өчен икегезнең берегез жавапка тартылырга тиеш. Кайсыгыз хаклы? Иптәшләрнең менә шуны беләселәре килә. Завод чаклы заводны заказчыга биргәндә үзенә махсус кушылган эшне ничек ташлап качарга мөмкин? Нинди вөждан белән? Сез менә шунысын әйтеп бетермәдегез. Көтәбез, Хәмитов?

Хәмитов көлеп куйды.

— Кызык. Минемчә, сез ялгышасыз. Киресенчә, бәләкәйрәк эшне үз иңнәренә калдырып, үз җилкәмә зуррак йөк күтәрдем мин. Сез күтәрә алмаганны, иптәш Насыйбуллин. Мин кирәкле эш башкардым. Безнең трест управляющийсыз, җитәкчесез калган хәлиткеч бер моментта, мин, аның урынбасары, шул вазифаны да өстемә алганмын икән, бу минемчә, һич тә җинаять түгел. Әйе, мин үземнең иҗтимагый бурычымны гына үтәдем. Министр да, Агарков та, Аппаков та минем докладтан канәгать калдылар.

— Кем... Кем синнән сорады шул эшне?— дип кычкырып сораудан тыелып кала алмады Насыйбуллин.— Кем?

Ләкин Хәмитов андый гына кискенлектән каушарлык түгел иде инде. Ул инде тантана итә иде.

— Бүтәнчә ярамый иде. Югыйсә без югары оешмалар каршында тиешле дәрәҗәдә күренә алмас идек. Эшнең үтәлешен белер өчен махсус рәвештә Мәскәүдән министр килгән икән, рас Агарков белән Аппаков миңа мөрәҗәгать итә икән, сезнең кәефкә туры килмәгән өчен генә баш тарта алмыйм бит инде. Гафу итегез, завод төзелешенең җиңү белән тәгәлләнүе хакында рапорт бирдем.

Ниһаять, иптәш Насыйбуллин, колакларыңа ышанырга мәҗбүр син. Кичә генә тулы хокуклы управляющий икәнеңне белсәң, бүген инде бүтән дәрәҗәдә булуыңны аңладың. Хәл шуннан гыйбарәт: ерак хатирәдәгечә, җилкәңә кемдер, баш миенә батып керерлек итеп, тимердән дә катырак нәрсә белән китереп орды. Һушыңны җуеп, күпмедер вакытка өнсез калдың. Иптәшләрең хәзер сиңа күзләрен зур ачып карап торалар. Син шундый кызганыч хәлдә: егылмасмы дип сагайдылар. Ярамый, ярамый болай. Әз генә калган өметкә чытырдап ябыш, өстәл читенә генә түгел. Шулай, менә шулай. Һәм молодец, авып төшмәдең. Хәзергә шул да бик җиткәндер. Әйе, көл төсле чырай белән булса да утырып калдың. Акрын-акрын күзләрең дә бүлмәне кабат күрә башлады. Һәм менә хәтта күкрәкнең әчеткән бер төшендә сүз укмашып, телгә дә килде:

— Негодяй!

Бу сүзне Фәез беркемгә карап әйтмәсә дә, адресат аны тайпылышсыз кабул итте.

— Гафу итегез, кем була инде ул «негодяй»? Телегез әйткәнне колагыгыз ишетәме?

Шушы рәвешле чын күңелдән әрепләшәләр икән, әле синең хәл начар ук түгел дигән сүз.

— Бүгеннән башлап бер трестта безгә урын юк.

— Монда мине сез куймадыгыз.

— Мин! Үз башыма — мин үзем! Ә хәзер, хәзер бу кабинетны калдыруыгызны үтенәм.

— Бу кабинетта кем калыр, анысы билгесез әле.

— Слушай, Хәмитов,— дип Глазов урыныннан сикереп торды да чак кына талпынып куйгандай итте һәм түр өстәлгә бармакларын терәп, сүз белән канәгатьләнә алды.— Кеше белән шулай тупас сөйләшергә кем хокук бирде сиңа? Нинди хезмәт белән яулап алдың аны?

— Синең кебек ялагайдан түгел.

— Ничек? Ничек диден?
— Ишеткәнеңне әйттем. Шунысын өсти алам: ставканы бик үк шәп атка куймыйсың. Акылың булса... акыллырак булсаң... Ә син миңа алай чекерәймә, куркытуың бар.
— Менә бит нинди кеше син!
— Хәзер үк, ишетәсеңме, Хәмитов, кабинеттан хәзер үк чыгыгыз. Аякларыгыз басасы булмасын бу идәннәргә бүтән.
— Сездән соң, иптәш Насыйбуллин. Анда да бик ашыкмыйча.
— Ярый, аңлашылды.— Фәез ирексездән ямьсез хәлгә шаһит булып утырган кешеләргә карады.— Гафу итегез, нәрсәнедер күреп җиткерә алмадык. Сизенә идем, әлбәттә. Ләкин шуннан узылмады. Ары таба болай барып булмый. Планерканы, Глазов, азагына җиткерегез.
— Фәез Сәлимович! Ашыкмагыз!
— Әйе, сез төгәлләгез, үтенәм.

Шул сүз белән Фәез үзенең ял бүлмәсенә кереп китте. Бераз гына арлы-бирле йөренгәч, карават башына иелеп, ике учы белән күзләрен каплады. Күзләр күрми торганда чак кына дөнья тынычлангандай тоелып китте. Утырды. Шунда бераз гына оеп та китә язды бугай. Унунбиш минут узганнан соң аркасыннан кемнеңдер чәбәкләгәнен абайлап баш калкытса, Глазов икән.
— Я, ничек?— дип сораган булды Фәез, гәрчә тәгаен нәрсәнең ничек икәнлегеи уйлый ук алмаса да.
— Планерканы төгәлләдек. Заданиеләр ачык, төгәл.
— Ә! Рәхмәт. Бүтән көннәрдә дә шулай дәвам итәрсең.
— Аңламадым, Фәез Сәлимович.
— Үзем дә аңлап җиткермим. Шуңа күрә әйтүем. Хәзергә бөтенесен үзең кара. Миннән башка. Аңладың бит?
— Аңладым да...
— Хәзергә шунысы җитеп торыр.

Фәез елмаерга көч тапты. Елмаеп дусларча кул кысышкач, җәяүләп өенә кайтып китте. Өйдә чебен очса, аның канат тавышлары да ишетелер иде. Чебеннәрме, әллә чебеннәрдәй зеңләп секундлар очамы? Юк, колакта — тынлык чыңы. Ә җилкә яна, ялкыны башка каба... Баш үз вазифасыннан баш тартмакчы. Ләкин зиһеннең дезертирлыкка, тик торырга хакы юк. Нәрсә булса да уйласын һәм уйлар чоңгылыннан тиешле карар тапсын... Малай чакта су төбеннән ком алып чыккан кебек... Кайчак кулга бака кабырчыгы эләгә иде... Буш кабырчык, ләкин ул да табыш санала иде. Ә хәзер кулга ни эләгер? Әһә! Сорау туды! Сорау — хәрәкәтнең башы. Сорау тудымы, җавап мәҗбүри табыла, табылачак.
Сорау:
— Әгәр заводны төзү, тапшыру заданиесе үтәлмәсә, өзелсә? Ул чакта да Фәезне эзләмәсләр, Хәмитовны табып, аннан гына җавап сорарлар иде микән?

Эзләрләр иде һәм бик тиз табарлар да иде. Ә җиңү килгәч, Фәезнең кирәге бетте. Җиңү! Җиңү! Җиңү килгәч, батырлар күбәя. Җиңелү килсә, кискәгә бер кеше башы куела. Анда ул башны тиз табарлар иде. Ә хәзер... Хәзер лавр яфраклары тезәргә җайлырак, ягымлырак башлар килеп чыкты, күрәсең. Ахрысы, Фәезнең мескен башы лаврлар белән бизәлер өчен түгел, кискәгә куяр өчен генә яратылган булгандыр. Заманнар бүтән булса, Фәез гомере шулай чикләнгән булыр да иде микән?

Мәгәр болай булырга тиеш түгел. Әле Фәезне тагын эзләячәкләр, табачаклар, фикер сораячаклар, гәрчә рапорт бирергә инде барыбер чакырмасалар да. Фәездән өлгеррәкләр алга узды... Шундый да өлгерлек! Әгәр шундый җитезлек барын моңарчы башына китерә алса, Фәез башкачарак эш иткән булыр иде: болай ук гамьсез булмас иде. Ләкин

барыбер, барыбер аны табачаклар, чакырачаклар, сөйләшәчәкләр. Моңа ирешү юлы бар шикелле — көтү, түземлелек... Сабырлык өчен бүләк — сары алтын... Әйе, кызыл, ал төсләрне Фәез инде җуйды. Нишлисең, һәркемгә үз өлеше — сары да матур төс... Ямьсез төсләр юк, ямьсез эшләр генә бар...

Күпме көтәргә туры килер икән — бер, ике, өч көн?

Хатынсыз, баласыз, хәтта чебенсез өйдә тынлык зеңгелдәвен — дүрт стена фаразларын тыңлап күпме түзәргә мөмкин?

Хатынсыз, баласыз, чебенсез өйдә диварлар телгә килде. Диварларданниндидер җәнлек шәүләләре уза. Шуларның берсе ас дип атала. Диварда Кама тугае сурәт шикелле җанлана... Кама тугаенда Фәез балык тотып утыра.

Җил тими — ышык, тыныч. Балык үзе дә сагындырмый гына каба тора. Каршыда — ак матурлык. Ә артта... Артта ниндидер чыштырдау... Балык кечкенә резинканы тирбәтеп куйса да, Фәез артка борылып карамыйча булдыра алмады. Караса, ниндидер бәләкәч җәнлек. Аңа эндәшә дә, чакыра да алмады ул. Шулай да елтыр күзләр гаепсез елтырап, күңелдә ниндидер яктылык җемелдәтеп куйды. Гөнаһсыз кечкенә күзләр кеше карашы белән очрашкач та тере, шаян килеш ялтырый бирделәр. Матурлык өчен рәхмәт йөзеннән кеше аңа бер-ике балык ыргытты. Тик җәнлек курыкты һәм каядыр чабып китте. Каядыр түгел, илле-алтмыш метр ераклыктагы вак агач өеме артына. Ул көнне җәнлек бүтән күренмәде. Ләкин бер бирелгән бүләк кире алынмый. Балыкларны шул килеш калдырды кеше. Һәм ялгышмады. Иртән килүенә ул калдырган күчтәнәч юкка чыккан иде.

Кеше янә, озак кына резинка көпшәгә карап, балык каптырып утырды. Һәм бер заман — яр өстендә тагын чыштырдау... Таныш чыштырдау. Кеше күтәрелеп караса, яр өстендә башын-муенын уйнаткалап, кичәге елгыр танышы тора иде.

— Я, исәнме? — җәнлек җавап итеп, борын очларын кыймылдатып куйды.

Җәнлеккә инде исем кушарга да мөмкин икән — ас дип атала бу җәнлек, бу елларда күзгә бик сирәк күренә торган кунак.

— Балык ошадымы соң? Әһә, ошаган. Мә, алайса тагы.

Балыктан бу юлы курыкмады ас. Качмады, ләкин кагылмады да. Ул аны кеше киткәч кенә алачак.

Икенче көнне балык тагын юкка чыккан иде. Һәм бу юлы да кеше бераз гына утыргач та чыштырдау кабатланды.

— Әһә, бик шәп. Килдеңме? Бик шәп. Менә кулга эләккән беренче балык — синә. Ал, курыкма, ал.

Асның ятсынуы күзгә күренеп кимегән иде. Балыкны ул тәпиләре белән капшап карады, мәгәр ашамады. Аның күзләре һаман кешегә карый һәм ниндидер җылылык сирпи иде. Бу — күчтәнәч өчен рәхмәт билгесе, мөгаен.

Шул көннән соң кеше белән ас күп нәрсәләр хакында сүзсез аңлаштылар — таныштылар һәм дуслаштылар. Шуннан соң алар инде бер рәттән диярлек утыра башладылар. Кеше балык тота, ас карап тора һәм сый өчен сикергәләп сөенечен белдерә, рәхмәтен әйтә.

Шулай бер ай чамасы вакыт узгандыр.

Алда — кармак, артта ас уйнаклавы... Һәм күз ачып өлгергәнче — ямьсез бер адәм акыруы. Акыру гына түгел, ят кеше йөгереп тә килде һәм аска йодрык кадәр таш та тондырды. Тотмакчы булып, куып та карады. Ә Фәез:

— Нишлисез, котырган мәллә сез? — дип балык тоткан җиреннән ярга менеп кычкырса да инде соң иде.

Ас дигән җәнлектән җилләр искән. Ят юлаучы, арттарак калган чана бавын яңадан кулына эләктереп, яңадан көйле генә атлап китте:

— Ас ләбаса! Ас! Нинди кыйммәтле тире! — дип мәгънәсез мыгырданды үзе.

Икенче көнне балыкларны ас өчен махсус тотып, әзерләп куйса да аргта таныш кыштырдау ишетелмәде, кабатланмады. Икенче-өченче көнне дә шулай. Аптырагач, Фәез:

— Сиңа таш ыргытучы мин түгел ләбаса. Мин сиңа гел балык кына ыргыттым. Минем бер гаебем дә юк ләбаса, ник миңа үпкәләдең син, ник килмисең? — дип ялварса да ас елтыр күзләрен түгел, бәләкәй койрыгын да күрсәтмәде шул.

Аннары кеше кабат очрашуга өметен бөтенләй өзде һәм ялгышмады. Шуннан соң инде менә өчме, дүртме ел узса да, һаман күзгә күренми җәнлек. Күренмәс тә. Ләкин ул күңелдән дә китмәс — күзен елтыратып карар да торыр. Ә гаепле кешегә ни җаза? Югалту ачысын кичердеме ул? Фәездән башка беркем берни югалтмады, беркем берни... Югалтуларның инде саны да югалып бара бугай, ләкин ас һаман иреннәрен уйнатып килә дә чыга, килә дә чыга. Аңлатуы кыенрак була. Һаман да шулай.

— Югал күздән, ас, тизрәк кач син. Ас, кач, кач!

Җәнлек исә һаман үҗәтләнә, күктәге йолдызлар рәвешле итеп күзләрен җемелдәтә.

Аны куркыткан кеше белән дә бәхәс һәр йокысыз төндә яңара...

— Ни дип куркыттың син аны?

— Ничек инде ул «ни дип»?

— Максатың нәрсә иде — таш ыргытуның мәгънәсе?

— Максат, мәгънә... Кызык булды миңа, кызык! Аңлыйсыңмы? Ә сиңа ни зыяным тиде? Әллә кулыңнан берәр әйбереңне тартып алдыммы?

— Алдың шул. Нәрсә икәнен атап әйтә алмыйм. Мәгәр бик тә кыйммәтле бер әйберемне тартып алдың.

Хатынсыз, чебенсез, тормышсыз өйдә якты күләгәләр генә яшәү галәмәте сиздерә. Күз алдыннан уйнаклап елтыраган елгыр җәнлек Зәрингә, һәм аны куркыткан адәм Хәмитов кыяфәтенә кереп куя. Ул да булмый, караңгыдан Кама күзләре текәлеп карый. Кама янында Фәез үзе дә бар икән. Алар урамда икән. Алар урамның ике ягыннан атлыйлар. Каядыр туктаусыз баралар.

— Кама, син, бәхет эзләп, бәхетсезлек таптың. Теге чактагы кебек, тузбаш дип, тагын зәһәр еланга туры килдең. Теге чакта агудан арынсаң, хәзер инде беркайчан да, беркайчан да хатаңны төзәтә алмассың. Син үзеңне, мин яраткан Каманы, мәңгелеккә югалттың. Бүтән таба алмаячаксың — минем кебек үк. Беркайчан да!

Икесе урамның ике ягыннан атласа, икесе бер таба барсалар да, озакламыйча, араларына автобуслар, трамвайлар, йөк машиналары дөбер-шатыр килеп керә. Инде кабат бергә булыйк дигәндә, корыч шау астына килеп эләгүең бар... Һәлакәт хәтта үзенә чакыра да кебек. Шуңа карышу йөзеннән Фәез бөтенләй кирәкмәгән якка, җәһәннәмдәй чокырлы-чакырлы төбәккә — Мәләкәс атлы инешкә таба ярсынып атлый. Әйтерсең, анда кемдер көтә...

Адәм чыккысыз ярдан мәтәлеп имгәнә язса да, баш һәм арка миләре селкенсә дә, юк, тиз генә хәл ачыкланырга ашыкмый. Мәләкәснең бер бетон торбага сыеп калган мескен агымын кызганудан башка хис туа алмый. Тик бер нәрсә ачык төсмерләнә кебек: нидер үзгәрде, гомергә төзәлмәс өчен имгәнде. Яшәүнең дә моңарчы булган көен, рәвешен әлеге үзгәрешкә яраклаштырып, дөньяга мөнәсәбәтне дә үзгәртергә туры киләчәктер. Яңа хәлдә искечә яшәү кебек аңсызлыкка, булдыксызлык оятына дучар булмаска кирәк. Тиз, тизрәк!

Төшләрне, уйларны, караңгылыкны аралап, җир өстенә якты иртә килә. Баш конвейерның ишек төбендә — халык. Җирнең ак күкрәгенә тантана сәбәбе күтәрелә:

— 000 001 — гаҗәеп сан, капкадан чыгып, пьедесталга менә. Ул! Ул!

Тантана уртасында Павел белән Фарук. Теге чакта Фарук халык алдына чыгарга курыкса, баһадир машина — корыч җанлы, бернинди каушау белмичә, тыныч гөрелди. Аның корыч сүзе радио аша илгә тарала. Аның корыч сүзләрен хуҗалар, төзүчеләр, Мәскәүдән, Казаннан килгән кунаклар дәвам итә. Баһадир машинаның кабинасына — кызыл комачка ак хәрефләр белән язылган горур мәгънә күкри:

— Кабул ит, Ватан! Бездән — беренче машина!

— Безнең урамда бәйрәм бит, шайтан алгыры! — дип кем өчендер кабатлый Насыйбуллин.— Җирдә барыбер чын хезмәт, чын гаделлек тантана итә! Ялганнан автомобиль яралмый. Ялганнан бары тик ялган ярала.

*
* *

— Фәез Сәлимович, хәерле көн!

— Исәнме, дөнья!

— Сезне Агарков күрергә тели.

— Рәхмәт, Алевтина Федоровна. Кайчан?

— Бүген сәгать бишкә ул сезне көтә. Вакыт табарга тырышыгыз.

— Вакыт юк инде ул. Ләкин... Ярый, барырмын!

Әйе, түземлек — көч. Әнә бит чакырдылар, үзләре таптылар, кирәк булгач. Билгеле дәрәҗәдә максатка ирешелде.

Фәез Агарков ишеген ачты. Аппаков та шунда икән. Иртәрәк килдем, ахрысы, дип, ишекне кире япмакчы иде, тик Агарков тизрәк әйтеп өлгерде:

— Әйдә, Фәез Сәлимович, уз.

Узды Сәлимович. Баш управляющий карашы күрсәткән урынга — озын өстәлнең беренче урындыгына килеп утырды. Хәл-әхвәл сорашканнан соң Агарков:

— Кайда югалдың син? — дип сорады.

— Югалганым юк, Игорь Дмитриевич.

— Нишләп эш урынында түгел?

Шушыннан соңгы әңгәмә берьюлы ике телефоннан сөйләшкән кебегрәк килеп чыкты. Кырыс сорау — Аппаков тавышы. Аңа шундый ук җавап. Тынычына — Агарковка — тыныч сүз.

Кырыс сорау:

— Соңгы имтихан вакытында сез кая югалдыгыз?

— Кайчан?

— Әйтик, кою заводы мәйданында дәүләт заданиесе төгәлләнгән көнне. Сугышчан бурыч үтәгәндә.

— Сугышчан бурыч үтәлгән һәм төгәлләнгән көннәрдә, һәрвакыттагыча мин үземнең сугышчан постымда булдым.

— Ягъни, ресторанда?

— Төш вакытында бер сәгать.

— Аннары?

— Аннары кою заводы дирекциясендә. Иртәнге сигездән башлап, кичке тугызга хәтле. Кемнәрдер сезгә рапорт биргән чакта, без әле...

— Сез әле кемнәр беләндер күңел ача идегез. Хатыныгыз белән аерылышуга көч түгә идегез.

Фәез, бөтен хикмәтне берьюлы аңлап, кабынып китте. Барлык рәнҗү-үпкәләре, алдану, мыскыллау әчесе кушылган ачуы берьюлы дөрләп китте:

— Болары — минем шәхси эшем. Минем әлегә сездән ярдәм сораганым юк. Сорамам да.

— Ә мораль? Җитәкче морале?

— Кайберәүләр кебек мин карьера өчен җанымны сата алмыйм.

— Кемнәр кебек?

— Үзегез уйлагыз. Сезнең бурычка керә ул.

Агарков сагая, Аппаков бераз аптырый калды. Нәрсәнедер төшенделәр шикелле. Шунда Аппаков сүзне икенчегә борырга тиеш тапты:

— Гади эшче, бетончы, балта остасы, бульдозерчы, хәтта бригадирның прогул ясавын күз алдына китерү мөмкин. Шуннан да югарырак белгечләрнең, юк, гафу итегез, күз алдына китерә алмыйм. Ә бит сез, гафу итегез, трест управляющие! Һәм прогулчы! Моның өчен гайре табигый сәбәп кирәктер.

— Сез сәбәп күрмисезме?

— Гафу итегез, күрмим.

Фәез тагын кискен сүз ычкындырмагае дип, тыныч утырган Агарков сүзгә катнашырга булды:

— Сез бәлки югалып торуыгыз белән нәрсәдер әйтмәкче булгансыздыр, ә? Мин бераз сизенәм шикелле. Төгәл беләсем килә: теләгегез нәрсә?

— Теләгем шул гына — үземнең киләчәксез кеше түгеллегемне сиздерергә тырышу.

— Юкка. Сез инде аны расладыгыз.

— Кирәгем бетеп киттеме?

— Көязләнмәгез, Фәез Сәлимович, сезгә килешми алай.

— Ышанасым килә.

— Сез гидротехника буенча белгеч бит әле?

— Әйе, төшенәм, рәхмәт.

— Анда җиңелрәк булыр дисезме? Уйлап карагыз. Ялгышмаслык булсын, үкенмәслек.

— Аңлыйм. Монда минем бурыч үтәлде. Хәзер батырлар күп... Тегендә башлана гына.

— Анысы да хак. Коровкин белән сөйләш. Риза булса, шалтыратыр.

— Рәхмәт, Игорь Дмитриевич, минем сүз бетте.— Фәез урыныннан кузгалгач, Агарков кул изәп аңа сабыр итәргә кушты.— Мин сезне тыңлыйм, Игорь Дмитриевич.

— Синең фикерне белеп калыйк. Үз урыныңа монда кемне тәкъдим итәр идең?

— Анда әйбәт егетләр бар.

— Конкрет.

— Глазов, Черных...

— Ә тагын?— дип ашыгыч сорау бирде Аппаков.

Аның нинди фамилия ишетәсе килгәнен Насыйбуллин белә, тик андый исемне Фәез телгә алмаячак. Шуңа күрә Аппаков үз картасын ачып салырга мәҗбүр:

— Ә урынбасарың? Хәмитов?

— Рапорт бирергә вакыт җиткәч, курыкмагыз, ул үз җаен табар.

Елмаебрак утырган Агарковка карап, Аппаков иреннәрен кысып куйды. Тик бераздан янә дәвам итте:

— Без Хәмитовны әйбәт кеше, дип исәплибез. Андый кадрлар безнең өчен кадерле.

— Кадерлесен белмим, ләкин гаять кыйммәтле.

— Ачыграк әйтегез...

— Андый бик ягымлы, сүзгә оста парадный затлар КамАЗ кебек төзелештә урын биләмәгән булса, күп төзелешләр үз сметасына сыяр иде. Менә ни хәтле бәя тора сезнең кыйммәтле кадрларыгыз.

Аппаков бая кискен сүз ишеткәндәгедән һич ким гаҗәпләнмәгәндер: кузгалып, бот чабып куйды.

— Карагыз әле, карагыз — бер кеше башында ни хәтле уй!— дип елмаерга тырышты.

Фәез Агарковка карады. Көлемсерәвенә караганда, баш управляющийның кәефе җимерелмәгән иде. Шул ук вакытта аның күзләре тагын ашыкмаска кирәген аңлаттылар шикелле. Шул сәбәптән Насыйбуллин тагын тынды.

— Син Хәмитовка чынлап та ничегрәк карыйсың? Мөмкин булса, объективрак,— диде Агарков тынлыкны бозып.

— Фикерем шул: андый кешегә Чаллы кебек бөек төзелештә урын булмаска тиеш.

— Артык кискен түгелме?

— Соңгарак калып әйтелде.

— Ярый, рәхмәт, искә алырбыз.

Сөйләшүнең болай төгәлләнә язуы белән Аппаковның ризалашасы килмәде бугай.

— Карагыз әле, иптәшләр. Кадрлар белән шулай шаярырга ярыймыни? Кичә генә шәп иде кеше, бүген кирәге беттеме? Җитдиме бу?

— Монда ул, дөресен әйткәндә, Лазаревтан да уздырып җибәрде. Хәзер, ә киләчәктә...

— Кызык әйтәсез, Игорь Дмитриевич. Анатолий Самойлович хәзер дә хөрмәтле кеше бит, минемчә.

— Чөнки ул үз урынында.

Җитәкчеләр бәхәсенә шаһит булмас өчен Фәез китәргә рөхсәт сорады. Агарков бу юлы ни күз белән, ни сүз белән каршы килмәгәч, тик генә чыгу җаен карады.

Ул чыгып киткәч булачак әңгәмәнең, дөресе — бәхәснең нәрсә, кем хакында барганын чамалау кыен түгел сыман. Сүз Лазаревтан башланып, азакта Хәмитовка, аннан соң бәлки Насыйбуллинга күчкәндер. Агарковның Лазаревка биргән бәясен Фәез шөбһәсез әйтә ала.

Лазаревны үзе башлаган мәйданнардан китәргә мәҗбүр иткән сәбәп менә нәрсәләрдән гыйбарәт: планнарга сыймаган үзгәрешләр ул уйлаганнан катлаулырак булып чыкты һәм бер масштабка күнеккән зиһен колачы икенче зуррак масштабка җитмәде. Шуның нәтиҗәсендә кеше парадный шәхескә әверелде. Җитештерү сферасында курчаклар озак яши алмый...

Хәмитовны, билгеле, Аппаков яклагандыр һәм, ихтимал, егет бәясез калгандыр. Шул кирәк аңа. Ләкин Насыйбуллин үзе? Аңа нинди мөһер сугылды икән?

Нинди генә булса да, Насыйбуллинның үзе өчен инде барыбер...

Ә шулай да... шулай да җилкәгә килеп, әйтерсең, Аппаков сүзләре бәрелә:

«Синең чынлыкта нинди кеше булуың һич мөһим түгел, ә бүтәннәргә нинди булып күренүең, аларның сине нинди итеп күрергә теләүләре мөһим. Син аларга нинди рәвештә кирәк булсаң, алар сине җәмәгатьчелек карашы өчен шундый итеп иҗат итәчәкләр. Алар теләгезаказы белән үк чынлыгыңнан башка икенче «син», өченче, дүртенче һәм, хаҗәт табылса, бишенче «син» хасыйл ителәчәк...»

Бүгенге көндә Насыйбуллинның нинди кыяфәтләре яши икән? Аның үзенә хәзер бөтенесе барыбер. Тик шулай да...

Шулай да җилкә сызлапмы сызлый бит. Шул сызлаумы әллә күз алларын караңгылата?

Гидростанция тарихы еллар буе хәрабәләр мисалында, йокыга талган хәлдә ятты. Шлюз каркаслары арасында әллә нигә бер күтәрелгән ак пар гына кышларын кар каплаган чокыр-чакырларның җан биреп үк бетермәгәнлеген сиздерерлек түгел иде. Кыш-көзләрдә җил сызгыра-сызгыра тормыш галәмәте кузгата торса да, җәй көннәрендә монда сопсоры төссезлек ваемсыз патшалык итә бирде — чикерткәләр чекердәми, җәнлекләр күз елтыратып узмый, еланнар шуышмый. Җирнең бер кат кабыгын ашап, моторлы кодрәт узган. Борынгы тормыш галәмәтләре төсле хәрабәләрне ходай үзе дә онытнандыр кебек.

Ләкин көннәрдән бер көнне Фәез Насыйбуллин, кәгазьләр актарып утырганда, гидростанциянең сизелер-сизелмәс кенә булса да сулап ятуын төшенде. Баш идарәдә эшләгән чакта үзе җибәргән кәгазьләр... Әгәр аларны бүтән кеше җибәргән булса, мөгаен, Фәез ул кешене формалист, гамьсез дигәндәйрәк сүзләр белән мөһерләр иде...

Инде болай ярамый.

Кабинетында, өендә күпме техник әдәбият бар, Фәез аларның барысын аркылыга-буйга үлчәп, тикшереп чыкты — хәтеренә төшерде, зиһененә күчерде. Куйбышев шәһәрендәге «Гидропроект» институты белән, Казандагы һәм Якты Ярның үзендәге компетентлы кешеләр белән киңәште. Баш идарәдә чакта бу эш аның өчен көязлек булып исәпләнә иде — дәрьяга ул өстән генә карый ала, ә төпкә чумарга җай хакында уйларга аңа вакыт бирелмәгән иде.

Дәрья төбендә менә ул нәрсәне ап-ачык күрде. Гидростанция корылмаларын Ленинградның «Гипротранс» институты төзегән. Көчле оешма. Документларның сыйфаты иң югары дәрәҗәдә. Хәтта эш сызымнары да вакытында җибәрелгән булып чыкты. Ә буа һәм күпер нигезе проектларын Мәскәү институты эшләгән. Ленинградта яралган күпер һәм аның терәкләре Мәскәү институты ташларына таянырга тиеш. Тик Мәскәүдә билгеләнгән нигезнең нинди буласы Ленинградтан күренеп җитмәгән. Өске корылмалар су астында калачак корылмалар размерына — чүлмәккә капкач — туры килми. ГЭС бинасы мөмкин кадәр кыскалыкка — экономиягә омтылса, аскы нигезләр аны инкарь итә, яратмый...

Ике институт проектын берләштерү Фәезне көткән булып чыкты. Карандаш һәм линейка хәзер төштә дә кулдан китми.

Турбина блоклары. Аларны алданрак эшләп бетерергә кирәк. Күпер чак кына арттанрак иярә. Аны ашыктыру ярамый, тоткарлау да дөрес булмас иде — нигез ташларын су күмсә, өстәмә җайсызлыклар килеп чыгачак.

Күперне дә, блокларны да яраклаштырып салу өчен барлык көч һәм материалның бер кулда булуы шарт. Ә гамәлдә блоклар аргы ярга әкрен генә үрмәләсә дә, күпернең әле тәгаен хуҗасы юк.

Күпернең вариантлары белән таныша торгач, шунысы тәмам мәгълүм булды: бүгенгесе көндә бу эш белән конкрет шөгыльләнер өчен Фәез Насыйбуллинның компетенциясе бәләкәйләнеп калган икән. Баш идарәдән торып җитәкчелек итәргә кодрәте җиткән булыр иде, ә монда... Хәл киресенчәгә әйләнеп куйган. Борис дус теләгәнчә яшәгән-эшләгән булса, геройларча яшәмәгән булса, хәзер буа һәм күперне Фәез үз кулына алган булыр иде.

Туган һәм сөйгән елгасы Кама аркылы челтәрле күпер салу Фәезнең белә-белгәннән бирле чакырып торган ерактагы зәңгәр хыялы булып килде. Берничә ел элек, баш идарәдә бу хакта баш вату җае юк чакта ук, күпер проектын булдыруны башлап ул кузгатты. Фәез инициативасы белән заказчылар киңәшмә җыйдылар һәм анда баш идарә-

дән Фәезгә катнашырга туры килде. Ул барып кергәндә тавышлар инде иң биек ноктага менеп җиткән һәм сүзләр һаман бер тирәдә бөтерелә иде: Күпернең проекты шушы көнгәчә эшләнмәгән. Фәезнең китконенә өч ел... Ул киткәндә нәкъ шушы хәл иде. Мәскәүдә бер оешма күпернең үзен таләп итсә, икенчесе, аңа тиешле материал фондын һәм акчаны да бүтән төзелешкә — КамАЗга бүләк иткән.

Бәхәсләргә тәнәфес бирер өчен секретарь кыз директорга телефон трубкасын алырга әйтте. Гадәти «Әйе, тыңлыйм»нардан соң, директорның чырае каралганнан карала барып, тавышы иң түбән ноктага кадәр төшеп җитте.

— Бернинди сроклар да юк, бернинди вәгъдә. Әйе. Без нәрсә? Без бүгеннән әзер. Ләкин бит... Нинди күпер? Проект үзе юк, ничек эшкә тотынсыннар? Әйе, КамАЗны да нәкъ шулай башладылар. Килделәр дә җир казыдылар, ташлап киттеләр, дә тагын килеп икенче ысул белән казырга керештеләр. Инде җайлана дияргә була. Әйе, төзелешнең яртысы тәгәлләнә язгач, проектлар, хәтта эш сызымнары да килеп житте. Әйе, биналарны ватып яңадан корырга туры килгәләде. Безнең дә шулайрак килеп чыгуы ихтимал. Әйе, уйлашырбыз. Әйе. Ләкин акча... Аны каян алырга? Әйтәбез, язабыз. Рәхмәт, хушыгыз.

Шуннан соң проектчылар хакында сүз булып алды. Алар эшкә тотынырга әзер.

— Ә акча?

— Анысын Фәез Сәлимович белә.— Бу сүздән һәммә кеше, шул җөмләдән Фәез дә уч төбенә генә елмаеп куя.— Акча булса проект булыр иде. Подрядчик та бәлки табылыр иде. Проект булмагач, акча да гөл... Шулай да күпер — төшемле эш. Уйлашыгыз.

— Рәсми кәгазь бирерсез. Бөтенләй алынмасак, конструкцияләрне өлешкә бүләргә мөмкин.

— Шашлык ысулы? Анысы гамәлдән чыгарылган.

— Уйлашырбыз. Бер фикергә килербез.

— Хуҗалык исәбендә булуыгызны онытмасагыз, хәзинә сезне үзе эзли.

— Анатолий Самойлович белән киңәшербез.

— Ә сез үзегез?

— Мин үзем... баш идарә кесәсендә егерме миллион сум акчага гына урын калгандыр дип уйлыйм.

Фәез икенче көнне үк бу киңәшмә тәкъдиме белән баш инженерны һәм баш управляющийны таныштырды. Алар да Фәез кебек уйлыйлар икән.

— Күпернең бетоннан салынуы күздә тотыла, Анатолий Самойлович.

— Шуннан?

— Бу ысул белән минем соңгы елларда кызыксынганым юк. Үзегез беләсез, вакыт дигән нәрсә...

— Гидростройдагы иптәшләр?

— Белмим шул. Барыбер безнең контрольсез эшли алмаслар.

— Әһә. Синең нинди дә тәкъдимең бар кебек.

— Күперне, мин әйтәм, металлдан ясасак? Шәһәрне ул бермә-бер матуррак итәчәк.

— Тыелган ысул.

— Бәлки узар? Ә хәзер заказчыга металл күпер хакында язу төшерәбез.

— Һәм Мәскәүгә?

— Һәм Казанга.

Гадәти фикер алышулардан соң Фәез тутырган кәгазьләр баш управляющий раслаган җитди документ сыйфатында Казанга китте, ан-

нары, Фәез аңлап бетермәгән нәрсә: баш инженер шул эш белән махсус шөгыльләнер өчен гидростанция төзелешеннән Айрат Хәмитов дигән яшь иптәшне җибәргән. Аңа ияртеп, Рәхилә һәм Кама исемле кызларны. Алар кайтканнан соң озак та көттермичә, Казаннан күңелле хәбәр килеп төште.

Лазарев бүлмәсенә, тантаналы рәвештә килешү өчен, директорны дәштеләр. Заказчының кәефе төшенке икәнне сизепме, әллә болай үз гадәтенчәме, Лазарев, ачык елмаеп, кунак белән ике куллап күреште һәм утырышкач та шат тавыш белән дәште:

— Хөрмәтле Марс Зарипович, ике кыйтганы, Азия белән Европаны тоташтырачак күпернең контурлы сызыклары, ниһаять, күзгә күренерлек була башлады. Без бу эшкә алынырга бүгеннән риза.

— Рәхим, Анатолий Самойлович, ләкин...

— Дәүләт үзе кушкан эшкә акча тапмый калмас, курыкмагыз. Булышырбыз.

— Анысына да рәхмәт, ләкин бит...

— Ләкин ул металлдан курка, Анатолий Самойлович,— дип Фәез ачыклык кертергә тиеш булды.

— Әйе, металлдан рөхсәт итмәячәкләр. Хөкүмәт карары белән тыелган. Бетонга заявка көтәләр.

— Сезгә, ялгышмасам, бүтән төрле карар килде. Анысы да хөкүмәт карары бугай?

— Барып чыкса, миннән тормас иде дә бит, ләкин...

— Ләкин — рәхмәт. Килештек. Проектлар көтәбез.

Шушы рәсми килешүдән бирле өч ел узганнан соң, Насыйбуллин гидростройның үз кешесе булып кәгазьләр актарганда, күрәчәк: эш нәкъ шушы рәсми килешү ноктасында тыныч кына черем итә икән әле...

Фәез болай да минимумга калган йокыны, ялны тагы да кыса төшеп, тиешле әдәбият юллады. Моңарчы мәҗбүрияте чыкмаган һәм бик үк катлаулы булмаган технология рәвешләре хәзергесе көндә өр-яңа положениеләргә әйләнгән ләбаса!

Бер актарды, өч, дүрт, биш тә актарды, укыды, кабатлап, сызгалап бакты, әмма күпер төзү практикасыннан ераграк калган булып чыкты. Елганың аръягы төслерәк хыял — алсу теләк сурәтендә... Шул теләк аркасында, тегe чакта·

— Без алынабыз!— диде Лазарев.

— Без алынабыз бу эшкә!— диде баш идарәнең баш инженеры.

Ә үз куллары белән тотынырга тиешле Фәез Насыйбуллин курка калды. Ничек? Нидән башларга? Җыелышлар оештырыпмы? Кешеләр акыл һәм сүзне җәлләмәс анысы. Тик шуннан соң?

Аяк астыннан бетон нигез ычкынды — кулга карандаш һәм логарифмик линейка буйсынмый. Элегрәк аларның кирәге булмаган. Лазаревка әле дә кирәкми. Ул — оештыручы! Ул инде карандаш һәм линейканы сагынмыйдыр да. Кабинет, телефон, киңәшмә, җыелыш, трибуна, микрофон... Менә аның эш кораллары. Фәез дә шулай яши алырмын дип, ахрысы, кирәкмәгән тарафка шактый ара ияреп барган. Хәзер аңлады шикелле. Әгәр соң булмаса.

Коровкин бүлмәсендә чираттагы уйланулар. Махсус чакырылган белгечләр белән бергәләп кәгазьләр, саннар, диаграммалар өстәлгә җәелгән, диварларга кадакланган. Насыйбуллин анда үзенең карашларын аңлата:

— Безнең барлык проспектларда һәм проектларда бетон күпер каралган. Аны металл белән алмаштыру өчен махсус хөкүмәт карары кирәк. Без андый рөхсәтне алган идек. Ләкин смета — элекке, анда металл күпер юк. Димәк, барлык сметаларны яңадан карарга, инстанцияләрдә тикшерергә, расларга кирәк. Мондый мәшәкать төзү срокларын

тагын да сузар иде. Хәзерге кискен шартларда без бу фикерне яклый алмыйбыз.

Белгечләр Фәезне якладылар. Алар тәкъдиме белән күпер башка предприятиегә күчерелде.

Баш идарәнең баш инженеры урынбасары иптәш Насыйбуллин тарафыннан җибәрелгән күрсәтмә, гидростройның баш инженеры булган Фәез Сәлимович тарафыннан кире кагылды...

Дәрья тирәнлегендә туры килмәүләрне бетерү өчен дә шактый баш ватарга кирәк иде. Азакта үз фаразларын Фәез Мәскәүгә дә, Ленинградка да җибәреп, уңай җаваплар алды.

Проектчылар ничек шул арада өлгерә алганнардыр, берничә айдан яңа документлар инде килә дә башлады. Эш сызымнары атналарга ук бүленгән. Күпер салучылар гына өл.ерсен... Проектта билгеләнгән ике елга Фәез сыешачак. Коровкин аның белән сүзсез риза.

Ләкин аларны шундый матур көннәрнең берсендә Агарковка чакырдылар. Иртәнге сәгать алты туларга ун минут кала. Алевтина Федоровна аягүрә торып каршылады:

— Тизрәк, алар көтәләр.

— Нинди рәк эш икән?

— Ашыгыч. Министр килде.

— Министр?— Фәезнең җилкәсен таныш ялкын ялап куйды.

Агарков министрга башта Коровкинны, аннары Насыйбуллинны тәкъдим итте. Характеристика икесенә берәү житте:

— Яхшы белгечләр.

— Әйбәт,— дип, эш мәсьәләсенә күчте министр.— Бурыч гади генә түгел, ләкин башкарып чыгарга кирәк. Игорь Дмитриевич та шул фикердә — сезгә аны ышанып тапшыру мөмкин.

— Тыңлыйбыз сезне, иптәш министр,— диде Коровкин сагаеп.

— Бурыч шуннан гыйбарәт, хөрмәтле иптәшләр. Киләсе елның маенда — димәк, бер елга якын вакыт бар — буаны ябарга кирәк. Шул бурычны кабул итә аласызмы?

Сорауның мәгънәсен: «Югыйсә, сездән дә уңганракларны эзләргә туры киләчәк»,— дип фаразларга мөмкин иде. Хөрмәтле иптәшләр шым булды: «Ике елга әйбәт кенә исәпләнгән бурыч...» Ә житәкчеләр берике минут тынлыкны гадәти хәл дип кабул итсәләр дә, шуннан артыгын килештерә алмадылар.

— Бурыч аңлашылдымы?— дип сорады Агарков.

— Кабатлауның кирәге юкмы?— диде министр.

Бурыч аңлашыла, кабатлауның кирәге юк иде.

— Фикер?

Фикерне Фәез әйтергә тиеш бугай. «Янсам, әйдә, мин яныйм, күнегелгән»— дип уйлады ул. Задание һичшиксез өзеләчәк һәм ул очракта Насыйбуллинны беренче булып табачаклар. Дөресен әйтү урынлырак булыр.

— Миңа мөмкинме?

— Рәхим итегез.

— Мин проект заданиесе буенча бу эшнең ике елга исәпләнүеннән башлар идем.

— Конкрет фактлар?

— Алар күп. Беренчесе — әле су кумдерү өчен котлован әзер түгел.

— Искә алдык.

— Күпернең нигезләре салына гына башлаган.

— Тагын бармы?

— Санасаң күп. Ләкин бер сүз белән әйткәндә: технология бозылачак.

Җитәкчеләр, әлбәттә, уйга калмыйча булдыра алмадылар. Ләкин аларның уе һич тә сроклар хакында түгел иде. Агарков:

— Тем не менее, без бүтән срок куя алмыйбыз,— дип министрга карады.

— Димәк, алынабыз, ә?— Министр, нишләптер Фәезгә баягыдан ныграк текәлеп карады — танырга, хәтерләргә тырыша иде бугай...

— Мин сезне аңлап бетерә алмыйм,— дигән ризасызлыкны Агарков Коровкинга төбәп әйтте.— Я? Ризамы, алынабызмы? Сез үзегез генә түгел — без барыбыз бергәләп. Аңлашылдымы? Шулай.

Коровкин бугазына утырган төенне йотып:

— Шулай,— дип расларга мәҗбүр булды.

— Молодцы. Без сезгә ышанган идек, ышанабыз да,— дип мактарга ашыкты министр.— Ләкин шунысын хәтерегезгә салыгыз — срокны күчерү мөмкин түгел. Моның өчен сез башыгыз белән җавап бирәчәксез. Ә үтәлмәсә, мин лично үзем сораячакмын. Кисәтеп куям, мин сорый белермен.

— Ышанычыгызны акларга тырышырбыз.— Бу вәгъдәне Коровкин шактый ук кыю әйтергә тиеш булды.

Хәл ителде — баш кискәгә куелды.

*Дәвамы киләсе санда*

# Илдар Юзеев

# МӘҢГЕЛЕК БЕЛӘН ОЧРАШУ

ШИГЪРИ ТРАГЕДИЯ

**ТРАГЕДИЯ ГЕРОЙЛАРЫ:**

Атлант — безнең заман кешесе. Археолог.
Икар — аның улы. Космонавт.
Аллалар:
Зевс — Җир-Күк белән идарә итүче Баш алла.
Арей — аның улы, Сугыш алласы.
Афина — Зевсның кызы, аның башыннан, акылыннан барлыкка килгән зәңгәр күкләр алиһәсе.
Анд — Җир асты алласы.
Анан — Язмыш алласы.
Хор.

Вакыйга Бүгенге, Борынгы һәм Киләчәк заманнарда Җир астында, Җирдә, Күктә бара.

## Пролог

**Җир шарын хәтерләткән ярымшар. Кыя-таулар. Диңгез. Өстә — чиксез күк гөмбәзе. Якында гына — археологларның палаткалары.**

**Кояш байый. Археологлар эштән туктаганнар. Отряд җитәкчесе Атлант диңгез буенда казылган траншеядан күтәрелә.**

Атлант
Ишетәсезме, Җир астыннан
Нindидер өннәр килә?

Хор
Өннәр килә?.. (*Тавыш кайтаваз булып яңгырый.*)
Кемнәр килә?

Атлант
Моңа кадәр ачылмаган,
Ачасы серләр килә!

Хор
Серләр килә!

Атлант
Ишетәсезме, күк йөзеннән
Нindидер өннәр килә?

Хор
Өннәр килә? (*Кайтаваз.*)
Кемнәр килә?

Атлант
Җир белән Күк, Күк белән Җир
Очрашыр төннәр килә.

Хор
Төннәр килә?..

Атлант
Җир астының ачкычлары —
Безнең кулларда хәзер,
Җир астының баскычлары
Безнең юлларда хәзер.
Котлыйм, дуслар!

Хор
Ачкычлар — безнең кулда!
Баскычлар — безнең юлда!

Атлант
Таңга кадәр! Хәерле төн!

Хор
Хәерле төн! Таңга кадәр!

**Төнге йокыга юнәләләр.**

**Атлант** *(күккә карап.)*
Мин әле бу — Җир баласы,
Сиңа аваз салам...
Ник ачмыйсың серләреңне?
Ник дәшмисең, Галәм?

**Күкләр хоры**
Очрашмадык!

**Атлант**
Нигә?

**Күкләр хоры**
Очрашмабыз!

**Атлант**
Нигә?

**Күкләр хоры**
Очрашмабыз мәңгегә!
Мәңгегә! Мәңгегә!

**Атлант** *(Җир астына карап.)*
Мин әле бу — Җир баласы...
Ишет, узган заман!
Синең белән аңлашырга,
Очрашырга барам!

**Җир асты хоры**
Очрашмадык!

**Атлант**
Нигә?

**Җир асты хоры**
Очрашмабыз!

**Атлант**
Нигә?

**Җир асты хоры**
Очрашмабыз мәңгегә! Мәңгегә! Мәңгегә!

**Атлант**
Басып торам меңнәр һәм миллионнар
Ятып калган Җирдә,
Күпме буын кыя-ташлар булып
Катып калган җирдә.
Җирдә яшәр өчен мәңгелеккә
Килмәвемне беләм,—
Тик шулай да очрашырга телим
Мин мәңгелек белән!

**Кыя-ташлар хоры**
Очрашмабыз!

**Атлант**
Очрашырбыз!

**Кыя-ташлар хоры**
Очрашмабыз мәңгегә!

**Атлантның космонавт улы Икар керә.**

**Икар**
Кояш баеп килә. Ял итәргә
Вакыт сиңа да... Әйдә, әти!..

**Атлант**
Туктый алмыйм, улым... Без эзләгән
Серләр менә шунда күмелгән.
Мәрмәр ташка кирәк бәрелгәч тә,
Сиздем: без эзләгән шәһәр бу!

**Икар**
Җир астында нинди таш булмас!

**Атлант**
Мә сиңа да, Икар, пычак, щетка...
Әмма сак бул!

**Икар**
Тукта, әти, сөйләшәсе иде...

**Атлант**
Бар, йокла, улым...
*(Кулына кәйлә, пумала алып, траншеяга төшә, эшкә тотына.)*

**Икар**
Килдем сине күреп китәргә.
Иртән мине озатырсың, әти...

**Атлант**
Кал, улым...

**Икар**
Кала алмыйм, әти. Кояш. Эссе.
Тузан. Балчык. Гел-гел казыну.
Нинди кызык табасыңдыр...
Узган заман — узган...

**Атлант**
Ачыш көтә безне! Шәһәр. Сарай.

**Икар**
Ул ачыштан берәр файда бармы?
Ярый. Борынгылар яшәгәннәр...
Җир астында күмелеп калганнар.
Ә безгә бит, әти, артка түгел,
Бары алга, алга барасы...
Менә мин Киләчәккә китеп барам...
Балачак әкиятендәге кебек,
Очыйк икәү без Кояшка таба!

**Атлант**
Дедал белән Икар кебекме?

**Икар**
Сөйлә, әти, Икар легендасын...
Бала чактан аны белсәм дә,
Һаман кызык...
Сабый чагым искә төшә...

**Атлант**
Дедал атлы оста архитектор
Патша сараенда яшәгән.
Ул омтылган күккә, чиксезлеккә —
Патша чыгармаган утраудан.
Дедал үзенә дә, улына да
Каурыйлардан канат ясаган.
Очкан болар икәү югарыга...
Икар башта барган иярең.
Оча торгач, Икар этисеннән
Аерылган, сүзен тыңламыйча,
Һаман күккә менгән... һәм Кояшта
Канатлары янып, диңгезгә
Егылып төшкән...

**Икар**
Сөйли идең йоклатырга теләп,
Ә мин һаман... һаман сөйләтәм.
Мин егылмам, әти, корабымның
Канатларын йөз, мең Кояш та
Яндыралмас!

Атлант

Шулай була күрсен! Әмма, улым,
Киләчәккә кыю очканда,
Үзган һәм Бүгенгегә таянмыйча,
Икар язмышына дучар булма!
Өч заманның урталыгын тапкан
Адәм тиңсез эшләр кыла ала!

Икар

Шигең юкка, әти, мин — Бүгенге Чорның
Егылуны белмәс Икары!

Атлаңт

Син — Галәмне айка,
Мин — Җир астын...
Эзләгәнне берчак табарбыз!

Икар

Тик шулай да, әти,
Гомерең буйларына эзләсәң дә,
Табалмадың Атлантиданы...
Атлант исемен бабам юкка биргән?

Атлант

Нык ышанам: Атлантида булган —
Җанга сеңгән миңа — бабамнан.
Юк, легенда түгел Атлантида —
Җирдә яшәгәннәр атлантлар.
Килгән бер чор, монысы әлегә сер:
Һәлакәткә дучар булган ул.
Сәбәбе ни? Нигә? Ни булган?
Легенда да әйтми. Шул сорау
Әтине дә тирән уйга салган,
Борчый мөнә бүген мине дә.
Бу сорауга җавап бирми торып,
Тынычланмас күңел, тынмас — уй!
Әти яу кырында ятып калды,
Шул хикмәтнең серен белмичә.
Соңгы хатларына караганда,
Ул, мөгаен, шушы тарафта
Һәлак булган... Бәлки, мөнә шушы
Тауларда ук... Әйе, шушында!

Икар

Фараз итик, әйдә, монда дип...

Атлант

Яуга киткән чакта әти миңа
Нәсел шәҗәрәсен калдырды.
Җиде бабамның мин исемен беләм.

Икар

Кызык. Әмма бармы кирәге?

Атлант

Ераккарак барып, бабамнарның
Бабаларын күрәсе иде.
Нәселемнең генә түгел, кешелекнең
Шәҗәрәсен эзлим мин, улым...

Икар

Хыялый син, әти...

Атлант

Бер адым да алга китә алмас
Кеше хыялсыз.
Син дә җир әйләнеп йөрмәс идең...
Минем әле олы хыялым бар!

Икар

Әйт, әти...

Атлант

Заманнарны бергә очраштыру!

Икар

Ягъни мәсәлән?

Атлант

Борынгыны, Бүгенгене
Күзгә-күз карашып сөйләштерү...

Икар

Ышаныр да идем, бу әкиятне
Сабый чакта әгәр сөйләсәң...

Атлант

Һәр хыялның нигезендә — чынлык!
Әмма моның өчен мин хәзер үк
Җир астына кереп югалам...
Анда күтә мине борынгылар...
*(Траншеядан аның башы гына күренә.)*

Икар

Шаянлыгың миңа ошый, әти,
Сиңа бер сүзем бар... югалмый тор.

Атлант

Әйтеп кал, Икар...
Мине анда, аста көтәләр
Грек аллалары, атлантлар...

Икар

Әти, тиздән — мин очам!

Атлант

Улым... Икар... Тойды күңелем...
*(Траншеядан чыгып.)*
Кайсы йолдызга?

Икар

Әлегә — Җир тирәли!

Атлант

Әниең?

Икар

Аңа — ләм-мим! Әйдә, борчылмасын!

Атлант

Хәерле юл, балам! Кара, сак бул!
Йолдызларга барып бәрелмә!

Икар

Тырышырмын, әти!

Атлант

Мә, ал бабаңнарның шәҗәрәсен...

Икар

Нигә — миңа? Торсын үзеңдә...

Атлант

Күктә — шәҗәрәнең дәвамы...
Берчак Җирдә — яшәү чыганагы
Бетәр... Әйе! Башка җисемнәргә
Күчәр киләчәкнең кешеләре...
Мә, ал, Икар...

Икар

Әйдә, ярый, синең төсең булыр... *(Ала.)*

Атлант

Җырлыйк, әйдә, аерылышу көен...

Икар
Беребез оча — Киләчәккә.
Атлант
Беребез китә — Узганга.
Икар
Йолдызга карап калырсың...
Атлант
Син күкләрдән узганда!
Очрашырбыз!
Икар
Кайда?
Атлант
Җирдә!
Икар
Киек каз юлларында!
Очрашмасак?
Атлант
Очрашырбыз!
Икар
Сагынырсың җырларында...
Беркайчан да очрашмыйлар
Узган белән Киләчәк.
Атлант
Мин ышанам: икесе дә
Очрашуга киләчәк!
Очрашырбыз!
Икар
Кайда?
Атлант
Җирдә!
Икар
Киек каз юлларында!
Очрашмасак?..
Атлант
Очрашырбыз!
Икар
Сагынырсың җырларында!
Очам, әти, иртә-таң белән!
Атлант
Палаткага кереп йокла, Икар!
Мин килермен...
Икар
Йокыны онытма! *(Китә.)*
Атлант
*(Улы артыннан сокланып карап кала. Траншея эченә төшеп, әкрен генә җыр көйли-көйли, эшкә тотына.)*
Очрашырбыз!
Кайда?
Җирдә!
Киек каз юлларында!

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

**Бу музыка Җирдә дә, Күктә дә серлехыялый моң булып, дәвам итә.**

**Кинәт — шартлау!.. Атлант эшләгән траншеядан балчык өеме күтәрелә. Дәһшәтле музыка, хор авазлары.**

Икар *(йөгереп керә дә траншеяга ташлана.)*
Әти! Әти!
**Хәсрәтле-үкенечле музыка. Караңгы траншеядан, баеп барган кояш нурларында күренеп-югалып, әкрен генә Икар күтәрелә. Аның кулларында — тынсыз-хәрәкәтсез калган Атлант.**
Күкләр хоры
Очрашмабыз!
Җир асты хоры
Очрашмабыз!
Кыя-таулар хоры
Очрашмабыз!
Күкләр, кыя-таулар, җир асты хоры
Очрашмабыз мәңгегә!
Икар
Әти! Әти!
**Шартлау тавышын ишетеп, археологлар йөгереп керәләр.**
Хор
Ни булды?
Икар
Ул... яралы... Авыр хәлдә!
Хор
Атлант, ник дәшмисең?
Ни булды?
Атлант *(көч-хәл белән)*
Дусларым... Икар улым...
Җиргә куегыз...
*(Аны, күтәреп алып, траншея алдындагы калку җиргә куялар.)*
Хордан берәү *(шартлау булган урынны карап.)*
Җирдә качып калган снарядлар...
Күпме еллардан соң шартлаган!..
Атлант
Дошман...
Берсе белән — этине юк иткән...
Берсен... миңа саклаган...
Икар
Әти, хәлең ничек?
Атлант
Зинһар... монда калдырыгыз...
*(Кояш баеп, караңгылана. Сүнә барган кояш нурларында Атлантның йөзе яктыра.)*
Кояш баеп...
Җир белән күк тоташа...
Хор
Җир белән күк тоташа...
Атлант
Узганга барам... дошманга
Үч итеп мин... ут аша...
Хор
Саташа...

# Яралы Атлантның саташуы

## Беренче акт

## 1. Атлант җир астына китә

**Атлантның күз алды караңгыланып, археолог дуслары аңа борынгы грек театрының хоры булып күренә. Кыялар өстендә күк күкри, яшен яшьни. Аллалар тавы — Олимп өстендә — алар кабызган мәңгелек ут җилферди.**

Хор
И, аллалар кабызган ут,
Якла Җир балаларын,
Афәт, бәла-казалардан
Сакла Җир балаларын!
О, дәһшәтле күк күкрәүләр
Һәм яшеннәр алласы!
Синең шәфкатең астында
Яши адәм баласы...
*(Күк белән Җир тоташкан тау башында Баш алла Зевс пәйда була, Хор сәҗдәгә егыла.)*
Җиргә яшеннәр атасың
Ни өчен,ниләр өчен?
Без — сабый Җир балаларын,
Гөнаһлар булса, кичер!
*(Икенче якка борылып.)*
Кодрәтле сугыш алласы,
Син кызган безне, кызган...
Болай да бит Җир йөзеннән
Күпме сугышлар узган!..
*(Югарыда Сугыш алласы — Арей үзенең атасы Зевс янына килеп баса.)*
Кил, акыллар алиһәсе,
Шәфкать, мәрхәмәт булып,
Уят туңган тереклекне,
Нурларың белән җылыт!..
*(Акыл алиһәсе Афина атасы һәм абыйсы янында урын ала.)*
Ташлама үз тәкъдиреңнән
Безне, язмыш алласы,
Синең язганың буенча
Яши адәм баласы...

**Аллалар рәтендә — язмыш алласы Анан күренә. Атлант әкрен генә аллаларга таба бара. Күк күкрәү, яшен яшьнәү тавышлары астында, аллалар Күк белән Җир арасында юк булалар. Атлант таудагы баскычлар буйлап аллаларга якынрак урынга күтәрелә.**

Атлант
Әй, кешеләр! Күтәрегез
Башыгызны югары...
Күрәсезме, күк йөзендә
Киек каз юллары!

Хор
Бу ни бу? Мондый алланы
Күргәнебез юк әле.
Атлант *(күккә сокланып карап.)*
Киек каз юллары...
Хор *(күтәрелә төшеп, хәйран калып.)*
Киез каз юллары...
Күктә мондый матурлыкны
Күргәнебез юк әле!
Син нинди алла?
Атлант
Гади бер зат. Күптән инде
Күктән йолдызлар күзлим,
Мин күкләрдән алла түгел,
Туганнарымны эзлим...
*(Антенналы аппарат ала. Башта Галәмгә сигналлар озата, аннан соң бик матур, көйле сузып, чакыру авазы бирә.)*
А-у-у-у-у-у-у!..

**Күктән Атлантка таба салават күперенә охшаган төрле төстәге нурлар төшә, төсле музыкага ияреп, күктән шул ук тембрда икенче аваз ишетелә.**

Күктән аваз
Ә-ү-ү-ү-ү-ү-ү!..
*(Аваз күкләр хорына әверелә.)*
Хор *(артка чигенеп.)*
Бу нинди серле аваз?!
Атлант
Ишеттеләр! *(Күккә.)*
Без очрашыйк!
*(Күктән аваз, хор)*
Киек каз юлында!
Хор
Ни диләр?
Атлант
Кемдер җырлап сөйли!
*(Аваз-хорны «тәрҗемә» итә.)*
«Аңлашсагыз әгәр...
Борынгылар белән...
Киек каз юлына...
Илче булып киләм!» — диләр.
*(Күккә.)*
Ул — минем дә хыял,
Ул — минем дә теләк,

Анда бару өчен,
Сезнең ярдәм кирәк!
*(Музыкаль сигналлар.)*
Алар аңладылар...
Күктән ярдәм көтәм...
Анда бару өчен,
Җир астына китәм!

Хор

Күктә дә юк — хаклык,
Җирдә дә юк — чынлык!
Китмә, егет, Җирдән,
Анда — мәңге тынлык!

Атлант

Сау бул, Көнем, Күгем,
Җир астына барам,
Якынайсын өчен,
Күкләр белән арам!
Ачар өчен барам
Мәңгелекнең серен.
Очрашканга кадәр
Сау бул, Көнем, Күгем!..

**Күктән Җиргә сибелгән төсле музыкаль авазлар аны Җир астына алып кереп китә...**

## 2. Атлантның җир асты алласы белән очрашуы

**Караңгы Җир асты дөньясы. Борынгы кешеләр яшәгән мәгарәне хәтерләткән сарай. Югарыда, тәхеттә — Җир асты алласы — Аид.**

Аид

Әллә өзелдеме кинәт
Мәңгелекнең чылбыры,
Кая китте аллалыкның
Гамьсез һәм алтын чоры?..
Кайчагында адәмнән дә
Көнләшкән чаклар була:
Кыска гына гомер яшәп,
Мәңге йокыга тына.
Йоклыйсы иде Адәмдәй,
Тик Алла килеш кенә...
Үлепләр йоклыйсы иде бер —
Ярамый — Зевс килә!

Күләгәләр хоры

Еллар, гасырлар йоклагач,
Онтылып, рәхәт оеп,
Уяндык бүген йокыдан
Шомлы куркыныч тоеп...

Аид

Татлы йокы күргәне юк,
Әле дә аллагыз сабыр,
Җир астында тере булу
Мең-миллион тапкыр авыр...

Күләгәләр хоры

Ялгыштыкмы ышанып без
Сүзләренә алланың?
*(Аидка таба кулларын сузып.)*
Җир астында — тынгылык дип,
Әллә инде алдадың?
Безгә чилтерәп ага торган
Суларны корыттылар,
Җир йөзендә тере җаннар
Ник безне онытттылар?

Аид

Исән кешеләрне күбрәк
Оныталар тормышта.
Адәмнәрнең гомерләре
Кебек, хәтере кыска.
Йоклагыз, сезнең гозерләр
Тапшырылыр Зевска.
Сезне искә алу көнен
Билгеләү өчен бүген,
Баш аллабыз — Зевс килер,
Калдырып Җирен-Күген.

Күләгәләр хоры

Ник безне онытттылар?!

**Югалалар. Җир өстеннән «тук-тук-тук» шакыган тавыш, аның артыннан археологлар хоры ишетелә.**

Аид

Кемдер шакый... *(Тыңлый.)*
Атлый. Якыная...

**Атлантның адымнары музыкаль аваз булып яңгырый. Кинәт, караңгылыкны факел белән яктыртып, Аид алдында Атлант барлыкка килә.**

Кем син? Монда патша — тынлык,
Я күләгә, я өрәк,
Син ялгыш килгәнсең, ахры...
Кем кирәк?

Атлант

Җир астының үз алласы —
Кодрәтле Аид кирәк.

Аид

Ул — мин!

Атлант

Синең белән сөйләшергә
Исәп бар аяк терәп!

Аид

Иң дөресе — ашыкмыйча,
Үлгәнче сабыр итү,
Гадәт юк бездә адәмне
Терелэй кабул итү.

Атлант

Бу — минем әле барганда
Күңел кушкан туктальш...

Аид

Юлың еракмыни әле?

Атлант
Атлантидага барыш!
Аид
Атлантида?! Буш хыял ул
Платон уйлап тапкан...
Атлант
Мин табармын! Ышанычым —
Кұптәннән — бала чактан.
Ә хәзер...
Җир йөзеннән тереләрдән
Сәламнәр алып килгән
Илче очрашырга тели
Илдәш — туганнар белән.
Аид
Эш итсәм дә гомер-бакый
Гел үле җаннар белән,
Сөйләшергә яратам мин
Конкрет саннар белән.
Кабул иттем Европадан
Дөнья сугышларыннан:
17 гасырда — 3,3 млн. кеше,
18 гасырда — 5,4 млн. кеше,
19 гасырда — 5,7 млн. кеше,
1 бөтендөнья сугышыннан — 4 млн. кеше,
2 бөтендөнья сугышыннан — 50 млн. кеше...
Күпмесе — синең танышлар,
Күпмесе — туганнарың?
Атлант
Азатлык, хаклык яклыны
Туганнар саныйм барын!
Бер мизгелгә генә, сорыйм,
Илдәшләр, уяныгыз!..
*(Музыкаль авазлар бирә.)*
А-у-у-у-у-у-у!
*(Бу аваз әкренләп көчле хор булып күтәрелә. Атлантның факелы нурында сугыш корбаннарының уянганы күренә.)*
Җирдә шушы факел булып
Яна сезнең җаныгыз!
Газап диңгезенә батып,
Яки газиз җиргә ятып,
Снарядлар күккә атып,
Туфракка әйләнгәннәр,
Ил өчен һәлак булганнар,
Сез бездә исән, туганнар,
Сезнең белән безнең рухлар
Өзелмәс бәйләнгәннәр!
**Сугыш корбаннары Җир, Диңгез, Күк сугышчылары киемендә Атлантка таба киләләр. Атлант — уртада кала.**
Сугышчылар хоры
Исән-сау калдымы илебез,
Суыбыз, Җиребез, Күгебез?
Исәнме әниләр, балалар,—
Җиңүне күрмәдек күбебез...
Без җирне күтәреп торабыз,
Уянмас йокыга талсак та,
Туктаттык илбасар яуларын,
Үзебез таш булып калсак та...
*(Тораташ булып катып калалар.)*
Атлант *(арадан берсен танып алып.)*
Әти!
*(Кочакларга тели. Таш дәшми, кузгалмый.)*
Әти! Бу мин... улың Атлант...
*(Куллары белән Тораташның битен сыйпый, алай да уята алмагач, музыкаль аваз бирә.)*
А-у-у-у! Әти!
Тораташ *(кузгалып.)*
Улым, килдеңмени?
Атлант
Миллион корбан арасыннан
Мин сине танып алдым.
Әти...
Тораташ
Дошман явын уздырмыйча,
Тораташ булып калдым.
Атлант
Нигә алар ачулылар?
Тораташ
Без ышанып киттек Җирдән
Соңгы бу сугыш диеп,
Балаларга яшәү биргән
Соңгы бу сугыш диеп...
*(Тораташларның сүзсез авазы.)*
Яңа сугыш гөрелтесе
Диңгездә, Җирдә, Күктә...
*(Еракта атом бомбасы шартлаган авазлар.)*
Ракеталар һәр кешене
Юк итәр йөкләр йөртә!
*(Тораташларның ярсулы-нәфрәтле авазы.)*
Атлант
Без көчәйгән саен, Җирдә
Дошманнар арта бара...
Алар безне дә...
Тораташ
Безне дә!
Атлант
Упкынга тарта бара.
Җиребезне күз карасы
Кебек саклабыз аны...
*(Уйга калып.)*
Тик шулай да... Җир — афәттә...
Ә мин йөрим узганнарда
Эзләп Атлантиданы...
Тораташ
Атлантиданы?
Атлант
Әти, киттем, Җиргә кайтам!
Тораташ
Юк, кире китмә, улым!
Эзләп тап Атлантиданы,

Дәвам ит изге юлың!
Җир баласы уйга калыр
Күкләргә ашканда да,
Бер ачылган хакыйкатьне
Яңадан ачканда да...
Хәерле юл!..

Атлант

Киттем эзләп... Тыныч йокы!

Йокламам көнен-төнен:
Табармын мин, ачармын мин
Атлантиданың серен... (*Китә.*)

Тораташлар **авазы**

Нигә дөнья тыныч түгел,
Җир-туфрак җиңел түгел?!

## 3. Атлант аллалар арасында

Хор

Нигә киттең тере килеш
Җанлы фани дөньядан,
Җир астында ни кылырсың
Шундый төндә син, адәм?
Бу — шундый төн: Күк белән Җир
Очрашуга килгән төн,
Аллаларның баш алласы
Күктән җиргә иңгән төн...

**Олимп тавыннан Зевс һәм башка аллалар Җир астына таба төшәләр.**

**Җир асты. Аллалар: Аид, Зевс, Арей, Афина, Анан.**

Аид

Хәерле төн, баш аллабыз!

Зевс

Хәерле төн!

Аид

Көтәләр...

Зевс

Гадәттәгечә тынлыкмы?

Аид

Җир астын селкетәләр!
Анда — шартлау! Монда — аваз!

Зевс

Син күрсәң иде Күкне!

Арей

Җирне инде әйткән дә юк!

Афина

Чыдарга мөмкин күпме?

Зевс

Сабыр бул, кызым, син — алла!

Афина

Кешелек кая бара?

Арей

Кая барсын? Һәлакәткә!..
Адәмгә — өстен кара!
Безнең өчен ул адәмнәр
Һәммәсе кырмыскалар,
Үзләреннән авыр йөкне
Күтәрергә осталар!.. (*Көлә.*)
Кырмыскалар... Уйлары да,
Буйлары да кыскалар!..

Зевс (*ярсу белән.*)

Айга, Марс, Венерага
Менде шул кырмыскалар!!!
Кешелекнең яшәргәме,
Юкмы дигән мәлендә
Адәм — алла, ә без, ә без —
Кырмыскалар хәлендә!..

Арей

Шаярасың!

Афина

Арттырасың!

Арей

Алласыз — яшәп кара!

Зевс

Хәзер дөньяда бик күпләр
Алланы онытып бара!

Арей

Ник һәммәсен вакытында
Сукмадың яшен булып?

Афина

Газап үзеңә кайтыр иде
Адәмнәр яше булып...

Зевс

Күкләр булып та күкрәдем,
Таш булып суктым яман!
Берәм-берәм куркытудан
Файда юк — башка заман!
Җирдә, Күктә һәм Диңгездә —
Власть ычкынып бара,
Һәрбер адәм «мин алла!» дип
Алда кычкырып бара.
Үтте антик герой чоры...
Балта, кылычлар, уклар...
Күтәрелә материклар,
Утраулар, континентлар!
Күпләрне әсир итәргә
Булса да факел белән,
Эш итәргә кирәк алда
Акыл, тик акыл белән!
Дөнья — икегә бүленгән...
Югарыдан, түбәннән,
Һәрбер илгә, материкка
Ракеталар төбәлгән!
Ике як та көтә тынып,
Кем башлар, кайчан башлар,
Җирне юк итәр бомбаны
Кем ташлар, кайчан ташлар?!
Киеренке тынлык... Дөнья
Кайчан бетәр ишелеп?..

Арей

Нишләргә тиеш аллалар?

Афина

Кая бара Кешелек?

Зевс

Киләчәк — язмыш кулында...

Арей
Энә... Ананнан сора!
Зевс
Анан, дөнья-кешелекнең
Килер язмышын юра!
*(Аллалар утырышалар. Анан уртага чыга.)*
Күктән Җиргә караганда
Ни күрербез алда без?
Анан
Тыңла, Зевс аллабыз!
Күрәм, ишетәм... аларның
Яңадан уянганын,
Герострат токымының
Утыннан Җир янганын.
**Балет. Герострат токымнары, кулларына факел тотып, биләр. Бөтен тирә-якны ут ялкыны чорнап ала.**
Җирләр-күкләр, диңгез-таулар,
Океаннар — ут була.
Зевс
Кемнәр кала?
Анан
Коллар, әсирләре белән
Геростратлар торып кала,
Башкалары — юк була!
Афина
Туктат, эти, бу мәхшәрне!
Арей
Бу — ошый миңа, Анан!
Зевс
Тынычлан, кызым Афина!
Афина
Тончыгам! Утта янам!
Арей
Мин — Герострат ягында!
Афина
Димәк, синең йөрәк — таш!
Арей
Бел, Афина, мин күптәннән
Геростратка теләктәш!
Зевс
Тукта!
Анан
Икенче язмыш:
Геростратлар дөньялыкны
Ни хәлгә китергәннәр:
Җир белән бергә, үзләрен
Яндырып бетергәннәр!
Борын-борын заманнарда
Җир шары бит ут була...
Тагын шул хәленә кайта —
Ут була да — юк була!
Арей
Ә аллалар?
Анан
Аллаларга берни булмый...

Арей
Җир күкрәп яна тора,
Җир дөрли-дөрли янганны
Аллалар карап тора.
Менә бу — кызык! Тамаша:
Кешелек тынып кала.
Җир йөзендә адәм бетә...
Аллалар торып кала!
Башлана Адәмнән башка —
Хәсрәтсез, гамьсез тормыш!
Афина
Коточкыч! Ямьсез тормыш!
Күктән карап торырбызмы
Адәмнән эзләп гаеп?
Без — аллалар... Адәм кочтә
Әйт, этием!
Әйт, Аид!
Аид
Фани дөнья нишләсә дә,
Минем өчен барыбер.
Җирнең асты исән булса,
Аидка — эш табылыр!
Арей
Җир бөтенләй янып беткәч,
Юк була ич асты да!..
Аид
Мәрхәмәтле алла Зевс
Эш табар күк астында!
Афина
Эти!..
Зевс
Адәм белән дә бик авыр:
Тынгы да юк, ял да юк...
Аид
Ял да юк!
Зевс
Дөнья бетсә — адәмнәр юк!
Адәм бетсә... алла юк!..
Аид
Алла юк?!
Арей
Алла юк?!
Зевс
Син дә... Син дә... мин дә юк! Юк!
Арей
Син дә?
Аид
Син дә?
Афина
Дөрес, эти! Мин дә юк!
Зевс
Аяныч, ләкин факт!
Бу — адәмнәргә билгеле,—
Сезгә — аңларга вакыт!
Афина
Бу сүзләрең аяз күккә
Языла барсын, эти,

Адәмнәрнең яклаучысы,
Әле дә син барсың, эти...

Зевс

Алла булу хасиятен
Саклап калырга кирәк,
Язмышның безгә кулаен
Сайлап алырга кирәк...
Юра, Анан...

Анан

Өченче язмыш!
Җир белән Күк арасында
Ызгыш һәм талаш китәр,
«Кемгә күпме?» тиеш диеп
Йолдызлар санаш китәр...
Хисапсыз ул йолдызларны
Үзара бүлеш китәр...
Җир белән Күк сугыша-сугыша,
Миллиардлап үлеш китәр...

Аид

Килсеннәр, Җирнең астында
Һәркемгә урын җитәр!
*(Анан язмышын юраган арада, Аид Зевсны бер читкә чакырып ала.)*
Гадәттән тыш хәл, аллабыз!

Зевс

Тыңлыйк, язмыш ни юрый...

Аид

Минем биләмәләремдә
Теп-тере Адәм йөри!

Зевс

Ә?! Ни дисең? Кайда? Кайчан?
Адәм?!

Аид

Чын Адәм... Йөри атлап...

Зевс

Кем ул?! Кемнәр нәселеннән?!

Аид

Исеме аның — Атлант...

Зевс

Атлант?!
Йоклап калгансың! Җебегән!
Алла исеме — хәрәм!
Мәңгелекнең серләренә
Кереп бара ул Адәм!

Аид

Атлантиданы эзлим, ди...

Зевс

Аллаларның серенә
Кереп бара! Тап төшердең
Аллалар нәселенә!
Ничек җөрьәт иткән... Гаҗәп...

Аид

Аның кулында — ут бар!

Зевс

Аллаларга бәла килде!

Аид

Ходаем, үзең коткар!

Зевс

Бүген мондый могҗизага
Адәм — сәләтсез, беләм...
Димәк, бәйләнешкә кергән
Күктәге затлар белән!
Һәлакәткә тиң куркыныч!

Аид

Вулкан ат! Юлын капла!
Җимерелсен җире-күге!
Җир астын гына сакла!
Я аллам!

Анан *(юравын дәвам итеп.)*

Төпсез Галәм бушлыгында
Яңадан хаос булыр,
Тере җаннар истәлеге —
Кайтаваз — тавыш булыр!
*(Шул вакыт Атлантның «А-у-у-у» дигән музыкаль авазлары ишетелә.)*

Зевс

Бу нинди тавыш-аваз?
Бу нинди таныш аваз?

**Кинәт Атлантның чакыру авазына борынгы атлантларның күләгәләре күренә. Балет: озын буйлы, көчле атлет гәүдәле борынгы атлантлар шәүләсе-биюе. Алар берберсенә чылбырлар белән бәйләнгәннәр, авыр башлары түбән иелгән. Там-тамнар шашып елый. Юлбашчылары Атлант, титаник бер көч белән, чылбырын өзеп атып, алга чыга. Иркен, азат хәрәкәтләр, ул күккә очып итәр сыман... Атлант иптәшләрен дә көрәшкә чакыра. Там-тамнарның ашкынулы-ярсулы-шашып көлүле ритмында алар чылбырлардан ычкыналар: башлар югарыга, күккә таба омтылып, күтәреләләр...**

Зевс *(ярсып.)*

Анан, туктат!

Анан *(куркып.)*

Бу — минем юрау түгел!

**Караңгылыктан, астан факел тотып, Атлант килеп чыга. Ул биюче атлантларның күләгәләренә таба бара.**

Арей *(чигенеп.)*

Адәм!

Афина *(сокланып-гаҗәпләнеп, алга таба бер адым атлап.)*

Теп-тере Адәм!

Зевс

Каушамаска!

Атлант

Атлантлар, мин сезгә килдем!

Зевс

Тетрә, Җир, күкрә, Күк!

**Күк күкри, вулкан атыла, яшен яшьни.**

Атлантларның шәүләсе еракка китеп югала. Там-там тавышлары гына...

Атлант

Атлантлар, туктагыз!..

*(Атлантның өстенә таш-туфрак ява, аның кулындагы факел сүнә. Кап-караңгы булып кала. Яшен яктысында аллаларның горур йөзләре, күк күкрәү арасында Атлантның ыңгырашкан тавышы гына ишетелеп куя.)*

Арей тавышы

Бетте!

Зевс

Сеанс тәмам!

Арей

Мондый язмышны юрарга
Өлгерә алмадың, Анан!

*(Афинадан башка аллалар, Атлантның гәүдәсе өстендә — югарыда каһкаһә белән көләләр.)*

Аид

Мәңгелеккә теркәргәме?

Арей

Сорап та торасы юк!

Афина

Ашыкмагыз!..

Арей

Теркә, Анан!

Аид

Юк... Адәм буласы юк!
Әй! Алыгыз!

Афина

Әти... әти! Белмибез бит,
Сөйләшмәдек, ни әйтер...
Монда килү миссиясе,
Бәлки, изге нияттер?..

Арей

Күп сөйләшми юк итәргә!

Афина

Сорыйк башта үзеннән...

Зевс

Хәзер ул — куркыныч түгел:
Бәйләнешләр өзелгән!
Безгә илтеп ябыгыз!

Аид

Алыгыз! *(Һушын югалткан Атлантны Аидның хезмәтчеләре алып китәләр.)*

Арей

Куркыныч бетте!

Зевс

Бетмәде!
Адәм — Марста! Айда!
Венерада!

Аид

Җир астында!

Зевс

Аллалар урыны — кайда?

Арей

Адәм безне Җирдә, Күктә
Һаман кысармы шулай?

Анан

Мин сезгә тәкъдимнәр әйттем.

Афина

Язмышның кайсы — кулай?

Аид

Миңа кайсы да — барыбер!

Анан

Язмыш ни куша — шулай...

Арей

Ике як та бирсен-бирсе
Бетерсә, безгә — уңай!

Афина

Ике зур көч бер-берсенә
Күтәрелгән чагында,
Мин — Ирекккә, Гүзәллеккә
Омтылганнар ягында!
Алар җиңсә, сугышлардан
Ваз кичәр азат илләр...
Җирдән — Күккә, Күктән Җиргә
Илчеләр озатырлар...

Арей

Утопия! Сугышларсыз —
Яши алмый Кешелек!

Анан

Язмыш ни язса, шул була...

Аид

Миңа — барыбер... Җир асты
Төшмәсен тик ишелеп!

Зевс

Ишетегез, сугышларсыз
Яши ала Кешелек!

Арей

Мин — кушылмыйм!

Афина

Рәхмәт, әти!

Анан

Язмыш кушса — булыр да...

Зевс

Адәм хәленә төшкәнче,
Калыйк язмыш кулында!
Әйе, коллар азат булып,
Дөнья — тын булып калыр,
Әмма ирек алган Адәм
Аллалар урынын алыр!
Минем, синең, синең, синең,
Синең урынны алыр!

Арей

Түзә алмыйм!

Аид

Җир асты — сау!

Анан

Язмыш язса — шул була!

Зевс

Яки Адәм өстен чыга,

Я аллалар — хур була!
Нәтиҗә шул!

Арей

Әйттем бит мин...

Зевс

Хур булганчы — зур булу!

Арей

Минем вариант — раслана...

Ананк

Язмыш кушса — шул кала...

Арей

Һәлакәтне якынайту!

Зевс

Тик бердәнбер юл кала!
*(Афина сискәнеп китә.)*

Афина

Әти, юкмыни соң бездә
Һич кенә дә мәрхәмәт?
Җир — аллалар һәм адәмнәр
Әнкәсе — булырмы һәлак
Үз балалары кулыннан?!

Зевс

Бик дөрес уең, кызым,
Миңа да кыен, кызым...
Булса да Җир — һәммәбезне
Бар итүче Әнкәбез.
Ачылды шомлы хакыйкать,
Әрнү белән әйтәбез:
Миллиард еллар йөрдек Җирне
Өлкән алиһә күреп...
Язмыш төзәтте ялгышны:
Түгел икән мәңгелек!
Ә без — юкка чыга торган
Зат түгел — ана юктан...
Җир мескенем, түбән төшеп
Югала... аллалыктан.

Арей

Адәмнәр дә юкка чыга!

Зевс

Ә мин — өстемә алам —
Түбән аңлы җаннар торган
Яңа бер җисем табам!

Арей

Браво!

Ананк

Язмыш!

Аид

Җирнең асты
Калса, миңа — барыбер!

Афина

Ә мин түзәлмәм, йөрәгем
Җир-әнкәне сагыныр...

Зевс

Биргән антларны яңартыйк!
Аллалар серен ачмаска! *(Кабатлыйлар.)*
Адәм белән катнашмаска! *(Кабатлыйлар.)*
Кемнәр анттан читкә китә —
Мәңгелек җәза көтә! *(Кабатлыйлар.)*

Афина

Өстә... анда... Җир-әнкәбез...
Тоям җиде кат аша...

Зевс

Һәлакәте якынлаша,
Сизә, мескен, саташа...

**Икенче акт**

## 4. Афинаның Атлант янына килүе

**Аста, түбәндә — Зевсның яшен утларыннан яраланып, үлемгә дучар ителгән Атлант. Югарыда — нимфалар [1] уртасында—Афина.**

Нимфалар хоры

Бер битең — Ай, берсе — Кояш,
Гел-гел нурлар җыясың...
Җир йөзенә мәрхәмәтле
Нурларыңны коясың...

Афина

Җылы нур сипсә дә күкләр,
Ач һәм ялангач күпләр...

Нимфалар хоры

Гүзәллектә беркемнең дә
Күктә, Җирдә тиңе юк
Кеше яшәеше — мизгел...
Гомереңнең — чиге юк...

Афина *(нимфалар югала.*
*Афина — тирән уйда.)*

Җир йөзендә — бертуктаусыз сугыш...
Адәм гомере — мизгел болай да.
Ә кешеләр...
Мизгел гомерен дә яшәмичә,
Җир астында тынып калганнар...
Әйе, без — аллалар — Күк затлары...
Без — яшерен, серле чиксезлек.
Мин — алиһә, Күктән тартып алып,
Җиргә якты, җылы тараттым...
Галәм... Кояш... Ай да, йолдызлар да
Һаман калыр... Ә ник, нигә соң
Югалырга тиеш салкын Җирдә
Тормыш кора белгән Кешелек?!
Мин сокланып, кайчак көнләшеп тә,
Карап тордым аска, түбәнгә:
Алла башкаралмас могҗизалар
Иҗат иткән серле Кешегә.

[1] Нимфалар — борынгы греклар чишмә алиһәләрен кызлар кыяфәтендә сурәтләгәннәр һәм аларны нимфалар-кәләшләр дип йөрткәннәр.

Без — аллалар белән тиңләгәндә,
Адәм гомере, әйе, бер мизгел...
Чиксез еллар дәвамында белдем:
Кайчак ул... кодрәтле бездән дә!
Кешелекнең алга барышында
Хаклык һәм Явызлык — дошманнар...
Хаклык җиңгән саен, Явызлык та
Гел көчәя, мәкерләнә бара...
Җирнең астында да, өстендә дә,
Диңгез төпләрендә, күкләрдә,
Кешелекне юк итәрлек көчләр...
Нишләргә?
Бар Галәмгә акыл нуры чәчкән,
Җылы хисле җанлы түгәрәк
Явызлыгы, хакыйкате белән
Янып көл булырмы?
Чиксезлектә барча тереклекне
Иҗат иткән олуг Җир-әнкә,
Җирнең-күкнең акыл иясе
Үлемсез дип йөргән Җир-әнкә,
Бер мизгелдә юкка чыгарсыңмы?!
Ә аллалар — изге балаларың —
Явыз адәмнәрнең шашуын
Яклап, Күктә гамьсез калырлармы?
Әтиемә каршы... куркыныч уй...
Ул картлыгы белән ялгыша:
Явызлыкка каршы көрәшәм дип,
Усаллана, шәфкатьсезләнә...
Әмма... бар уйлары — саф ният белән...
Атлант шәүләләре пәйда булгач,
Ник сискәнде атам?
Ә Адәм...
Нигә килгән атлантларны эзләп?..

*(Атлачтка таба бер адым атлый.)*

Адәм белән, ераклыкта торып,
Сөйләшүдән — антны бозу юк...

*(Тагын бер адым атлый. Базның капкачын ача. Түбәндә яраланып егылган Атлантның газаплы йөзе яктыра.)*

Адәм, син исәнме?

Атлант

Син кем?

Афина

Алиһә.

Атлант

Кайсысы?

Афина

Афина.

Атлант

Зевсның кызымы?

Афина

Каян беләсең?

Атлант

Бала чакта әти сөйли иде...
Син килер дип өмет иткән идем...

Афина

Нигә?

Атлант

Син шәфкатьле, хисле алиһә бит.

Афина

Каян беләсең?

Атлант

Әти сөйли иде.

Афина

Әтиең кайда?

Атлант

Монда ята... Сугыш корбаны.

Афина

Адәм гомере — болай да бик кыска...
Һәр буынга — сугыш...
Сез... адәмнәр...

Атлант

Мин — Адәмнең илен яклап кына
Сугышырга мәҗбүр нәселеннән.

Афина

Адәм, нигә Җир астына килдең?

Атлант

Атлантиданы эзләп...

Афина

Таптыңмы?

Атлант

Эзләренә төшкән идем...
Тагын югалттым...
Синең явыз һәм шәфкатьсез атаң...

Афина

Тел тидермә! Алла сугар!

Атлант

Зевс сукты инде!
Атылган кош кебек егылып төштем
Җиргә түгел, Җирнең астына.
Чакыр миңа барлык аллаларны...
Мин аларны!..

Афина

Адәм, узынма!
Мин аңламыйм сине...
Җирегезне соңгы афәт көтә...

Атлант

Әйе, соңгы сугыш куркынычы...
Шуның өчен монда килдем дә.
Бүгенгегә — изге борынгылар
Һәм Киләчәк рухын кушып кына
Һәлакәттән мөмкин котылу!..

Афина

Аллаларның катнашыннан башка
Башкарырга уйлыйсызмы шуны?

Атлант


Әгәр кешеләрнең акылыннан,
Хыялыннан туган Алла булса...

Афина

Әгәр дә ул... синең алда булса?

Атлант

Әгәр дә ул минем алда булса,
Түзеп тормас иде бу хәлгә.
Әсирлектән азат итәр иде...



*иктор Аршинов рэсеме*

Афина
Күкнең мәрхәмәтсез кануннары
Тыйса ул теләктән алланы?
Атлант
Бабаларым патша кануннарын
Җимереп, Бәхет-Ирек яулады...
Афина
Без болай да Күктә — иреклеләр...
Атлант
Үзе азат булып, бүтәннәргә
Газап бирүчеләр — мескеннәр...
Сез — кемнәр?
Афина
Без — илаһи затлар!
Атлант
Безгә сез — ятлар!
Мине көтә Җирдә — илдәшләрем...
Монда — көтә иде атлантлар.
Сез — аллалар — кешеләрнең Җирдә
Күккә омтылышын сиздегез,
Сез — аллалар — явыз кодрәт белән
Бер илченең юлын өздегез!
*(Үз алдына.)*
Киләчәктән — инде бер хәбәр юк...
Ә атлантлар... хәзер юк алар...
Әллә инде максатыма җитми,
Җир астында эзсез югалам?!
Афина *(үз алдына.)*
Нишләргә?
Ниятләре — изге:
Кешелекне коткаруда үе.
Ярдәм итсәм?.. Антым бозыла...
Мондый адәми уй һич килешми
Алиһәгә — Зевс кызына!
Ул сиздерми...
Әмма күреп торам —
Бетә Адәм — тыны кысыла...
Адәм, синең әниең исәнме?
Атлант
Әнием... Исән... Ул карт... мине көтә...
Һәм ялварып сорый алладан:
«Кайтарсана, кайтар улымны»... ди,
Ышана шул, бәгърем... ул — надан...
Афина
Әнисең генә түгел, өмет белән
Көтә әле сине Зур әнкәң...
Атлант
Ул юк инде... әллә кайчан вафат...
Афина
Исән әле синең Җир-әнкәң!
Атлант
Җир-әнкәм...
Афина
Ул минем дә газиз Зур әнкәм.
Без бит — бер үк ана балалары;
Адәмнәре — Җирдә, Күктә — аллалары.
Әмма без — үлемсез балалар!

Атлант
Әгәр дә мин синдәй алла булсам,
Җирдәге һәр изге анага
Үлемсезлек бирер идем...
Афина
Зур әнкәгә телик — үлемсезлек!
*(Үз-үзенә.)*
Ул мәңгелек булсын өчен дә
Күкләр белән каршылыкка кереп,
Якыная барам Кешегә!..
*(Өскә карап.)*
Саф җилләрем,
Аяз зәңгәрлектән
Җир астына юллар сызыгыз...
Төнге нурлар,
Күктән бу Адәмгә
Салават күперләре сузыгыз!..
*(Караңгылык балкып, Атлантка салават күперенең нурлары сузыла, шул ук вакытта базга баскыч төшә. Атлант баскычтан югары күтәрелә.)*
Юлдаш булсын сиңа, Адәм,
Салават күперләре!
*(Үзе кире чигенә.)*
Атлант
Рәхмәт, алиһә! Ачылсын
Күк капусы серләре!
*(Аваз бирә.)*
А-у-у-у-у-у!
**Күктән «Ә-ү-ү-ү-ү-ү-ү!» дигән таныш авазлар килә башлый. Шул ук чакыру авазына атлантларның шәүләләре там-тамнар ритмына ярсу хәрәкәтләнеп килеп чыга. Алар, сөенечтән шашып, «Ә-ү-ү-ү-ү-ү-ү!» дигән таныш аваз белән, Атлантка таба киләләр.**
Афина *(үзе дә сизмәстән.)*
Атлантлар!..
Атлант
Атлантлар!..
**Күләгәләр Атлантка бик үк якын килмичә, туктап калалар.**
Атлантлар хоры
Без атлантлар дигән мәгърур халык идек,
Атлантида утравында тормыш кордык,
Сугышлардан — талашлардан баш тарттык та,
Ирек яулап, Шатлык чәчтек, Бәхет урдык.
Юлбашчыбыз — Атлант батыр, акылы — Җир,
Көче — океан, хисе — олуг диңгез иде...
«Патша да — без, алла да — без, титан да — без,
Бу утрауда һәрбер атлант — тигез»,— диде.
Гаделлекнең дошманнары чиксез икән,
Төрле яктан безне килеп камадылар...
Патшалар да, аллалар да, титаннар да
Урап алып, үлем белән янадылар.

Мең көн, мең төн көрәштек без — бирешмәдек,
Көч бетсә дә, җиңә бардык бер-бер артлы...
Мең беренче төнне кинәт давыл купты,
Җир тетрәде, күк күкрәде, вулкан атты!
Төшендек без: үч саклаучы Зевс алла
Атлантлардан котылырга күргән чара,
Афәт, дәһшәт арта бара,— атлантлар да,
Дошманнар да океанга бата бара...
Әйтте Атлант: «Җирдә-күктә нәсел калсын,
Хаклык ничек суга батсын, юкка чыксын?!.
Икесе дә канат ясап хыялланды:
Интал белән улы Зукар күккә очсын!»
Бата-бата, өметләнеп, карап калдык,
Очты Интал, очты Зукар Күккә таба...
Атлантида, без — атлантлар, соң мәртәбә
Бердәм җырлап, киттек... киттек төпкә таба...
Ярсуыннан тынды Зевс, гәүдәләрне
Ярга атты: «Бетте атлант дигән нәсел...
Менә, Аид, сиңа — утрау хәрабәсе,
Берниндн дә эз калмасын,— тирән яшер!..»
Без — атлантлар, беләлмибез — токымыбыз
Исән калып, киләчәккә юл алдымы,
Интал белән Зукар әллә Күк йөзендә
Эзсез калып, безнең кебек югалдымы?!
Без — атлантлар...

**Атлантларның күләгәләре Җир астына «батып» юк була.**

Җир астыннан атлантлар хоры

Без — атлантлар, югалдыкмы?

Күктән хор

Югалмадык! Югалмадык!

Атлант *(кәйлә белән казый-казый.)*

«Күккә очучы Атлант»...
Атлантиданың символы!
Ул берничә... Димәк, алар
Океанда калдырганнар...

*(Афина янына, югарыга күтәрелә-күтәрелә.)*

Җир астында — юкка чыккан
Атлантларның сагышы.
Күктән килә — исән калган
Атлантларның тавышы!
Халык — баткан, Хаклык — калган,
Җиргә, Галәмгә күчкән,
Күккә очкан, өстен калып,
Мәкердән, яман үчтән...
Берсен без белмәгән көчләр
Тартып алганнар өстән,
Берсе — Җиргә, мәрхәмәтле
Туфракка «егылып» төшкән.
Минем шәҗәрәм Җир-Күккә,
Суларга ялгерелгән!..
Димәк, мин дә атлантларның
Җирдәге нәселеннән!

*(Күтәрелә-күтәрелә, Афинага якынлаша.)*

Нинди ачыш! Җирләр-Күкләр
Тугәнлаша баралар!

Афина

Адәм... тукта!.. Безнең белән
Ерак сезнең аралар!..

Атлант

Ерак, әмма синең белән
Якыная баралар...

Афина

Хәзер — нинди шат баласың...
Бик күпләргә — ят баласың...

Атлант

Башым — Күккә тигән сыман!..

Афина

Кеше, иртә шатланасың!..
Шомга калып, Галәм көтә
Явызлыкның тантанасын...
Аллаларның бөек серен
Ачмаска дип ант иттем мин.
Әмма бүген коточкыч бер
Җинаятьнең шаһитымын...
Җинаятьче — минем атам!..

Атлант

Явызлыкка — хөкем бар ул!

Афина

Булмый аны хөкем итеп,
Үзе... үзе хөкемдар ул!
Калтыратып һәм тетрәтеп
Тота Суын, Җирен, Күген...
Аллаларның яшерен эшен
Мин ачарга мәҗбүр бүген...
Ни буласын белеп торам,
Аллаларның бозам антын,
Җирдә-Күктә әзерлиләр
Атлантида варнантын!

Атлант

Атлантида варнантын?!

Афина

Җиргә тизрәк кайт син, Адәм!

Атлант *(соклану, рәхмәт хисләре белән.)*

Зәңгәр күкләр алиһәсе...

Афина

Сак бул... Әйдә, озата барам...

Атлант

Син... Кешегә якынайдың!..

Афина

Һәм алырмын җәзасын да!
Катнашасым килми минем
Кешелек җеназасында!

Атлант

Нинди моңлы, илаһи син!..

*(Барыр юлына салават күперенең нурлары төшә.)*

Нур сибәсең юлларыма...

Афина

Салават күперләре сузам:
Тотынып кайт нурларына!

А т л а н т
Асрыклабыз якынлашып...
А ф и н а
Күп югалттык ятлар булып...
А т л а н т
Атлантларның бер символы
Калсын синдә ядкарь булып. *(Афинага тапшыра.)*
Хуш, алиһә... *(Китә.)*
А ф и н а
Исән-сау чык
Мәңгелекнең сереннән!
Исемең ничек?
А т л а н т *(югала-югала.)*
Атлант!
А ф и н а
Атлантлар нәселеннән... *(Караңгылыкта кала.)*
Н и м ф а л а р х о р ы
Бер битең — көн, бер битең — төн...
Танымаслык — төсләрең.
Зәңгәр күкләр алиһәсе,
Нишләдең?..
А ф и н а
Нишләдем?!
*(Борынгы греклар йоласын үтәп, озын кара толымнарын кисә дә атлантларның хәрабәләре өстенә сала.)*
Атлантларга... Афинадан...
Озын кара чәчләремне
Гомер бакый кисмәдем...
Нишләдем?..
Н и м ф а л а р х о р ы
Толымнарың төннәр алды...
Нишләдең?..
Беләсең ич, Җирдә түгел,
Күктә — синең ишләрең...
Зәңгәр күкләр алиһәсе, нишләдең?..
А ф и н а *(кыска чәчләрен тотып.)*
Нишләдем?!.
**Төн караңгылыгында югалалар. Арей күренә.**
А р е й
Адәм туфрагында — алла толымнары!..
Үз күзләрем белән күрмәсәм,
Ышанмас та идем... Ниһаять,
Бик күптәнге шигем расланды:
Аллалыктан ул түбәнгә төшкән!
Афина...
Үзе егылып төшә күкләрдән.
Бөек ата юкка тудырган да
Чиксез биеклеккә күтәргән!
Шулай була Җирдә, Күктә, Суда
Власть йомшаганда... Күр дә тор:
Тора-бара Адәм ярты юлда
Туктап калмас,
Күк түренә — безгә үрелер!
Йокы бирми миңа куркыныч шик:
Күзәтергә, тикшерергә кирәк... *(Югала.)*

## 5. Афина — атасы Зевс каршында

**Аид сарае. Зевс ялгыз. Аид йоклый.**

З е в с
Күләгәләр... Күктә, Җирдә тынса,
Калкып чыга Диңгез-Сулардан...
Эзәрлекли алар... Юк итә дә алмыйм,
Котыла да алмыйм шулардан!..
Йоклап китсәм, төшләремә кереп,
Кинәт ташланалар, буалар...
Адәм кодрәтендә калкып чыкты...
Тагын күләгәләр... Бу — алар!..
Аид! Үлгән сыман йоклый...
*(Селкетә.)* Аид! Уян!
А и д
Ни бар, аллабыз?
З е в с
Ничек шулай тыныч йоклыйсың син?
А и д
Үлгәннәрдән үрнәк алабыз!
Йоклау өчен миндә — әйбәт шартлар!
З е в с
Адәм эзләп килгән!.. Ни уйлыйсың?
А и д
Мин уйламыйм.
З е в с
Калкып чыкмаслармы... атлантлар?..
А и д
Атлантлар?..
Ышан, даһиебез, Җирнең асты
Өскә килгәндә дә тапмаслар!
Күпме еллар узган... Хәтер тузган...
Хәтта хәтердә дә калыкмаслар!
З е в с
Күләгәләр?!
А и д
Миндә — адым саен күләгәләр...
Монда — зарурилар, кирәкләр.
Үзем күләгәгә әверелдем,—
Курка миннән хәтта өрәкләр!
*(Көлә-көлә урыныннан тора.)*
З е в с
Базны качалмаслык бикләдеңме?

Аид
Адәм чыдамас!
Тикшерергә диеп төшсә әгәр,
Баш аллабыз үзе чыгалмас! *(Кәлә.)*

Зевс
Ышанма син йозак-биккә дә...

Аид
Дәһиебез юкка шикләнә.
Нәкъ адәмчә ысул: автоматик
Ачыла һәм янә бикләнә.
Аның серен тик аллалар белә.
Сезнең өчен инде тырыштым.

Зевс
Бик аз гына тынычландым кебек...

Аид *(йокларга бара.)*
Дәһи, тыныч төн!

**Арей, аның артыннан Анан керәләр.**

Арей
Каравыл!

Анан
Язмыш!

Зевс
Ни булды?!

Аид *(ятарга җыенып.)*
Җирнең асты — өстәме?

Арей
Адәм — юк!

Зевс
Ничек?!

Аид *(ятып.)*
Базда ул...

Арей
Баз — ачык!

Зевс
Ә?!

Аид
Булмас...

Анан
Мин шаһит!

Зевс
Кайда Адәм? *(Аидның юрганын алып ата.)*
Синнән сорыйм!

Аид *(урыныннан төшеп.)*
Анда иде...

Зевс *(ярсып, Арей өстенә килә.)*
Кайда ул?!

Арей
Ул... качкан!

Анан
Язмыш...

Зевс
«Язмыш»...
Ник сизмәдең шуны алдан?

Анан
Адәм язмышы бу, аллам!
Һич гаебем юк...
Арей — шаһит... бергә булдык...

Зевс
Качкан... Качкан... Димәк, Адәм
Алла белән катнашкан?!

Аид
Бик тә, бик тә ышанычлы
Иде йозак-келә...
Аның серен беркем белми...
Тик адәмнәр белә...
Әй лә... тик аллалар белә!
Мин гаепсез, үзең шаһит, аллам!

Зевс
Кем гаепле?!
*(Һәрберсенә шик белән.)*
Син?! Син?! Син?!

Арей
Түз, атам, бераз чыда...

Зевс
Ул, мәңгелек серен ачып,
Якты дөньяга чыга?!
Ничек кенә булса да, ул
Исән чыкмаска тиеш,
Аллалар абруен саклап,
Зевс — сукмаска тиеш!

Арей
Үз сүзең: «Алла, сукса да,
Белеп сугарга тиеш!»
Минемчә, ул Җир өстенә
Исән чыгарга тиеш!

Зевс
Мөмкин түгел!

Арей
Атам, тыңла...

Зевс
Ул кайтыр... Җирдән атлар!..

Арей
Җиргә килеп чыгу белән —
Юк булыр, ягъни... шартлар!

Зевс
Төшенмим, Арей... Тик сизәм:
Хәйлә оста үрелгән...

Арей
Яшен тизлегендә уйлап,
Чаралары күрелгән.
Адәмнең чыгу юлында
(Дошманы һаман ата...
Узган сугышта ярылмый
Калган снаряд ята.
Син бит, әти, алар кебек,
Ерактан да атасың...
Адәм шунда житкәч кенә,
Шул җирне кузгатасың!..

Зевс *(сөенечтән.)*
Һәм Адәм юк!.. Әкрен генә
Таң җиле булып исәм...
Безнең дә кеше алдында
Кимегән абруй исән!

Мактыйм, улым, безне янә
Күтәрәчәк бу эшең...
Адәмнәр белән көрәштә
Сизелерлек — өлешең!
Үземә лаек алмашлар...
Атагыз бик картайган...

А р е й *(ирония белән.)*

Әйе... лаеклы алмашлар...

З е в с

Кызым... Афина кайда?
Ул йокласын... уятмагыз...
Бик аргандыр шул кызым.
Киләчәккә өмет баглап,
Күктә янган йолдызым...

А р е й

Адәм белән бәйләнешкә
Кергән синең «йолдызың!..»

З е в с

Ялган...

А р е й

Адәм белән сөйләшкәнен
Анан ишетеп калган...

З е в с

Ышанмыйм... *(Ананга.)*
Колакларың ялгышкандыр...

А н а н

Шушы колаклар ишетте:
Язмыш шулай кушкандыр...
Кичер, аллам!

З е в с

Җир астында, табигый хәл:
Колакларың ялгышкан...

А н а н

Әйе... төнлә саташтым мин...
Узмыш юк шул ялгыштан!

А р е й

Ялгышмаган,
Анан дөрес аңлаган.
Үзем тикшердем: бу төнне
Афина йокламаган!

З е в с

Дәлилләр юк... Ул — илаһи,
Күкләрдән дә пакь бала...

А р е й

Бертуктаусыз мактый торгач,
Хәтта Кояш таплана...

З е в с

Кайда Афинам... табыгыз...

А р е й

Әнә... ул... үзе килә...

**Киеренке тынлык. Барысы да аның каршына басалар. Әкрен генә адымнар белән Афина керә. Аны танырлык та түгел: чәчләре тузган, төсе үзгәргән...**

З е в с *(шөбһә-өмет белән карап торгач.)*

Кызым, кәефләрең ничек?
Төнлә ничек йокладың?

А ф и н а *(өметсезлек-төшенкелек белән.)*

Йокламадым.

З е в с

Авырыйсыңмы әллә, кызым?

А ф и н а

Юк.

З е в с

Җир астында түгел, кызым,—
Күктә синең урының.
Зәңгәрлектә болыт сыман
Тараладыр толымың...
Озын кара толымнарның
Иясе тик син генә.
Андый толымнар алдында
Афродита чигенә...

А р е й

Нигә сорамыйсың, Ата,
Кайда соң ул толымнар?..

З е в с *(Афинага якын килә. Курку-шик белән.)*

Үз күзләремә ышанмыйм:
Кайда соң ул толымнар?!

А ф и н а

Кисеп калдырдым.

З е в с

Кайда?

А р е й

Адәмнәр кабере өстендә!
Үз күзем белән күрдем!

А ф и н а

Нинди түбәнлек... Димәк, син.
Арттан сагалап йөрдең?

З е в с

Чынмы бу, кызым, нахакмы?

А р е й

Ә хәзер сора кызыңнан:
Төнлә кем белән булган?

З е в с

Төнен кайда булдың, Афина?

А р е й *(усал.)*

Кайда булдың?

А ф и н а

Адәм белән!

*(Һәммәсе торараш кебек катып кала.)*

З е в с

Кем белән?..

А ф и н а

Адәм белән!

З е в с

Адәм белән?!

*(Калганнар да һәрберсе үзенчә шул ук сүзләрне кабатлыйлар.)*

А ф и н а

Әйе, Адәм белән.

Арей

«Ул — илаһи бала... пакь бала...»
Менә шулай Кояш таплана!

Зевс *(өмет белән.)*

Ялгышыңмы, әллә язмышыңмы?..

Анан

Язмыш, язмыш...

Аид

Ялгыш, ялгыш...

Арей

Хәзер... аклана...

Афина

Язмышым да, ялгышым да түгел,
Хаклык яклы булган адәмнәргә
Миндә — күптән сөю саклана!
Адәмнәрнең туфрагына тамды
Күзләремнән аккан яшьләрем,
Адәмнәрнең туфрагында калды
Ихтирамым булып чәчләрем...

Зевс

Хыянәт!!! Үз атаңа!

Арей

Аллаларга!

Зевс

Мәңгелеккә, Күккә хыянәт!

Анан

Даһиебез, уйлыйм: ул мөгаен,
Ярты юлда туктап, үкенгән...
Язмыш йолыр, бәлки, хөкемнән...

Зевс

Кылган гөнаһыңа үкенденме?

Афина

Ярты юлда туктап калмадым:
Озатып куйдым аны...
Җир-әнкәгә каршы юнәлтелгән
Серен ачтым һәрбер алланың!
*(Һәммәсе сискәнеп китә.)*

Анан

Язмышның — ар ягында!

Аид

Ялгышның — ар ягында!

Арей

Җинаять!

Зевс

Җинаять!!!

Афина

Хыянәт һич була алмый
Мин кылмаган җинаять...
Шулай бит, әти, әйтче?
Туп-туры карап әйтәм мин:
Син — үзең җинаятьче!
*(Һәммәсе куркып кала. Зевс калтырап куя, әмма сиздерми.)*
Йөрәгемдә күпме еллар
Сөю саклаган атам...
Гаделлекне, Хакыйкатьне
Кыю яклаган Атам...
Адәмнәрдән «Бөркет» исемен[1]
Ул юкка алган булган,
Күктә, Җирдә бөеклегең
Ул — матур ялган булган!

Зевс

Адәм — ялгыш юлга керткән,
Акылыннан яздырган!

Аид

Адәм аны аздырган!

Анан

Язмыш шулай яздырган!

Аид

Язмыштан — узмыш юк!

Афина

Менә монда — Җир астында —
Атлантида ята...
Бу — кемнәрнең җинаяте,
Әйтче, изге ата?!

Зевс

Нинди Атлантида? Кайда ята?
Адәм сүзен сөйли... Адәм сүзе — хата!

Афина

Менә — хәрабәнең бер кисәге:
«Күккә очучы Атлант»...
Чынлыкны булмый юк итеп,
Туфрак белән каплап!

Аид

Я алла!
Каян, каян килеп калыккан?!

Афина

Башта океанга батыргансың,
Күмдергәнсең аннан Аидтан...

Аид

Бу — аллалар сере... Син дә — алла!

Арей

Адәм коткысы!

Зевс

Күңелеңә яхшы от шуны:
Барлык кылган гамәлләрем
Сезне саклау хакына,
Юл куймау нияте белән
Күктә Адәм затына!

Афина

Шуны оныткансың, Ата!
Халык бата, Хаклык калка!
Атлантларның нәселләре
Җирдә, Күктә — исән!
Хаклык белән катнашудан
Кечерәймим, үсәм!
«Атлантида варианты» —
Сезнең соңгы иҗат!

Арей

Йомшама, ата, кызыңны
Җәзаларга озат!

---

[1] Борынгы грек мифларында һәрбер аллага бер кош яки хайван исеме багышланган булган (Зевска — бөркет).

Зевс
Күпме сөендем: «Акыллы
Бер бала үстергәнмен».
Бала түгел, Күк йөзенә
Зур бәла үстергәнмен!
Уйлыйсыздыр: «Алда — әти,
Аның хөкеме көтә...»
Атаң — юк! Атаң — юк... Сине
Күкләр хөкеме көтә!
Аллалар! Мине тыңлагыз!
Менә шул соңгы сүзем:
Җәза — Олимп тауларында!
Алып китегез үзен!..

**Аллалар Афинаны алып китәләр. Зевс, акылдан шашкан кыяфәттә, алар артыннан бара...**

## 6. Афинаны җәзалау. Атлантның һәлакәте

**Олимп таулары**

Хор
1. Бу дөньяда кеше генә
Җирне ут итә ала.
Ут явыз көчләр кулында,
Җирне юк итә ала!

2. Яна-яна батармы Җир,
Калдырып Мәңгелекне?..
Галәм сиңа карый, Кеше,
Җирнең гомере күпме?

3. Хыялый биеклекләрдә
Илаһи утлар яна.
Һәлакәттән Җирне бары
Тик кеше коткарала!

**Тау башында аллаларның Афинаны җәзага алып килүләре күренә. Кыска чәчләре җилдә җилфердәгән Афина, башын югары күтәреп, алдан, аның артыннан — Арей, Аид, Анан киләләр. Зевс — артта.**

Арей
Тукта! *(Афина туктала.)*
Әти, әмер бир!

Зевс
Аллалар җыелдымы?

Арей
Көтәләр!

Зевс *(уртага баса, Афинага.)*
Түбән төш!

Арей
Сиңа әйтәләр!
*(Афина бер баскыч түбән төшә.)*

Зевс
Тыңлагыз, аллалар!
Җир-Әнкәне алиһә дип йөрү
Ялгыш булган!
*(Тынлык.)*
Хатабызны Анан төзәтте.
Мәңгелек дип белгән Җир-әнкәнең
Бер мизгелдә мөмкин юк булуы!

Аллалар
— Юк булуы?!
— Ничек инде алай?
— Җир-әнкәбез мескен...
— Бичара...
— Чынмы бу?

Зевс
Расла, Анан!

Анан
Әйе, Җир-әнкәнең хәле шундый...

Зевс
Җир-әнкәбез, димәк, аллалыктан
Төшеп кала...

Аллалар
— Авыр язмыш!
— Бәхил бул, Әнкә!
— Рәнҗемә син безгә... балаларга...
— Язмышы шул...

Зевс
Расла, Анан!

Анан
Әйе, Җирнең шундый язмышы!

Зевс
Икенче мәсьәлә!
Тыңлагыз, аллалар! —
Арабызда түбән тәгәрәгән,
Түбәнлеккә төшкән алла бар!

Аллалар
— Кая тәгәрәгән?
— Кайда төшкән?

Зевс
Адәм белән бергә тоттык аны!

Аллалар
— Күрәселәр бар икән?
— Алла дигән бөек исемгә тап төшерде!
— Шаһитлар бармы?

Арей
Мин! Аид! Анан!

Анан
Шаһитлыктан — узмыш юк!

Аид
Җир асты — шаһит!

Бергә
Нинди гөнаһ кылган?

Зевс

Җиргә-Күккә сыймас гөнаһ:
Ул — аллалар серен ачкан!

Аллалар

— Җирдә-Күктә булмаган хәл!
— Антын бозган!
— Олы җинаять!
— Хыянәт!
— Кем ул? Кем — чиктән узган?!

Афина

Ул — мин! Афина!.. *(Һәммәсе тын кала.)*

Аллалар

— Афина?!.
— «Зәңгәр күкләр алиһәсе»!
— Көтмәгән идек!
— Җавабын бирсен!

Зевс

Әйе, ул — минем кызым Афина!..
Әмма хөкем алдында
Һәммәбез тигез... Җәзасын
Аласы бар аның да!

Аллалар

— Баш аллабыз, үзең сакла
Андый бәла-казадан!
— Алсын тиешле җәзасын!
— Узмыш юк шул — җәзадан!

Арей

Сузма, тизрәк хөкем чыгар!

Аид

Җәзаны сайла — үзең!

Анан

Язмышына да язылган:
Әйтсен ул соңгы сүзен!

Зевс

Соңгы сүзең?!.

Афина

Юк минем соңгы сүзем.
Җирдә кешеләр әйтерләр
Хәлиткеч соңгы сүзен!
Җир-әнкәне һәлакәттән
Коткарасы урында,
Сез уйлыйсыз Явызлыкка
Ярдәм итү турында!
Мин ышандым: гамьсез генә
Күктән сез күзәтерсез,
Җирне, Атлантида кебек,
Упкынга озатырсыз!
Үзегезнең Әнкәгезне
Үлемгә озатырсыз
Һәм, изгеләр булып, Күктән
Тын гына күзәтерсез!

Арей *(Зевска.)*

Туктат!

Зевс

Җитте!

Аллалар

— Юк, сөйләсен!
— Әйтеп бетерсен!

Афина

Әйе, Кеше кайгыларын
Йөрәккә якын алдым,
Сез еракка киткән саен,
Аларга якынайдым!
Сөенмисез Кешеләрнең
Башы Күккә тигәнгә,
Адәм биек күтәрелә...
Ә сез... ә сез — түбәндә!

Аллалар

— Ни карап тыңлап торасыз?!
— Ул сөйли Адәм сүзен!
— Бәлки, дөресен әйтәдер!
— Тыңлап бетерик үзен!

Афина

Әнә — Адәмнең урыны...
Аллалардан югары!
*(Һәммәсе югарыга карыйлар, кешеләрнең сугыш корбаннарына багышлап кабызган мәңгелек утын күреп, катып калалар.)*

Зевс

Бу — нинди ут!?

Афина

Сезнең мондый изге утны
Якканыгыз юк әле!

Аллалар

— Бу — нинди ут?!

Афина

Җир астында миллиард җаннар
Туфрак булып, онытылган...
Сезнең фатихалар белән
Юк булганнар — Ут булган!

Зевс

Аллалар каргышы төшсен!
Хөкем чыгарды атаң...
Үзем тудырган кызымны
Мин яшен булып атам!

Арей

Җирне дә онытма, Атам!
*(Яшен атыла, күк күкри, җир тетри.)*

Афина

Алга, Кеше, югарыга
Күк йөзеннән атлап бар!
*(Яшен яктысында Җир астыннан чыгып килүче Атлантны күреп, сөенеп.)*
Хаклык мәңге-мәңге батмас,
Яшәгәндә атлантлар!
*(Егыла. Шул ук вакытта Җирдә дә снаряд шартлап, Атлант, яраланып, ава.)*
Ах, явызлар!..
*(Дәһшәт тына. Җирдә — хәрәкәтсез яткан яралы Атлант. Югарыда — яшен суккан Афина... Сүзсез-телсез калган аллаларның шомлы куркыныч йөзләре...)*

Зевс

Киттек, аллалар, күченеп

Бу каргалган урыннан.
Адәмнәр менә алмаслык
Биеклекләр юлыннан!..
*(Кешеләрнең Мәңгелек Уты янында кечерәеп калган Утны ала. Афинаның җансыз яткан гәүдәсенә карап.)*
Кызым... Афина... Бәхил бул... *(Ахры, күзләреннән яшь тә тама..)*

Арей *(Зевска, әмер бирү тоны белән.)*

Йомшама! Алга! Туры!
*(Аллалар Зевс һәм Арей артыннан теләр-теләмәс кенә ияреләр.)*

Зевс *(кире әйләнеп.)*

Исән калсаң... кайт, балам... *(Китә.)*

Афина *(бераздан көч-хәл белән башын күтәрә.)*

Җир-әнкә белән калам!.. *(Башы тагын хәлсезләнеп төшә.)*

## Эпилог. Икарның анты

**Яраланган Атлант, аның улы Икар һәм археологлар яктыра.**

Атлант

Улым... Кил...

Икар

Килдем.

Атлант

Атлантиданы таптым... Тыңла...
Икәү — исән калганнар...
Берсе — Күктә, берсе... Җирдә...
Без... Җирдәге атлантлар...

Икар

Без — Җирдәге атлантлар!

Хор

Без — Җирдәге атлантлар!

Атлант

Күктән Җиргә тапшырылган
Сигналларны сизделәр...
Җирнең-Күкнең дошманнары
Элемтәне өзделәр...
Эзлә... тап... Күк туганнарын...
Аваз бар — Киләчәктән...
Коткарыгыз Җиребезне
Коточкыч һәлакәттән!
Мин... ышанам: ул да, син дә...
Очрашуга киләчәк...

Икар

Очрашырбыз!

Атлант

Кайда?

Икар

Күктә —
Кнек каз юлларында...

Атлант

Очрашырбыз.

Икар

Очрашмасак?..

Атлант

Сагынырсың... җырларыңда... *(Күккә карап.)*
Зәңгәр күкләр алиһәсе... *(Үлә.)*

Икар

Эти! Эти! *(Өстенә каплана. Матәм музыкасы.)*

Хор

Атлант! Атлант! Бездән китте...

Икар

Изге ант итеп әйтәм...

Икар һәм хор

Коткарырбыз Җиребезне
Коточкыч һәлакәттән!
Кешелек дошманнарының
Мәкерле уен өзеп,
Тормыш биргән Туган Җиргә
Яуларбыз Үлемсезлек!

*Апрель, 1982*

Марсель Зарипов

# ОТЫШЛЫ ӘЙЛӘНЕШ

ОЧЕРК

*...Азык-төлек программасын үтәү миллионнарча совет кешеләренең киеренке хезмәтен таләп итәчәк. Кадрларыбызның белеме һәм оештыру осталыгы, партиянең массалар арасындагы эшенең бөтен бай тәҗрибәсе — барысы да эшкә җигелергә тиеш.*

Л. И. БРЕЖНЕВ

Авыл тормышы бөтенләй бүтән, кайгыңа да, шатлыгыңа да барысы бергә шаһит була. Бер өйгә сөенеч килгән икән, бөтен авыл бергә шатлана, ә бер авылда шундый бәйрәм икән, тантанасы — районга, бөтен тирә-юньгә тарала.

1981 елның җәйге чилләсе иде. Миңа Татарстанның Актаныш районында кышны әйбәт уздырган терлекчеләр хөрмәтенә оештырылган тантанада катнашырга туры килде. Хәзерге авыл тормышында озын-озын өзекләр юк бит: кышын да эш муеннан, җәен дә кышны исән-имин үткәрү өчен кайгыртып тырышасың. Һәр минут санаулы, шулай да Актаныштa җаен тапканнар. Бәрәңгене утыртып, карабодайны чәчеп бетергәннәр, күпьеллык үлән басуларында «ясалма яңгыр»ны җайлап җибәргәннәр. Бу печәнне урыны-урыны белән чаптырып, яшел он ясау агрегатларына ташый башлаганнар. Кояшлы, җылы, якты җәйдә дә салкын кышны онуту юк!

Нәкъ шундый көннәрнең берсендә Актаныштa район терлекчеләренең бәйрәмен уздыралар. Терлекләрне зыян-зарарсез кышлатуга кемнең өлеше кергән — сыер савучымы ул, азык ташучымы, абзар караучымы — барысын да чакырып, хезмәтләрен хөрмәт белән билгеләп үтәргә карар кылганнар. Кышның үзәккә төшүчән суыгын гына түгел — анысы белән генә крестьянның һушын ала алмыйсың — терлекләргә азык җитмәү афәтен дә сер бирми үткәреп җибәргән терлекчеләрнең бу бәйрәмдәге сөенечен түкми-чәчми тасвирлау мөмкин түгел. Урамнарга плакатлар, кызыл әләмнәр эленгән. Культура сараеның фойесында күрсәткеч такталар бар. Аларга күз ташлау белән терлекчелекнең кай тармагы алда икәненә төшенәсең, һич тә баш ватып торасы юк. Берсеннән-берсе ләззәтлерәк ашамлыклардан өстәлләр сыгылып төшәрлек! Сәхнә артында агитбригаданың баянчылары төрледән-төрле көй сузалар, җырчылар тавыш чарлый, биючеләр аяк кыздыра. Бәйрәм икән, барысы да бәйрәмчә булсын, дип тырышалар.

Бу тантанада туган тәэсирләр ифрат күп төрле, барын бер тәртипкә салуы да кыен, күзгә ташланган һәр күренеш бик мөһим, бик кирәкле, һәрхәлдә, игътибарга лаек кебек тоела. «Таулар» колхозының япь-яшь савымчысы Рәкыя Нуретдинованы мактауларын ишеткәч, залда утыручыларның шатлыгы бермә-бер артты. Партия райкомы секретаре Равил Камилҗанов, Рәкыянең барлык иптәшләреннән дә күбрәк сөт савуын хәбәр итеп, кызны котлавын һәм аңа кыйммәтле бүләк тапшыруын гына көтеп тор-

дылар да, дәррәү килеп, кул чабарга тотындылар. Кызның бу җиңүе, бер яктан карасаң, көтелмәгән шатлык. Чөнки аның фермада эшләргә исәбендә дә булмаган. Сәүдә эшенә керергә уйлап, ул ниндидер курсларда укып йөргән, көтмәгәндә генә сыерлар сава башлаган һәм, барысыннан да уздырып, җиңүчеләр рәтенә баскан. Булдырган кыз! Ничек шулай килеп чыккан соң? Башкалар, гомер буе сыер карасалар да, Рәкыя уңышына ирешә алганнары юк. Андыйларга эш шатлык түгел, авыр бер йөк булып тоела. Хикмәт нәрсәдә?

Хәер, башта мин моңа әллә ни гаҗәпләнмәдем. Бу тормышта көтелмәгән хәлләр дә шактый еш очрый бит. Спортны гына алыйк: чаңгы эзенә яки бозлы юлга әле берәүгә дә билгеле булмаган яңь-яшь чаңгычы, тимер аякта йөгерүче чыга һәм моңарчы күренмәгән рекорд яулый. Чаңгычылардан — Галина Кулакова, Ринат Сафин, тимер аякта йөгерүчеләрдән Лидия Скобликова, Борис Шилков, Наталья Петрусева, җиңел атлетлардан Куц, Борзов җиңүгә шулай ирештеләр. Монда иң мөһиме — бәхет сәгатеңне кулдан ычкындырмаудыр, мөгаен, үз мөмкинлегеңне төгәл чамалый белүдер...

Башта мин терлекчеләрнең җиңүендәге сәбәпләрне дә һәр кешенең шәхси сыйфатыннан гына күрдем һәм әллә ни нечкәртеп тикшереп тормаган идем. Табигый ки, һәр уңган кеше хезмәтенең матур нәтиҗәсен күрергә омтыла. Бу юлы да башкалар Рәкыядән үрнәк алыр, сыерларын уңган кыз кебек үк карый башлар. Килер бер көн — аларны да мактап телгә алырлар.

Әмма уңышның серенә бәйрәмнәрдә, тантаналы нотыклар тыңлап кына төшенеп булмый икән ул. Җиңүгә кемнең ничек ирешкәнлеген беләсең килсә, көн-төн мал караучы кешеләрнең эш урыннарына, кырларга, фермаларга барырга кирәк. Мин дә фермаларда йөреп, малларның ни ашаганын күрэп, үзем өчен көтелмәгән бер ачыш ясадым: баксаң, кайсы савымчының — җиңүче икәнлеге, кайсының артта калачагы әллә кайчан иген кырында, председатель кабинетында расланган планнарда, агрономның чәчү әйләнешен билгеләгән картасында ук хәл кылына икән, ләбаса!

Сыер саву — уен эш түгел. Дөрес, машиналар хезмәтне шактый җиңеләйтте, гомер буе дәрья-дәрья сөтне савучы кулларның сызлануыннан зарланулар кимеде, шулай да кыенлыкларның беткәне юк. Азыгы мул фермаларда савымчыларның йөзе балкып тора, алар күп сөт биргәннәре өчен, сыерларын иркә сүзләр белән мактыймактый күңелле итеп эшлиләр. Азык ягы начар булганда, хәлләр мөшкел. Мин монда күләмне генә дә күздә тотмыйм, күбрәк игътибарны аның сыйфат ягына юнәлтәсе килә. Кайбер фермаларга керсәң, терлегеннән бигрәк савымчыларны кызганудан җан әрни. Алар да барыбер шул ук эшләрне үтәргә мәҗбүр бит: малларга азык тарата, тиресне чыгара, сыерларын чистарта, савытларын юа, әмма азабы җилгә оча — сауган сөте юк дәрәҗәсендә.

«Таулар» колхозы терлекчеләренә, әйтик, Шәймәрдәнов исемендәге колхоз савымчыларына караганда, әлбәттә, эшләү рәхәтрәк, чөнки аларның сыерларына ризыкны, күпме телисең, шуның кадәр үк булмаса да (зоотехниклар кайда да азык бирәмлеге чамасын санап кына торалар), төрләндеребрәк, туклыклырак итеп бирәләр.

«Таулар» колхозының председателе Инсаф Заһертдинович Камалетдинов — алга карап яшәүчән, акыллы, уңган кеше. Ул бүгенге адымының иртәгә кая илтәсен яхшы чамалый. Мисал өчен генә әйтим. Безнең заманда гаилә башлыклары күп балалы булырга әллә ни кызыкмыйлар. Тормыш — болай да катлаулы нәрсә, бераз үзең өчен дә яшәп калырга кирәк, диләр, бер-ике бала — җитеп ашкан. Камалетдинов башкача уйлаган, аның ун баласы бар. Вакытын да, мөмкинлекләрен дә тапкан, көчен дә кызганмаган, балаларын аякка бастырган. Аннан да бәхетлерәк кемне табарсың?! Камалетдиновлар өендә ел тәүлеге буе оныклар чыр-чуы хакимлек итә. Кеше язмышында шуннан да зуррак бәхетнең булуы мөмкинме?!

Гаилә, балалар, оныклар турындагы фәлсәфә сүз арасына болай гына килеп керде шикелле. Шулай да, әгәр тирәнрәк уйлап карасаң, кешенең тормышта кылган һәр эше аның шәхси сыйфатларына, сәләтлелегенә яки көчсезлегенә барып тоташа. Күп кенә председательләр, совхоз директорлары борчак чәчүдән котылып калу ягын карыйлар, чөнки аның «холкы» шактый четрекле. Эшне катлауландырмыйча гына да уңыш бирә торган бодай, арыш, арпа булганда, нигә үз башыңа үзең кайгы алып торырга? Инсаф ага башкача уйлый. Монда чәчүлек җирләренең унике процентын-

да — борчак. Авыр җәйләрдә, борчакны чалгы белән чабып, кул тырмасы белән тарап, басуны әй борынча бүлеп биреп, җыеп алган чаклар да була. Аның каравы «Таулар»ның терлекчеләре кышны курыкмыйча каршылыйлар, ит, сөт кимер инде, дип, дер калтырап яшәмиләр. Сыерларның тагарагындагы фуражның унбиш проценты — башка төр бөртеклеләрдә булмаган витаминнарга, аминокислоталарга, аксымга бай борчак.

Инсаф агадан: «Кыендыр инде?» — дип сорыйм. Сүз авыл кешесенең үз мәшәкатьләреннән олырак мәсьәләләргә — кырларга, фермаларга, әзерләү оешмаларына, «Сельхозтехника»га, ут күршеләргә, җитәкчеләргә күчеп торды да кабат председательнең үз гаиләсенә килеп тоташты.— Кыендыр, әй?

Ул миңа бик җитди итеп әздерәп карап торды.

— Нигә алай «кыен» ук дип әйтеп салдыгыз әле?

— Гадәткә кергән бит инде,— дим.— Бер-беребездән: «Җиңелдер? Рәхәттер?» дип сорарга өйрәнелмәгән.

— Шул-шул менә: без гел, кыендыр, дип уйлап башларга күнеккәнбез. Тормышның ләззәтен тоеп яшәү өчен, күз алдына аның матур ягын ешрак китерү кирәк! Бу заманда зур гаилә башлыгы булу җиңел түгел түгелен, тик балаларымның миңа күпме шатлык китергәнен чамалый аласызмы соң сез?! Балалардан башка миңа мең мәртәбә читенрәк булыр иде, тормышым, тырышлыкларым бөтен мәгънәсен җуяр иде. Баласыз гаилә — тамырсыз агач кебек бит ул. Кайбер авылларда капка төбендә сәлперәйгән карт-корчыклар гына күреп йөрим мин. Машина артыннан кычкыра-кычкыра бөтерелеп чабучы малай-шалае булмагач, нинди йорт ди ул?! Бүген кыен, алдагысы күңелле булачак. Борчак игү дә шулай. Басуга чәчү белән, быел бу борчак нилэр күрсәтер, дип шүрләбрәк йөрисең, тик, алай итми, болай булмый, дигәндәй, амбарда борчак мөлдерәп тормаса, эшләр харап!..

Булса да булыр икән кешедәге гайрәт! Кыяфәт тә шәп бу Инсаф ага Камалетдиновның: киң җилкәләр, төз буй, затлы киемнәр. Үзе тыныч кына сөйләшә. Холкының ныклыгына хәйран калырлык.

— Борчаксыз кем харап булсын инде? — дим. Миңа председательнең тел төбен белергә кирәк.

— Көт тә тор! Физик яктан гына да түгел, вөҗданың газаплана башлаячак.

— Аңламыйм.

— Аңа төшенү авыр түгел. Сыерның сөте кайда икәнен беләсеңме?

— Анысын беләм — телендә!

— Өстәп тә җибәрергә була: председательнең башында да, савымчының учында да әле ул сөт. Мин, җитәкче кеше, юньле фуражым юклыгын белә торып, фермага барыйм да, савымчылардан сөт муллыгын ни йөз белән таләп итим ди?! Ит белән сөтне сүз сөйләп кенә арттырып булмый аны, апаем, һәйбәт азык әзерли белергә кирәк!

Каләм-кәгазь белән генә эш иткәнлектән, мин терлек азыгының, хәтта элеваторда эшләнеп, озын-озак чиратлар торып кына кулга төшерелә торган концентратларның да, тукландыру сыйфаты ягыннан караганда, бер-берсеннән җир белән күктәй аерылып торырга мөмкин икәнлекләрен, төп аерманың азыктагы аксым күләменә, моның исә фермалар, димәк, савымчылар язмышына ни кадәр бәйле булуын белми идем әле. Ул җәйдә мин шул ук Актаныш районының Шәймәрданов исемендәге колхозында, амбар кенәгәсен актарып, фуражда нинди бөртекнең күпме булуын белдем һәм терлекчеләр бәйрәмендә бу колхоз савымчыларының ни өчен макталмавын да аңладым.

Сыер тагарагына печән, салам, чөгендер, силос белән бергә һәрчак бөртекле кушылма да салына. Бөтен хикмәт әнә шул кушылманың сыйфатына барып тоташа. Әгәр ул кибәктән генә тора икән, бу шул ук салам инде. Ә фуражга төрледән-төрле бөртекләр салынган булса, бу инде — бәйрәм, ягъни ит, сөт, май муллыгы дигән сүз.

Мисалга саннар китерми, котылып булмас. Иренмик, башта Шәймәрданов исемендәге колхозның амбар кенәгәсеннән кайбер саннарны карыйк әле.

Урып-җыюның иң кызган аеннан саналган сентябрьдә малларга бөртекне кызганмый биргәннәр. Бу айда малларга 1211 центнер арыш, 816 центнер бодай, 478 центнер арпа, 16 центнер да 30 килограмм борчак калдыгы ашатылган. Октябрьда

терлек тагарагына арыш, арпа һәм бодай — 125, 2254, 175 центнер күләмендә салынган.

Ноябрьда фуражда нинди үзгәрешләр була? Арыш, бодай, арпа өстенә 33 центнер вика калдыклары кушыла, 2158 центнер фуражда тоелмый да ул. Декабрьда фураж бирү бераз арта, 2561 центнерга җиткерелә, әмма борчак белән вика монда да 158 центнер гына кушыла. Январьда да шул ук хәл, борчак фуражның 8 процент чамасын гына тәшкил итә.

Февральдә терлек азыгына бөртек салу кими, күрәсең, запасның бетү куркынычы килеп баса, борчак бөтенләй бирелми, фуражга бары тик арыш һәм бодай, бодай һәм арыш кына салына. Мартта күренеш үзгәрә, чәчүлеккә калдырылган запаска керәләр, ахры, агрономнарны кысалар, сыерлар табынына борчак, вика кебек затлы ризыклар да бирелә.

Апрельдә инде кояш күңеллерәк карый башлый, әмма терлекләрне көтүгә чыгарып булмый әле, киресенчә, ризыкны мулрак итәргә, тәрләндерергә кирәк, тик өсәкләр тап-такыр, шул ук бодай, арыш, арпадан торган фуражга 48 центнер да 53 килограмм вика калдыгы өстиләр.

Май аенда фермалар, апрельдә ни күрсәләр, шуны ук кичерәләр, ә июньдә яшел чирәм күренә башлый, арышны яшел килеш чабалар, су сиптереп үстерелгән печәннән файдаланалар, рационга декабрьда тотылганның яртысы кадәр бөртек тә өстәлә. Нинди бөртек, дип сорасаң — шул ук бодай, шул ук арпа...

Инде менә июль башында кышны исән-имин уздырып җибәргән терлекчеләрнең бәйрәмен оештырганнар. Табигать барлык колхоз-совхозларга бер үк тәрле: салкынын да, җил-бураннарын да тип-тигез бүлгән иде. Әмма Шәймәрдәнов исемендәге колхоз терлекчеләре бәйрәмдә ниндидер хуплау сүзе ишетергә өмет тә итмәделәр.

Могҗизалар күтеп яту заманнары үтте. Мин, фермаларындагы хәлләр белән яхшы таныш булганга, шәймәрдәновлыларны ел йомгагы буенча мактамаячакларын алдан ук белеп тордым. Савымчылар кызганыч, әлбәттә, тик, нишләмәк кирәк, күрсәткечләр күпме көч түгүеңә карап түгел, хезмәтең китергән нәтиҗә белән билгеләнә. Мактаулы савымчылар исемлеген «Таулар» колхозының яшь-яшь терлекчесе Рәкыя Нуретдинова башлап җибәрде. Ул һәр сыерыннан 4062 килограмм сөт сауган. Рәкыя артыннан шул ук ферма алдынгыларының исемнәре Әнисә Афзалова, Хания Нурисламова, Мөслимә Вагыйзуллина тезелгән. Бу савымчылардан соң дүрт мең килограммнан кимрәк сөт алган кызлар тезелгән. һәр сыердан савылган сөт күләмен күрсәтә торган сан 3300 килограммга төшкәч кенә, Шәймәрдәнов исемендәге колхозның шулай ук таңнан-таңга фермада тир түгүче уңганнары телгә алынды: Таһия Хасбиева, Рәсимә Фәхриева, Флюра Сабирова, Наилә Солтанова, Зәйнәп Низамова... Тырышлыкларына тел тидерерлек түгел бит, югыйсә, нәтиҗәсе генә күзгә күренми. Борынгылар, сыерның сөте — теленда, дип, белми әйтмәгәннәр. Ашатуыңның рәте булмагач, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр фермада чиләнүдән генә ни файда?! Акыллы хуҗалар фуражга алтын бәясенә торырлык бодай белән арыш салырга ашыкмыйлар: бердән, малларга файдасы аз, икенчедән, бөртек әрәм. Терлек өчен иң туклыклы ризыктан ясмык, фасоль, борчак, соя санала. Сояда мәсәлән, аксым матдәсе 36 процентка җитә, бодайда — 12, арышта — 11, дөгедәге аксым исә нибары 6,7 процент кына.

Ни өчен чәчү әйләнешен терлекчелек мәнфәгатьләреннән чыгып планлаштырмыйлар, басуда нәрсә үстерү турында уйлаганда, ни өчен малларның тагарагына ни салыначагы белән кызыксынмыйлар?

Бу сорау, беренче карашка, беркатлырак яңгырыйдыр, әмма аңа туры җавап табу шактый кыен, аңысын биниһая катлаулы тормышның үзеннән эзләргә кирәк. Чыннан да, ни өчен кайбер колхоз-совхозлар кышны борчагы да, викасы да, солысы да, арпасы да, кукурузы да җитәрлек күләмдә булган әйбәт фураж белән каршы алалар, икенчеләр исә терлек азыгына кыйммәтле, әмма бәрәкәтсез арыш белән бодайны исраф итәләр?

Гади генә тоелса да, ифрат мөһим бу мәсьәләгә чишелеш эзләп, мин төрле өлкәләргә бардым, күп белгечләр белән очрашып сөйләштем, кайчак, кайнар бәхәсләргә кергәләргә туры килде. Үземнең дә кайбер фикерләрем үзгәрде. Хуҗалыкта исәп-хисапны яратучан Инсаф ага Камалетдинов мине саф суын Кама белән Иделгә

коючы сихри Агыйдел буйларыннан озатып калгач, юлым Терек елгасы ярына, Төньяк Кавказның мәгърур таулары һәм серле үзәнлекләренә барып чыкты. Аннан илнең төп туендыручысыннан саналган кара туфраклы Воронеж, Курск, Белгород өлкәләрендә булдым. Тәэсирләргә баеп, бик күп мисаллар җыеп, илебез башкаласына — төрле яклардагы меңнәрчә кешеләрнең хезмәтен бер ноктага туплаучы, аңа юнәлеш бирүче оешмаларга килеп туктадым.

Күреп белү — эшнең яртысы да түгел әле ул. Шулкадәр озын-озак юл үтүләрнең, кәгазь-каләм алып, газап чигеп утыруларның сәбәбен башкаларга да аңлатырга, үзеңнең ачышларга аларны да инандырырга кирәк, иң четереклесе шул анык. Язучының да иң якты теләге — башка һөнәр ияләренеке кебек үк, үз кылганнарыннан җәмгыятькә файда китерү ләбаса!..

*

* *

Кабарда Балкариясендәге «Майский» совхозының директоры Михаил Григорьевич Роменский — Шолохов романында сурәтләнгән Нагульнов кебегрәк, юлында очраган шик-шөбһәләргә бик исе китмәүчән гаҗәеп бәхетле кеше.

Бәхет кенә дә түгел, бу — аның тормышы, язмышы.

Әлеге җылы якларга Роменский 1965 елда килгән һәм, минем уемча, Төньяк Кавказ тирәләрендә беренче буларак, җәнлек совхозы корып җибәргән. Моңарчы Камчаткада яшәвен истә тотып, аңа форель кебегрәк затлы балыклар үрчетергә тәкъдим итеп караганнар. Әмма ул җиңел юлдан китәргә кызыкмаган, махсус совхозда чәшкеләр үстерә башлаган.

Мин «совхоз кору» сүзен кулландым. Бу тәгъбирдә кешенең иҗат итүен сиземләргә мөмкин.

Яңа завод салынамы, совхоз оештырыламы, гадәттә, аны тизрәк планга элэктеру ягын карыйлар, аннары, аяк терәп, акчасын, төзелеш материалларын, тегесен-монысын таләп итәргә тотыналар. «Майский» совхозы исә алдан планга керми калган. Роменский өчен бу киртә генә әллә ни зур фаҗига булмаган, совхозын ул Госбанктан бурычка алып кора башлаган. Бурычның, рәсмирәк итеп әйтсәк, ссуданың исә иң отышлы саналганы да акча гына бирә. Калган кирәк-яракның бөтенесен, мең дә бер каршылыкны җиңә-җиңә, үзеңә табарга кала. Бу хәл күп очракта кичеп чыга алмаслык авырлыклар тудыра. Мисал итеп теләсә никадәр вакыйгалар сөйләргә мөмкин!

Роменский очкыннар чәчеп торучы яшь егет тә түгел, пенсия чорына якынлашып бара. Үткән сугышта ул очучы булган, дошман самолетларын бәреп-бәреп төшергән, аның үзен дә машинасының фюзеляжы аша пуляләр тишкәләгән. Әмма Михаил Григорьевичның йөрәге яшьләрнекеннән һич кенә дә ким дәрләми. Язмыш аңа кечтеки бер сөенеч кенә китерсен, калганын Роменский үзе очлый. Гомер буе уңышсызлыклардан зарланып йөрүче кешеләр белән чагыштырганда, киресе килеп чыга, бу үзе кыенлык эзли кебек, хыялындагыны тормышка ашыру өчен, янып-көеп йөри. Борчуларсыз гына уза торган гомерне ул күз алдына да китерергә теләми шикелле. Бүгенге көндә, бөтен эшләр алдан ук планлаштырылып, кысалар эченә кертелгән кайсы гына директор, «монысын бирмиләр», «рөхсәт юк», «планга кертмиләр» кебек аһ-зарсыз яши? Роменский шуңа охшаш мең кыенлык алдында калган булса да, зарланып-нитеп тормыйча гына, илгә менә дигән совхоз корып биргән. Ит, затлы тиреләр житештерә, миллионлаган файда китерә. Йөз мең чәшкеле ферманың ни икәнен күз алдына китерегез, шактый зур байлык!

Инде чамалап карагыз: кайсы директор, муеннан бурычка батып, завод, фабрика сала башлар иде? Андыйны кайдан табасың? Роменский тәвәккәлләгән. Бурычын исә, процентын-фәләнен кушып, вакытында кайтарып биргән, 20 миллион сум табыш та алган.

Җебегәнрәк кеше өчен бу кадәресе дә, Эльбрусның ак бозлы түбәсе кебек, бөтен гомер буена ымсындырып торучы бер биеклектәй тоелыр иде инде. Роменский тагын да колачлырак яңалык белән янып йөри башлый, ала-кола боланнар үрчетергә алына. Җанны җилкендерүчән теләкләр күпләргә хас, әмма кайберәүләр,

канатлы хыялларын күңел түрендә йөртә-йөртә дә, шуның белән канәгатьләнеп тә кала. «Майский» совхозының директоры сүзен озакка сузучылардан түгел, әйткән икән, нәкъ шулай эшләп тә куя. Хәзер Нальчик тирәсендәге таулар өстендә тимер рәшәткә белән бүлеп алынган мәйданнарда мәһабәт боланнар яшәп ята. Аларның тармакланып үскән яшь мөгезләреннән гаҗәеп шифалы пантокрин дигән сыекча алына. Дөрес, Роменскийның эшләре дә шома гына бармый. Боланнарның итен дәүләткә тапшыру — мең бәла икән. Моңа кадәр Ерак Көнчыгышта, Якутск тирәләрендә яки Нарьян-Марда гына асралганга күрә, Төньяк Кавказдагы болан итен дәүләткә кабул итү шартлары каралмаган. Монысы гына әллә ни зур кайгы түгел, әлбәттә, булган малга хуҗа табылыр.

Моннан ун ел элек, исемен махсус карарга кертеп, Роменскийга йорт куяны үрчетү бурычы йөкләтелә. Норма 400 баш ана куян асраудан башлана, дәүләткә куян тиресе, диетик ит тапшыру планы карала. Директор борчуга төшә: нәрсә инде ул 400 баш куян?! Озын-озак уйлап тормый ул, фермаларны үзе теләгәнчә мул иттереп салдыра һәм ике мең баш ана куян асрый башлый. Монда хәзер ел саен 60 000 куян үстерәләр. Үрчемнең яртысы ит белән тирегә тапшырыла, калганнары илнең башка фермаларына нәсел өчен озатыла.

Соңгы вакытларда Роменский әле күпләр өчен яңалыктан саналган шөгыль белән мавыкты —ябык бинада су күселәре үрчетә башлады. Читлекләрен көйләгән, сәер имезлекле су эчкеч җайланмалар булдырылган, азык тагараклары тездергән, аучыларга күлдән бер-ике дистә су күсесе ауларга кушкан. Хуҗалыктагы бу яңа тармак та эзгә төшеп бара. Бүгенгесе көндә «Майский»да промышленность казанышларына нигезләнгән яңа төр ферма эшли, анда унбиш мең су күсесе тәрбияләнә. Нәтиҗәсе — күз алдында. Хәзер бу эш ил күләмендә киң кулланышка керә, яшь күселәрне сорап кына торалар. Татарстанда да, Урал якларында да, Калинин өлкәсендә дә су күселәрен үрчетү фермалары күренә башлады.

Әгәр һәр омтылышының төбендә үз хезмәте өчен, бу якты дөньяда уздырган һәр көне өчен җаваплылык тоеп яшәвен искә алмасаң, Роменский кылган эшләр, аның җан тартышып тырышуы, хуҗалыкны әледән-әле яңа тармакларга тарткалап кертергә ашкынуы, беренче карашка аңлашылып та җитми. Партия эшенә ихластан бирелгән, гаҗәеп көчле холыклы, югары дәрәҗәдә тәрбияле бу җитәкче, зур максатларга йөз тотып алга барганда, юлда очраган каршылыклардан шүрләп калмый, һәр кыенлыкны тиз арада җиңү әмәлен таба. Авырлыклар исә аңардагы көрәш рухын тагын да көчәйтә төшә.

Шактый читкә кителде, бугай. Сүзне Роменскийның үзенә-үзе сорап алган хәсрәттән башлаган идек бит. «Майский» совхозы директорының азык әзерләү цехы турында горурланып сөйләвен һич онытасым юк. Зур-зур заводлар белән чагыштырганда, камиллеге, масштаблары ягыннан әллә ни шаккатырмаса да, бу цех тирәннән уйлап, файда китерерлек итеп салынган булуы белән сокландыра. Гөжләп утырган калориферда борчак, арпа, солы, кукуруз куыралар, аларны шунда ук тарттыра да башлыйлар, аңа яшел масса, әллә нинди тәмләткечләр кушалар, тагын бер махсус машина аша чыкканда, әлеге хуш исле, ләззәтле кушылма, безнең телгә гранула дип кереп бара торган, бавырсак сыман кыяфәт ала.

Мондый бавырсакларны су күселәре дә, куяннар да бик яраталар, автоэчергечтән килә торган су белән куша-куша тәмләп ашыйлар икән. Цехта эшчеләр күп түгел, нибары сигез генә кеше. Корылманы салу 37 мең сумга төшкән.

Роменский шикелле өлгер директорны, һич икеләнмичә, мактарга кирәк иде, тик мин уйлап куйдым: бу цех ни пычагыма кирәк булган соң? Мәгълүм ки, илдә әзерләү министрлыгының комбиазык ясау заводлары бар һәм «Зверопром»га караган хуҗалыклар, шул исәптән «Майский» совхозы да, җәнлекләренә кирәкле бөтен ризыкны шуннан алырга тиеш. Нигә соң бу Роменский, мең бәясенә төшереп, үз цехын ясап мәшәкатьләнгән?

Элеваторларга машиналарыңны вакытында җибәрергә генә иренмә, витамины да, грануласы да, концентраты да әзер килеш килеп торачак лабаса?!

Күңелемдә шуңа охшаш сораулы уйлар уянганлыктан мин, Роменскийның үзешчәнлеген мактаудан тыелып тордым, бу хакта аңа да әйттем. Директор үземнән сорады.

— Элеватордан кайткан комбиазыкның нинди икәнен беләсезме соң сез?

— Юк. Стандарт буенча ясала торгандыр инде...

— Стандартын стандарттыр ул, бәлки. Әмма ләкин нинди стандарт бит? Менә хикмәт нәрсәдә! Бер көнне шоферым гаражда ярты капчык комбиазык калдырган. Иртән килсә, бөтен гараж иләнен күсе маэтләре тутырган, ди. Агуланганнар.— Директор аклангандай аңлатырга тотынды.— Без бит башкалар өлешенә кермибез. Элеватордан үзебезгә тиешле комбиазыкка салыначак ашлыкны алабыз, түләп, әлбәттә, әзер комбиазыкка түләгән кебек...

— Башкалар өлешенә кермисездер, бәлки. Тик үз кесәгездәгене туздырганда, шулай юмарт кылану да килешеп бетми, азык әзерләү цехыгыз утыз җиде меңгә төшкән бит!

— Без шуның бәрабәренә миллион табыш алдык. Сез бер тиен дә табыш бирми торган ферма асрауның нәрсә икәнен беләсезме?

— Бераз чамалыйм кебек.

— Андый хуҗалык ул, беләсегез килсә, кешеләрнең энҗе кебек күз яше, хәерчелек, мескенлек. Теге күсе маэтләре турында мин арттырыбрак җибәрдем, бугай. Ә менә йорт куяннары, азык начар булса, кырылып үлә башлыйлар. Элеваторда азыкка калдык-постыкны күп кушалар, ахры. Безнең миллионлаган табышларыбызның нигезендә үзебезнең азык әзерләү цехыбыз тора...

Бу сөйләшүне шунда туктатып, тирәндәрәк яткан сәбәпләрне тикшереп карыйк әле. Роменский кебек үз эшендә бары тик гадел һәм файдалы алымнарны гына алга сөрүче директорны өстәмә мәшәкатьләр, зур чыгымнар бәрабәренә әллә нинди комбинацияләр корып азапланырга нәрсә мәҗбүр итә соң? Агымдагы хәлләрме, әллә киләчәктәге үзгәрешләрне тоюмы, әллә бөтенләй башка берәр сәбәпме? Директорның мондый тәвәккәллегендә, минемчә, бүген үк алга килеп баскан мәсьәләне хәл итәргә тырышу да, хуҗалыкның иртәгесе көне турында тирәнтен кайгырту да бар.

«Майский» совхозында чәшкеләр, боланнар гына үрчеткәндә, азык мәсьәләсе әллә ни зур мәшәкать тудырмаган. Боланнарны тау битләрендә табигый көтүлектә йөрттеләр, чәшкеләргә кирәгән ит комбинаты биреп тора. Йорт куяннары белән су күселәренә исә бөртекле, үләнле ризыклар кирәк. Су күселәре арпага да канәгать, ә менә куяннар үләнен дә, татлы кишерен дә, аларга өстәп тагын әллә нинди витаминнар да сорыйлар. Теләгәннәрен бирмәсәң, ул озын колаклар шатлык китерер дип көтмә икән.

Көяшлы Кабарда Балкариясе — кукуруз һәм бодай үстереп дан казанган як. Илебезнең илледән артык өлкәсе, крае, автономияле республикалары Төньяк Кавказ уңганнары үстергән кукуруз орлыгыннан файдаланалар. Дөрес, чәчү әйләнеше кануннарын, ягъни кайсы басуда ни үстерергә кирәклеген күрсәтүче чират тәртибен, шулай ук терлекчелек мәнфәгатьләрен искә алып, бу якларда да фуражлык иген үстерергә — солы, арпа, борчак игәргә тиешләр. Тик күп хуҗалыклар бодай белән мавыга. Республика басуларының нибары процент ярым чамасы — 5 мең гектар чамасы гына борчакка бүленгән, арпаны 16 мең гектарга чәчәләр. Республикадагы мал-туарга исә ел саен өч йөз мең тоннадан артыграк концентрат кирәк. Бу ихтыяҗны басуларга чәчкән бер уч борчак һәм арпа белән генә канәгатьләндерергә азаплану кукуруз боламыгыннан күмәч пешерергә теләгән кебек үк мәгънәсезлеккә китерә. Концентратларның туклыклылык дәрәҗәсе түбән булу фуражга салына торган бөртекне арттыра барырга мәҗбүр итә. Унбиш ел элек республика фермаларындагы фуражда 22,9 процент бөртек булган, уныпчы бишьеллыкның соңгы елында бу 40 процентка җиткән. Фураж куллану да, аның бәясе дә үсә, әмма терлекләрнең һәм кош-кортның ите дә, мае да артмый. Һәр сыердан уртача 2200 килограмм сөт савалар, симертелә торганнары көнгә ярты килограмм, дуңгызлар 220 грамм гына артым бирә. Бу хакта сөйләгәндә, иң элек азык җитмәүне сәбәп итеп китереп куялар. Исәпли башласаң, терлекләргә кирәгеннән артык, бер ярым норма ашатылган булып чыга. Бер центнер сөт алу өчен — 1,8, сыер итенә — 16,9, дуңгыз итенә — 10,9 центнер азык бирәмлеге тоталар. Азык җитмәү шундый буламыни?! Киресенчә, ул артык күп, кадере беткән.

Кабарда Балкариясендә терлек азыгын болай әрәм-шәрәм итүне аерым шартлар белән аңлаталар. Янәсе, мондагы колхоз-совхозлар илгә кукуруз белән бодай өлгер-

тергә алынганнар икән, әзерләүләр министрлыгы фуражга кирәкле аксымлы бөртекләрне башка җирләрдән табып бирергә тиеш. Әмма көн дә кирәкле азыкны башка җирдән ташу күп чыгымнарга, өстәмә мәшәкатьләргә бәйле. Я транспорт табылмый, я кирәкле запас юк, очы очка ялганып бетми кала. Гомумән дә, аксымлы азык җитмәү — бер безнең илдә генә түгел, гасырыбызның дөньякүләм мөһим мәсьәләсе ул.

Шул хәлләрне күреп-белеп торган зирәк җитәкче, әйтик «Майский» совхозы директоры, нишли ала соң? Терлек азыгы әзерләргә тиешле оешмаларның аһ-ваһ килүен тыңлап торудан гына җәнлекләрнең тамагы туймаячагын бик ачык аңлый да азыкны үз көче белән булдырырга алына.

Беренче карашка, бу алым Кабарда Балкариясе шартлары өчен генә, фуражга кирәкле бөртекләрне үзендә җитештермәгән республикаларда гына очрый. Республика уныичы бишьеллыкта ашлык сату планын арттырып үтәгән, ә ит, сөт җитештерүе артта калган. Терлекләрнең баш исәбе шактый, пландагыча керем алырга да мөмкинлек бар иде.

Төньяк Кавказдан кайткач, мин Казан янындагы бройлер фабрикасына бардым һәм, гаҗәпләнүемә каршы, нәкъ шушы ук хәлгә тап булдым. Ак халатлы лаборанткалар элеватордан китерелгән азыкны, әллә нинди тигезләткеч, болгаткыч машиналар ярдәмендә, тиешле дәрәҗәсенә җиткерергә азапланалар. Михаил Григорьевич Роменский башына төшкән хәсрәт монда да бар икән! Комбиазык заводларының продукциясен урыннарда өр-яңа баштан эшкәртү гадәткә кергән икән. Шул вазифаны үтәүче белгечләр планда ук каралган икән ләбаса! Гаҗәп! Колхоз-совхозларда азык цехы булдыру түгел, ә терлекне ансыз гына асрарга тырышу гаҗәп булып чыга түгелме соң?

РСФСРның «Птицепром» главкасы дәүләткә ел саен 22 миллиард йомырка тапшыра торган 846 колхоз-совхозны берләштерә. Аларда 4302 эшче таләп итүче 569 азык цехы гөрләп утыра. Монда азыкның сыйфатын яхшырталар, каршы бер сүз дә әйтмәс идем — кирәкле эш. Әмма, ачыклыйрак төшсәң, аңлыйсың. Бу цехлар комбиазык заводларының ярдәмче предприятиеләренә әйләнгәннәр, алар әзерләүләр министрлыгы заводлары башкарырга тиешле эшне кабат эшлиләр, төзәтәләр, яхшырталар. Бер Роменский гына түгел, йөзләгән, меңләгән терлекчеләр, мал-туар асрауның файдасын күрим дип, әнә шул юлга мәҗбүри басалар.

Хуҗалыкларга өстәмә чыгым, кирәкмәгән мәшәкать тудыручы бу ысул икенче берәүләргә бик җайлы. Колхоз-совхозлар концентратларның тулы хакын түли. Яхшымы ул, начармы — бәясе бер. Шулай итеп, комбиазык заводлары башкаларның тырышлыгы хисабына баеп ята, дигән сүз.

Укучы минем күңелдә кайнаган ачуны аңлыйдыр инде: үзем Мәскәүдә, метродан чыгып, Кржижановский урамы буйлап әзерләүләр министрлыгы урнашкан күпкатлы бинага таба атлыйм, үзем сораулар бирү турында уйлыйм. Нинди хәл инде бу, дим, халык хуҗалыгының зур бер тармагы башкаларның тырышлыгына аркаланып яшәп ята түгелме соң?!

Ниндирәк җавап ишетәчәгемне дә чамалабрак куйдым: колхоз-совхозларга да берәр үпкә белдерерләр, ниндидер аңлашылмаучанлык телгә алыныр һәм киләчәккә якты өметләр багланыр, дип ышандым. Сөйләшә торгач исә, хәлнең тәмам гадәти күренешкә әйләнеп калганлыгы ачыкланды.

Россия Федерациясенең әзерләүләр министрлыгына караган комбиазык индустриясе главка начальнигы Нил Петрович Притула:

— Сез бик дөрес әйтәсез. Бу мәсьәләдә безгә таныш булмаган бернәрсә дә юк,— дип, минем бөтен ялкынымны сүндерде дә куйды.— Хөкем чыгарырга ашыкмагыз! Әүвәл безнең хәлне карагыз!

— Минем хөкем генә хәлне җиңеләйтерме соң?

— Һич югында мәсьәләгә ачыклык керер, дип уйлыйм. Без бит азыкны игенче ни бирсә, шуңардан ясыйбыз. Химик элементлар өстәү күпмедер файда китерә, әлбәттә, әмма ашлыкны берни белән дә алмаштырып булмый. Дозаторларга, болгаткычларга безнең ниләр салганны беләсездер инде?

— Беләм. ЭВМга нинди программа бирелсә, сез шуны кушып, болгатып чыгарырга тиеш.

— Анысы — теория бит аның. ЭВМ кушканча гына эшли башласаң, безнең заводларны әллә кайчан ябып куярга туры килер иде. Кагыйдә буенча салынырга тиешле, аксымга бай бөртекләр безнең кушылмаларга, хуш ис чыгарыр өчен, им-том чамасында гына эләгә...

Соңгы ун ел эчендә, 1970—1980 елларда, РСФСР комбиазык промышленностеның бөртеклеләргә булган ихтыяҗы 7 миллион 56 мең тоннадан 20 миллион 596 мең тоннага кадәр арткан. Бу саннарның ни белдергәнен дә ачыклыйк. 1970 елда комбиазыкка 3663 мең тонна бодай кушылган. Бу — азыктагы бөртеклеләрнең яртысыннан артыгын тәшкил итә, арпа — 27 процент, солы белән борчак бик аз, 7,13 һәм 3,95 процент кына. 1980 елда бөтенләй башка пропорция: бодай — 43,49 процент, ә иң күп аксымлы борчак юк дәрәҗәсендә, аны 96,7 мең тонна гына кушалар, бу сан комбиазыктагы бөртеклеләрнең ярты проценттан да азрак өлешенә тигез. Чыннан да, борчак хуш ис бөркелдерү өчен генә салына икән. Концентратларга ун ел элек шактый мул кушыла торган соя калдыгы да, көнбагыш түбе дә берме-бер кимегән.

Бу ун елда төрле җәйләр кичердек: бер тамчы яңгырга тилмерткәне дә булды, чиләкләп койган яңгырдан басуларга керә алмый да аптырап-аптырап калгаладык, әмма терлек азыгы әзерләү предприятиеләренең аксымлы бөртекләр алуы бер үк юлдан барган: аксым кимегән дә кимегән, кимегән дә кимегән. Терлекчелек белән шөгыльләнүче һәркем азыкта бодайның азрак, ә борчак, солы, арпа кебек бөртеклеләрнең күбрәк булуы хәерле икәнен бик яхшы белә. Үзе бик кадерле ризык булса да, туклыклылык ягыннан нәтиҗәсез бодайны терлек тагарагына салудан ни файда? Крестьянның гомер-гомергә туплаган тәҗрибәсе белән санашмау бу. Себер әкиятчесе Петр Ершов «Бөкре тай» исемле әкиятендә җүләр Иванушканың туганнары Данил һәм Гаврилдан көлә көлүен, әмма алардагы крестьяннарга хас сыйфатны югары бәяли. Ул аларның төп һөнәрен болай сурәтли.

Егетләр бодай чәчкәннәр,
Башкалага да илткәннәр...

Сиздегезме? Әкиятен — әкият, әмма борын-борыннан бодайны хайван тагарагына түгел, халык табынына куялар.

Сүз арасына кыстырып әйтик, тәҗрибә, бүгенге заманның терлек, кош-корт асрауда дан тоткан илләрнең практикасы, безнең элекке крестьян хуҗалыкларындагы кебек үк, мал-туарга бодай ашату белән һич мавыкмауны раслый.

Профессор В. Г. Козловский берничә ел элек Англиядә булып кайтты. Ул фермаларда да йөргән, кеше саен нибары 0,2 гектар гына сөрү җире тиярдәй кечкенә илнең халыкны ничек туйдыруы белән кызыксынган. Басу-болыннарга ни чәчәләр, терлекләргә нинди ризык бирәләр? Кайткач, галимнең искиткеч кызыклы китабы чыкты. Белгечләр күптән укыгандыр да инде, китап 1967 елда, Мәскәүнең «Колос» нәшриятында басылды. Китаптан күренгәнчә, шул кечкенә Англия — дөньякүләм әһәмиятле нәсел фермасы икән бит! Монда мал-туарның нәселен яхшырту, селекция эшенә ныклы нигез салынган. Галимнәрнең, фермерларның таланты, тырышлыгы, тәвәккәллеге нәтиҗәсендә мөгезле эре терлекләрнең — 30, сарыкларның — 40, дуңгызларның — 10, атларның исә әйбәт 20 нәселе булдырылган. Әлеге фермерлар моннан бер гасыр элек чыгарылган «Бөкре тай» әкиятендә макталган персонажлар кебек үк фикер йөртәләр икән. Профессор Козловский, галимгә хас төгәллек белән, Британия фермаларының терлекләргә бер ел эчендә 16,5 миллион тонна концентрат ашатулары да, бу ризыкта бодайның нибары 1,3 миллион тонна гына булуын, ягъни 7,9 процент кына алып торуын да язган. Безнең тырыш игенчеләр җыеп биргән гәрәбәдәй бодайны дуңгызлар, кош-кортлар ашап бетерә булып чыга.

Сабыр гына уйланыйк әле, ашыгу һәрвакытта да файдага түгел ул. Комбиазык заводлары, кагыйдәләргә каршы килеп, үз тегермәннәрендә кадерле бодайны тарттырып ята икән, бәлки колхоз-совхозлар вика, фасоль, соя, борчак кебек бөртеклеләрне үзендә калдыру ягын карыйдыр?

Биологлар, аксым — яшәү чыганагы, дип раслыйлар. Зоотехниклар шул ук мәгънәне башкача әйтәләр: аксым — көр мал-туар, сөт, ит ул, диләр. 1980 елның кышкы

айларында Татарстанның Балык Бистәсе районы терлекчеләре сыерларының сөтен 13 процентка арттырганнар. Фураж аларга да артык бирелмәде. Тик аның составында арпа — 11756 тонна, ягъни 40 процент, борчак — 7348 тонна — 25 процент, солы — 3243 тонна, 11 процент, арыш — 10 процент, бодай — 13 процент тәшкил итә иде. Аһ, башка фермаларыбызга да шундый фураж булса, әй!

Кызганычка каршы, бу район кебекләр меңгә — бер очрый. Гомуми күренеш хафага гына сала. 1980 елда РСФСР колхоз-совхозлары фуражга 30 миллион 700 мең тонна бөртек тотканнар, шуның өчтән бер өлеше — бодай, ә кузаклылар аның 6 процентын гына алып тора.

Ни хикмәт соң? Мондый тузга язмаган хәлләр нәрсә нәтиҗәсендә туа? Гомер-гомергә иң кадерле саналган ризыгыбыз бодайның дәрәҗәсен төшерү кайдан килеп чыга? Кемнәр моңа сәбәпче?

* * *

Борчак, вика, фасоль, ясмык кебек кузаклы культураларның аксымга, бөртекләргә караганда баерак булуы, алар белән тукланган терлекнең калҗасы ук тәмлерәк, сөте каймаклырак икәнлеге, кем әйтмешли, хан заманыннан ук мәгълүм нәрсә.

Мәгълүмлеге мәгълүм, әмма ләкин терлек тагарагына бодай салалар. Ник? Ни өчен?

Сәбәпләрнең төрлесе бар икән: техник сәбәпләр дә, агрономик сәбәпләр дә, оештыру эшләрендәге катлаулылыклар да җитәрлек. Мин үзем, мәсәлән, әхлакый, психологик сәбәпләрне беренче урынга куям. Чөнки һәр эшнең этәргече булып кеше күңеле, вөҗдан кушуы, җан талпынышы алга чыга. Кузаклы культуралар аксымга бик бай, әмма аларны җыеп башкару кешедән җитезлек, өлгерлек, төгәллек, тизлек, аяусызлык таләп итә. Кулыңнан килми икән, кузаклыларга тотынмавың хәерлерәк. Урып-җыю вакытында аз гына акрын кыймылдасаң, кузаклар чыртлап ярыла башлый, басуыңны ап-ак борчак каплап ала. Кузаклылар чәчкән җирне, гадәттә, уҗым ашлыгы алмаштыра, димәк, урып-җыюны тиз арада башкарырга кирәк, көзге чәчү үкчәңә баса. Аны җыеп алу өчен махсус техника юк, гап-гади ургычлар гына бирелә. Бу урында авыл хуҗалыгы өчен машина төзүчеләргә дә үпкә белдерергә кирәк· кузаклылар өчен махсус машиналар ясау турында уйлаган кеше дә юк.

Крестьянда, борчакны кайда төртсәң, шунда тишелә, дигән сүз бар. Шытып та чыга, гөрләп үсә дә ул, әмма ләкин җыеп алуы — әҗәл белән бер. Сукканыңны улчи башласаң, йөзең кызара, борчак бодайдан да, кукуруздан да, арпадан да азрак чыга. Әгәр аның башка сыйфатларына игътибар итмәсәң, бәласеннән баш-аяк, дисең дә басуга кертмәү ягын гына карыйсың, әлбәттә. Нишләргә соң: җыйгыч машиналар юклыкны сәбәп итеп, мич башында җылынып кына йоклап ятыйкмы?

Кабарда Балкариясенең «Красная нива» колхозы председателе Михаил Михайлович Клевцов белән дә без иң башта кузаклылар турында сөйләшеп киттек. Инде алдагы сүзләрдән аңлашылганча, республикада фуражга кирәкле культуралар белән әллә ни шөгыльләнмиләр. Мәсьәләнең бу ягы һәр хуҗалык җитәкчесенең үз карамагына тапшырылган. Клевцов нинди чаралар күргән соң? Унынчы бишьеллыкның соңгы елында ул бодай басуын кысу бәрабәренә, борчакны 180 гектарга арттырып чәчкән. Бодай гектарына 39 центнер уңыш биргән, борчак — нибары 27 центнер. Гомумән, уңыш күләме, ничек кенә санасаң да, ике мең центнерга кимрәк. Менә сиңа чәчү әйләнеше!

— Югалтуың күп бит,— дим мин аңа.— Үзең әле отыш турында сөйләнәсең?

— Кем ничек исәпли бит? — ди ул.— Центнерларга гына карасаң — югалту, әмма ләкин мин башкача исәплим.

— Ике исәп — бер хисап инде ул.

— Мин аны терлек азыгына әйләндереп санарга өйрәнгән. Без ел саен терлек тагарагына — мең ярым тонна бодай, ике мең тонна кукуруз салабыз. Хайваннарга алтын бәясенә торырлык бөртек ашатабыз, нәтиҗәсе әллә ни сөендерерлек түгел, малларга азыкның төрләндерелгәнен, ләззәтлесен, туклыклысын бирергә кирәк. Сыер-

лардан өч мең килограмм сөт алабыз, артымнары да әллә ни түгел. Әлеге фураж белән шуннан артыгын көтеп тә булмый. Борчак чәчеп без әнә шул максатларга кирәкле аксымны табабыз. Центнер саны кимесә кимесен — аның каравы, без аксымга байыйбыз.

— Аңлашылып җитми,— дим мин.

— Соң, борчактагы аксым, бодайдагыга караганда, икеләтә артыграк бит! Менә шуннан чыгып исәплик!

Саный торгач, аксымга байлыгы ягыннан караганда, бер гектар борчак бодай һәм башка башаклы культуралар биргән югары уңышны каплады да куйды. Соя игү тагын да отышлырак, тик аны теләсә кайда үстереп кенә булмый икән.

Бөртеклеләрнең аксымга байлыгы ягын исәпләп эш итү — ил күләмендә мөһим мәсьәлә. Галимнәр 1967—1971 елларда кырлардан җыелган протеин матдәсенең табышын чагыштырып караганнар. Солының бер гектары — 2,07 центнер, арпаныкы — 2,1 центнер, кукурузныкы — 3,45 центнер, борчакныкы 3,59 центнер аксым бирә икән.

Гомуми уңышка карап, игенчегә төп бәя бирелә: аны президиумга утыртыргамыюкмы, фамилиясен җиңүчеләр рәтенәме, әллә кара исемлеккә теркәргәме, бүләк бирергәме-юкмы?.. Шуны белгәннән соң кем үз ихтыяры белән югары уңыштан баш тартсын? Клевцов өчен мондый адым җәһәннәмгә керү белән бер. Нәрсә, аның башына тай типкән мәллә?!

Клевцов «Красная нива» колхозына Кабарда Балкариясе Министрлар Советы Председателенең хәзерге беренче урынбасары Николай Никитович Евтушенкодан соң килгән. Н. Н. Евтушенко монда кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре язган. Шунысы мөһим ки, ул әлеге хезмәтләрен, кайбер өлгер диссертантлар кебек, коры саннарга карап кына язмаган, колхозда чын-чынлап гыйльми эш җаелдереп җибәргән, уңышны күтәргән. 1965 елда колхоз гектарына 29 центнер ашлык алган булса, торабара бу сан үскән дә үскән, гектардан 45 центнер җыю гадәти күренешкә әйләнгән. Уңыш моннан түбән төшсә, яңа председатель хакында ни сөйләрләр? Әлбәттә, эшкә бәя бирү шуңа охшаш хәлләргә барып тоташа икән, хуҗалыкка файда китерә, дип, гомуми уңышны киметергә кем җөрьәт итә алсын?!

«Красная нива» председателе Клевцов нәтиҗәсен дә үзе ясап күрсәтте.

— Күрдеңме? — диде. Әле аның икенче ягы да бар. Үзеңдәге фураж арзанга төшә, ә комбиазык өчен өч мәртәбә артык түлисең. Акча чыгардыңмы, итеңнең, сөтеңнең, йомыркаңның үзкыйммәте үсканнән-үсә бара. Терлекчелекнең экономикасы, кырчылыкныкына караганда йомшап кала. Хикмәт экономикада гына да түгел. Күңел сына. Игенчене мактаган булабыз, дуңгыз караучыларны, сыер савучыларны, терлек симертүчеләрне, табышсыз эшлисез, дип, гел ачуланып торабыз.

— Табыш булмагач, нишләмәк кирәк? Чыгымны да капламаган хезмәтне мактамыйлар бит инде!

— Эшнең отышсызлыгы өчен мине тиргәргә кирәк булгандыр. Үткән бишьеллыкта ел саен мең ярым тонна комбиазык сатып алдык, ярты миллион сум акчабыз шуңа китте. Аны үзебездә генә ясарга икән, туклыклырак та була, арзанграк та төшә. Фермаңнан ит, сөт, йомырка алыйм дисәң, азык базаңны үзеңдә оештыру хәерлерәк. Басуыңа нәрсә чәчүне дә акыл белән исәпләп эшләргә кирәк, әйтик, терлеккә ашатырга уйласаң, бодайны чамалап кына чәч, борчакны арттыр: сөтең дә, маең да, ит артымың да җайга салыначак...

Шунысын да билгеләп үтик, тормышта алга нинди максат куеп яшәү бик әһәмиятле. Әйтик, без хәзер сыерлардан өч мең килограмм сөт алучы көтүләрне мактыйбыз. Бу — РСФСРдагы уртача савымнан мең килограмм чамасына зуррак күрсәткеч. Үз эшенә кем ничек карый бит! Шул ук акыллы, укымышлы, көчле рухлы Клевцовны гына алыйк. Хикмәт аның фәннәр кандидаты булуында, авыл хуҗалыгын яхшы белүендә, эшчәнлегендә генә дә түгел. Тормыш ихтыяҗлары белән бәйле алмаса, аның яхшы сыйфатлары күзгә дә күренмәс иде. Минем карашымча, Клевцов холкының иң кызыгырлык ягы шунда, ул — урталыкта баручылардан түгел, алда атлаучылардан үрнәк алып эш итә. Якын гына, Пятигорск янындагы «Пролетарская воля» колхозында дала токымлы кызыл сыерлардан дүрт мең ярым килограмм сөт савалар, ә Клевцов җитәкли торган «Красная нива»да — шактый ким, хәтта чагыштырырга да уңайсыз. Хуҗалыклар рәттән яшәп ята бит, күршеләр, бер үк кояш җы-

лысыннан рәхәт күрәләр. Дөрес, монда Клевцовның артталыгын аклардай бер нәрсә бар, «Пролетарская воля» — специальләштерелгән хуҗалык, «Красная нива» исә бөтенләй башка, аны, тәҗрибә төсендә диярлек, тегесенә дә, монысына да тарткалыйлар, аның җиреннән, Кавказ кояшыннан файдаланып, үстерергә мөмкин бөтен азыктөлекне алырга тырышалар: бодай, кукуруз, сыер һәм дуңгыз ите, йомырка, җиләкҗимеш, яшелчәләрдән татлы тырма, петрушка, көнбагыш, сүс, үлән оны, хәтта ярты миллион сум керем бирүчән кыяр орлыгы да ясыйлар.

Иң мөһиме — төрледән-төрле продукция җитештерү түгел, колачлылык, күләм. Клевцовка борчылырга кирәкмәс иде, әмма тагын да әйбәтрәк нәтиҗә турында хыялланунын зарары юк. «Красная нива», басуының йөз гектарына туры китереп исәпләгәндә, 600 центнердан артык сөт, 140 центнер ит, бөртекләләр чәчелгән җиренең һәр йөз гектарына чамалап санаганда, 100 мең данә йомырка җитештерә. Колхоз үзенә тапшырылган планны үти, акчасы да җитәрлек, хаҗәте чыккан саен, дәүләт банкысына бурычка кереп тормый.

«Игелек эшләгән өчен рәхмәт көтмиләр!» — дип әйтеп куя яздым. Көчсезләр генә теләсә нинди булдыксызлыкка аклану эзләп азаплана, кыю җитәкче, вөҗданлысы, башкаларда өстенлек күреп алса, үз эшен дә яхшырту ягын карый башлый.

Клевцов Котляревская станицасына әле күптән түгел генә килеп урнашкан, әмма ләкин үзен монда мәңгелек председатель итеп билгеләнгәнгә саный, һәм, көтелмәгән хәлләр чыкмаса, моның нәкъ шулай булачагына башка кешеләрне дә ышандырырга тырыша. Ул бүгенге авылның әйдәп баручысына бик охшаган, аңардагы хуҗалыкчанлыкка, крестьян хезмәтенә хөрмәт белән каравына, председательнең эштәге һәр нечкәлекне белүен, чынбарлыкка конкрет мөнәсәбәттә икәнлеген, киләчәкне тоеп фикер йөртүен дә өстәргә кирәк.

Минем күп кенә председательләр белән очрашкалаганым бар, шулай да һәр эшкә Клевцов кебек исәп-хисап белән, ялкынланып тотынучыны хәтерләмим. Эш белән, күпсанлы кешеләр белән җитәкчелек итүнең хикмәте дә шунда инде: хезмәтең кешеләргә һәм әхлакый, һәм материаль отыш китерсен!

Алга куйган максат — бер нәрсә, ә үтәлгән эш — башка, кайчак шулайрак та була: сызылып куелган кагыйдәләр тормышның үзеннән килеп чыккан каршылыклар алдында чепләрәмә килә. Клевцов бөртекләләрдән югары уңыш җыю белән генә канәгатьләнми, ул, сабырсызланып, терлекчелекнең отышлылыгы турында да кайгырта. Борчакны күп җыеп булмый икән, аның каравы, ул фермаларның төп тирәгеннән санала, басуларга шифа бирә, аның артыннан җир азотка баеп кала, икенче җәйне анда бодай гөрләп үсәчәк!

— Ник без ашлыкның сыйфатын дөрес бәяләргә теләмибез? — дип борчылып куйды Клевцов.

— Нишләп? Элеваторларда ашлыкны бик җентекләп тикшерәләр бит!

— Нәрсә тикшерәләр соң алар: дымлылыкны, чүплелекне, бодайның җилемлелеген бәялиләр. Җилемлелек югары икән, артыграк түлиләр. Кайчан, кайсы агрономга, бөртекләләрнең аксымы күп булган өчен рәхмәт әйткәннәре бар? Барысы да гомуми сан артыннан куалар, рәхмәте дә, даны да, премиясе дә центнер саны өчен бирелә. Син үстергән ашлыкта протеин аз, дип, берәүне дә тиргәгәннәре юк әле. Гомуми уңышны гына исәпләү дөрес түгел, игенченең күпме аксым бирүен санарга кирәк. Планга да шуны кертергә!

— Аны исәпләп буламы соң?

— Ник булмасын?! Ямпольлылар әнә чөгендер уңышын да аңардан саф шикәрне күпме ясауга карап исәплиләр...

Кеше эшчәнлегенең һәр тармагындагы кебек үк, хәзер авылдагы эшләр бик катлаулы. Бу мәшәкатьләрне үткәндәгеләр белән чагыштырып та булмый, алар үзгәрә торалар. Әлбәттә, гел бер урында таптанмыйбыз, алга барабыз, ул җитди катлаулылыкларга бәйле. Буш җирдә ни эшләсәң дә күзгә ташлана, ә инде ныклы хуҗалык төсенә кергән колхоз-совхозларда яңа баскычка менү кыен. Бу авырлыклар техникагафәләнгә генә бәйләнмәгән, без хәзер еш кына эшнең нәтиҗәлелеген хәл итүче кеше шәхесенә, аның эшкә булган мөнәсәбәтенә кагылышлы катлаулылыклар белән бәрелешәбез.

һәрчак иң югары стандартка йөз тотып эшләргә яратучы Клевцов, көтүендәге сыерларның күп хуҗалыклар өчен зәңгәр хыял гына булган 3 000 килограмм сөт бирүләре белән генә канәгатьләнмичә, «холыксыз» борчак игелә торган чәчүлеген арттырырга тәвәккәлләгән. Сөтне аңа караганда шактый аз алучы хуҗалыкларда да мондый адым ясарга ашыкмыйлар.

Воронеж янында «Гремколодезный» совхозы бар. Мин шуның директоры Виктор Иванович Нестеренкодан, яхшы нәселле сыерлар хәзерге кебек 2 300 килограмм түгел, 4—5 меңәр килограмм сөт бирсен өчен басуга нәрсәне күпме чәчәргә кирәк, дип сорадым.

Директор шактый вакыт уйланып торды, нәрсәнедер исәпләп карады, аннары, алда эшләүчеләр мондый хәлгә куеп калдырмаган булсалар, мин бодай басуларын кысу хисабына борчакны, арпаны, арышны арттыра төшәр идем, диде.

— Шул гынамы?

— Юк. Сөтсез сыерларны бетерер идем. Азыкны гына әрәм итеп яталар.

— Ник бетермисез соң? — Мин бу сорауга нинди җавап ишетәсемне аңлый идем инде.— Акт төзи белмисезме әллә? — дип тә өстәдем.

— Актын гына язар да идең аның... Иткә дә тапшырып булмый, баш санын киметүче, дип, гаеплəячәкләр...

Бу хакта күпме сүзләр, карарлар, аңлатмалар чыкты. Крестьянны мәгънәсез таләпләр белән аптыратмаска, дидек, икмәк, ит, май, җиләк-җимеш, яшелчәне мөмкин кадәр күбрәк булдырып, дәүләткә азык-төлекне күбрәк тапшыру юлларын үзе тапсын!

Л. И. Брежневның 1982 елгы май Пленумында ясаган чыгышында бик мөһим мондый сүзләр бар: «Бөтен авыл хуҗалыгы производствосының нигезе дип тулы хокук белән атарга мөмкин булган колхоз һәм совхозларга карата администраторлык итүдән һәм вак опекадан кискен төстә котылырга кирәк. Дәүләт планында күздә тотылмаган нинди дә булса бурычлар үтәүне, дәүләт отчетында билгеләнгәннән тыш информация сорауны кемнең кем булуына карамастан тыярга кирәк».

Кызганычка каршы, бездә еш кына бөтен исәп-хисапларга каршы килеп, колхоз-совхозларга шундый чикләүләр куела ки, аларның җитәкчеләре, үз максатларын тормышка ашыру өчен, дәресрәге, аларга җәмгыять һәм дәүләт тарафыннан бирелгән хокуклардан файдалану өчен, мең төрле хәйлә корып, баш вата.

Россия — зур, киң, иркен, әлбәттә. Аның гомум хәленә бер-ике колхоз яки совхоздагы эшләр генә әллә ни тәэсир итә алмый. Шулай да өенчесе, дүртенчесе... унынчысы да битарафлыкка бирелсә?.. Илдәге 45 мең председатель һәм директор арасында Клевцов кебекләр азрак, күпчелекне гадәтиләр тәшкил итә. Белүен дә беләләр, күрүен дә күрәләр, әмма чарасына керешмиләр, аксымга бай кузаклы культуралар басуларда кими бара, туклыклы кушымталар фуражга һаман азрак, хуш ис өчен генә салына. 1965 елда Россия Федерациясендә кузаклылар 4 миллион 853 мең гектарга чәчелгән, бусы да әллә ни күп түгел әле аның, чәчүлекнең 3,9 процентын гына алып тора, инде унынчы бишьеллыкта бу мәйдан тагын 1,5 миллион гектарга кимителгән.

Күп мәшәкатьләр, аерым осталык, тәҗрибә таләп итүчән сояны чәчмәүләрен аңларга да була әле, ни өчен борын-борыннан игелгән, зур файдалар китергән борчакны читкә этәрәләр?

Аңлашыла, борчак — холыксыз, таләпчән культура. Аны чәчтеңме, кулыңа сәнәк, тырма алырга туры килә. Борчакны иртә яздан ук чәчәләр, җыю вакыты да тиз килеп җитә. Аннан бушаган җир уҗым ашлыгын чәчү өчен әзерләнә. Борчак урыла, сугыла, саламы өемнәргә урнаштырыла — кыр чип-чиста, сөреп җибәр дә уҗым бодаеңны яки арышыңны сип кенә! Борчакның тамырында азотлы куыкчыклар ясалганлыктан, аны үстергән басуның җире «суырылып» калмый, киресенчә, уңдырышлыга әйләнә. Борчак үскән бер гектар җир кырга чыгарылган 35—40 тонна тирескә бәрабәр. Бу культураның тагын да кыйммәтлерәк бер сыйфаты бар әле: ул — безнең илдә игелә торган кузаклыларның аксымга һәм барлык аминокислоталарга иң бае. Хәтта мул уңыш бирүчән кукуруз да, лизин дигән бик кирәкле витаминны җитенкерәмәүдән, борчак белән ярыша алмый.

Безнең якларның борын-борыннан килгән, гасырлар буе тупланган тәҗрибәсе чәчүлек җирләрнең уннан бер өлешен кузаклылар алып торырга тиешлеген раслый. Кузаклыларның тамырында азотлы куыкчыклар хасил була, димәк, башка төр культуралар үзләштергән азот кабат тулыландырыла. Борчак — люцерна кебек культураларны җирнең химик реакторы дип юкка гына атамыйлар. Борчак кешеләргә — кузак, җирнең үзенә ашлама бирә.

Шул кадәрле файдалы культураны, аны үстерү бик кулай, үзенә генә түгел, башкаларга орлык өчен дә җитештерергә мөмкинлеге булган хуҗалыклар да читкә этәреләр, чәчү әйләнешеннән борчакны чыгарып калдырырга тырышалар.

Кемнең ничек эшләве — бер хәл; кем ота, кайсы югалта — шунысы мөһим.

Кара туфраклы зонаның үзәгендә, Курск өлкәсе Горшеченский районының «Рассвет» колхозында председатель Иван Филиппович Ильин, район авыл хуҗалыгы идарәсенең баш агрономы Владимир Иванович Григоров белән бергәләп соңгы елларда җәйләрнең начар килүенә сукранып утырабыз. Колхоз өч ел рәттән корылык кичергән, уңыш юк, хуҗалык тәмам алҗыган, муеннан бурычка баткан. Колхоз басуларының картасын алдык, нинди туфракка ни чәчелгәнен карадык. Әһә, көтелмәгән бер нәрсә килеп чыкты! Апрель аеннан башлап уракка төшкәнче басулар яңгыр тамчысы күрмәгәннәр, кояш кыздырган да кыздырган, җир утлы табаны хәтерләткән, бөтен яшеллек көеп беткән, әмма алда борчак игелгән җирдән — утызар центнер, люцерна белән клевердан соң чәчелгән урыннан егерме җидешәр центнер бодай чыккан. Менә сиңа табигать шартлары! Менә сиңа корылык!

Корылыкка, табигатьнең шәфкатьсезлегенә карата күпме аһ-зар ишетербез. Уйлабрак карасаң, табигатьнең ни гаебе бар? Аңа үпкәләргә, канәгатьсезлекләр белдерергә нинди хакыбыз бар соң безнең, үз эшләребезне җайга салсак, тәҗрибәгә хөрмәт белән карасак, элек кайда ялгышканыбызны тикшеребрәк эш итсәк, мөгаен, файдалырак булыр иде. Борынгы кеше табигать биргән әзер тәм-томнарны җыеп йөрүдән туктап, игенчелек белән шөгыльләнә башлагач, күпме каршылыкларны җиңә килгән. Икмәк әзер килеш күктән төшмәгән бит. Табигать кешегә кайчан нишләргә кирәген, нинди законнар белән санашмый мөмкин түгеллеген һаман өйрәтеп торган.

Ильин агрономлыкка укыган, колхоз өчен җанын аямый. Үткән ел монда байтак кына клевер орлыгы җыйганнар. Крестьянга бу орлык алтыннан да кадерлерәк. Клевер орлыгы өчен азык концентратын сигез тапкыр артыграк бирәләр, өстәвенә уч тутырып акча да аласың әле, центнерына — биш йөз тәңкә! Ильин бу орлыкны сатарга бик ашыкмаган әле, хәбәрен тараткан таратуын, әмма үзенә кирәгрәк алучыны эзләгән. Хәбәр таратырга дисәң, безнең кешеләр озак көттермиләр. Әлеге орлыкның барлыгын Белоруссиядә дә ишеткәннәр, капчыкларын күтәреп килеп тә җиткәннәр. «Рассвет» клевер орлыгы өчен болардан акча түгел, ....чөгендер төйи торган машина сораган. Орлык бар, рәхим ит, әмма ләкин чөгендер төяүче машина кирәк!

Ильинның башы эшли, табыш та ала белә, тик җирдән теләсә ничек файдаланып, алда ни күрәсен уйлап җиткермичә, үз башына үзе бәла китерә. Колхозның нилэр чәчүен, культуралар чиратын ничек аралаштыруын, чәчү әйләнешен ни рәвешле коруын гына күздән кичерик. Бодай белән арпаны 1600—1900 гектарда үстерәләр, ә хәтта корылыкта да уңыш бирергә мөмкин булган борчакны 100 гектарга калдырганнар. Табигатькә ачуланыр урын юк, монда бер үк басуга — бодай арты бодай яки арпа арты арпа чәчәләр. Кузаклыларны 250 гектарга чәчсәң дә, бик әйбәт булыр иде дә, юк, алай итмиләр, уйлап та бирмиләр. Бүген 150 гектарга чәчелми калган борчак — киләсе елда җыела алмый калачак мең центнер бодай бит ул.

Мәсьәлә хәтта потларда, центнерларда гына түгел. Бодайны, әлбәттә, кара парга игү яхшы, ике кат сөрелгән булса, бигрәк тә әйбәт, мондый шартларда ашлыкның аксымын ике процентка арттырырга мөмкин. Борчак артыннан чәчсәң, тагы да ота төшәсең, бу җир азотка баетылган була. Азот күп булдымы — аксым арта диган сүз. Экономистлар, басулар норма таләп иткән кадәр азот керткән очракта ил күләмендә 1,5 миллион тонна аксым алырга мөмкин, диләр. Бу — 750 мең гектар иген басуыннан җыелган уңышка тиң.

Якындагы ун ел эчендә илнең ашламалар җитештерүчәнлеге шактый арттырылырга тиеш. Азык-төлек программасында мондый саннар китерелә: 1985 елда авылларга — 26,5 миллион тонна, аннан соңгы биш елда 30—32 миллион тонна минераль аш-

лама бирелачәк. Зур саннар бу. Тик әле монысы да тиешле нормага килеп җитми, шунлыктан һәр хуҗалык үзе дә басуларның уңдырышлылыгын арттыру өчен һәрчак борчылып, мәсьәләне чишәрдәй ысуллар эзләргә тиеш.

— Киләчәктә нишләмәкче буласыз соң? — дип сорыйм Ильиннан.— Кузаклыларның бүгенге һәр гектары иртәгә игеләчәк бодай уңышын арттырачагын да белеп торгач, бәлки, чәчү әйләнешегезне яңадан карап чыгарсыз, үзгәрешләр кертерсез?—дим.

— У-у! Яңгыр коя башласа... Борынгы бабайлар кебек сәнәк, тырма тотып җыярбызмы?

— Сәнәктән курыккан кеше иген игә алмый, аңа мич башында гына утырырга кирәк,— дим.— Тәвәккәл җаннар бар бит, чәчүлек җирләренең ун-унбиш процентында борчак үстерәләр.

— Юктыр ла? Кайдан килсен!?

— Ульяновск өлкәсендә, мәсәлән! — дим.— Сезгә нәрсәдән куркып торырга — үзегез хуҗа бит, тәвәккәл таш яра! Җебеп утырсаң, гомердә дә җиңә алмассың!

Әңгәмәдәшемә җитди кисәтү ясаганлыгымны үзем дә сизәм, тик сәбәбе дә шактый мөһим бит, телгә гел усал сүзләр килеп тора. Бүгенге көн өчен генә отышлы күренгән алымга ияреп, җирнең бәрәкәтен саклаучы, кара туфракның гомерен озайтучы ысулны Курск өлкәсендә бер «Рассвет» колхозы председателе Ильин гына кире какмый. Унынчы бишьеллыкта өлкәнең Горшеченский районында 52 мең гектар иген кыры исәпләнгән, шуның нибары 1,5 мең гектарына гына борчак чәчкәннәр, 60—70 процентын арпа белән тутырган еллар булган. Галимнәр, профессиональ терминга әйләндереп, бик кыска итеп аңлатылган бу эшнең төбендә чәчү әйләнеше тәртипләрен тупас рәвештә бозу, әйтик, бер үк җиргә чәчелә торган культураларны чиратлаштыру кебек игенчелек кагыйдәләре белән санашмау, белә торып, басуларның киләчәген куркыныч астына кую, уңышны табигый һәлакәтләр хөкеменә тапшыру ята лабаса!

Җае чыккан саен, табигатьне гаепләмәсеннәр, көтелмәгән бәхетсезлекләргә аркаланмасыннар өчен, ике мисал китерергә уйлыйм. Беренчесе — илебезнең икмәкле мул бирүче шул ук кара туфраклы ягыннан. Бу якларда бөтен регионның үрнәгенә ярарлык Таш дала дигән урын бар. Табигый шартлары шул ук: җире дә, явым-төшеме дә, кояшлы көннәре дә, кискен җилләре дә — барысы да төбәкнең гомуми шартларына туры килә. Әмма акыл белән, «фән кушканча» эшләгәнлектән, 1981 елгы коры җәйдә дә болар бөртеклеләрдән уртача 25 әр центнер уңыш җыйдылар. Бодай һәр гектардан 37 шәр центнер чыкты. Кара туфраклы өлкәләр күләмендә исә уңыш уртача 10 ар центнер тәшкил итә иде.

Икенче мисалны КамАЗ кебек автогигантлары, Түбән Камадагы нефть-химия комплексы, илгә 2 млрд тоннадан артык ягулык биргән нефть промыселлары булган Идел буеннан китерәм. Узган бишьеллыкта Татарстандагы хәлләр әллә ни мактанырлык түгел иде. Дөрес, уртача һәр гектардан алына торган уңыш 1,2 центнерга артты, еллык бөртек җитештерү 4 миллион тоннага якынлашты, әмма әле бу гына дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәргә җитми иде. Унберенче бишьеллыкның беренче елы да зур куанычлар китермәде, дәүләткә сатылган икмәк символик өлеш рәвешендә генә булды — нибары 100 мең тонна. Татарстан статистика идарәсе отчетларына, бу хәлне аңлатырга тырышкандай, «уңышсызлык аркасында» дигән әйләнмә килеп керде. Уңышсызлыкның сәбәбе — табигатьнең шәфкатьсезлеге, корылык, язмыш — барына да әнә шулар гаепле, кешеләрнең моңа һичнинди катышы юк, янәсе.

Ни өчен без, кыенлыклар килсә, кешеләрнең җаваплылыгын сызып ташлыйбыз әле? Мөмкинлекләр бөтенләй аз булган чакларда да Татарстан игенчеләре соңгы елларда уртача 10 центнер алмый калмыйлар иде. КамАЗ янындагы «Гигант» совхозы, мәсәлән, унынчы бишьеллыкта гектардан уртача 34 әр центнер ашлык алды. Искиткеч! Мондый отышны сугару җайланмаларына кайтарып калдырырга да мөмкин, әлбәттә, совхозның 2 мең гектар җиренә ясалма рәвештә су сиптерелә. Тик хәзер су сиптерүче хуҗалыклар башка районнарда да күп бит. КамАЗ янына урнашкан Тукай районының сугарулы басуларыннан гектарына 43 центнер азык бирәмлеге алынган, ә «Гигант» аны 73 әр центнер җыя.

Хакыйкатькә күз йомарга, җирдән аерылырга ярамый. Әлбәттә, табигать бинигаһая көчле, тик тормыш, кешенең ихтыяры, аның хезмәте, тырышлыгы — хәлиткеч көч.

Курскилылар, кара туфраклы якларның башка регионнарында яшәүчеләр, Идел буе игенчеләре, себерлеләр, Ерак Көнчыгыш игенчеләре, һава шартлары уңайлы килгәндә, ничәмә тапкырлар мул уңыш җыеп алгаладылар һәм табигать, җиргә битарафлыклары, ялкаулыклары, «алма пеш — авызыма төш!» — дип, ваемсызланып яткаННары өчен, аларны ничә тапкырлар җәзалады. Бик булдыклы күренгән председатель Иван Филиппович Ильин колхозы сукыр тиенсез калган, бер бурычын түләп бетерә алмый, икенчесенә кереп бата. Ул гынамы соң? Хуҗалыгы белән кеше акылы түгел, кырыс табигать идарә иткән бик күп колхоз-совхозлар Горшеченский районында шундый ук кыен хәлне кичерәләр.

Җиңүгә барганда, җиңел, беренче карашка гына отышлы күренгән юлны сайлаучы председательләр, директорлар барысы да әнә шушындый күңелсез хәл кичерәләр. Үткән бишьеллыкта дәүләт амбарларына керергә тиешле кузаклыларның 3 миллион тоннасы салынмый калды.

Хикмәт уңыш алмауда гына түгел. Чәчүен үк аз чәчә башладылар — шунысы аяныч. Элекке елларда Россия федерациясе иген кырларының җиде процентын кузаклылар алып тора иде, хәзер бу сан икеләтә кимеде. Кузаклыларга кырын карау игенчелекнең нигезен какшата, агрономия һөнәренең чәчү әйләнеше турындагы изге кагыйдәсен боза, кешеләр, борын-борыннан килгән акыллы тәҗрибәдән, фән казанышларыннан, бүгенге ачышлардан файдаланырга теләмичә, җирне рәнҗетәләр.

Әгәр игенчелекне — хуҗалык итүнең арифметикасы, дип санасак, игенчелек белән терлекчелекнең икесен бергә алып бару югары математикага тиң. Һәм ни өчен шул кадәр катлаулы, бары тик иң төгәл кагыйдәләргә таянып кына чишелергә тиешле мәсьәләләр язмышы председательләрнең, директорларның кәефе ниндилегенә барып тоташкан да, без табигать көчләреннән дер калтырап яшәү көненә калганбыз соң?

*

* *

Көндәлә туган кызыксынуларга җавап табу ниятеннән мин Мәскәүнең Орлик тыкрыгына, Россиядәге бөтен колхоз-совхозлар белән идарә итүче оешманың штабына юнәлдем. Монда Калининградтан Камчаткага кадәр булган бөтен хәлне белеп торалар. Миңа да кирәкле белешмәне бирерләр, мөгаен: нәрсәнең ничеклеген, кайдалыгын, ни өчен алай икәнен аңлатырлар. Авыл хуҗалыгындагы хәлләр белән якыннанрак танышa барган саен, мине борчыган сораулар ныгый гына төште: ни сәбәпле терлек азыгы өчен кирәкле, җир өчен файдалы кузаклыларны чәчү азайганнан азая, ни өчен комбиазык һәм концентратларның туклыклылыгы түбән, ни өчен акыллы председательләр сыердан өч мең килограмм сөт алырга тырышып, бөртеклеләрнең тулаем күләмен югалтудан курыкмыйлар, ә мондый ысулдан баш тартучы җитәкчеләр, терлекчелек мәшәкатьләрен җиңә алмыйча, бөлгенлеккә төшәләр, муеннан бурычка баталар. Ни өчен болай бу, ә?

Россия федерациясе авыл хуҗалыгы министрлыгының терлек азыклары, үлән басулары һәм көтүлекләр главкасы начальнигы Валерий Федорович Агафонов, аның урынбасары Эдуард Петрович Маевский гомуми белешмә бирделәр. 1966—1970 елларда фуражга уртача бөтен терлек азыгының чирегеннән артыграк күләмендә — 34,5 миллион тонна бөртек тотылган. Унынчы бишьеллыкта исә — 60 миллион тоннага җиткән, бу инде азыкның 40 процент чамасы. Терлекләргә бөртек ашату ит, сөт, йомырка, йон алуга караганда тизрәк арта бара икән.

Терлек азыгына кемнең нинди ашлык тотуы нинди шартларга барып бәйләнә икән соң? — дигән бик үк күңелле булмаган сорауны чишү өчен, мин шул ук бинаның аскы катына төштем дә Үзәк план-экономика идарәсенә кердем.

Главка начальнигының беренче урынбасары бүгенге авылны, аның хуҗалыгындагы конкрет хәлләрне яхшы белүче Максим Семенович Литвинов янында гомуми күренешне шактый тиз тасвирлап бирделәр. Бүлек хезмәткәре Галина Тимофеевна Ситникова тау кадәр кәгазьләр арасыннан кирәкле саннарны эзләп тапты. Гаҗәпкә калдым, белми йөргәнмен, Татарстанның ярты миллион тонна борчак җыйган чаклары бар иде бит, хәзер ул да фермаларына... бодай гына бүлә диярлек. Республика колхоз-совхозлары 1980 елгы уңыштан 1 миллион 162 мең тонна бөртекне фермаларга калдырган. Шуның

кырык процентка якыны, ярты миллион тонналабы — бодай, борчак ун процент чамасы, нибары — 118 мең тонна.

Туланың авыл хуҗалыгы идарәсендә фураж өчен нинди бөртек калдырылуын исәпкә алып тормыйлар, ни калса, шуңа шекер итеп яшиләр икән. Унынчы бишьеллыкның соңгы елында өлкәдәге фермалар ихтыяҗы өчен — ярты миллион тонна бодай, 193 мең тонна борчак калдырылган. Курск өлкәсе фермаларында исә фураждагы аксымга бай бөртек — бер процент чамасы гына.

Саннар төрле-төрле, чуп-чуар, әмма аларда җитәкчеләрнең башкарган эштән тиз генә табыш алырга омтылуы ачык чагыла. Элеваторлар центнер, тонна белән эш итә, арышмы ул, бодаймы, кукурузмы, арпамы, борчакмы, әллә карабодаймы — аларга барыбер, центнер саны гына тулсын! Терлек яки кош-корт туендыру өчен бәрәкәтле саналган бөртекләр, башка культуралар белән чагыштырганда, уңышны кимрәк бирә, аларны җыюы да катлаулы, сабырсызланып, отыш алырга омтылган җитәкче ул юлга басмый, аңа бүген үк җиңүче булу әһәмиятлерәк. Күрдеңме: ул күпме суктырган! Иң зур уңыш аныкымы — аныкы, дәүләт планнан тыш тапшырылган бөртеккә хакны бер ярым арттырып түли. Нигә файдаланып калмаска: кузаклылар белән баш ватып торганчы, чәч тә чәч бодай.

Иген кыры — эшнең башы гына. Крестьян хуҗалыгы игенчелек белән генә канәгатьләнә алмый. Көньяк районнарда, кара туфраклы басуларда бөртеклеләр белән күп мавыгырга өйрәнгәннәр өйрәнүен, ә төньякта, уңдырышсыз җирләрдә авыл кешесенең төп терәге — мал-туар, кош-корт. Бозавы-ние белән сыеры мөгрәп тора, чучкасы-фәләне, унлап тавыгы, үрдәге, казы, кәҗә-сарыклары... һәм шул терлек-туары аңа борыннан ук иген кырын ничек файдаланырга, ни чәчәргә, нәрсәне, күпме урып алырга кирәклеген тәгәл билгеләүдә төп күрсәткеч булып торган.

Бодайның бәясен арттыра торган тагын бер сыйфаты бар, җилемлелек дәрәҗәсе ул. Җилемлелеге яхшы бодайдан гына күпереп торган күмәчләр салып була! Элеватор лаборанткасы, җилемлелекне бәяләп, 28 дән 31 процентка кадәр тамга суга. Шуңа карап, бодайның хакы 30 процентка арта. Әгәр прибор җилемлелекне 32 процент итеп күрсәтсә, бәя 50 процент арттырып түләнә.

Кагыйдә буларак, алга максат куеп эшләгәндә, нәтиҗәгә ирешәсең инде аны. Дәүләт үзе бодай үстерүнең бөтен нечкәлекләрен тирәннән аңлап, хуплап тора икән, нигә бөртеклеләрнең шул «падишасы»н икмәскә?! Унынчы бишьеллыкта РСФСР, тугызынчы бишьеллык белән чагыштырганда, бөртеклеләрне 4 миллион 869 мең тоннага арттырыбрак җитештерде. Күбрәккә арттырылса да, шәп буласы иде дә, еллар яхшы килмәде. Шулай да бодай кырларында эшләр начар бармады, кайбер очракларда, бу хакта өндәү билгеләре куя-куя язарга мөмкин. Бодайның көчле сортларын сатып алу, уртача исәпләгәндә, ел саен 2 миллион 140,9 мең тоннага җитте. Артым 1 миллион 698,2 мең тонна тәшкил итә. Бу биш ел эчендә бодайның өстәмә бәя белән алына торган кыйммәтле сортлары 7,5 миллион тонна әзерләнде.

Материаль кызыксындыру чарасы — көчле нәрсә! Ставрополь крае хуҗалыклары унынчы бишьеллыкта көчле бодай сату планын 3,2 мәртәбәгә арттырганнар. 1980 елда гына да край 943,4 мең тонна — көчле бодай, 789,4 мең тонна кыйммәтле бодай саткан, колхоз-совхозларга өстәмә рәвештә генә дә 29 миллион сум акча түләнгән. Краснодар краенда мондый өстәмә 32 миллион сумга җиткән. Омск өлкәсе, бишьеллык планы буенча көчле бодайны 260 мең тонна гына әзерләргә тиеш булса да, ул аны дәүләткә 1 миллион 68 мең тонна саткан һәм, һәйбәт ашлык өчен, өстәмә рәвештә генә 68,8 миллион сум акча алган.

Әйе, гәрәбәдәй бодаебыз белән бөтен дөнья алдында горурланабыз. Бу өлкәдәге уңганнар турында язуы да рәхәт. Тик мин шул юллар артыннан ук кузаклыларны үстереп дан алган, борчак, соя, вика, люцерна игү осталарын да мактарга теләр идем. Кызганычка каршы, мөмкинлек юк. Аерым совхозларны, районнарны телгә алырга була, әмма тулы бер өлкәне, крайны яки республиканы тапмадым. Андыйлар юк.

Машина төзүчеләр дә борчакны рәнҗетәләр. Авыл хуҗалыгын техника белән киң колачлап коралландыру чорында, басуларда биниһая көчле тракторлар, комбайннар гөрләп тора, ә борчак кырын эшкәртә торган махсус машиналар юк. Бер үргыч бар,— көчсез, ышанычсыз, бердәнбер үргыч. Басулардагы кимсетелү өстенә, борчакка түләү мәсьәләсендә дә буталчыклыклар күп.

Соңгы елларда берәр республиканың, өлкә яки крайның дәүләткә кузаклылар сату планын үтәү очрагы аяз көндә яшен сугу кебек кеше ышанмастай хәлгә әйләнде. Җиденче бишьеллыкта РСФСРда ел саен уртача — 1 миллион 109 мең тонна, сигезенчесендә — 1 миллион 48 мең тонна, тугызынчысында — 937 мең тонна, унынчысында исә нибары 577 мең тонна борчак әзерләнгән. Бу борчакның дүрттән бер өлешен Татарстан биргән, калган өч өлешне РСФСРның башка республика, өлкә һәм крайлары тутырган. 1982 елның 18 апрелендә «Правда» газетасы унынчы бишьеллыкта илнең ике бик зур республикасы — Белоруссия һәм Үзбәкстан дәүләткә бер грамм да борчак сатмадылар, дип искәртеп язды. Шуннан ары кая барасың?!

Әмма ләкин бер көнлек отышка омтылу, тизрәк җиңүчеләр рәтенә басарга тырышу гадәте шул кадәр көчле ки, хәтта иген уңышы өчен җавап бирергә тиеш булмаган, бары тик терлекчелек белән генә шөгыльләнеп, ит, сөт, май, йон җитештерергә генә алынган хуҗалыклар да аксымга саран, әмма мул уңа торган ашлык чәчәргә ашыгалар. Күп кенә булсын, янәсе, файдалымы-юкмы — анысын уйлап тормыйлар. Төп нәтиҗә начаррак икән, әйдә, булсын, телгә алып сөйләгәндә, бер ялтырап китүең ни тора!

* * *

Мин, дәүләткә бөртеклеләр сатудан азат ителгән, төп максаты терлек азыгын сөт, май, ит, йомыркага әйләндерү булган махсус хуҗалыкларның басуларында ниләр игелүен күз алдына китерү җиңеләйсен өчен, Белгород өлкәсе, Жданов исемендәге колхозның ниләр чәчүен тәфсилләп аңлатырга уйладым. Бу махсус хуҗалык, төгәл исәп-хисапка нигезләнгән оешма буларак, мөмкин кадәр яхшырак, күбрәк азыктан тагын да мулрак, әйбәтрәк продукция ясарга тиеш.

Басуларның 54 процентына иген чәчелә икән. Шуның 30 процентын — бодай, 15 процентын — арпа алып тора. Иң азы солы белән борчак игелә, борчак — 4,5 процентка, солы — 2,7...

Күңелдә туган фикер белән уртаклашудан тыела алмадым.

— Саннар әллә ни сөенерлек түгел шул,— дидем.

— Ни булган? — Юлдашым минем тавыштан белгородлылар гомер ишетмәгән тәнкыйть аһәңе сизеп алды, ахры.— Бәлки монда уйлап җиткерелмәгән нәрсәләр бардыр әле, шулай да нигездә без хаклы. Мондый хәл бездән генә башланмаган, еллар буе шулай бара.

Чыннан да, бер хуҗалыкта гына шундый хәл булса, сөйләшеп тә тормас идең...

* * *

Беләм, производствоның эчендә кайнаган кешеләр кәгазь-каләм әһелләрен бик өнәп бетермиләр. Миңа исә аларның сүзе бик кадерле. Бу юлы да Татарстанның Балык Бистәсе районы авыл хуҗалыгы идарәсе баш зоотехнигына, бөтен гомерен фермаларга багышлаган тәҗрибәле терлекче Иван Яковлевич Булатовка шалтыраттым. Ачыкларга теләгән мәсьәлә шул ук: әгәр дә мәгәр, бөтен уңышның терлекләрне туендыруга китәчәген белсәң, 80 миллион гектарлы иген кырына ниләр чәчәр идең, дидем. Аның җавабы:

— 8 миллион гектарына — арыш, 24 енә — арпа, 16 сына — солы, 16 сына — бодай, 16 сына — кузаклылар.

Терлекчелеккә нәрсә кирәген һәркем яхшы белә, әмма иген чәчә башласалар, теория бөтенләй читтә кала. Илнең колхоз-совхозлары 1980 елны 3 миллион 829 мең гектарга гына борчак чәчкәннәр.

Бу урында кузаклылар белән шөгыльләнүче галимнәргә, селекционерларга да теләк белдерергә мөмкин. Борчакның өлгерүгә үк коела башлый торган, җыеп алу өчен отышсыз сортларын алмаштырырга вакыт күптән җиткән бит инде. Яки башаклы культураларның аксымын арттыру өчен ник җитдирәк шөгыльләнмәскә? Игенчеләр

авыл хуҗалыгы машиналарының камилләштерелгән яңа төрләрен көтә-көтә зарыгып беттеләр инде.

Гасырыбызның могҗизасы булган химиягә ышанычлар аеруча зур безнең. Химиклар нинди генә яңалыклар ачмады инде — даруларны, каучукны, буяуларны, пластмассаларны, спиртны, тукымаларны, шикәрне, бензинны синтетик ысул белән ясый алалар. Аксым мәсьәләсе әле һаман чишелешсез хәлендә калса да, лизин, триптофан, метионин кебек аминокислоталарны да аппаратлар ярдәмендә дә ясарга мөмкин, диләр. Хәтта ясалма юл белән табылган кара һәм кызыл уылдыкны ипигә ягып ашаучылар да бар. Химиклар аксымлы өстәмәләр — терлек азыгына кушыла торган чүпрәләрнең серен ачтылар. Азык-төлек программасында күрсәтелгәнчә, 1990 елда терлек азыгына кертелә торган химик өстәмәләр 1,2 миллион тоннага җиткереләчәк. Димәк, химиклар да тик тормый: әзлиләр дә, табалар да, тик ул яңалыклар артык кыйммәткә төшә әле. Җир йөзендә иген кырларыннан, көтүлекләрдән, урман-болыннардан да юмартрак аппаратлар хәзергә юк. Терлек азыгы чүпрәсендәге бер тонна аксым — 900 сум. Бу ун ел элек шулай иде, фәнни ачыш өчен, әллә ни күп вакыт түгел. Балык онындагы аксымның тоннасы — 1 300 сум. Хәзер без җыя торган бөртеклеләрдәге бер тонна протеин — 700 сумга, ә кузаклыларда 200 сумга гына төшә. Игенчегә әнә шул исәптән чыгып эш итәргә кирәк.

Монда Америка фермерларының эш алымын искә төшерү дә зыян итмәс, алар, океаннардан файдалануны һич тә читкә какмастан, химияне дә эшкә бик оста җигәләр, әмма аксымны, нигездә, басулардан, болыннардан, көтүлекләрдән алуны отышлыга саныйлар. Бодайны анда да яраталар, 23 миллион гектарга нәкъ менә аны чәчәләр, шул ук вакытта кузаклы культураларны да онытмыйлар, монда 25 миллион гектарга соя игелә. Сояның исә 36 процентын аксым тәшкил итә. Аны бер генә гектарга чәчсәң дә, шуңардан 15 әр центнер гына уңыш җыйсаң да, бу — 600 килограмм протеин, 300 килограмм май дигән сүз. Безнең басулардагы күренеш бөтән төрле, монда 60 миллион гектар җирне бодай алып тора, кузаклыларга исә нибары 6 миллион гектар гына бүленгән.

КПСС ҮКның май (1982 ел) Пленумы карарларында да бу хакта аерып алып әйтелә. «1985 елда бөртекле һәм кузаклы культураларны җитештерү — 12—14 миллион тонна, 1990 елда 18—20 миллион тонна булырга тиеш,— диелә.— Идел буенда, Кара туфраклы якларда, РСФСРның үзәк районнарында бу культуралардан уңыш җыюны аеруча арттырырга...»

Исемә, кылт итеп, председатель Камалетдинов, Клевцов, Нестеренко килеп төште. Программа нәкъ әнә шундый җитәкчеләрнең теләген хуплый икән бит! Нәкъ әнә шул акыллы хуҗалар үрнәгендә эшләргә кирәк икән ләбаса!

Яңа юлда агротехник, технологик кыенлыклар да күп очрар, әмма, миңа калса, иң авыры — психологик каршылык булыр кебек. Басуга нәрсә чәчү мәсьәләсен кешеләр, җитәкчеләр, ягъни колхоз председательләре, совхоз директорлары хәл итәчәк бит. Алар ни уйлар? Тели икән — чәчә, иренсә, аңа берәү дә күрсәтмә бирмәячәк. Хуҗалык җитәкчесенең ихтыяры гектарларга бәйләнеп калмасын, әмма ләкин илгә нинди ашлыкның күпме күләмдә кирәклеген планлаштыру хокукын да сызып ташларга ярамый. Ни өчен берәүләр кузаклыларны иген кырының унбиш процентына чәчәләр дә, җыеп та алалар, икенчеләр җирнең өч процентындагы борчак өчен дә сыкранып яшиләр? Берәүләр борчакны үзе үстерми, башкалардан алачагына өмет итә, кашык тотып, кеше казанына килә, икенчеләр, уңыш алса да, дәүләткә сатмый, үз хаҗәтенә генә тота. 1979 елда Воронеж өлкәсенең колхоз-совхозлары 145 мең тонна борчак җыеп алганнар, шуның 3,2 мең тоннасын гына сатканнар. Икенче елда уңыш икеләтә арткан, алар план буенча 75 мең тонна борчакны дәүләткә сатарга тиеш булганнар, әмма 52 мең тонна гына сатылган. Табигать шартлары бик уңай килгән 1976 елда Россия Федерациясендә 4 миллион 952 мең тонна кузаклы культура җыеп алынган. Бу — планлаштырылганга караганда, бер миллион тоннага артыграк. Әмма шуның егерме проценты гына дәүләткә сатылган, план үтәлми калган.

Шушындый хәлләр бер генә дә, ике генә ел да түгел, шактый вакыт дәвам итә. Сәбәбен табигатьнең холыксызлануы белән генә аңлату ышандырмый. Өстәмә түләүләр китерердәй бодай сату шул ук шартларда да уңышлы үтәлә ләбаса! Хикмәт нәрсәдә соң? Унынчы бишьеллыкта Россия Федерациясенең колхоз-совхозлары бодайның

кыйммәтле сортын 10 миллион тонна сатканнар, төрле өстәмәләрен кушып санаганда, аның һәр центнеры 22 сумга төшкән. Аз түгел! Күләмен бер якка куеп торып, җан иясенә кирәкле матдәне, ягъни аксымны, исәпләп карыйк. Бодайның аксымга байлыгын уртача һәр центнердан 12 килограмм дип куйсак, әзерләүләр оешмасы аксымның 12 килограммын 22 сумга сатып алган булып чыга. Кузаклыларның сыйфаты-фәләне өчен һичнинди өстәмәләр дә каралмаган. Борчакта исә аксым, бодай белән чагыштырганда, икеләтә күбрәк, 24 процент. Борчакның центнеры 20 сум тора, димәк, дәүләт протеинның 24 килограммы өчен 20 сум гына бирә. Дөрес, бодай — бөртеклеләрнең иң затлысыннан санала, әмма борчакның да мактарлык сыйфатлары шактый, аңарда һич ни белән алыштыргысыз аминокислоталар бар: лизин, цистин, тирозин, аргинин, гистидин, триптофан... Ә соя белән люпинда исә аксым 45 процентка җитә. Аларда май да күп. Уңыш җыярга гына өйрәнә алмыйбыз.

Терлек азыгы әзерләү тармагы хәзер тулы мөстәкыйльлеккә иреште. Кырлар, болыннар, көтүлекләр — барысы да фермалар ихтыяҗын канәгатьләндерергә тиеш. Инде хәзер үк иген кырының һәр өченче гектарыннан алынган уңыш терлекчелек ихтыяҗын канәгатьләндерүгә тотыла. Димәк, фуражга ындыр табагына кайткан ашлыкны бүлгәләү дөрес түгел, басуның үзен үк, зоотехник кушканча, туклыклы фураж ясарга мөмкинлек бирә торган культураларга бүлеп бирергә кирәк. «Рассвет» колхозында Ильиннан: «Шулай итәрсезме соң?» — дип сорыйм. «Юк»,— ди ул. Белгородта өлкәнең авыл хуҗалыгы идарәсендәге терлек азыгы әзерләү бүлеге начальнигы Александр Федорович Еньшиннан: «Зоотехниклар мал-туарга кирәкле культураны чәчә аламы, үзендәге җиргә үзе хуҗа була аламы алар?» — дип сорыйм. «Юк,— ди,— без хуҗа түгел».

Инде уйлап карыйк: кайдан башлана, кая барып терәлә соң бу эшләр? Кузаклыларны өнәмәү, һәм төшемле, һәм үстерүе җиңелрәк культуралар белән мавыгу әнә шуларга ук тоташа түгелме? Уңышның ниндилеген билгеләгәндә дә нәтиҗәне тонналар саны гына түгел, бөртеклеләрнең аксымга ни дәрәҗәдә бай икәнен исәпләргә вакыт җитмәгәнме? Бу очракта тракторчы белән комбайнчы, агроном белән председатель, селекционер галим белән партия эшлеклесе — барысы да хезмәтне җыеп алган уңыштагы файдалы сыйфаттан чыгып бәяләргә өйрәнерләр иде.

Сүз уңаеннан әйтергә мөмкин, бодайның да төрлесе бар бит, бөртектәге аксым дәрәҗәсе аның нинди сорт булуына гына түгел, игенченең аңа күпме тир түгүенә дә бәйле. Элеваторга, белгородлылар кебек, аксымы 10,34 процентлы гына бодайны да илтергә була, аксымлылыкны — 15, хәтта 20—25 процентка кадәр күтәрергә дә мөмкин. Аксымы 20 процент булган бодай — һич тә коры хыял түгел. Әйтик, җилемлелек артыннан кумыйча, башка сортлы бодай игәргә дә ярый бит. Бу бөртекнең 216 төрле сорты бар, шуның 50 төрлесеннән генә күмәч пешереп була, калган төрләре терлек азыгы өчен дә ярый. Көньяк районнарда игелә торган көчле бодайда, табигать шартлары яхшы җирдә, бодайның аксымы күп. Әмма ләкин җилемлелеге югары дәрәҗәдәге бодай өчен өстәмә түләүне башкаларның да эләктерәсе килә, шунлыктан кара туфраксыз, салкын якларда да, гәрчә алар саткан бодай терлек азыгы әзерләргә генә тотылса да, көчле бодай игәләр. Колхоз-совхозлар бодай игүне торган саен арттыра баралар, аксым дигән нәрсә исә кими бара. 1976 елда РСФСРда җыелган бодайның 13,11 процент аксымы булган, аннары әле ул тагын 0,27 процентка артып алган, соңра бу күрсәткеч гел кимү юлына баскан, 1979 елда кеше тырышлыгының төп нәтиҗәсен күрсәтүче бу матдә нибары 12,5 процентка калган.

Язмамның соңгы өлешенә күчкәч, уйлап куйдым: мине дөрес аңлармы соң, табыннарыбызның түрендәге ризыкларны әзерләү өчен иң кирәкле затлы бодайга каршы кизәнгән бит бу, димәсләрме? Алай түгел! Күпереп пешкән күмәчтән дә кадерлерәк ни булсын?! Ватаныбызның йөз аклыгы бит ул бодай! Дөньяның барлык илләре безнең бодай алдында баш ияләр. Аның игенчелек тарихында данлы урыны бар.

Мин әнә шул үзе затлы булса да, мал-туар симертү өчен отышсыз ризыкның абзар тиресенә әйләндерелүенә, җыеп алынган бодайның 40 процентын терлек тагарагына илтеп салуга каршы. Ак күмәчнең урыны — абзарда, тирес арасында түгел, табын түрендә булсын!

## Марсель Галиев

# ЛОРКА ИЛЕНДӘ

Андалузия киңлекләре... Йөгерек юл безне Гранада шәһәреннән Испаниянең бөек шагыйре Федерико Гарсиа Лорканың туган җиренә алып бара. Еракта кучкарланып торган мәрмәр таулар күренә. Як-якта төсләр чиратлаша. Мартирос Сарьян картиналарын хәтерләткән манзара. Чиста, төпсез күк йөзенең биеклеген тагын да искәртергә теләгәндәй очынып үскән эвкалиптлар, кояш тамчылары сыман янып утырган җимешләре белән чуарланган әфлисун агачлары, сөзәк тау битләрендә зәйтүн куаклары тезелеп киткән. Кырыгынчы параллель... Монда елның өч йөз егерме көненә бер генә болыт та күренми, бер генә тамчы да яңгыр төшми икән. Табигате белән нәкъ кытай ландшафтына охшаган, ди безне озата баручы гид.

Ызаннар белән бүлгәләнгән кырларда ара-тирә эшләп йөрүче крестьяннар чагылып кала. Уенчык шикелле кечкенә тракторлар кыймылдый. Бер якта өлгергән бөрәңге җыялар (май ае бит!), икенче баштан яңасын утыртып та киләләр. Көлсу туфрак, сугарулы кырлар. Уңышның һәр бөртеге өчен никадәр тырышлык сораладыр бу җирләрдә. Чехов әйткәнчә: тәртә кумсәң, тарантас үсеп чыгарлык, карга канатыдай зәңгәрсу-кара туфраклы якларда туып үскәнгәме — бу җирләрнең төсе миңа ят тоела. Әмма һәр кешенең туган җире үзенә газиз инде. Монда да тормыш-көн итү, мәңгелек хәрәкәт, яшәү өчен көрәш бара. Үз җиренең матурлыгын җырга салучы шагыйрьләр туа. Хәер, матурлыгын гына микән?.. Алай булса, шагыйрьләр җирдән үз үлеме белән генә китәрләр иде.

> Әгәр шигырь күңел чәчәге генә булса...
> Гарсиа Лорканы
> лимон агачына терәп
> франкочы атмас иде.
>
> Ренат Харис.

Әйе, Лорка 1936 елны франкочылар тарафыннан атып үтерелә. Шагыйрьнең соңгы минутлары турындагы төрле язмалар арасыннан мин берсен сайлап алам. Аны төнлә, ялгызлар камерасыннан алып чыгып, башка тоткыннар белән бергә машинага утырталар. Машина, Гранада шәһәрен чыккач, кечкенә бер авылда туктый. Фонтан янында алар таңны көтәләр. Карабин аскан фалангистлар тәмәке тарта-тарта йөренәләр. 19 нчы август төне... Лорка берни сизми, кая алып барасыларын да белми әле.

Таң атып килгәндә... сандугачлар уянган бер мәлдә... Сьерра Невада тауларның кар түбәләренә кояшның тәүге нурлары кагылганда... шагыйрь йөрәгенә караңгы күзле мылтык көпшәләре төбәлә. Берничә пуля тиюгә карамастан, шагыйрь кабат аягына басарга тели, үлем белән тартыша. Шул чак фалангистларның берсе аягы белән аның гәүдәсен җиргә кыса һәм битенә төбәп атып җибәрә.

Шушы моңлы иртәдә булган фаҗигане башыннан кат-кат кичереп, кешелеген җуйган фашистларны туктатырга теләп, дөньяның күпме шагыйрьләре Лорканы үз

күкрәге белән ышыкларга вакыт аша талпынып карамаганнардыр?! Әгәр каршысында егерменче гасырның олы шагыйре торганын белсә, хәтта атылган пуля да тарих хәтерендә кара упкын булып каласы ике арада эреп юкка чыккан булыр иде.

**...Төшсен миңа, төшсен**
**Үтерелгән,**
**Тумый калган җырлар каргышы...**
**Дөньяның бер нәни кургашы мин,**
**Кешелекнең зур бер ялгышы...**
**Роберт Миңнуллин.**

Соңгы мизгелендә, үзенә төбәлгән мылтыкның мәкерле күзенә карап, Лорка ниләр уйлады икән? Аңа үзе яраткан цикадалар тавышы ишетелде микән? Андалузия күгеннән үрелеп алып, шигыреннән шигыренә күчереп йөрткән Ай аны соңгы мәртәбә күреп калырга дип таулар артыннан калыкты микән? Булгандыр. Күз алдына шулай китерәсе килә. Шагыйрь йөрәгә тукталганда, Андалузия күгенең бер йолдызы күк бәгыреннән өзелеп төшкәндер. Соңгы минутында шагыйрь шушы җирнең, күкнең кадерен белүчеләр барлыгын уйлагандыр. Дөньяның төрле почмакларында үзенең дәвамчылары — яңа шагыйрьләр туасына ышангандыр.

**Чыклы август иртәсендә**
**син егылгач, Гранадада**
**әфлисуннар — алтын түгел,**
**нәкъ кырык ел кан төсендә,**
**траурда испан халкы,**
**Федерико Гарсиа Лорка!**
**Рәдиф Гатауллин.**

38 яшьлек Лоркага төбәп аткан мылтык авазлары тынарга да өлгермәс, берничә ел үтүгә, немец фашистлары тарафыннан 38 яшьлек татар совет шагыйре Муса Җәлил җәзалап үтерелер. Фашистлар кайсы гына илдә калыкмасын, аларның максаты бер — җан кыю. Бары тик җәзалау ысуллары гына үзгәрә, үлем кораллары гына камилләшә бара.

Гарсиа Лорканың фалангистлар кулыннан һәлак булуына ул чакта әле күпләрнең ышанасы килми. Бу шомлы хәбәр, шагыйрьнең үз чагыштыруы белән әйтсәк, «кара салават күпере» сыман баш очында эленеп тора. Ышанасылары килми, чөнки Лорка бернинди политик партиядә дә тормаган була. Әмма ул үзен ярлылар партиясе ягында дип саный. Художник үз халкы белән бергә елый да, көлә дә белергә тиеш, ди ул, һәм моны иҗаты белән раслый. Чын мәгънәсендә табигать җырчысы: төсләрдә — авазларны, авазларда төсләрне таба белгән шагыйрьнең күпьяклы таланты (Лорка — драматург, музыкант, рәссам һәм артист ул) ачылып, бөтен тавышына яңгыраган бер чорда Испаниядә фашистлар хәрәкәте башлана, гражданнар сугышы кабынып китә. Үз иле һәм үз халкы язмышына битараф булмаган шагыйрьнең Андалузия юлларыннан шом салып узган жандармериягә нәфрәт белән язган шигырен франкочылар кичерә алмыйлар.

Франко режимы илне тимер тырнак астында тоткан дәвердә, Гарсиа Лорканың китапларына үз илендә дөнья күрергә насыйп булмый. Хәтта аның гәүдәсе күмелгән җирне дә ачыклый алмыйлар.

Бүгенге көндә Гранададан сигез чакрым ераклыктагы Виспар кешеләре әйтүенчә (шагыйрьнең атылган җире), Лорка белән бергә ике тореро һәм бер укытучы да үтерелгән. Аларның гәүдәләре Айданамар чишмәсе янындагы зур таш кырыена, карт зәйтүн агачы төбенә күмелгән, имеш.

Автобус эссе кояш астында әлсерәп яткан юлдан, кулагәсен иартеп, алга ашкына. Әйтерсең, бер төркем татар язучылары, сәнгать кешеләре, автобуска төялеп, Тукай-Кырлайга бара. Күңелне сафландырып, чистартып кайтыр өчен, янына килеп йөрәрдәй бөек шагыйре, шигъри мәккәсе булган халыклар бәхетледер ул. Бәхет — уртак шатлык, уртак хәзинә. Шуңа күрә шигърият ил чикләрен атлап чыга, күп телләрне

үзенеке итә. Бүтән телләрдә дә яңгыраган шагыйрьләр иҗаты, бүтән халыкларның да кабул итүе аша зурая, яңа яктан ачылып китә, үзгә яңгырашларын таба. Дөнья шигъриятенең асыл уллары арасында Тукайны да Европа илләренә ныклап танытасы иде!

Мин тәрәзәдән кайчандыр Лорка сокланган табигать күренешләрен күзәтеп барам. Көчле килешми, тыныч кына йөзеп калган манзара артында еракта калган фаҗигане башын әзли. Юл буенда, яшеллек арасында, уйдык-уйдык булып ут-кызыл чәчәкләр балкып кала. Кыргый чәчәкләр — чәчрәп киткән кан тамчылары сыман, франкочы пулясы тигәч, шагыйрь йөрәгеннән тамган кан тамчылары гүя, утлы чәчәкләр булып, бөтен Андалузия киңлекләренә сибелгән. Шәфәкъ вакытында көмеш гөмбәзле тау түбәләренә шушы чәчәкләрнең шәүләсе кызарып төшәдер сыман. Әллә соң борынгы таулар бөек улларын вакытсыз җуйганны бик соң аңлаган тарихның үзе шикелле кызара микән...

Менә без бер, ике катлы, шикәр кебек ак йортлардан торган Фуэнте Вакирос авылында. Фуэнте — чишмә чыккан урын дигән сүз. Шагыйрьнең иҗат чишмәсе дә шушыннан дөньяга калыккан.

Безне алькальд (административ җитәкче) Франсиско Мартин Гарсиа каршылады. Без дигәнем — РСФСР Язучылар союзы оештырган сәяхәтчеләр төркеме — Мәскәү һәм Ленинград язучылары, әдәбият-сәнгать белгечләре, галимнәр, Казаннан без өчәү: язучы Аяз Гыйләҗев җәмәгате белән һәм мин.

Урындагы муниципалитет бинасында Лорканың якташлары белән кыскача очрашусөйләшү, истәлекле бүләкләр алмашу булып алды. Җыелган халык арасында Испания коммунистлар һәм социалистлар партиясе членнары да бар.

— Теге елларда миндә Лорканың китабы бар иде,— диде Мартин Гарсиа.— Ләкин мин аны кешегә күрсәтергә курыктым. Лорканың исемен дә телгә алырга ярамый торган еллар иде. Ләкин, тыелуга да карамастан, чын испанлылар шагыйрьнең иҗатын күңелләрендә сакладылар,— диде ул.

Күренекле тәнкыйтьче Феликс Кузнецов:

— Сездә Лорканың исемен дә телгә алырга ярамаганда, аның китаплары безнең илдә рус һәм башка халыклар телендә күпләп басылды, иҗаты вузларда өйрәнелде,— диде.— Безнең илебез — Советлар Союзы шагыйрьнең икенче Ватаны булды.

Моны тыңлаган испанлыларның йөзендә чиксез рәхмәт хисләре чагыла иде.

Нинди генә телдә язмасын, кайсы гына илдә яшәмәсен, алдынгы карашлы, ирек өчен көрәшүче, халык рухын чагылдыручы шагыйрьләрнең уртак Ватаны, чынлап та, безнең илебез булды — поэзия Ватаны. Күпне күргән, дөньяга күпне биргән Бөек рус поэзиясе аларны үз канаты астына ала барды.

Франко режимы таркалганнан соң гына Гарсиа Лорка иҗаты үз иленә яңадан әйләнеп кайта. Китаплары күпләп басыла, пьесалары уйнала башлый. Туган җирендә шагыйрь истәлегенә мемориаль төзелгән. Укыган мәктәбенә аның исеме бирелгән. Һәр елның июнь аенда, шагыйрьнең туган көненә багышлап, Фуэнте Вакироста шигъри бәйрәм үткәрү дә гадәткә кереп бара икән.

Лорканың туган йорты каршында торганда, ирексездән, аның шундый юллары искә төште:

> **Әгәр мин үлсәм,**
> **балкон ишекләрен япмагыз —**
> **аннан мин**
> **кырдагы игенчеләр тавышын тыңлармын.**

Әмма сәяхәтчеләр өчен шагыйрь туган йортның тәрәзәсе корулы, ишеге бикле иде. Бу йорт хуҗалар кулында икән. Киләчәктә аны, сатып алып, музей итеп эшләү күздә тотыла, диделәр безгә ул чакта.

Мондагы йортлар да, урамнар да үзгәрмәгән, Лорка исән чактагыча икән. Бу ташлар аның аяк тавышын хәтерлидер әле. Бу тәрәзәләрдә аның уйчан йөзе чагылып үткәндер, диварларга күз карашы сеңеп калгандыр. Шагыйрь сүзгә әйләндерергә өлгерә алмаган илаһи хисләр шушы тирәлеккә күчеп, табигать белән кушылгандыр сыман. Әлеге табигатьне үз күзләрең белән күргәч, аның мәгълүм шигырьләре дә

яңа төсмерләргә баеп, моңарчы тоеп, искәртеп өлгермәгән чагылышларда балкып китә.

...Гибралтар бугазы яныннан үтешли, кул сузымы гына ераклыкта бик ачык булып күренгән Африка ярларын карарга дип тукталган идек. Бер якта — Атлантик океан, икенче якта — Урта диңгез. Шушы бөек дәрьяларны күрештергән урынны тамаша кылып йөргәндә, без Аяз Гыйләҗев белән хәйран калып тукталдык. Биш-ун гасырлык эвкалипт, магнолия, хикмәтле инҗир агачларын күреп тә болай ук гаҗәпләнмәгәнбездер. Нәрсә күрдек дисез — гап-гади ромашкалар! Бөтен төрләре белән ят, купшы табигать эргәсенә адашып кына килеп чыккан шикелле, сары карашларын мөлдерәтеп тып-тын гына утыралар. Күңелләрне ягымлы хис биләп алды. Туган як исе, таныш моң, кадерле төс сирпелгәндәй иде елмаеп утырган ак таҗлы чәчәкләрдән. Шул мәлдә Хәсән ага Туфанның ятланган шигырь юллары хәтердә янә кабатланды:

> **Ромашкалар тирбәлә җилдә**
> **Бер күренеп, тагын күмелеп,**
> **Йөгерә-йөгерә шаян нәниләр**
> **кырда качыш уйнаган кебек.**

Ромашкалардан соң каеннар сагындырып куйды. Каеннар диюгә, шигърият мәйданына Есенин калка. Күңелләргә якты төшереп, тездән әбагалар ерып килүче каеннарны ул бит җитәкләп шигърияткә алып килде. Есенин дигән сүзнең үзеннән үк каен исе, каен төсе чагыладыр шикелле...

Лорка, Туфан, Есенин... Үз табигатенең үтә нечкәлекләрен хикмәтле сүзләр аша кеше җанына җиткерүче аваздаш, аһәңдәш өч шагыйрь берлегән тойдым мин бу минутта. Үз җырчысы булмаса, матурлык та уңар иде, сүнеп-сүрелеп калыр иде. Телләре үзгә, яшәгән җирләре үзгә булса да, дөньяны яшәртүче шагыйрьләр рухы бәйләнештә икән. Әйе, шагыйрьләрсез дөнья бик картайган булыр иде...

Лорканың туган җиреннән китәр алдыннан безне крестьяннар урап алды. Совет иле язучыларыннан, әдәбият-сәнгать галимнәреннән торган мондый зур төркемнең Фуэнте Вакироска беренче тапкыр килүе икән. Кызыксынулары йөзләренә чыккан. Берничә еллар элек монда Евгений Евтушенко, аннары Лев Ошанин килеп киткән булган. Безгә бүләк итеп бирелгән Лорка һәм Неруда истәлегенә чыгарылган китапта Евтушенконың «Когда убили Лорку» шигыре испанча тәрҗемә ителеп басылган иде.

Гранада университетында очрашу вакытында шагыйрь һәм журналист Хуан де Локса әлеге шагыйрьләрне җылы итеп искә алды. Лев Ошанин Фуэнте Вакироска барасы юлны сорагач, бер испанлы:

— Сез анда нигә барасыз?— дип кызыксынган.

— Мин дустым янына барам,— дип җавап биргән шагыйрь.

Без Лорканың якташларына значоклар, истәлекле бүләкләр биреп калдырдык. Саубуллашканда алар кул бөгеп, йодрыкларын җилкә тигезлек күтәрделәр.

— Compañeros [1].

Бу — биш бармакны бер төенгә җыеп, теләктәш булыйк, гадел булыйк, без бит бер планета уллары, дигән мәгънәне аңлаткан кебек иде.

— Рәхмәт сезгә, тагын килегез!

Бөек шагыйрьне олылап килгән өчен рәхмәтле карашларында бераз моңсулык та бар иде бугай. Крестьян дигәнең кайсы гына илдән-милләттән булмасын, хәтта кыяфәте, фигыле-торышы белән дә бер-берсенә охшаган, ахры. Табигать белән бер бөтен булып, яшәүгә шулайдыр ул, күзләрендә — җир җылысы...

Алда яшь топольләр арасыннан сузылган юл. Сандугач канатында төнге чык тамчыларын күрә белгән шагыйрь кайчандыр шушыннан Гранадага чыгып киткән. Гранада... Берничә гасыр элек гарәпләр төзеп калдырган «Алһамбра»сы, корридалары белән атаклы шәһәр. Бер карасаң, җемелдәүле күбеккә охшап торган затлы күлмәк итәкләрен тавис койрыгыдай сузып, икенче карасаң, авыр, бөтерелмә итәкләрен диңгез дулкыныдай шаулатып, кастаньет шыкылдатып биюче ут карашлы сылу кыз-

[1] Иптәшләр.

лары белән атаклы мавритан стилендәге Фламинга биюләре, төсле авазлар, ритм-хәрәкәт, кайнар дулкын булып шагыйрь иҗатына килеп кергән. Шушы шәһәрдә Лорка беренче китабын чыгарган, аннары, пьесаларын куйдырырга дип башкалага юл тоткан.

Төнге Мадрид... Борынгы биналар белән беррәттән алтынсу һәм көмешсу ялтыравыклы егерменче гасыр архитектурасы күзгә ташлана. Күпме кешенең акылын, дәрт-дәрманын алтынга, кыйммәтле кәгазьгә әйләндереп, калын диварлар артына яшергән, серле-караңгы тәрәзәле чит ил банклары тезелеп киткән урамнар. Лорка язганча, бу борынгы таш урамнардан, кылычлары белән җилне кисеп, кайчандыр жандармнар узгандыр. Шәһәр өстендә очкынлы тояк тавышлары, булачак корбаннарының ишеген каккан шикелле, дәһшәт салып яңгырагандыр. Хәзер әлеге урамнарда машиналар ташкыны. Як-якта бер-берсенә ышкылып диярлек туктап калганнары тоташ рәт — диңгез дулкыны ярга чыгарып ташлаган кабырчыклар кебек. Испания мәйданында без һәйкәл ансамбле янында тукталабыз. Атлы җайдак — Дон Кихот һәм ишәккә атланган Санчо Панса. Озаграк текәлеп карасаң, һәйкәл икәнен онытып җибәрүең бар — йөзләрендә җанлы кеше чалымнары. Әгәр, арттa, биек постаментта тыныч акыл белән карап торучы Сервантес булмаса, алар егерменче гасырның күкрәп килгән ташкынына каршы кузгалып китәргә әзерләр сыман. Сервантес сабыр гына карап тора. Гүя ул шушы чорның үз рыцарен көтә. Яңа Дон Кихот калкып чыкса, Санчосы табылыр...

Урамда соңгы мода белән киенгән яшьләр: кул чабып җырлап киләләр, урам ташына утырып тәмәке тарталар, испанча кайнарлык белән кызып-кызып сөйләшәләр. Тәмен арттырырга теләгәндәй, «Пепси» һәм «Кока-кола» дип салкын яктылык белән кычкырып торган неон рекламалы барларда да — күбесенчә, яшьләр. Алар Лорка иҗатын беләләрме икән? Бик битараф түгелләрме? Кара еллар кабатланса, коралны кемгә каршы төбәрләр алар? Кешелекнең меңнәрчә еллар төзегән һәм тудырган сәнгать җәүһәрләре, атом дәһшәтенең кара гөмбәсе астында калып, тораташка әйләнмәсме, дигән хәвеф бармы алар күзендә? Ышанасы килә, бөтен кешелекнең яктыга, тынычлыкка йөз белән борылуына ышанасы килә...

Фуэнте Вакирос — шагыйрьнең чишмә башы — арттa кала. Каршыда — Лорка дөньяга чыгып киткән юл. Еракта — мәңгелек кар түбәле Сьерра Невада таулары. Юл — ак болыттай каршыга агып килүче шул тауларга таба. Бу юлның тукталышы юк. Ул миллионнар күңелендә тармаклана. Бу юл сине шагыйрь катына, шигъриятнең мәңгелек тәхетенә илтә.

*1981.*

# ИЛДАР ЮЗЕЕВКА 50 ЯШЬ

## Гариф Ахунов

# КЫЯДАГЫ БӨРКЕТЛӘР



Илдар Юзеев белән бергә юлга чыгучылар байтак. Илленче еллар башында аларны — Шәүкәт Галиевне, Хисам Камаловны, Илдар Юзеевны һәм Рәшит Гәрәйне беренче булып Сибгат Хәким күреп алган иде. Аннары алар төркеменә яше олырак булган, әмма авырып тору сәбәпле матбугатка соңарыбрак килгән Гамил Афзал кушылды. Болар барысы да—талантлы шагыйрьләр. Әдәбиятның йөген инде төпкә җигелеп тартучылар. Шәүкәт тә, Хисам да, Рәшит Гәрәй дә инде илле еллыкларын уздырдылар, Гамил Афзал инде хәтта алтмыш еллыгын да уздырып җибәрде, баксаң-күрсәң, алар арасында иң яше Илдар булган икән, аның илле яше тик әле менә хәзер генә, 1983 елның 3 январенда гына килеп җитте. Кайбер әдипләрнең бәйрәмнәрен үткәргән чагында укучылар, нигә, аңар да илле тулдымыни инде, дип гаҗәпләнәләр, чөнки эшләгән эшләре чыпчык борыны чаклы гына була. Илдар Юзеевның эшләгән эше шулкадәр дә күп, нигә, аңа илле генә туламыни әле дип гаҗәпләнүчеләр күп булыр, мөгаен.

Әдәбиятка илленче елларда шагыйрьләр белән бергә прозаиклар буыны да килде. Мин дә шулар белән бергә кулга каләм алган идем. Шуңа күрә Илдарның «Тормыш җиңә» исемле беренче поэмасыннан, аңар шагыйрьлек исеме алып килгән «Таныш моңнар»ыннан башлап барлык 20 поэмасын да, бик күп санлы шигырьләрен дә, республикабыз театрларында һәм илебезнең башка сәхнәләрендә уйналган дистәдән артык пьесасын да беләм шикелле. Аларның язылган, китап булып басылган чакларына да, шагыйрьнең сөенеч-шатлыкларына, иҗат газапларына да шаһит булдым.

Инде менә «Шигырь китапханәсе» сериясендә Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган аеруча тулы җыентыгы кулга килеп керде.

Турысын әйтеп сөйләшик, шигырьләрне бер-бер артлы күп итеп, бер утыруда тоташ уку — гомумән авыр һәм, әйтер идем, гөнаһ эш. Шигырьдән туган хисләр йомарлам-йомарлам булып күңел байлыгына әйләнә барырга тиеш. Әгәр шулай икән, шигырь укудан ни файда?! Илдар Юзеевның соңгы китабын укый башлаганчы күңелдә шундыйрак бер курку хисе посып тора иде. Сөенечкәдер — ялгышканмын. Һәр шигыре, һәр поэмасы таныш булуга, инде бер мәртәбә укылган булуга карамастан, тәүге укыгандагы хисләр сүнмәгән булып чыкты, кабат уку белән алар яңарды, дулкынландырды. Чын поэзиянең көче күрәсең кабат-кабат дулкынландыра алуындадыр.

Илдар Юзеевның нинди шагыйрь, нинди шәхес булуын үзем аңлаганча укучыларга сөйләп бирер алдыннан иң әүвәл аның гармунчы булуына тукталып китәсем килә. Илдар-гармунчы берәүне дә кабатламый. Баян дип тә шашмый ул, аккордеон дип тә авыз суын корытмый, аның иң яратып уйнаган гармуны — хромка. Казан фаб-

рикаларында ясалган гадәти генә, күрер күзгә әллә ни зур да булмаган гармун Илдар кулына килеп электеме — үзгәрә дә китә. Илдар белән гармун бер организмга әйләнәләр. Илдарның борын канатлары киерелә, башы гармун өстенә ята, ә бармаклары, озын ак бармаклары гармун телләрендә бии. Мондый чакта тирә-юньдәге кешеләр дә, йортлар да, урман-сулар да, зәңгәр күлләр дә онытыла. Шундый да бирелеп, шундый да бер ихласлык белән уйный Илдар гармунны, андый сәгатьләрдә дөньяда моң гына яши, тоташ бер агынты булып агылган, җаннарны әйкәп алган моң гына торып кала.



Илдар Юзеевның поэзиясенә, утыз ел буена иҗат иткән шигъриятенә карата да шушы ук образны кулланырга булыр иде. Илдар Юзеев — зур сулышлы поэзия авторы, әмма аның гражданлык хисләре кайда башлана да, күңелләрендәге иң нечкә, иң интим хисләре кайчан бәреләнә — моны аерып каравы кыен. Тагын шул кадәресе бар: гадәти тормышта Илдар шыпырт егет, әкрен егет, аны хәтта шагыйрьдер бу дип әйтүе дә кыен; башны кырынрак салып, бер кулны ыграк селтәп, гел үз алдына карап йөрер, яки берәр көтелмәгән шаян сүзне дусларының әңгәмәсенә китереп кыстырыр да тагын үз дөньясына чумар, синең белән бүтән алыш-биреше булмас.

Менә хәзер, «Мәхәббәт китабы»ндагы шигырь-поэмаларны укып чыккач, мин аның бик күп белемле, бик тә кайнар хисле, чын шагыйрь икәнен тагын бер мәртәбә аңладым, тәнкыйтьчеләр Илдар Юзеев поэзиясен ачып бирдек дип әйтә алмый торганнардыр әле дигән фикергә килдем.

Илдарны яшьлек шагыйре, диләр. Бу сүздә дөреслек бар. Әмма яшьлек шагыйре дип әйтү белән генә Илдарның иҗади йөзе ачылып бетми. Әйе, яшьлеккә ул гомере буе турылыклы. Моннан утыз ел элек язган «Таныш моңнар»ында яшьлек хисләре Зөфәрнең өздереп гармун уйнавында да, авыл егетен, игенчене үзенә тиң күрмичә вузга китеп барган, аннары югары уку йортына әлегә алмыйча, Зөфәрен сагынып, үкенеп елаган Резидәкәйнең саф күз яшьләрендә дә бар. Әмма бу чорда әле Илдар башы-аягы белән Такташ поэзиясенә чумган, Такташтагы романтиклык, бунтарьлык, яшьлеккә хас тилемсәлек аны бөтенләе белән, хәтта стихияле рәвештә биләп алган иде. Шигырьнең алымнары, образ, сурәтләр, героиняга эндәшү, аның сөенечен, моң-зарын уртаклашу формалары Илдарның Такташ шигъри мәктәбендә яшәвен әйтеп тора иде.

Һәр җир тынган.
Ә син ялгыз гына
Йомшак чәчләреңне тарыйсың,
Ефәк тасма белән үрә-үрә,
Зур көзгегә таба карыйсың.
Ай-һай гәүдәң бигрәк сылу икән!..
Син үзең дә
«Уф!» дип куйдың,—
Ахры, түзмәдең...
...Ник, матурым, бигрәк моңайганнар
Төн карасы кебек күзләрең!
Аклы ситсы буй-буй күлмәгеңне
Саласың да тагын киясең.
Резидәкәй матур, ни кайгың бар,
Нигә башың түбән иясең!

Такташча табигый агыш. Шигырьдә хәтта сүзләр дә юк сыман. Хис кенә, моң гына. Әлеге романтик поэманы, хезмәткә, яшьлеккә, күңел сафлыгына дан җырлый торган поэманы Юзеев 21 яшендә иҗат итте. Димәк, 21 яшендә инде Илдар Такташның поэтик мәктәбен үзе теләгәнчә, сәнгатьле итеп куллана алырдай шагыйрь булган. Димәк, шушы яшендә үк инде аның дөньяны аңлавы, табигать авазлары белән әңгәмәгә керә алуы, кешеләргә мөнәсәбәте ачык булган. Илдар әдәбият мәйданына өйрәнчек шагыйрь булып түгел, җитлеккән шагыйрь булып килгән. Такташ поэтикасы аның үз эстетик идеалына туры килгәнгә, ул аныңча язган.

Алтмышынчы еллар башында Илдар Юзеевны поэзия сөючеләргә аеруча җитди

шагыйрь итеп таныткан бер шигыре басылды. «Тып-тын иртә» исеме белән йөри торган, ни барысы унөч юллы ул шигырьдә протез аяклы солдат асфальтка морзе әлифбасы белән суккандай басып, дөньяны кисәтеп уза. Бу исә шагыйрьнең алгы иҗатында ачылачак яңа бер теманың безгә хәбәр салуы иде. Каһарман ирләр, ил азатлыгы өчен җаннарын аямаган фидаи җаннар белән алды Юзеев күңелен. Фатих Кәрим истәлегенә багышланган кыска, ләкин тирән мәгънәле шигырь дә, «Авылым легендасы» да, «Клибернны тыңлыйм», «Тын океанда, тыныч чорларда», Тукайга, Заһидулла һәм Фәрит Яруллиннарга багышланган шигырьләр дә Илдарның патриотлыгын, дөнья иминлеге өчен көрәшкән асыл ирләргә соклануын, шулар батырлыгын бүгенге яшьләргә күчерергә теләвен әйтеп торалар. Алтмышынчы елларда ныклы үз тавышын тапкан, берәүне дә кабатламый торган, илен, җирен, туган телен ихтирам иткән, халыклар дуслыгына мәдхия җырлый торган шагыйрь җитеште. Аның әле тарихлар буйлап, таш диварлар кичеп йөрисе бар, аның әле гитлерчылар крематорий мичендә яндырган Хәйретдин Мөҗәй исеменнән поэма язасы бар... Әмма бу олы хисләр, киң колачлы, масштаблы тойгылар «Канкай углы Бәхтияр» легендасында инде тулысынча бөреләнә.

Тып-тып тояк тавышын
Тыңлап үскән баладыр,
Урал тауның сагышын
Җырлап үскән баладыр,
Акбүз атта барадыр
Канкай углы Бәхтияр.

Юллар бергә килгәнгә,
Ике батыр дус булган,
«Уң кулым син» дигәнгә,
Күңелләре хуш булган,
Пугачаугә кушылган
Канкай углы Бәхтияр.

Төрки халыкларындагы риваятьләр алымы әлеге легендада бик оста файдаланылган, һәм бердәнбер төгәл табылган шушы алым Канкай углы Бәхтиярнең батыр йөрәкле лачын булуына да, җиңүле адымнарына да, Илдар поэзиясенә хас романтиклыкка да туры килә.

«Канкай углы Бәхтияр»дән соңгы иҗат чорын Юзеев поэзиясендәге Батырлар китабы дип исемләргә булыр иде. Биредә Муса Җәлилнең фашизм тоткынлыгындагы соңгы көннәренә багышланган «Соңгы сынау» поэмасы да, Совет Армиясе полковнигы шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйнең соңгы сәгатьтәге уй-тойгыларын чагылдырган «Язылмаган поэма» да, «Тынлык белән сөйләшү» дә, «Таш диварлар авазы» да бар. Ләкин болар барысы да бер җепкә тезеп чыккан бер иш мәрҗәннәр түгел. Шагыйрь Юзеев һәрбер поэманың үз аһәңен, үз моңын, үз шигъри агылышын тапкан. «Язылмаган поэма» — ярсулы. Ул бүтәнчә була да алмый. Чөнки шагыйрь Мөҗәй крематорий мичендә яндырылыр алдыннан илләр, халыклар өстенә утлы сүзләрен ыргытырга, соңгы васыятьләрен әйтеп бетерергә тиеш. Поэма шулай уйланылган, шулай язылган.

Яктылыкны күбрәк күреп калыйм,
Баемачы, кояш, баема.
Бу минутым минем — язылмаган,
Ләкин язылачак поэма.
Күңелемдә йөргән поэманың
Прологын әйтеп калдырам.
Син дәвам ит аны, шагыйрь иптәш,
Фашист мине утта яндыра.
Бу сүзләрне
Каләм белән түгел,

Аккан каным белән язамын,
Тыңла, Идел,
Илем,
Казаным.

Бу — Фатих Кәримнең «мылтык түтәсенә» салып язган окоп шигырьләрен хәтерләтә. Юк, хикмәт формада түгел, форманы Мәҗәйнең үлем алдындагы йөрәк тавышы итеп шагыйрь Юзеев үзе тапкан. Кешеләргә ышанып дәшүе, дөньяга ышанып дәшүе белән Фатих Кәрим бу! Шигырьнең тәэсир көче белән, эмоциональлеге белән — Муса Җәлил!

Кешелек бәхете өчен гасырлар буена таш диварлар эчендә, зинданнарда һәлак булган каһарманнарга багышланган «Таш диварлар авазы» поэмасы форма ягыннан «Язылмаган поэма»дан нык аерыла. Анда ниндидер авырлык, саллылык, салмаклык бар. Моның шулай булуы бик табигый. Чөнки монда йөрәген уч төбенә чыгарып салган шагыйрь сөйләми, ташлар сөйли. Аларга ашыгу кирәкми, алар кеше хәсрәтен, кеше моңын гасырлар буена җыйганнар. Гасырлар буена сөйләп торырга тиешләр. Ташлар тарих саклый, ташлар фаҗига саклый. Шундый ук фаҗигалар планетаның төрле почмакларында бүген дә кабатланып торганлыктан, дөньяда тираннарны тудыручы өстен сыйныфлар, халыкны изеп-җәберләп яшәүчеләр булганлыктан, «яңа буын шагыйрьләрен көтә Мусалардан бушап төрмәләр» (Сибгат Хәким). «Таш диварлар авазы» — безнең татар поэзиясе күләмендә генә кала торган поэма түгел, илебез күләмендә генә кала торган поэма да түгел, ул планетага чыгарга тиешле, күп төрле телләргә тәрҗемә ителергә тиешле, Назыйм Хикмәтләр, Сәмәд Вургуннар поэзиясе кебек үк дөнья халыкларының күңелен биләп алырга, социал гаделсезлекләр, яшәү һәм үлем, сәгадәт һәм фаҗига, мәхәббәт һәм нәфрәт турында чаң сугып йөрергә тиешле поэма. Язылганына инде байтак еллар узган булса да аның әле русчага да тәрҗемә ителмәве бик үкенечле. «Таш диварлар авазы» — шагыйрьнең батырлар турындагы, мәхәббәт турындагы фәлсәфи фикерләвен туплап, югары ноктага күтәреп бирә алган әсәр. Ник дисәң, бу поэманы язар алдыннан шагыйрь зур әзерлек алып барды: унсигезенче гасырда һәлак булган Бәхтиярны, революция дәверендә



*Илдар Юзеев һәм Хәсән Туфан*

һәлак булган солдатны, Бөек Ватан сугышы каһарманнары Карбышевны, Мәҗәйне, Мусаны иҗат итте. Әмма болар берәм-берәм геройлар иде, аерым геройлар иде. Мефистофельгә җанын сатмыйча, соңгы сынаудан да исән чыккан Муса аркылы ул безнең бөтен тарихыбызга, азатлык көрәшләренә мөрәҗәгать итте. Ватанга, туган җиргә, туган телгә мөнәсәбәтне Мусаның ныклыгы, сугыш алды елларында тәмам чыныгып җиткән большевик булуы белән, яңа тәгълиматның, марксизм тәгълиматының, интернационализмны, барлык халыкларга тигез бәхет теләгән һәм шуның өчен көрәшкән коммунистлар тәгълиматының какшамаслыгын исбат итте. Коры сүз белән түгел, лозунг белән түгел, сәнгатьнең югары законнарына таянган әдәби сүз белән исбат итте. Безне Илдар Юзеев поэмаларындагы документальлек һәм шул документальлек белән янәшә шигъри өстәмәлек һәрчак дулкынландыра. Үлем алдыннан Мусаның «Фауст» китабын укыган булуы, ягъни шушы документаль нигез Илдар Юзеевка Җәлилне Мефистофель белән бәхәскә кертергә хокук бирә. Ә бәхәс коммунистик идеалларыбызны, коммунистик иманыбызны тагын бер мәртәбә, үтемле алымнар белән, сәнгать теле белән, сыйнфыйлык белән раслау өчен кирәк.

Әйе, Илдар «Таш диварлар авазы»на зур әзерлек белән, ныклы белем белән килде. Бу әзерлекне раслаган поэмаларга батырлар турындагы әсәрләр генә керми. «Әнкәй» поэмасы да шушыңар ук керә. «Мәхәббәт» китабына Илдар 20 поэманың 12 сен керткән. Әмма ул анда «Әнкәй» поэмасын кертүне дә кирәк тапкан. Әнкәй образы, иле чакырганга каршы килмичә, улларын ерак юлларга озата белгән, аннары балалары өчен ут йотып яшәгән әниләребез образы, Илдарның барлык батырларын да, таш диварлар эчендә исемнәре генә калган дөнья каһарманнарын да бәйли. «Әнкәй» поэмасы ерак казакъ даласында чирәм җирләр күтәрүче тракторчы егетнең эчке монологы төсендә язылган. Бу җәһәттән ул беркадәр «Язылмаган поэма» белән аваздаш. Әйе, аваздаш, язылмаган поэмаларыбыз әниләребез хакында да бар әле. Соңгы елларда бу темага күренекле совет шагыйре Рәсүл Гамзатов җитди поэма иҗат итте. Илдар Юзеевның «Әнкәй» поэмасын да мин шундый ук уңышлы, шундый ук чын әсәрләр рәтенә куясым килә. Автор бик табигый рәвештә әлеге монологка кулаклар кулыннан һәлак булган әти образын (милиция башлыгын), сугышта үлеп калган олы улны һәм бүгенге көндә дә ил байлыгын арттыручы, әнисе өчен өзелеп яшәгән кече ул образын бирә алган. «Әнкәй» поэмасы минем үземә батырлар һәм мәхәббәтне олылаучылар хакындагы китапның лейтмотивы, чишмә башы булып тоела, шуңа күрә әлеге китапка аның кертелүен бик тә урынлы һәм тиешле дип саныйм.

«Шагыйрь ничек туа, кайчан туа?» дигән сорауны еш кына ишетергә туры килә. Моңа төрлечә җавап бирүчеләр бар. Илдар Юзеев бер әңгәмә вакытында шаяртып: «Абыем Нил шуклыкларым өчен мине кыйный иде — тәнкыйтьче булды, мин җылый идем — шагыйрь булдым»,— диде. Уйнап әйтелгән булса да, нигез бар бу сүзләрдә. Моңлының моңын аңлау шагыйрь итә бугай кешене. «Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым»,— дигән бөек Тукаебыз үләр алдыннан. Дөньяны пакьларга теләү, аны тираннардан, палачлардан, соры кортлардан азат итеп күрергә теләү, явызлыкны җиңәрдәй көчләрне алга чыгару — менә шул шагыйрь итә бугай кешеләрне. Кәсепчеләрне, «салкын тимерчеләрне», акча исәбенә рифма коеп утыручыларны бер нәрсә дә шагыйрь итми һәм итмәячәк. «Графоман белән шагыйрь арасында нинди аерма бар?» дигән сорауга бүгенге заманның танылган бер шагыйре, болай дип җавап биргән иде: «Графоман үзенең шагыйрь булуына беркайчан да шикләнми, чын шагыйрь юк-юк та шикләнеп куя».

Дөньяны пакьлау мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк. Тукай Столыпин реакциясе көчәйгән чорда һәлак булган. Илдар Юзеев азат илдә, социализм илендә яшәп иҗат итә. Шулай булгачыннан, дөньяны пакьлау мәсьәләсе аңар кагыламы соң? Кагыла һәм бик нык кагыла. Егерменче гасырның икенче яртысында яшәгән шагыйрь, дөньяда атом бомбалары, лазерлар, канатлы ракеталар иҗат ителгән чорда яшәгән шагыйрь, кайсы гына милләтнең улы булмасын, нинди генә телдә иҗат итмәсен, Тынычлык мәсьәләсен, халыкларның Иминлеге мәсьәләсен әйләнеп уза алмый. «Җир шарының кайсы гына почмагында җир ярылмасын, ул шагыйрь йөрәге аркылы уза». Менә шуңа күрә үз халкының тарихыннан, бөек туганыбыз рус халкының һәм илебездә яшәгән башка халыкларның тарихыннан дөнья тарихына, таш диварлар авазына килеп чыгуын Илдар Юзеевның шигърияттәге табигый юлы дип саныйм мин,

шагыйрьнең, партиябез һәм халкыбыз таләп иткәнчә, тормышның үзәк агымында баруы, зур гражданлык хисләре белән янып яшәве дип саныйм.

Илдар Юзеевны без күп төрле шигырь җыентыклары, поэмалары, сәхнә әсәрләре буенча беләбез. Аның поэмаларының, шигырь китапларының интеллектуаль югарылыгына, бәлки, укытучы гаиләсендә туган булуы да ярдәм иткәндер. Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаган булуыннан һәм әтисенең укытучы-педагог булуыннан чыгып без аны икенче буын интеллигент дип әйтә алабыз.

Илдарга көрәшчеләр образын поэзиясенең үзәгенә алуда этәргеч көч булган тагын бер мөһим нәрсәне әйтеп китәргә кирәк. 1957 елны, әле беренче шигъри китабы гына басылып чыккан шагыйрь Татарстан яшьләре делегациясе составында башкалабыз Мәскәүдә Бөтендөнья яшьләре һәм студентлары фестивалендә катнашты. Шунда туган хисләрен, барлык континентларның яшьләренә карата булган мөнәсәбәтен, аларның җир йөзендә тынычлыкны сакларга әзер торуларын ул шигырь теленә күчерде. Батырлар турындагы поэмалар бәйләме шуннан башланып китте дә шикелле.

Озак еллар буе җәмәгать эшендә эшләве, дөресен әйткәндә, яратып-теләп эшләве аның гражданлык хисләренә көчле канатлар бирде. «Ялкын»да, «Чаян»да, «Казан утлары»нда бүлек мөдире, җаваплы секретарь булу, Татарстан Язучылар союзы идарәсенең председатель урынбасары булып, яшь иҗат көчләре белән эшләүне киң колач белән алып бару (ул эшләгән чорда республикабызның барлык районнарында зона конференцияләре үткәрелде, яшьләрдән уннан артык иптәш Язучылар союзы члены булып кабул ителде. Чаллыда язучылар оешмасы ачылды — болар барысы Илдар Юзеевның үз иҗатына да ныклык бирде, ышанып язарга, теләп язарга, гармун уйнагандай үзен тыңлап язарга мөмкинлек бирде.

Илдарны мин бәхетле шагыйрь дип саныйм. Аның шигърияте һәм сәхнә әсәрләре беренче башлап халык арасында киң танылды. Партияле халыкчан бу иҗатын язучылар җәмәгатьчелеге, партия өлкә комитеты һәм республикабыз хөкүмәте югары бәяләде. Аңа Татарстан АССРның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, республиканың Муса Җәлил исемендәге комсомол премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән югары исемнәр бирелде.

Мин аның туган җирендә — Башкортстанның Яңавыл районы Ямады авылында унбиш еллар элек ук булган идем. Шушы яклардан Әнгам Атнабаев, Сәҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов, Сәет Кальметовлар чыккан. Шушы төбәктә фәннәр докторы тәнкыйтьче Нил Юзеев һәм безнең халыкка киң танылган шагыйребез Илдар Юзеев туып үскән. Сүз дә юк, матур яклар. Елга-суларга, болыннарга, көмеш сулы күлләргә һәм карагайлы урманнарга бай яклар. Инде күбесе халкыбызның яраткан җырларына әверелгән, композиторлар көйгә салган «Яшь наратлар», «Янар чәчәк», «Төнбоек», «Яшьлек дустыма», «Урманнарга килдем», «Кайтам инде», «Бөркет турында җыр» һәм тагын башка бик күп җырларның беренче оеткысын Илдар Яңавыл якларында тапкандыр. Мин кистереп әйтмим, гөман кылып кына әйтәм. Чөнки инде менә утыз ел буена Илдар Казан каласына, Иделебезгә, Чулман буйларына гашыйк булып яши, бу бөек елгалар турында җырлар, шигырьләр, поэмалар иҗат итә.

* * *

Дөнья әдәбиятындагы олы төшенчәләр: кешенең тууы, үсүе, гашыйк булуы, рухи һәм физик көч җыйнавы, ахыр килеп, фаҗигасе — картлыгы һәм үлеме, гомер дигән зур юлда очраган сөенечләр һәм көенечләр, намус һәм вөҗдан, мәрхәмәтлелек, хезмәт ярату, ниһаять, дәрәҗәңне аңлау һәм үз-үзеңне яклый белү — болар барысы Илдар Юзеевның иҗатында (поэзиясендә һәм драматургиясендә) бик киң чагылыш таба. Шушы зур төшенчәләр елдан ел үсеп, камилләшеп кабатланалар. Кабатлануда логика бар: сабый бала белән үсмер егетнең яки ир уртасы абзый белән ак сакаллы зирәк картның дөньяны тануы бер түгел бит. Дөньяны тану ягыннан хәтта ир женесе белән хатын-кыз женесе дә аерыла. Кешелек кыйммәте дигән нәрсәне адәм баласы төрле чорында төрлечә үзләштерә. Әмма бәхәсләшеп булмый торган бер хакыйкать-

кә әйләнеп кайтабыз: адәм баласының күзе тумыштан нинди төстә булса, үлгәнче шул төстә кала, кара булса — кара, зәңгәр булса — зәңгәр. Гомер узу белән аңа акыллы сабырлык, уйчанлык, мәгънәлелек кенә өстәлә. Моның белән мин нәрсә әйтергә телим? Илдар Юзеев әдәбият мәйданына романтик булып килеп кергән иде, утыз ел поэзиягә турылыклы хезмәт иткәннән соң да романтик булып калды. Дөрес, аның яшьлек чорына, җитлегү чорына карап романтиклыгына да акыллы сабырлык, уйчанлык, тирәнлек өстәлде. Романтиклыкны ул беренче кумиры Такташтан алган иде, яшьлегендә аның хәтта кайбер алымнарын да кабатлаган иде, инде менә тәмам җитлегү чорында, поэтикасы Такташтан аерылган хәлдә дә, ул остазына турылыклы булып калды. Мин моны Илдар Юзеевның драматургиясенә, бигрәк тә соңгы елларда язган шигъри трагедияләренә карата әйтәм. Бу зур, көчле, яңа әсәрләр нигездә Һади Такташның «Җир уллары» трагедиясенә килеп тоташалар һәм алар, егерменче гасырның соңгы чирегендә вакыйгаларга, глобаль проблемаларга нигезләнеп, Такташның яңа шартларда яңача яңгыравы булып, Илдарның остазына турылыклы анты булып ишетеләләр.



*Илдар Юзеев балалар белән*

Бу очракта мин, әлбәттә, «Соңгы төн», һәм «Очты дөнья читлегеннән» трагедияләрен истә тотам. Әлеге киң колачлы, масштаблы, глобаль проблемаларны күтәргән шигъри трагедияләр иҗат ителгәнче, «Янар чәчәк», «Бөркетләр кыяга оялый», «Кыр казлары артыннан» кебек пьесалар иҗат ителде. Һәммәсе дә шигъри итеп уйланылган, Илдар Юзеев каләменә хас пьесалар иде алар. Гәрчә чәчмә итеп язылсалар да, күбесенчә гадәти көндәлек тормышны чагылдырсалар да, аларда күккә-биеккә омтылу, кеше күңеленең тибрәнешләре, җирдән сөйрәлеп бару белән, мал колы булып яшәүләр белән килешмәү, табигатьне олылау һәм аңар карата иң зур тойгылар саклау — гадәти шушы күренеш пьесаларында ук бар иде. Шуңа күрәдер, «Сандугачлар килгән безгә» исемле пьеса русчага да тәрҗемә ителеп, башка телләргә дә

кучеп, илебез театрлары буйлап китте. Аның хакында дистәдән артык мәкалә, рецензия басылды. Төрле өлкәләрдә, төрле телләрдә. Ләкин нинди генә шигъри әһәмле булмасыннар, нинди генә уңышка ирешмәсеннәр, болары әле — соңгы ике шигъри трагедиягә әзерлек чорлары иде. «Соңгы төн» белән «Очты дөнья читлегеннән» трагедияләре — татар совет поэзиясен, татар совет драматургиясен генә түгел, илебез әдәбиятын да күтәрерлек, аның өчен дә табыш булырлык әсәрләр. «Соңгы төн» шигъри трагедиясе «Соңгы сынау» поэмасына нигезләнеп язылган. Нигезләнеп, ләкин тәңгәл китереп түгел. «Соңгы сынау»да конкрет тарихи шәхес — фашизм тоткынлыгында җәзаланып үтерелгән Муса Җәлил алына иде. Аның Мефистофель белән, доктор Фаустның җанын алган кодрәтле зат белән бәхәскә керүе һәм җиңеп чыгуы рус әдәбиятының күренекле вәкиле, атаклы шагыйрь Василий Федоров тарафыннан югары бәяләнгән иде. Соңгы еллардагы поэзиягә борчылуын әйтсә дә, Валентин Устинов белән Илдар Юзеев минем күңелемдә совет поэзиясенең алга таба үсешенә зур өмет уяталар, дигән иде В. Федоров.

Инде менә «Соңгы сынау» драматик поэмасы шигъри трагедиягә әйләнде. Шагыйрь белән Мефистофель бәхәсе үзәккә алынып, анда Җир-Ананы саклау, Җир-Анага һәм безне тудырган аналарга карата тугрылык саклау, җанны сатмау кебек бик зур мәсьәләләр хәл ителә. «Очты дөнья читлегеннән» трагедиясе дә шундый ук планда. Биредә бөек Тукаебызга бәйләп, татар халкының тормышы, аның революциягә кадәрге язмышы, дөнья культурасы фонында безнең мәдәниятыбыз, туган җирнең һәм туган телнең кадерен белү, бөек гуманизм, халыклар дуслыгы, «рус белән сайрашып гомер итү»,— әлеге шигъри трагедияне киң сулышлы, глобаль проблемалы итәләр.

Илдар Юзеевның утыз еллык иҗатында бөек остазларының берсе булып халык иҗаты кала. Җырлар, мәкальләр, риваятьләр аның эпик әсәрләренә аеруча йогынты ясаганнар. Композитор Б. А. Асафьев озын, сузынкы җырларны «дөнья күләмендәге җыр культурасының иң югары этапларыннан берсе»,— дигән. Татар халкы культурасында «Карурманнарыбыз», «Иделләребез», «Олы юлның тузаннары», тагын әллә күпме җырларыбыз гасырлар буена җырланып килә. Бездә әле җырларның зурлыгы, тирәнлеге, зирәклеге тиешенчә ачылмаган. Әнә шул озын көйләребез, әнә шул озын җырларыбыз музыкаль җанлы Илдарга бик күп илһам биргән, аның шигъриятен тирәнәйткән.

«Соңгы төн» белән «Очты дөнья читлегеннән» шигъри трагедияләрендә Илдар Юзеев музыка, рәсем һәм башкару сәнгате өчен бик күп азык бирә. Җыр-моң да, балет та, драматик артистлар уены да — барысы да бар анда. Моңа тикле язучыларны, шагыйрь һәм драматургларны сәхнә сәнгате өчен әдәби материал бирмәүдә гаеплиләр иде. Инде менә халкыбызның ике бөек улы — Тукай һәм Җәлилә хакында, халыкның үзе һәм культурасы хакында лаеклы әсәрләр иҗат ителде. Тукайның йөз еллыгына, Мусаның сиксән еллыгына безнең театрларыбыз, телевидениебез, радиобыз бу әсәрләрне нык файдаланырлар, сәхнә телендә яңгыратырлар дип ышаныйк. Әдипләрне дөньяга чыгарырлык зур әсәрләр бирергә чакыручы тәнкыйтьчеләребез дә әлеге ике шигъри трагедиягә карата иркенләбрәк, төплерәк итеп үз фикерләрен әйтерләр.

Илдар Юзеевны, беренче зур юбилеен — илле яшьләгән җитди әсәрләр, вакыйга булырлык әсәрләр язып каршы алуы белән котлыйм һәм аның әле алга таба да җитди эшләячәгенә нык ышанам. Ул тормыш эчендә кайный, дөнья әдәбиятын, илебез халыклары әдәбиятын яхшы белә, кайчандыр үзен олы юлга алып чыккан өлкән шагыйрьләребез үрнәгендә яшь каләмнәр белән зур һәм нәтиҗәле эш алып бара.

## Рәүф Игъламов

# ХАКЫЙКАТЬНЕ ЭЗЛӘҮ ЮЛЫННАН

Без ул әсәрнең дөньяга килүен көтә идек инде.

Илдар Юзеев моңарчы дистәдән артык сәхнә әсәре иҗат итеп, үзен кеше күңелендәге иң нечкә тибрәнешләргә сизгер лирик, трагедия һәм комедия остасы буларак танытты. «Кыр казлары артыннан» һәм «Сандугачлар килгән безгә», «Онытылмас бәет» һәм «Соңгы төн», «Бәхетемнән узып барышлый» драматик поэмасы һәм «Кайтмый калсам, көтәрсеңме?» комедиясе... Ниһаять, Тукай образын терелткән шигъри трагедия — «Очты дөнья читлегеннән...» Шигырь һәм проза белән язылган, жанр һәм сурәтләү алымнары белән бер-берсенә һич охшамаган әсәрләр... Автор безне тормышның төрле катламнарына, авыл һәм шәһәр йортларына, төрле һөнәр, төрле буын кешеләренең катлаулы язмышына алып керә. Әлеге әсәрләрдә бүгенге көн күренешләренә үткәндәгеләр күләгәсе төшкәндә дә, бу — безнең чордан әллә ни ераклашу түгел,— (әйтик, Тукай замандашлары белән без әле дә бергә яшибез)— алар йөзендә буыннар, чорлар очраша. Кыскасы, әлегә кадәр Юзеев пьесаларының сюжет вакыты гасыр башыннан да элгәрерәк дәверләргә чигенгәне юк иде әле. Ләкин андый әсәр дөньяга килергә тиеш иде. Шигъри иҗатында гасырлар агышына, мәңгелек таш диварлар авазына колак салган, мәңгелек сораулар турында уйланган әдипнең драматургия өлкәсендә, сәхнә теле белән Мәңгелеккә мөрәҗәгать итүен көтә идек без.

«Мәңгелек белән очрашу» дип исемләнгән, жанр ягыннан «фантастик трагедия» дип билгеләнгән бу яңа әсәр — Илдар Юзеев иҗатындагы төп тема һәм мотивларның табигый үстерелеше һәм закончалыклы дәвамы. Хәлбуки шушы табигый күренешнең һич тә көтелмәгән бер ягы бар: пьесада сурәтләнгән вакыйгаларның урыны һәм вакыты да, Атлант, Икар, Зевс, Аид, Афина, Анан кебек персонажлары да драматург иҗатында беренче тапкыр очрый. И. Юзеев борынгы греклар хыялында туган һәм соңыннан антик чорның героик эпосында һәм трагедияләрендә мәңгеләштерелгән мифологик геройларга мәйдан бирә. «Ә бу нигә кирәк? Миф каһарманнарының бүгенге көн мәшәкатьләренә нинди кагылышы бар?!» — дип куярга мөмкин кайберәүләр. Билгеле, бу беркатлы сорауга җавап бирүе кыен түгел: антик чор сюжетларына һәм образларына мөрәҗәгать итү элек тә булган, ә егерменче гасыр, ул мифларга яңа яңгыраш биреп, заман төсмерләрен чагылдыручы интеллектуаль драма иҗат итте. Анысы шулай, тик менә ни хикмәттер, соңгы елларда безнең драматурглар әлегедәй сюжетлардан шактый еш файдалана башладылар шикелле. Юстинас Марцинкявичюсның «Прометей турында поэма»сын, Мостай Кәримнең «Ташлама утны, Прометей!» трагедиясен искә төшерик... Илдар Юзеев әсәренең төп үзенчәлеге, башкалардан аерып торган сыйфатлары нәрсәдә соң?

Иң беренче чиратта, аның жанр ягыннан, трагедия буларак аныклыгында, дип әйтәсе килә. Белгәнебезчә, трагедиядә бөтен вакыйгалар һәм характерлар киселеше уңай герой аша ачыла, бу жанрның төп пружинасы абсолютлаштырылган үзәк геройга, аның фикерләвенә, күңел хәрәкәтенә корыла. Үзәк герой итеп Прометейның алынуы ук трагедиягә ныклы нигез бирсә дә, асылда әлеге әсәрләрнең жанр ягыннан анык ук була алмавы гаҗәп бит. Эш нәрсәдә? Авторларның полифоник төзелеш принцибына йөз тотуында, ягъни «Прометей турында поэма» һәм «Ташлама утны, Прометей!» трагедияләрендә төп партияне башка темалар озатып баруында, вакыт-вакыт аны бөтенләй читкә кысрыклап чыгаргалавында. Бу сыйфат бигрәк тә Марцинкявичюс әсәрендә ярылып ята. Фикеребезне раслау өчен Марцинкявичюс иҗатына багышланган төпле һәм зур хезмәттән бер өземтә китереп үтү дә җитәр: «Тышкы һәм эчке хәрәкәт параллельлеге...— дип яза Й. Ланкутис,— «Прометей турында поэма»да аерым бер сыйфатка ия: ул бирелә зур стилистик контрастлар белән бәйләнгән. Шартлы рәвештә Зевс хоры дип атарга мөмкин булган персонажлар төркеме ачык

сатирик буяулар белән ясалган. Прометей белән Ио исемле кыз дуэтында героик ноталар яңгырый, урыны-урыны белән аларга хәтта мелодраматик төсмерләр кушылып китә...»[1].

Хәзер, әйдәгез, «Мәңгелек белән очрашу» әсәрендәге персонажлар белән якынлнрак танышуны дәвам итик. Пьесаның үзәк герое — Атлант. Аның Зевс, Арей, Аидлар белән бер мохитта, бер «компаниядә» пәйда булуы ук көтелмәгәнчәрәк. Югарыда телгә алынган әсәрләрдә, мәсәлән, Прометей борынгы мифта тасвирланган кыяфәтен үзгәртми һәм, гомумән, безнең аңа мөнәсәбәтебезне билгеләүдә антик әдәбият буенча таныш образ хәлиткеч роль уйный. Атлантка исә укучы анык, әзер мөнәсәбәттә түгел, бу геройга укучының ышанычын яулап аласы бар әле. Прометей үзенең героик омтылышы белән җәлеп итсә, Атлант — әлләни күзгә чалынмый гына үз иңенә төшкән авыр хезмәтне башкаручы — күк гөмбәзен күтәреп торучы.

Юзеев атлантларны — тырыш һәм көчле, әмма гади кешеләрне — герой дәрәҗәсенә күтәрә. Аның шигъри дөньясына сәнгатьчә бөтенләе әнә шуннан килә. Юзеев театрының идея-художество үзәге дә шунда. «Сандугачлар килгән безгә» әсәрендәге урман каравылчысы — «тимер кеше»ләргә каршы тигезсез көрәшкә ташланучы Хәмзин — шул Атлантларның берсе түгелмени? Яисә — «Кыр казлары артыннан» пьесасындагы археолог Халик Бикташевны, «Онытылмас бәет»тәге Шаһинурны искә төшерик... И. Юзеев пьесаларында җиңел язмышлы кешеләр юк. Хәмзин һәм Тукайны үлем алып китте, Шаһинур белән Халикны шәхси тормыш, гаилә бәхете читләтеп үтә. «Бәхетемнән узып барышлый» пьесасындагы рәссам Айтуар да яраткан кешесенең үзен аңламавыннан газаплана. Әйе, рухи гармония, гүзәллек һәм ялгышлык өчен көрәш җиңел түгел. Вөҗдан кушуы буенча гына яшәү, зур югалтулар кичергәндә дә үз принципларыңнан баш тартмау — авыр. Бу көрәш — яңадан-яңа корбаннар сорый.

«Мәңгелек белән очрашу» трагедиясенең баш герое һәлакәтенә игътибар итик. Аллалар җәзасыннан котылып кала Атлант, ә менә җирдә посып яткан туп шартлавыннан харап була. Кемдер бит шушы үлем коралын эшләп чыгарган, кемдер сугыш уты кабызып җибәргән... Ни өчен соң әле дөньяда золым өскә чыга, яхшы кешеләр корбан була? Җир йөзендә әшәке бәндәләр күбрәк булгангамы? Юк, әлбәттә. Кешелеклелекнең киң күңелле, тиз ярлыкаучан булуында хикмәт. Залимлек, усаллык шушы — киң күңелле мохиттан файдаланып, ваемсызларны, сыек буынлыларны, теләсә кем белән килешергә әзер торучыларны үз сафларына туплый. Анан — битараф, Зевс — гамьсез, Аид — ваемсыз. һәм менә алар инде Арей тырнагында, Арей ихтыярына буйсына башлыйлар.

Илдар Юзеев трагедиясендә аллалар, нигездә, үз традицион сурәтләрен саклый. Зевс һәрвакыттагыча «күкләр күкрәтә», Олимп тавында баш алла булуын онытмый. Язмыш алласы Анан, җир асты хуҗасы Аид, терекләкне кырып бетерү дәртеннән шашынган сугыш алласы Арей... Атлантка уртак нәфрәт нигезендә берләшкәнче, алар һәркайсы үз юлында, үз эшен башкарып йөри бирә. Ниһаять, трагедиядә үзенең мифологик сурәтенә туры килеп бетмәгән бер зат пәйда була — Афина.

Афина — язучының фикерләү үзенчәлеген ачарга ярдәм итүче образ. Әйтик, Зевс, Арей, Аид һәм Ананнарны пьесада катнаштыруның максаты болай да аңлашылса кирәк. Аларның бирედә булуы урынлы да, табигый да. Ә менә Афинага килгәндә... Ниндидер сөйкемсез сөяге бар шул образның. Хәтерләргә тырышып карыйк: борын заманнарда яисә бүген кайсы драматургның нинди әсәрендә бу легендар образ үзенә лаек урын ала алды икән?.. Фон рәвешендә түгел, әлбәттә,— тулы драматик эчтәлеккә ия хәлдә? Юк, андый әсәр искә төшми. Хис-дәрт утында янудан мәхрүм, иминлек һәм гармониягә омтылучан Афина драматурглар игътибарына лаек була алмаган.

Мәсәлән, Мостай Кәрим әсәрендәге Прометейга гашыйк алиһә—гүзәл Афротида. Прометей үзе Җир кызы Агазияне ярата да, пьесада нәкъ менә Афротида образы килеп керүе кызыклы. Илдар Юзеев әсәрендә исә гүзәл Афродитага урын юк, аны Афина җәлеп итә. Ни сәбәпле? Пьесада бит мәхәббәт турында да сүз бара. Ни өчен Афродита түгел, ә нәкъ менә Афина үзәккә куелган?

Бу сорау үзе үк безне драматургның иҗади уй-ниятенә һәм, димәк, аның поэтикасы серләренә якынайта.

---

[1] Ланкутис П. Поэтический мир Юстинаса Марцинкявичюса. М., 1980, 224—225 битләр.

Махсус искәрмәсез дә аңлашыла: һәр образның легендар тышчасы артында замандашларыбыз һәм заман мәшәкатьләре-гаме абайланып тора. Атлант — дөньяның ачысын-төчесен күп татыган кешеләрнең берсе, һөнәре белән дә әллә ни аерылып тормый, ул — гади бер археолог. Ә менә аның улы Икар — гадәттән тыш һөнәр иясе — космонавт. Афродита, горур Прометейны яраткан кебек үк, Икарга да гашыйк була алыр иде. Ләкин пьесаның төп каһарманы Икар түгел. Аннары, миф традициясе буенча, Афродита — Арейның мәгъшукасы. Пьесада исә Арей — Атлантка каршы чыгучы, аның һәлакәтен теләүчеләрнең берсе. Шулай итеп, Афродитаны пьесага кертү, аның, әйтик, Икарга — Атлантның улына мәхәббәтен тасвирлау Илдар Юзеев иҗатына хас булмаган, четерекле ситуациягә алып килер иде. Афродитаның мәгълүм талымсызлыгы (әле генә залим һәм җаһил куенында иде, инде гаделлек һәм тынычлык көрәшчесенә гашыйк имеш) — драматургны аннан читләштергән, гайрәтен чигергән төп кимчелек әнә шунда. Чын мәхәббәт өчен күңелләр берлеге, дөньяга караш уртаклыгы гына нигез була ала, дип раслый Илдар Юзеев. Аның бөтен иҗатын әнә шул фикер яктыртып тора. Тән һәм җан кушылуы исә тормышта бик сирәк күренеш. Шуңа күрә Юзеев пьесаларындагы геройлар еш кына шәхси бәхеттән мәхрүм булалар. Шуңа күрә аның эстетик принциплары геройның әхлакый сафлыгын калку итеп куйган Эсхил трагедияләренә якынрак тора.

Тарихтан билгеле булганча, Эсхил театры гражданлык тойгыларын алга сөрә, ачыктан-ачык гыйбрәтле һәм тәрбия мәктәбе булырга омтыла. Аның мәрмәрдән ясалган кебек нык, эре геройлары бер генә кайнар хис — җәмгыятькә хезмәт итү теләге белән генә яналар. Беренче трагедияләр авторының иҗаты тагын шул яктан кызыклы: ул Афина каласының демократик шартларында, иҗтимагый тормыш һәм культура чәчәк ату белән бергә, афиналыларның рухи үсешенә киң мөмкинлекләр ачылган чорда мәйданга килә.

Афина «Мәңгелек белән очрашу»да нәкъ Эсхилча үзгәреш-эволюция кичерә: ул югары әхлак принциплары таләп иткәнчә, Атлантны яклап, аллаларга каршы көрәшкә чыга, мәхәббәте хакына барча сынауларга һәм үлемгә әзер тора. Афинаның үз-үзен тотышы һич тә көтелмәгәнчә, әмма гайре табигый түгел: бу халәт аның рухи-әхлакый асылына туры килә. Бөтен әйләнә-тирәне мәкерлеләр, астан ут йөртүчеләр, куркаклар урап алганда, Вөҗдан янында Мәхәббәт булырга тиеш. Кешеләр күңелендәге яктылыкны яклап чыгарлык каһарманнар кирәк, көрәш һәм яу кирәк. Ул көрәш көн саен, сәгать саен бара: шифаханә палатасында, авылдашлар арасында, Олимп тавында...

Илдар Юзеев драматургиясенең уңай персонажларында автор идеалы бөтен тулылыгы белән гәүдәләнә. Әдәби-тарихи традицияләр белән бәгланыш турында сүзне дәвам иткәндә, рухи-әхлакый идеалга омтылыш ягыннан бу әсәрләрнең янә бер кат «трагедия аталары»н искә төшерүен әйтергә кирәк. «Еврипид кешеләрне чынбарлыкта булганынча итеп тасвирлый», дип язган Аристотель, мәсәлән, төп эстетик принциплары ягыннан Эсхилга якын торган Софоклның, киресенчә, кешеләрне нинди булырга тиешлекләрен күздә тотып сурәтләвен билгеләп үтә.

«Нинди булырга тиешлекләрен күздә тотып». Бу формула безне һәр заманда җәмгыятьнең сәламәт көчләрен тәрбияләүгә хезмәт итеп килүче драматургия сәнгатенең чишмә башына алып кайта. Шул ук вакытта әле генә телгә алынган үзенчәлек чынбарлыкка романтик караш белән дә бәйләнгән. Юзеев иҗатына да романтиклык чит түгел, әлбәттә. Ләкин бу романтик сулыш — аның әсәрләренең стилендә, ягъни романтик драмалар рухына йөз тотуында түгел. Юзеев пьесалары үзләренең асылы белән реалистик. Аның реалистик драматургиясенә романтик пафос әхлакый максатның эчтәлеге белән бәйле, рух-әхлак сафлыгына омтылу рәвешендә килеп керә. Ул сафлыкны әдип тыйнак, гади хезмәт кешеләре йөзендә гәүдәләндерә, халыкның тулы хокуклы вәкилләре исеменнән раслый. Алар — ил иңенә төшкән шатлыкны да, кайгыны да бергәләп күтәрешкән кешеләр. Фронтовик Хәмзин («Сандугачлар килгән «безгә»). Фронтовиклар Шаһинур («Онытылмас бәет») һәм Гаффан («Бәхетемнән узып барышлый»). Сугышта катнашырга өлгермәгән буын вәкилләренең әхлакый өлгергәнлеге исә шактый дәрәҗәдә әтиләр истәлегенә мөнәсәбәт, әтиләр эшенә тугрылыклылык белән билгеләнә. Гомумән, Юзеевның барлык әсәрләрендә хәтер—поэтик рефрен булып яңгырый. Адәм баласының кешелеклелек дәрәҗәсен билгеләүдә, аның

асылын тануда Хәтер — төп башлангыч, төп таяну ноктасы. Аңа таянып, Ватан, туган җир, Ана төшенчәләре күтәрелә. Хәтер образын үзәккә куеп, Юзеев халыкның тирән рухи көченә, киләчәгенә ышануын раслый. Чөнки, П. А. Вяземскийның мәгълүм сүзләре белән әйткәндә, «ирекле булмаган һәм аңа өметләнмәгән дә халыклар беркайчан да чын-чынлап тарих белән кызыксынмыйлар, кайсыберләре хәтта үткән вакыйгалар хатирәсен дә сакламый...»

«Кыр казлары артыннан» пьесасында, мәсәлән, борынгы бабайларның көмеш битлеге ике бертуганның арасы тәмам бозылуга сәбәпче була. Әмма... битлектә генәме хикмәт? Битлек бирелә бер символ гына. Хәтер, Бурыч, Хаклык белән Ялган, Туклык, Оятсызлык арасында нинди уртаклык булырга мөмкин?

Әлбәттә, тормышта бу төшенчәләр аерым, саф көе генә яши алмый. Чынбарлыкка тугрылыкны саклаган хәлдә, сәнгать тә үз категорияләренә, аерым алганда «уңай герой» билгеләмәсенә төзәтмәләр кертә тора. Драматург Юзеев та, әйтик, дөньяның мәңгелек хәрәкәтенә күз йома, еллар буе бер үк сыйфатларны яклап, бер төрле үк кимчелекләрне тәнкыйтьләвен дәвам итә, дип раслау гадел булмас иде. Кешегә, аның фикер сөрешенә мөнәсәбәт тотрыклы сакланып килгән тәгъдирдә дә, бу доминантаның киң һәм күптөрле драматик мәгънәләрдә чагылуын күрми мөмкин түгел.


*Илдар Юзеев һәм скульптор Васил Маликов*

Катып калган төшенчәләр белән эш итүче кешегә шул ук «Онытылмас бәет»нең герое бәхәскә урын калдыра торган булып тоелырга ихтимал. Шаһинур кайчандыр халык акчасын урлап качкан, утыз елдан артык гомер үткәч кайтып төшкән бәндәне танырга тиеш. Ул качак, карынындагы баласы белән бергә ташлап калдырган сөйгәнен эзләп, аны күрергә дип һәм шушы вакыт эчендә җыйган малын, арткан акчасын аңа тапшырырга теләп кайткан. Бу кешене кызганырга мөмкин: сөйгәненең бала тапканда үлгәнлеген белеп, инде ул баланы үсеп, җиткән кыз анасы булуын күреп, ничек тетрәнә ул! Бу кешене кызганасы килә башлый: ул беркайчан да бәхетле булмаган, инде тәүбәгә килгән, аңа хәзер байлыгына ия булып калырлык варислардан кала берни дә кирәкми. Ниһаять, мескен карт вөҗдан газабын кичерергә кайткан, ул үзен тануларын, аның кулыннан варислыкны алуларын тели. Ә Шаһинур — аның баласын тәрбияләп үстергән, авылның йөз аклыгы булган Шаһинур, картны танымамышка салыша. Гаделлекме бу? Дөреслекне яшерергә азаплану түгелме? Әйе, шул мизгелдә дөреслеккә каршы килә Шаһинур. Тәрбияләп үстергән кызларыннан аерыласы килми. Ләкин аның гөнаһсыз ялганы авыр тормыш сабаклары, ятимнәр күз яше белән аклана, бөтен авыл күз алдында үткән намуслы гомер мөһере белән раслана. Ул — сөйгәнен язмыш иркенә ташлап, авылдашларын алдап качкан бәндәнең соң мизгелдәге хак сүзеннән дөресрәк ялган.

Әлегәчә без Илдар Юзеев драматургиясенең ике зур, мөһим сыйфатын ачыкладык һәм билгеләп үттек: тарих һәм хәтер сабаклары аша заман күренешләрен аңларга омтылу аларның беренчесе булса, икенчесе — кешенең рухи һәм әхлакый дәрәҗәсен бәяләгәндә үзенчәлекле иҗади чишелешләр табу осталыгы. Татар халкының йөрәк парәсе булган Тукай-шагыйрь хакындагы «Очты дөнья читлегеннән...» трагедиясе әнә шул ике көчле агымның бергә кушылган төшендә туган.

Рәхимсез дөнья куенында калган бер ятим, изелгән, кимсетелгән милләт улы, егерме җиде яшендә үпкә чиреннән сулган бөек шагыйрь... Биографик тегәллек, чор күренешләренә игътибар сизелеп тора. Ләкин алар Тукай образын социаль-тарихи яктан гәүдәләндерүдә һичшиксез зур роль уйнасалар да, бөтен пьесаның һәм баш геройның тарихилыгы турында тулы мәгълүмат бирмиләр әле. Дөрес: буржуй-мещаннар дөньясы шагыйрьне үзенә кол итәргә, үз кубызына биетергә азапланган, бу ни-

ятләре барып чыкмагач, «киребеткән» Тукайдан йөз чөергән һәм, асылда, аның һәлакәтен якынайткан... Әгәр Юзеев шул хакта гына сөйләсә, безнең алда тарихи драма барлыкка килгән булыр иде, бәлки. Байгуралар, милләтчеләр, карагруһчылар белән тигезсез көрәштә һәлак булган талантны кызгану бүгенге көн өчен артык зур һәм яңа хис-фикер чыганагы була алыр иде микән?.. Тукайны мескен итеп түгел, җиңүче итеп, горур итеп күрсәте килә. Ул шундый булырга тиеш тә. Аның ачык һәм астыртын дошманнары, үлеменә сәбәпче булган шартлар күптән инде тарих чүплегенә ташланган, ә Тукай — халык бәгыреннән тибеп чыккан моң — безнең белән яшь, безнең оныкларыбызга да мирас булып калачак.

Илдар Юзеев шагыйрь шәхесен аның иҗатын тирәнтен өйрәнү һәм бербөтен итеп күз алдына китерү аша ачарга омтыла. Тукай шигъриятенең күпмәгънәле, катлаулы ассоциацияләрен, акыл белән генә түгел, йөрәк белән аңлауны таләп итүче образларын бүгенге көн яссылыгына күчерү — пьесаның чын тарихилыгы менә кайда! «Очты дөнья читлегеннән...» трагедиясе Тукай поэзиясенең бөеклеген, яшәүчәнлеген тагын бер кат раслый, аның, чорлар аша үтеп, яңа буыннар тәҗрибәсенә кушылып, киләчәк заманнарга да хезмәт итү көчен гәүдәләндерә.

Драматург бу трагедиясендә Тукай шигъриятендәге тыгыз төшле образларның берсенә — Кояшка мөрәҗәгать итә.

**Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт;**
**Бу үлек вөҗданны җанландыр, җылың берлән җылыт!**
**Мин адаштым, тугры юлга ул торып күндермәсә,**
**Дүрт ягым гыйсъян уты — сүнмәс һич, ул сүндермәсә.**

Тукайның бу юллары әсәр нигезенә салынган киң метафора булып ачыла. «Өмид» шигыре үзе трагедиядә турыдан-туры яңгырамый, әмма аның интонацияләре төрле өземтәләр рәвешендә китерелгән башка шигырьләрнең аһәңендә сизелә. Пьесаның иҗтимагый-тарихи умырткасын «Китмибез!», «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» кебек шигырьләр тәшкил итә.

Юзеев өчен иң мөһиме — шагыйрьнең тарихи йөзен күз алдына бастырудан да бигрәк, аның иҗаты белән безнең чор, бәхет, чынлык, вөҗдан, бурыч кебек төшенчәләрне безнең ничек аңлавыбыз арасындагы аваздашлыкны эзләү. Һәм шунысы гаҗәп, Тукай әйтерсең лә безнең күңелдәге уйны укып бара, безнең тарихи һәм иҗтимагый тәҗрибә дә, безнең чор катлаулыгы да, аның иҗатының сәнгатьчә көчен, анда күтәрелгән яшәеш проблемаларының олылыгын һәм мөһимлеген кире кага алмый. Шагыйрьнең:

**Мин сыялмыйм андый шартлар, фани дөнья вактына,**
**Башны бөксәм, зур җинаятьтер, олуг җан хаккына.**
**Ашкынамын мин әбәт бетмәс урынга, мәңгегә,**
**Мәңгелеккә — мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!**
**Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;**
**Бу кояш сүнсен, җиренә мин Кояш булмак телим,**

— дигән юлларын искә төшереп әдәбият белгече Йолдыз Нигъмәтуллина: «Бу мисал яктысында трагедиянең «Очты дөнья читлегеннән...» дигән исеме дә яңа мәгънәгә ия була. Образ һәм идеяләрне турыдан-туры кабул иткәндә, ул Г. Тукайны изелүдән һәм рухи ирексезлектән үлем коткарды дигәнне аңлатса, бирегә, бу очракта ул, өстәмә һәм, мөгаен төп мәгънәсе белән ачыла, ягъни шагыйрь иҗаты һәм шәхесенең әһәмияте чор кысаларын үтеп чыга, башка — гомумкешелек колачы белән исәпләнә,— дип яза. Нәкъ әнә шуңа күрә дә, Й. Нигъмәтуллинаның тулаем алганда тирән эчтәлекле әлеге мәкаләсендә пьесадагы бер мотивны аңлату белән килешәсе килми. «Татар халкы тарихының хәлиткеч борылыш моментында,— дип яза ул,— авыр, газаплы юл үтеп дереслек эзләгән Тукай күптәрле «социаль» авазлар арасыннан революционер-марксистлар тавышын ишетә алган, бары вакытсыз үлем генә аңа пролетариат поэзиясенең эстетик идеаллары дәрәҗәсенә ирешергә комачаулады». Түксан тугыз очракта мондый нәтиҗәне кире кагып булмый. Бары бер очракта гына

ул — ялгыш юлдан китү булып аңлашыла. Юзеев әсәрендәге романтик Тукайга карата ялгыш ул. Әлеге трагедиянең тарих һәм заман бәйләнешләреннән гыйбарәт структурасына мөнәсәбәттә ялгыш. «Пролетариат поэзиясенең эстетик идеаллары дәрәҗәсенә» ирешергә өлгермичә иртә өзелгән шагыйрь гомере — тулаем пьесаның тарихи-конкрет яссылыгында ята, әлбәттә. Ләкин Уралчы дип исемләнгән персонаж сүзләре белән билгеләнгән юл («Юл бер генә: капиталга һәм патшага туп ату!») бөек шагыйрь өчен кәтелмәгән, күңел күзе күрмәслек нәрсә булырга мөмкин түгел. Киресенчә, без биредә Уралчының фикер сәреше, дөньяга карашы билгеле бер чор белән чикләнгән булуын күрәбез.

**Шундый чор килер Рәсәйгә —**
**Бар җиһан күреп торыр:**
**Золым, ачлык, ялангачлык,**
**Булмагандай, онытылыр,**

— дип хыяллана ул. Ә шагыйрь шул хакта: «Муллык... Байлык... Тормыш ничек хәл итәр бу сорауны?» — дип уйлана. Аны матди яктан бөтенлек, туклыкка ирешү рухи ярлылануга, рухи хәерчелеккә юл ача күрмәсен дип шикләнү борчый.

**Ачлыкны күтәргән халык**
**Үтәрме ул сынауны!..**

Тукай белән Уралчы арасындагы сөйләшү — бер-берсен яхшы аңлаучы фикердәшләр бәхәсе. Бу бәхәснең асылы шунда, аларның берсе киләчәкне гомум бәхет кояшы белән яктыртылган итеп күрә, ә икенчесе шул Кояш яктысының барча күңелләрне эчтән балкытуын да тели. Кешелек бәхетенә һәр шәхеснең бәхетле итеп кенә ирешеп була. Юзеев трагедиясенең бердәнбер романтик персонажы кешелек дөньясының әнә шундый диалектик яктан катлаулы үсеш юлын алдан күрә кебек.

Илдар Юзеев драматургиясе социалистик реализм әдәбиятындагы трагиклык категориясенең үзенчәлеген аңлау юлында зур әһәмияткә ия. Әдип тормышка мәдхия җырлаучы героиканы кешенең җиңүле гамәлләреннән, казанышларыннан гына түгел, чәбәләнеп беткән яшәеш каршылыкларыннан да эзләп таба. Ул иҗат иткән пьеса сәхифәләреннән, аның әсәре буенча спектакль уйнаган сәхнәләрдән безгә тормыш хакыйкате — зур газаплар кичереп табылган Хакыйкать үзе мөрәҗәгать итә.

Ринат Мөхәммәдиев

# ТОРМЫШ ДӘВАМ ИТӘ

Аның һәр яңа әсәрен укыганда, пьесаларындагы геройлар белән театр сәхнәләрендә очрашканда, күңелгә һаман бер уй, бер сорау килә: «Хикмәт нидә?» Чынлап та, җылы һәм якты хисләр, кешелекле дөньяви уй-фикерләр уяткан бу иҗатның хикмәте нидә? Укучыны, тамашачыны тартып торучы, режиссер һәм актерларны илһамландыручы көч чыганагы кайда?

ТЕМАДАМЫ?.. Әйе, тема дигәннән, Т. Миңнуллин, кагыйдә буларак, заманча һәм актуаль өлкәгә, җитди тормыш материалына мөрәҗәгать итә. Аның иҗатында әлегәчә укучыны һәм тамашачыны битараф калдырган тема күтәрелмәде — моны һич икеләнми расларга мөмкин. Тарихка мөрәҗәгать итәме («Канкай углы Бәхтияр»), бүгенге чордашлары тормышынамы («Дуслар җыелган җирдә», «Ир-егетләр» һ. б.), ул һәр очракта көндәлек мәшәкатьләр белән яшәгән тамашачының күңелен тиз арада яулап ала, аның рухиятен үз дулкынына көйли.

Гадәттә, һәр әдипнең үзенә аеруча якын булып, иҗатында эзлекле рәвештә үстерә, дәвам итә килгән бер темасы була. Ә менә Т. Миңнуллин иҗатында бу хәл кабатланмый. Әйтерсең, күңеленә аеруча үз булган, таныш һәм якын булган теманы ул әле эзли генә. Таба һәм тапты дигәндә тагын яңа, әле моңарчы иҗатында бөтенләй күрелмәгән өлкәгә мөрәҗәгать итеп эзләнә башлый. Моны драматург иҗатының соңгы — җитлеккән чоры мисалында да күрергә мөмкин. Әйтик, «Ай булмаса, йолдыз бар»да ул кеше, аерым алганда татар хатынының, рухи ныклыгын күрсәтүне бурычы санаса, «Әлдермештән Әлмәндәр»дә тормыш һәм җирдә яшәүнең бөеклегенә, алыштыргысыз матурлыгына соклана. Ул да түгел, «Моңлы бер җыр» публицистик драмасында туган илгә бирелгәнлек, патриотизм хисләрен сәнгатьчә гәүдәләндерүгә алына һәм чираттагы әсәре «Монда тудык, монда үстек»тә илгә 2 миллиард тонна нефть биргән якташларының рухи эзләнүләре һәм хезмәттәге батырлыклары тасвирлана.

Шул рәвешле, драматургның һәр яңа әсәре яңа тормыш материалы, яңа бер өлкәне күтәреп чыга, яңа проблемалар, яңа конфликтлар, һәм иҗатында моңарчы күренмәгән яңа сәнгать чаралары... Димәк, хикмәт темада булып чыга түгелме? Юк, дип әйтергә нигез юк. Әйе, дисәк, җавап чамадан тыш беркатлы килеп чыгар иде. Чөнки әсәрләрендә күтәрелгән тема, тормыш материалы һәм проблемаларның әһәмияте ни дәрәҗәдә генә җитди булмасын, Т. Миңнуллин драматургиясенең әһәмиятен һәм популярлыгын әлеге кысаларда чикләп аңлату хакыйкатьтән ерак торыр иде.

Драматургның җирдә яшәү мәгънәсе, кешелеклелек, туган илгә һәм тормышка мәхәббәт кебек мәңгелек проблемаларга мөрәҗәгать итүе табигый. Чөнки ул шул проблемаларның тормыш ваклыкларыннан өстенлеген раслаган җәмгыятьтә, шул проблемалар һәм темаларның конкрет гәүдәләнеше, кабатланмас үрнәге булган кешеләр арасында яши. Әлеге тема һәм проблемаларда — аның үз язмышы, яшәү рәвеше, тормышында куелган төп максаты. Аларны өйрәнү, аерып алу яисә безнең алга китереп кую өчен Т. Миңнуллинга нинди хыялга бирелергә, җәннәт бакча-

ларына кереп адашырга да кирәк булмаган. Дөньяга ул туган авылындагы әти-әнисе салган гади өйнең киереп ачылган тәрәзәләреннән карый төсле. Һәм ул анда очраклы бер кунак кына түгел, үз кеше. Ә ата-баба корган йортларның тәрәзәләре көннең көн буена якты дөньяга, шагыйрь әйтмешли, «гел кояшка карый».

Әйтик, шул кояшлы тәрәзә төбендә үскән иң матур гөлләрнең берсе — Т. Миңнуллин иҗатын бизәп торучы олы масштаблы әсәрләрдән «Әлдермештән Әлмәндәр»гә игътибар итик. Темасы — җирдә яшәүнең бөеклеге, алыштыргысыз матурлыгын раслаудан гыйбарәт дидек. Автор әсәрен башлаганда ук, баш ватып азапланмагыз дигәндәй, аның күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган көр күңелле авылдашларына багышланган булуын искәртә. Әсәр, нәкъ без уйлаганча, балачактан үз тәрәзәләреннән күреп, сокланып үскән авыл картларына багышлана.

Хуш, багышлансын да ди. Авылдаш картларына багышлансын. Әмма җирдә яшәү ямен раслаган әсәр өчен 92 яшьлек бабайга караганда 18 яшьлек кыз образына мөрәҗәгать итү урынлы булмас идеме икән. Шуның өстенә язарга алынган әсәренең жанры да комедия — шаяру, көлү, елмаюсыз булмаячак, димәк. Картлыктан көлү булып чыкмасмы? Яшьлекнең үзен көлдергәндә кулайрак түгел идеме? Шул рәвешле сорауларны дистәләп күтәрергә, автор алдына кабыргасы белән куярга мөмкин булыр иде. Хәлбуки әсәрнең үзен укыган, сәхнәдә караган кеше бу хакта онытып өлгерә. Алай гына да түгел, әлеге бәйләнчек уй һәм шикләр аның башына да килеп карамый. Чөнки укыганы ямсә күргәне картлык һәм дөньядан зарлану түгел, әйттереп, бар нәрсәгә сокланып, тәмен белеп яшәүче якташыбыз турында.

Әмма ләкин 18 яшьлек кыз образында да әлеге күңел көрлеге һәм оптимизмны тасвирлап, күрсәтеп була иде түгелме? Бәхәссез! Шулай да шактый гына югалтуларга да дучар ителгән булыр иде тема. Яшь кешенең канатланып, рухланып яшәве ул болай да табигый, башкача була да алмый кебек. Ә инде Туган ил һәм халык белән үз язмышын уртак күреп, революция һәм колхозлашу чорларын үткән, ике сугыштан җиңүче булып кайткан, никә кат үлем белән якалашып та бирешмәгән, күпме генә югалтулар кичермәсен, барыбер бүгенге көненә сөенеп һәм киләчәгенә өмет әзми җырлап-биеп яшәгән ил карты белән очрашу бермә-бер үтемлерәк һәм гыйбрәтлерәк. Гайре табигый булган шартларда автор бүгенге татар авылының гадәти һәм, нигездә, типик булган аксакалы образын тудыра.

Шунда ук, Әлмәндәр образының тагы бер гыйбрәтле ягына күз салу урынлы булыр. Без әдәбият һәм сәнгать әсәрләрендә татар карты һәм татар карчыкларын күрсәтүдә штампка күнегеп бара идек. Әби булса — яулык чите белән авызын яшереп, «рәхмәт төшкере, рәхмәт төшкере, бигрәк тә әйбәт бала икәнсең», дип вакыйгаларга сокланып йөргән пассив эпизодик образга күнегеп җитсәк, бабайларга таяк тоттырып, «сөбханалла, сөбханалла»дан башканы әйттермәскә күнеккәнбез. Егерме-утыз еллар элек урнашкан шул штамп һаман кабатлана, дәвам итә килә иде. Туфан Миңнуллинның тиктормас, шаян һәм җор Әлмәндәре, әйттереп, җырлап-биеп йөргән Әлмәндәре — шундый шаблоннардан баш тарту буларак та игътибарга лаек новаторлык. Еллар үткән саен, яшьләр үзгәрә, хәзер яшьлек башка, «без яшь чакта болай түгел иде, тегеләй түгел иде» дип сөйлиләр икән, нигә әле яңа заман картларны, өлкәннәрне дә үзгәртмәскә тиеш. Табигать һәм тормыш закончалыкларыннан, үсеш һәм үзгәрештән беркем дә читтә калмый дибез түгелме соң.

Дөнья күргән, утны-суны кичкән карт образына мөрәҗәгать итеп, тормыш һәм җирдә яшәү матурлыгын расларга алынуның аеруча әһәмиятле һәм мәгънәви отышлы тагы бер ягы бар. Әлмәндәр — гадәти карт, гадәти кеше генә түгел — ул җирдә яңа тормыш корган, шул тормышны яклап берничә кат утка кергән, бу матур тормыш өчен гомере буе янып, көрәшеп яшәгән шәхес. Халкыбызның рухын билгеләп торган иң матур сыйфатларны үзенә җыйган һәм бер ноктага туплаган образ. Аның рус карты Евстигней белән бергә гомер итүе — интернациональ бердәмлекне күрсәтеп торса, Йөзембикә турындагы истәлекләре ярату хисләренең мәңгелеген тасвирлый. Шунда ук һәр эпизод һәм һәр сүзеннән аның чын патриот һәм хезмәт сөючә, укенерлек итеп яшәмәгән ир-ат булуы аңлашылып тора. Ә инде шуклык һәм җорлыклары — аның кеше буларак, шәхес буларак әле дә тулы канлы яшәүгә сусавын искәртеп килә. Җыебрак әйткәндә, шундый нәтиҗә үзеннән-үзе соралып тора: Әлмәндәр халыкның иң матур әхлакый, рухи һәм физик сыйфатларын үзендә туплап

кына калмаган, ул халык рухының бетмәс-төкәнмәс көчен, ныклыгын, интернациональлеген, тормыш сөючәнлеген һәм оптимизмын гәүдәләндерүче образ. Ул бер үк вакытта идеал да, чынбарлык та, авыл карты да, ил карты да. Әлмәндәр — халыкның үзе.

Әлеге әсәрнең бүгенге драматургиябездәге мәртәбәле урыны һәм киләчәге хакында инде язылмады түгел, язылды. Ул татар сәхнәсендә генә түгел, бер үк вакытта әдәбиятында да заман классикасы буларак танылырга лаек. Озын гомерле һәм зур киләчәкле пьеса. Һәм сүз башын искә төшерсәк, аның уңышында сайланган теманың әһәмиятлелеге, теманың ачылу җирлеге һәм формалары хәлиткеч роль уйныйлар. Әмма шул ук вакытта куелган сорауга җавап таптык дип тә әйтә алмыйбыз, хикмәт темада гына түгел икән. Димәк, сорау үз көчендә кала: «Хикмәт нидә?»

ӘЛЛӘ... МОҢДАМЫ? Драматургия әсәре турында сүз барганда, ул ниткән моң тагы дип, каршы төшүче булмастыр тәгаен. Чөнки вакыт үткән саен, үзен тотып күрсәтү, аңлату мөмкин булмаган бу төшенчә, катлаулы төшенчәнең, әдәбият-сәнгатьтәге урыны ачыклана, ныгый бара. Кайчандыр җырлар турында сүз чыкканда, аларда да халык җырларына мөнәсәбәттә генә, файдаланылган моң төшенчәсе тора-бара үзенең һәр шигъри әсәрдә булырга тиешлеген белгертеп өлгерде. (Моң булмаган шигырьләр дә бар бит дисәгез, шагыйрь булмаган шигырь чыгаручыларныкыдыр, диюдән башка чара юк.) Ул да түгел, сүз сәнгатенең чын осталары язган проза һәм драматургия әсәрләренә дә моң төшенчәсе чит нәрсә түгел икән бит. Ә. Еники прозасы, бигрәк тә хикәяләрендә моны тоймау һәм ишетмәү, гомумән, мөмкин түгел. М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары», «Кеше китә — җыры кала» һәм «Исәнме, Кәшфи абый!» повестьларында, А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» һәм «Җомга көн кич белән»ендә тотрыклы бер музыкаль аһәң, мәгънәле һәм тирән көй, тормыш һәм җирдә яшәү ритмын эченә алган эчке бер аваз ишетелеп тора. Тулы эчтәлекле һәм мәгънәсен әйтеп, аңлатып бирү гаять кыен булган әлеге моң — Т. Миңнуллин драматургиясенең дә тугрылыклы юлдашы. Ул аеруча «Канкай углы Бәхтияр», «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесаларында эзлекле рәвештә үстерелә һәм бер бөтен буларак дәвам иттерелә. Беренче әсәрдә ул, я азатлык һәм иреккә сусап көрәшкә чыккан ярлы халыкның күңеле түреннән чыккан җан ачысы, я бердәмлек һәм туганлыкны тоеп, үз көченә ышанып яуга барган бунтарь көрәшчеләр маршы булып ишетелә. «Әлдермештән Әлмәндәр»дә дә моң алдан сызып куелган бер юнәлештә генә хәрәкәт итми, оптимистик һәм күтәренке рух, әледән-әле үткәннәрне сагыну, югалтуларны искә алып юксыну кебек чигенешләр белән чиратлашып, бормаланып ага. Әйтик, Әлмәндәрнең хыялында унҗиде яшьлек карчыгы Йөзембикә янына кайтуы. Аларның су буенда чишмә башындагы очрашуы. Җанны өтеп алырлык моң белән уратылган күренеш. Шаярып, уйнап кына сөйләшә кебек үзләре, әмма ерактан, үткәннән килгән бер аваз, әйтеп-аңлатып бирү мөмкин булмаган тирән моңга әверелеп, бугазга төер килеп тыгыла. (Шушы урында әсәр турындагы сүз, ирексездән, Татар Дәүләт Академия театрында сәхнәләштерелгән эпизодка барып тоташа. Режиссер Марсель Сәлимҗанов, актерлар Шәүкәт Биктимеров һәм Алсу Гайнуллиналар тудырган гүзәл картина күз алдында тора.) Кабатланмас талантка ия сәхнә осталары һәм режисер эшенә иң югары бәя биргән тәкъдирдә дә, драматург кодрәте белән үк әсәргә гаять катлаулы, контрастлы моң салынган булуын искәрми мөмкин түгел:

— Әлмәндәр, без олыгайгач та Ай шул урында торыр микән?
— Юк.
— Кая китә?
— Мин аны алып төшеп, үзебезнең өй кыегына кадаклап куям.
— Алай итмә, Әлмәндәр. Бүтәннәргә дә кирәк ич Ай.
— Ярый алайса, тимәм, урынында торыр.
— Без картаербыз микән, Әлмәндәр?
— Мескеннәр генә картая.
— Без үләрбез микән, Әлмәндәр?
— Таптың сөйләшер сүз...

Якты, ачык күренеш, бәхетле, матур хатирә. Әле ачылырга өлгермәгән гөл чәчәген хәтерләткән мәхәббәт, яшьлек һәм яшьлекнең юлдашы булган җорлык.

Әмма... инде бары да узган, бары да хыялда гына сакланып калган. Күзләрне чагылдырырлык яктылык һәм матурлык эчендә — җанны үрсәләндереп җылатырлык сагышлы моң гына, тормышның кырыс законнары нигезендә яткан моң... (Әлбәттә, мине бу урында әсәрне укымаган, аның югарыда искәртелгән сәхнә вариантын күрмәгән кеше аңлый алмас.)

Ул моң ничек туа, аңарга драма әсәрендә нигез нинди чаралар белән салына? Бусына да өздереп кенә җавап бирү җиңел түгел. Шулай да диалогның табигыйлеге, тормышчанлыгы, һәр сүзнең күптөсмерлелеге аша чынбарлыкның кабатланмас күренешләрен, язмышларын сиземли барудан башка мондый мәгънәви тирәнлеккә ирешеп булмас иде. Шуңа күрә дә әдәби әсәрдә моң төшенчәсен сәнгатьлелектән һәм художество осталыгыннан аерып карау мөмкин түгел һәм урынсыз булса кирәк.

«Канкай углы Бәхтияр» һәм «Әлдермештән Әлмәндәр» кебек әсәрләрдә автор күңеле, хыялы аша әсәргә иңдерелгән моң укучыга һәм тамашачыга төрле вариант һәм төсмерләрдә барып җитәргә мөмкин. Монда аны сәхнәгә куйган режиссер һәм актерларның шул язылмаган эчке музыкаль агышны тою, сиземләве дә зур әһәмияткә ия. Ул гына да түгел, ялгыш сайланган тон һәм интонация белән автор мең газаплар кичеп ирешкән бу художество чарасын юкка чыгару да бик җиңел. Әмма югарыда искә алынган сәхнә вариантларында авторга хыянәт турында сүз дә булырга мөмкин түгел — милли сәхнәбезнең талантлы режиссеры Марсель Сәлимҗанов драматургны тулысынча аңлап кына калмый, ә аны үз күңеле байлыклары белән кушып түкми-чәчми тамашачыга җиткерә. Гомумән, Т. Миңнуллин белән М. Сәлимҗанов арасындагы иҗади дуслык — бүгенге татар сәхнәсе өчен уникаль күренеш, ул кайсыдыр яклары белән С. Сәйдәшев һәм К. Тинчурин арасындагы хезмәттәшлек, үзара аңлашу үрнәген хәтерләтә. Драматург белән режиссерның үзара аңлашуы бигрәк тә әсәрнең тирән катламнарында, эчендә яшеренеп яткан рухи байлык — моңны тамашачыга илтеп җиткерүдә ачык чагылыш таба.

Драматург укучыга һәм тамашачыга җиткерергә ниятләгән моң аерым очракта конкрет, җисемле гәүдәләнеш табарга да мөмкин. Югарыда искә алынган әсәрләрдә моң сәхнә сәнгате һәм сүз сәнгатенең күп төрле нюанслары һәм синтетик чаралары ярдәмендә иҗат ителгәнлеген күрдек. Ә менә «Ай булмаса, йолдыз бар» һәм «Моңлы бер җыр»да Т. Миңнуллин халык яратып җырлаган конкрет җырлар стихиясенә керә. һәм ул җырлар әсәрләрдәге лирик һәм драматик башлангычларны бермәбер көчәйтеп, үстереп җибәрәләр. Ә җыр һәм драма әсәре арасында туган яңа, гаҗәеп бәйләныш, үз чиратында, халык күңелендә озак еллар дәвамында яши һәм чарлана килгән моңга конкрет гәүдәләнеш биреп, аны яңа төсмерләр — драматик нечкәлекләр белән тагы да баета төшә.

Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре батырлыгының фәлсәфи һәм рухи нигезе, Туган ил намусы өчен, халкы намусы өчен соңгы тамчы каннарын да бирергә әзер торган унбер каһарманның изге антларына тугрылыклыгы табигате хакында уйланулар нәтиҗәсендә туган «Моңлы бер җыр» публицистик драмасының исеменә үк әлеге төшенчә салынган. Әсәрнең нәкъ менә шулай исемләнүендә объектив зарурлык барлыгы көн кебек ачык. Чөнки драма, чынлап та, Халык һәм Ватан язмышына барып тоташкан героик моңга нигезләнгән. һәм шул моңны укучыга, тамашачыга җиткерүдә халык күңелендә шыткан җыр «Сибелә чәчәк» гаять әһәмиятле роль уйный. Туган илдән еракта фашист төрмәсендә соңгы сәгатьләрен көткән, шул шартларда да тормышка, туып-үскән җиргә, якыннарына мәхәббәтләренә тугры калган имәндәй нык буынлы ирләр — совет солдатларының татар халкы арасында киң таралган нечкә лирик җыр башкаруы тетрәндереп җибәрә.

Гөлбакчага керәмсең лә,
Гөл чәчәген өзәмсең;
Өзелгән гөл чәчәге күк
Аерылдык — сизәмсең!

Сөйгән ярлар, туганнар, туган авыл һәм Ватанны юксыну, сагыну булып яңгырый җыр. Бигрәк тә соңгы ике юл сулышка кайнар дулкын булып килеп бәрелә:

**Сибелә чәчәк җилләр искәндә,**
**Өзелә үзәк исләремә төшкәндә...**

Сагыш һәм юксыну чамасыз зур, әмма үкенү яисә мескенәюнең чырае да күренми. Алай гына да түгел, өзлексез дәвам иткән, торган саен көчәя барып, бер ташкынны хәтерләтә башлаган җыр — тоташ моңга әверелеп — героик төсмер ала бара. Сагыну һәм моңаю гына түгел, шул сагынучыларның корыч стеналардан да нык җиңелмәс рухы авазы икән бит бу. Юкса, соңгы җәлилченең башы киселгәч тә ул мәңгегә тынып калырга тиеш түгел идеме? Ә җыр дәвам итә — моң артканнан арта, үскәннән үсә бара. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең үлемсезлеген раслаган моң батырлык һәм каһарманлык үрнәге булып Ватанга, туган илгә кайта, яңа буын җәлилчеләре күңеленә күчә.

Укучы һәм тамашачы буларак, «Моңлы бер җыр» драмасы белән очрашканда, миңа бар нәрсәдән көчлерәк тәэсир ясаганы да әлеге героик, патетик моң авазы булды. Һәм мин тагы бер мәртәбә Т. Миңнуллинның художник буларак сиземләү, тоемлау осталыгын тойдым — максатында булган югары идея һәм күңелендәге тирән моңны җиткерү өчен ул гаять отышлы чара тапкан. Халык күңелендә бөреләнеп чәчәк аткан лирик җырдан да кулайрак чыганакны бу очракта башкача табу мөмкин булмас иде.

Беренчедән, бу — халыкның үз моңы, аңа таныш һәм аңлаешлы моң. Икенчедән, элек-электән укучы һәм тамашачы күңелендә яши килгән бу җыр, иксез-чиксез дәрьядан көч туплагандай, һәркемнең үз рухиятеннән өстәмә көч һәм мәгънә төсмерләре алып тора. Өченчедән, үзенә таныш, аңлаешлы җыр белән яңа драматик шартларда очрашкан кеше күңелендә иҗади эзләнү процессы башланып, ул рухын яңа идея һәм эстетик кыйммәтләр белән баету ихтыяҗын тоя. Йомгаклап әйткәндә, «Моңлы бер җыр» әсәренең нигезен тәшкил иткән моң бер үк вакытта һәм идея, һәм эстетик кыйммәткә әверелә.

Халык күңелендә туган җырның драматик әсәр тукымасы белән органик кушылып бергә яши башлавы күзлегеннән «Ай булмаса, йолдыз бар» пьесасы шулай ук игътибарга лаек. Халык җыры «Мәдинә, гөлкәем», бер уйласаң, үзенең рухы белән әсәрдә тасвирланган драматик киеренке вакыйгаларга алай артык аваздаш та түгел кебек. Төп персонаж исеме Мәдинә булганга искә алынган сыман да тоелырга мөмкин. Әмма бу факт, безгә, беренчедән, халык җырларының күп сыйдырышлылыгы һәм тирәнлеге хакында сөйләсә, икенчедән, драматик әсәр үзәгенә салынган таныш җырның яңа шартларда яңа моң төсмерләре белән баеп китүе ягыннан да гыйбрәтле. Искәрүче булмый калмагандыр: җыр әсәрдә барган сюжет сызыгы белән бергә, вакыйгалар белән бергә өзлексез хәрәкәт итә, яңадан-яңа мәгънә һәм хис төсмерләре ала бара. Һәм шунысы кызык: бу төсмерләр күпме генә үзгәрмәсен, җыр бер генә очракта да гайре табигый яңгырамый, берөзлексез драматик җирлекнең аерылгысыз өлеше булып яшәвендә дәвам итә. Мәдинә белән Мирзанур арасындагы мәхәббәт чәчәк аткан, һәр икесе дә бәхеттә коенган чакта шул хисләрнең олылыгын, матурлыгын көчәйтеп килгән кебек, героиня язмыш тарафыннан коточкыч кайгыхәсрәтләргә салынгач та җыр драматик әсәрнең моң чыганагы булып кала. Бу факт исә, безгә, зәвык һәм профессиональ осталык белән куллана белгәндә, татар халык җырларының бәяләп бетергесез идея һәм эстетик җегәр чыганагы булуын ачык дәлилләп килә.

**Ай янында якты йолдыз,**
**Минем йолдызым бит ул;**
**Мәдинә, гөлкәем,**
**Минем йолдызым бит ул, бәгырькәем...**

Шушы урында лирик җыр һәм драматик әсәр арасындагы автор билгеләгән гармонияне тукми-чәчми тамашачыга җиткергән талантлы сәхнә осталары режиссер Гали Хөсәенов һәм артистка Дамирә Кузаева (Әлмәт драма театры коллективы куйган спектакль күздә тотыла) иҗат иткән эпизодлар күз алдына килә. Һәм тагы бер кат моңның әдәбият һәм сәнгатьтәге урыны хакында уйга биреләсең. Әдәби

жанрлар белән генә чикләнмичә, драматик сәхнәләрдә дә вакыт-вакыт хәлиткеч критерийга, әһәмиятле идея-эстетик чыганакка әверелә икән бит ул. Т. Миңнуллин драматургиясе һәм аның югарыда искә алынган сәхнә вариантлары моны күрсәтеп торган ныклы дәлилләр булса кирәк. Шулай да без табарга, эзләргә теләгән хикмәт — моң булып, моңда да тулысынча ачылып, чагылып бетми кебек әле. Соң, алай икән, хикмәт нидә?..

ИХЛАСЛЫКТАНМЫ? Чынлап та, авторның ихласлыгы — язган әсәрендә бар булганы, бөтен рухы, омтылышы һәм хыяллары белән ачыла алу сәләте зур әһәмияткә ия. Дөнья әдәбияты тарихына сәяхәт ясыйбызмы, бүгенге күпмилләтле совет әдәбиятлары тудырган әдәби җәүһәрләргәме, үз әдәбиятыбыз барышына күз салабызмы — чын иҗат эшенең, кагыйдә буларак, ихласлыктан, әдипнең үз әсәрендә һәм үз геройларына мөнәсәбәттә эчкерсез, риясыз, чын күңелдән бар табигате белән ачыла алуы әдәби әсәрнең халык күңеленә якынлыгы белән туры пропорциональ бәйләнештә булуны күрербез. Ә бит ул — ихласлык, иҗат процессында тулысынча чишелеп китә алу — сирәк очрый торган сәләт. Хәсән Туфан поэзиясенең бүгенге рухи яшәешебездәге урыны, идея-эстетик йогынты ясау көче, уйлавымча, иң элек, әлеге дә баягы, шагыйрьнең үз лирикасында соң дәрәҗәдә ихлас булып калуында.

Ихласлык, беренчедән, үз-үзеңне табу, үз күңелеңә, үз фикерләреңә иҗат процессында, бернинди фальшька урын калдырмыйча, үтеп керә алу сәләте булса, икенчедән, тормышка үз мөнәсәбәтеңне билгеләү, дөньяны үз күзләрең белән күреп, үз йөрәгең аша кичерү нәтиҗәсендә табылган әйтер сүзеңне түкми-чәчми кәгазь битләренә күчерә алу мөстәкыйльлеге. Юкса, әдәбиятка китаплардан, кинолардан алган тәэсирләрен сөйләү өчен генә, коры факт һәм конкрет вакыйгалардан тыш, үземнеке генә диярлек һич ни әйтә алмаган, әйтергә җөрьәт итмәгән авторлар да килми түгел. Ә шулай да, миңа калса, йөрәктән чыккан гына йөрәкләргә барып җитәргә сәләтле, дигән сүзләр бәхәс уятмаска тиешле.

Ихласлыкны яклап инде шул тикле фикер йөрткәннән соң янә Туфан Миңнуллин драматургиясенә әйләнеп кайтырга вакыттыр. Аның пьесалары белән танышкач берничә кат уйга калганым бар: нигә әле геройлары күп сөйләшеп теңкәне корытмый, нигә монологлары кыска, диалоглары җанлы һәм мавыктыргыч була аның? Кабат кайтып күңелдән кичерсәң, төпченә калсаң, аермачык булып күз алдына килә — ул геройларын сөйләштерми икән ләбаса, алар үзләре сөйләшә, әсәрдә үзләре мөстәкыйль тормыш белән яши, уйный-көлә һәм көрәшә, җиңә, җиңелә икән. Аның иң зур фикри җаваплылыкны укучы һәм тамашачыга җиткерергә тиешле образы да безнең кебек үк иң гади камырдан ясалган, тормышчан һәм гадәти кеше була икән. Кемнедер шаккатырырга азаплану да юк, югары материялар хакында классик фәлсәфәләрдән цитаталар китереп аяктан егарга да маташмыйлар. Шуңарга аларның үзара аңлашуы монолог һәм диалогларга бүленми дә төсле, ә табигый сөйләшү буларак кабул ителә, вакыйга һәм күренешләргә гармонияле төстә үрелеп бара. Югарыда кат-кат искә алынган драмаларда шундый гадилек һәм гадәтилек рәвешендә чагылган ихласлылык та хәлиткеч эстетик чара булып тора. Хәер, әсәрнең идея эчтәлеген, төп проблемаларын мәгънәви камилләштерүдә дә ихласлылык соңгы рольне уйнамый.

Әйтик, «Моңлы бер җыр» драмасындагы ана белән шагыйрь очрашуын яисә унбер каһарманның туган яклары, якыннары турындагы истәлекләргә бирелүе эпизодларын гына күз алдына китерсәк тә, алар арасындагы аңлашу һәм сөйләшүнең никадәрле тормышчан һәм гади булуын тою — димәк, ихласлыгына төшенү — кыен булмас. Исәнлек-саулык сорашалар, хәл-әхвәлләрне белешәләр һәм, нәтиҗәдә, чын мәгънәсендә аңлашалар (ана белән шагыйрь очрашу эпизодында). Һичнинди күз яшьләре, төче сүзләр дә кирәкми, урра кычкырып күкрәк төю дә юк, аңлашыла — ана белән бала арасындагы изге җепләр өзелмәс ныклыкка ия, Ватанга тугрылык бар нәрсәдән өстенрәк шагыйрь өчен.

Фашизм читлегендә яткан унбер ир-ат та бит яңгыравык сүзләр белән шаккатырырга, үз-үзләренә пьедестал куярга омтылмый, ә каядыр Кама Тамагы яисә Мамадыш якларындагы бер гади татар авылында очрашкан егетләр кебек шаярышырга, кызык мәзәкләр сөйләшергә дә үзләрендә көч табалар. Һәм шул табигыйлекләре аша укучы һәм тамашачы күз алдында аларның җиңелмәс образы, үрнәк

булырлык патриотлык сыйфатлары ачыла. Ихлас һәм гадәти әңгәмә артында масштаблы каһарман образлар булуы һәрдаим күзгә, күңелгә бәрелеп-тоелып тора.

Шунда ук тагы бер гыйбрәтле фактка игътибар итеп узу кызыклы булыр. Яшь шагыйрь — безнең замандаш егетнең Җәлил һәм җәлилчеләр белән җиңел генә аңлаша алмавы, әңгәмә кора алмый иза чигүе дә аның бераз чынбарлыктан өстенрәк, гадәти тормыштан югарырак булырга омтылып фикер йөртүеннән — ихлассызлыгыннан килмимме икән... Автор моны әйтергә, аңлатырга теләгәндерме-юкмы, ул кадәресе безгә мәгълүм түгел, ә хакыйкатьтә нәкъ менә шулайрак килеп чыккан. Батырларны идеаллаштырып, алар белән гадәттәгедән җитдирәк һәм акыллырак итеп сөйләшергә омтылу егет алдында үзе теләгән сорауларга җавап табуда күп каршылыклар тудыра. Ә чынлыкта шундый каһарманлык кылган кешеләр дә гадиләр, табигатьләре белән үк гадәтиләр икән. Үзләре ихлас булганнар белән бары тик ихлас төстә генә аралашу, аңлашу һәм уртак тел табу зарурлыгы ачыклана.

Инде янә «Әлдермештән Әлмәндәр»гә кайтып, тагы гыйбрәтле бер эпизодны күз алдына китерик: Әлмәндәр, Әҗәлдән качып, күптәнге дусты — күршедәге рус авылына Евстигней янына килә. Кыска гына арада драматург рус һәм татар халкы арасындагы ихлас дуслыкның, интернациональ дуслыкның чын мәгънәсендәге сәнгатьле үрнәген күрсәтүгә ирешә. Утны-суны, күп кыенлыкларны бергә-бергә кичергән, бер язмыш, бер максат һәм идеаллар белән яшәгән рус һәм татар картының үзара аңлашуыннан гыйбарәт булган юлларга игътибар итик:

Әлмәндәр: Ястәгнәй! Знакум!

Евстигней: Кем бар анда?

Әлмәндәр: Кто такуй, знаешь? Ни знаешь — маклашка дам.

Евстигней: Альмандар?

Әлмәндәр: Знал, маклашка ни дам. Гости пришул — чәй давай, дивка давай.

Евстигней: Шайтан! Нихаль, Альмандар? Якши?

Әлмәндәр: Хураша! Сам хураша?

Евстигней: Якши! Бик якши! Каян килден?

Әлмәндәр: Деревня. Свая деревня. Тибя давна ни видал.

Евстигней: Якши! Бик якши! Айда, кил, утыр монда. Мин да уйлаган синга барырга. Вот умарта, бал киряк. Янгир бар, бал бар, куп бар. Син бал бар?

Әлмәндәр: Мнугы. Гуд хураша, дуж есть, сулныца есть, свиты мнугы, пчала туда-сюда мнугы литит. Тибя кислый мед есть? Меня есть. Әлмәндәр кислый мюд пил. Әҗәлдән бижал. Әҗәл спал, Әлмәндәр Ястәгнәй знакум бежал.

Сөйләшү, ике милләт вәкиле арасындагы аңлашу, шул рәвешле дәвам итә. Алар яңадан очрашуларына чын күңелдән сөенәләр, бер-берсен исән-сау күрүләренә, дөнья тыныч һәм матур булганга, җәйләр матур килгәнгә, бал кортлары арлы-бирле очканга куаналар. Җир җимертеп яшәгән, дөньяга сокланып туймаган бу икәүгә тугызар дистә дип кем уйлар. Яшәү ямен, үзара татулык һәм дуслыкның олылыгын, күңел күрлегән тасвирлауның чын сәнгатьле үрнәге ич бу. Гүзәл үрнәк!

Шунда ук, тагы бер детальгә — Әлмәндәр һәм Евстигнейның сүзләренә игътибар сорала. Әлмәндәр, бар белгәнен файдаланып, русча сөйләшергә, ә Евстигней, тырышып-тырышып, татарча аңлашырга омтыла. Бер карасаң, бу — ике карт арасындагы ихлас дуслыкны чагылдыру өчен файдаланылган шартлы алым гына булып тоелырга мөмкин. Әмма диалог ифрат дәрәҗәдә тормышчан һәм табигый — табигать кочагында, фидакарь хезмәт һәм татулык белән яшәгән төрле милләт вәкилләре арасындагы ихласлыкны төкми-чәчми күз алдына китерә дә бастыра. Шушы ихласлык нәтиҗәсендә автор илебез халыклары арасындагы интернациональ дуслыкның нәфис үрнәген чагылдыруга ирешкән. Нибарысы гадәти бер эпизод кына булып тоелган әлеге очрашу әсәрнең масштаблылыгын, тирәнлеген һәм чын мәгънәсендәге кешелекле аһәңен тудыруда гаять әһәмиятле урын ала. Кайтып-кайтып укып карасаң, игътибар итсәң, артык берни дә юк кебек бит, югыйсә, ихласлык кына бар. Әйе, ихласлык!!! Укучыны булсын, тамашачыны булсын, авторга бәйләп, үз итеп, якынайтып торган, сәнгать әсәре белән, аның геройлары белән бер булып яшәргә, борчылырга һәм уйланырга, хыялланырга һәм канатланырга мәҗбүр иткән шарт — ихласлык. Шулай да хикмәт аңарда гына да түгел кебек.

ЖОРЛЫКТАМЫ?.. Язмыш тарафыннан нинди генә сынауларга дучар ителмәсен, сәламәт тән һәм күңелдә һәрчак һәм һәр урында җорлык һәм шаяру, тапкырлык һәм күңел көрлегенә урын бардыр диеп беләм. Халыклар һәм, аерым алганда, татар халкы тарих барышында нинди генә афәт һәм туфаннар кичермәсен, күңел көрлеген, җорлыгын югалтмаган. Пугачев бунты елларында булсын, Бөек Ватан сугышы чорындамы, күңеле сыкраган, югалтулардан үрсәләнгән, моңайган чакларында да ул уен-көлке һәм шаяру тойгыларын югалтмаган. Ил өстенә килгән теләсә нинди кыенлыклар һәм афәтләрнең ахыры җиңү белән тәмамлануның сере дә халык рухына күңел көрлеге һәм җорлыкның мәңгелек юлдаш булуына бәйләнештә булса кирәк.

Балачак һәм үсмер елларны, туып-үскән авылны искә төшергән чакларда, белмим, кемгә ничек, әмма күпләр күңелендә үткән гомер, вакыйгалар хикмәтле хәлләр, гыйбрәтле һәм тапкыр сүзләр, җорлык һәм тапкырлык белән, барыннан да элек, якты һәм кояшлы мизгелләрдә сакланып кала икән. Каравыл өендә кышкы бураннарда җыелып тәмәке төтәткән агайларны күз алдына китерәм, болынга печәнгә төшкән чакларны, клуб бакчасына кичке уенга җыелган яшьләрне, тәнәфес вакытында коридорга чыккан балачак дусларымны хәтерләргә тырышам — һәркайсының бер хикмәте, бер кызык гадәте, кабатланмас сөйләшү үзенчәлеге, тапкырлыгы һәм җорлыгы булган икән. Чынлабрак уйлап баксаң, һәркем үзенчә гыйбрәтле һәм кызык, җор һәм кабатланмас дәрәҗәдә матур икән бит. Күңелендә болыт әсәртесе булмаган чакларда, һәрхәлдә, бу шулай тоела, дөнья һәм кешеләр гыйбрәтле, мавыктыргыч.

Драматург Т. Миңнуллин — үзенең иҗатында әнә шул хакыйкатьне армый-талмый раслаучыларның берсе. Ул — халыкның, аеруча типик характер үзенчәлекләреннән җорлыкның гаять әһәмиятле нәрсә булуын тирәнтен аңлаган, тойган һәм шуны расларга омтылган сүз остасы. һәм шунда ук искәртү урынлы булыр, тормыштагы, кешеләрдәге әлеге характер үзенчәлегенә игътибарлы булуы белән бергә, үзе дә табигатьтән ул хәзинәне чумырып алган. Алай гына да түгел, драматург өчен җорлык — уен-көлке, шаяру гына да түгел, ул — яшәү рәвеше, халыкчан фәлсәфә тирәнлеге һәм художество осталыгының бер компоненты да булып тора. Әйе, җорлык — турыдан-туры тапкырлык, хикмәтлелек, халыкның фәлсәфи фикере, тормыш тәҗрибәсе белән дә тыгыз бәйләнештә. Т. Миңнуллинның югарыда кат-кат телгә алынган «Әлдермештән Әлмәндәр»ен янсә «Моңлы бер җыр»ын искә төшерәбезме, «Ирегетләр» һәм «Дуслар җыелган җирдә» кебек әсәрләренме,— һәр очракта тормыш тәҗрибәсе һәм халыкның фәлсәфи практикасына нигезләнгән җорлык, тапкырлык фикер җебен хәрәкәтләндерүче төп энергия чыганагы булып яши.

Авторның тамашачы һәм укучы тарафыннан яратып каршы алынган «Диләфрүзгә дүрт кияү» водевиле, бер карасаң, баштан ахырынача җыр-бию, шаяру, мутлану һәм уен-көлкегә корылган кебек. Монда, һәрхәлдә, җорлык фәлсәфи тирәнлек һәм гыйбрәтлелектән башка гына яшидер күк. Жанр үзенчәлеге, әсәрнең үзәгенә алынган сюжет һәм конфликт, чынлап та, геройларның җорлыгы тышкы эффектлардан гына гыйбарәт дигән нәтиҗә өчен мул җирлек бирә. Чәчрәп торган авыл егетләрен бер чая кызның шулай җиңел генә кәкре каенга терәтүенә дә аек акыл белән уйлаганда ышанып ук җитәсе килми. Әмма сәнгать әсәре, чын сәнгать әсәре аек акыллыларга гына йөз тотарга тиешме икән? Чын сәнгать һәм әдәбиятның шартлы чаралар һәм художестволылык белән аек акылны да әсәрләндерерлек тәэсир итү көче булмаса, канатсызны канатландырырлык, хыялсызны хыялга биреләдерерлек, йоклаганны уятырлык шифалы чыганагы булмаса, аның булуыннан булмавы артыграк түгелме...

Диләфрүзнең мутлыгы артында бу очракта да яшьлекнең табигый көче, фәлсәфи бөтенлегенә нигезләнгән җорлык тулып ята. Дөрес, үзләренә күрә, җорлык кияүләрдә дә юк түгел, аларның да бит соңгы максаты уен-көлке генә түгел — өлгереп пешкән матур кыз. Кемдә генә булмас андый татлы матур хыял, тамаша залында һәм укучылар арасында бишенче-алтынчы кияүлеккә кандидатлар булмас идеме әллә?! һәм һәркайсының максатына ирешүдә үз мутлыгы, үз җорлыгы, үз фәлсәфәсе... Ә Диләфрүз өстен чыга! Ни өчен? Чөнки аның җорлыгы табигать һәм тормыш закончалыкларына, әхлак һәм рухи кагыйдәләргә ныграк нигезләнгән. Соң чиктә ул кияүләрнең кешелек сыйфатларыннан көлми ич, изге төшенчәләргә кагылмый гына, изге

хисләр өчен көрәшә. Изге тойгы һәм хисләрне бер мавыгу һәм шаяру, үзмаксат итеп алган, халыкның тормыш практикасыннан килгән рухи нормаларга битарафлык күрсәткән калай әтәчләргә бер кечкенә акыл дәресе бирә. Шуңа күрә дә Диләфрүзнең шаяртуы — гадәти бер мутлык кына түгел, ә чын мәгънәсендәге фәлсәфәгә нигезләнгән җорлык. Рухи чисталык һәм гармониягә юнәлдерелгән җорлык. «Диләфрүзгә дүрт кияү», шул рәвешле, драматург иҗатындагы гаять әһәмиятле һәм актуаль проблемалар күтәргән әсәрләр арасында лаеклы урын алып тора.

Т. Миңнуллин соңгы әсәре «Монда тудык, монда үстек»тә дә иҗатының хәрәкәтләндерүче механизмы булган җорлыкка җаваплы идея һәм эстетик функцияләр йөкли. Әсәрнең уңышы нидә дигән сорау бирсәләр, һич икеләнүсез, драматургның нефтьчеләрне дә, иң беренче чиратта, кеше итеп күрүендә, тормыштагыча җор табигатьле, көндәлек ыгы-зыгылары белән матур булган образлар тудыруында дияр идем. Әлегә андый сорау бирүче юк, шуңа күрә драматик повестьның үзен хәтергә төшерик. Чынлап та, әсәр Татарстан нефтьчеләре турында, әмма нефть — үзмаксат түгел, ул геройларның язмышын бәйләп, уртак максат өчен көрәштә очраштырып торган нәрсә генә. Һәм нәтиҗәдә, барыбер, нефть өчен бөтен гомерен һәм егәрен дә кызганмаган фидакарь хезмәт батырлары галереясы күз алдына килеп баса. Тема дип, эшче яисә колхозчы образы дип азмы буш сүз сөйләүчеләр булды, ә Туфан Миңнуллин вышкаларны сурәтләми, технологик процесслардан репортаж китерми генә максатына ирешкән. Нефтьне дә кешеләр чыгара икән бит, алар да һәркайсы үзенчә яши һәм фикер йөртә торган шәхесләр икән ләбаса. Умырып эшләүгә дә карамастан, телләрендә гел производство гына түгел, көндәлек мәшәкать, тормыш гаугалары, үзара бәрелеш, бәхәсләргә дә урын бар икән.

Ә инде әсәрнең үзәген тәшкил иткән образларга килсәк, алар арасында Саттар ага Биккинин, бер яктан, чын мәгънәсендәге Татарстан нефтьчесе буларак күз алдына килеп басса, икенчедән, кеше буларак та ил картының типик варианты булып чыккан. Нефтьче буларак та, ил карты буларак та халык рухындагы җорлыкны — фәлсәфи тирәнлек һәм рухи матурлыкны үзенә җыйган шәхес. Укучы һәм тамашачының күңеле әсәрнең башыннан ук нәкъ менә шул образга йөз белән борылып, иярен китүе һич очраклы күренеш түгел. Тормыш тәҗрибәсе, гыйбрәтле язмышы, ачык күңеле һәм җор сүзе белән аерылып торган кеше образына битараф калып булмый. Җорлык — табигыйлек, җорлык — рухи матурлык һәм гармония чагылышы, җорлык — фәлсәфи үткенлек, җорлык — яшәү оптимизмы һәм кеше булу дигән сүз. Тик барыбер хикмәт аңарда гынамы икән?!

Драматург яңа иҗат планнары белән янып яши, эзләнә, борчыла һәм куана. Алдагы көннәрдә укучы һәм тамашачыларына ул тагы нинди бәхетле минутлар, сәгатьләр китерер — әйтү җиңел түгел. Тагы нинди хикмәтләр чыгарыр? Яңа хикмәтләрнең хикмәте нидә дип, бәлки әле күпләр баш ватар... Күңеленә хуш килгән, җанга якын һәм үз булган күренешне өздереп кенә кемнең аңлата алганы бар, бәлки куйган соравыма күңел булырлык җавап таба алмавым белән мин дә бәхетлемендер әле. Дөнья — сокландыргыч дәрәҗәдә матур, талант — серле икән. Ни генә булмасын, тормыш үзенекен итә — тормыш дәвам итә. Димәк, һәммәбезне яңа табышмаклар көтә...

Флера Сафиуллина

# ХӘЗИНӘДӘ НИЛӘР БАР?




Совет властеның беренче елларында, әле гражданнар сугышы бетеп җитәр-җитмәс чорда, бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин, Владимир Даль төзегән рус теленең аңлатмалы сүзлеге уңаеннан, аның бераз өлкәчел характерда булуын билгеләп, хәзерге рус теленең шундый ук сүзлеген төзергә кирәк; кызыл армияче паегы биреп, утыз галимне шул эшкә утыртканда әйбәт булыр иде дип яза[1]. Шундый авыр чорда юлбашчыбызның яңа социалистик дәүләттә яңа тормышны чагылдырган сүзлекләр төзү перспективасын да күрә алуына таң каласың.

Октябрь революциясеннән соңгы елларда милли республикаларда йөзләгән төрле сүзлекләр басылып чыкты. Хәзерге көндә аларның ниндиләре генә юк: энциклопедик, тәрҗемәле, синонимнар, антонимнар, диалектологик сүзлекләр, чагыштырмалы-тарихи, терминологик, фразеологик, язучы теле сүзлекләре, кеше исемнәре, топонимик, телне-илне белү сүзлекләре... Әмма шулар арасында иң дәрәҗәле урында — аңлатмалы сүзлекләр. Алар телнең байлыгын, мөмкинлекләрен билгелиләр, филология фәненең үсешен күрсәтәләр, киң халык массаларының иҗтимагый хезмәтендә турыдан-туры катнашалар.

Илебездә күп кенә милли телләрнең аңлатмалы сүзлекләре басылып чыкты яисә төзелеп ята. Татар теленең дә аңлатмалы сүзлеге укучылар кулында. Әмма сүзлек өзер булганчы күпме тарих үткән...

Казан университеты профессоры, гарәп телләрен укытучы Ф. Эрдман 1829 елда ук инде, аптырашта калып, болай дип яза: «Гаҗәп бит, без бөтен яктан татарлар белән чолганып алынган булсак та, татар теленең күләме һәм төрле катламнары турында аз беләбез, аның ни тәфсилләп төзелгән грамматикасы, ни тулы сүзлеге генә түгел, уртача гына төзелгән булса да сүзлеген дә күрсәтә алмыйбыз». Ф. Эрдман татар теленең тулы сүзлеген төзүне үз өстенә йөкләүне сорап, университет Советына үтенеч язып бирә. Сүзлекнең проекты турында ул болай дип яза: «Сүзлектә татар теленең дингә, чиркәү эшләренә, борынгылыкка, тарихка, географиягә, табигать тарихына, гадәтләргә, дәүләт учреждениесенә, закон чыгаруга, диңгез эшләренә, сәүдәгә, көнкүрешкә һәм аның тәртипләренә, җир эшкәртүгә, ауга, балыкчылыкка, фабрикага, мануфактурага, тау эшенә, хәрби эшкә, им-томга, тылсымга, математикага, астрономиягә,

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә. Казан, 1964, 35 том, 402 бит.

анатомиягә, дипломатиягә, алхимиягә, архитектурага һ. б. караган гади сүзләр дә, абстракт мәгънәле сүзләрнең бөтенесе дә булырга тиеш»[1]. (Ф. Эрдман 1785 елда язылган һәм кульязма хәлендә сакланып калган С. Хәлфиннең ике томлык сүзлеге[2] барлыгын белеп җиткермәгән, күрәсең.) Ф. Эрдманның программасы 12 параграфтан булып, аларда сүзләрнең урнашу тәртибе, кайсы телдән алынуы, сайлап алу принциплары, сүзләрнең мәгънәләре һәм аларны аңлаткан мисаллар, фразеология һ. б. турында сүз бара. Программада татар сүзләрен русчага һәм латинчага тәрҗемә итеп бирү күздә тотыла. А. Троянскийның 1833 елда чыгачак 2 томлык сүзлеге[3] турында да Ф. Эрдман белмәгән, билгеле. XVII—XVIII йөзләрдә чыккан дистәләгән кульязма сүзлекләр турындагы мәгълүмат та аңа, ни өчендер, барып җитмәгән.

Татар теле гимназияләрдә, университетларда укытылган, аның белән фәнни җәмәгатьчелек кызыксынган бу чорда күп санлы грамматикалар да языла. Әмма телнең күпчелек сүзләрен туплаган аңлатмалы сүзлеккә ихтыяҗ аеруча зур була. Бу зур, җаваплы, мактаулы эшне К. Насыйри беренче булып башкарып чыга. Аның «Ләһҗәи татари» исемле ике томлык (I том — 1895, II том — 1896 ел) сүзлегендә 10467 сүз теркәлә. Сүзләргә аңлатма бирүнең төп принцибы итеп К. Насыйри синонимнар китерү юлын сайлый, шулай ук тасвирламалар да бирә. Шул чор җанлы халык теле материалын шактый тулы чагылдыруы ягыннан сүзлек зур әһәмияткә ия. Төрки телләр тарихында беренче аңлатмалы сүзлек булуын да искәрсәк, аның әһәмияте тагын да арта төшә.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң сүзлекләр төзү, бигрәк тә ике телдәге сүзлекләр төзү, аеруча киң җәелеп китә. Шуның белән бер үк вакытта аңлатмалы сүзлек өчен дә материал туплана килә, һәм озак та үтми, Җамал Вәлидинең зур хезмәте дөнья күрә. «Татар теленең тулы сүзлеге» дип исемләнгән бу сүзлекнең ике томы гына (I том — 1927, II том — 1928) басылып чыга һәм алфавитның 15 хәрефеннән башланган 11719 сүз бирелә. Сүзлекнең тарихи-лингвистик әһәмиятен билгеләп, анда иллюстратив материалның күплеген, байлыгын һәм төрлелеген аеруча басым ясап әйтү кирәк.

50 нче еллар уртасында аңлатмалы сүзлек төзү проектлары берсе артыннан икенчесе барлыкка килә тора. Н. Исәнбәтнең, Ф. Фасеевның кызыклы проектлары тәкъдим ителә. 1958 елда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеген төзүгә сүзләр җыю өчен лексикологик сораулык» басылып чыкты. Аны Ф. Фасеев төзегән һәм мөхтәрәм профессор Л. Җәләй редакцияләгән. Аерым төшенчәләрне атау буенча сораулыкларның ахырында искәрмәләр урнаштырылган. Ф. Фасеев аңлатмалы сүзлек төзүнең халык соравы буенча башкарылуын әйтә.

Һәм менә шушы ихтыяҗны канәгатьләндереп, соңгы 20 ел эчендә диалектологик, синонимнар, татарча-русча һ. б. дистәләгән сүзлекләр дөнья күрде. Инде көтеп алган аңлатмалы сүзлегебез дә укучылар кулына килеп керде.

Ә аңа хәтле күпме эш башкарыла әле... Аңлатмалы сүзлек төзү өчен хәзерлекнең иң беренче, иң әһәмиятле этабы — аның картотека базасын булдыру. Бу юнәлештә 1958 елдан 1963 елга кадәр системалы эш алып барыла (өлешчә ул әле дә дәвам иттерелә). XX йөз башы татар әдәбияты классиклары һәм хәзерге чор язучыларының әсәрләре (кайберләре — өлешчә) карточкаларга салына. Мәктәп дәреслекләре, политик һәм фәнни-популяр китаплардан, татар халык авыз иҗаты әсәрләреннән дә сүзләр туплана.

Мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар, телгә мәхәббәте, кызыксынуы зур булган аерым кешеләр ярдәме белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел секторында миллионлап сүздән торган картотека төзелде, «Хәзерге татар әдәби теленең аңлатмалы сүзлеген төзү инструкциясе» (Казан, 1964) басылып чыкты һәм турыдан-туры сүзлек өстендә эш башланды. Бу зур хезмәт 1970 елга әзерләнеп бетте. Аның I томы 1977 елда, II томы — 1979 елда, өченче том 1981

---

[1] Ф. Эрдман документлары Казан университетының А. Лобачевский исемендәге китапханәсендә, сирәк китаплар бүлегендә саклана (№ 4391).

[2] Халфин С. Татарский словарь, в пользу обучающегося при Казанских гимназиях юношества татарскому языку, сочиненный при оных же гимназиях, 1785. Бер нөсхәсе Казан университеты китапханәсендә саклана (№ 8782, 1 һәм 8782, 2).

[3] Словарь татарского языка и некоторых употребительнейших в нем речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии священника Александра Троянского, т. 1—2. Казань, 1833—1835.

елда басылып чыкты. Сүзлек төзү эшенә 7 ел, бастырып чыгаруга 12 ел, барлыгы 19 ел вакыт киткән. Беренче карашка, озак кебек. Ләкин аңлатмалы сүзлекләр төзү тарихына күз салсак, безнең сүзлекнең язмышы шактый бәхетле күренер. Мәсәлән, күренекле лексикограф Х. Касарес язганча, швед теленең тулы сүзлеген төзүгә 10 ел, бастырып чыгаруга 67 ел вакыт киткән. Ә бит аны эшләүдә 18 академик катнашкан! Дүрт томлык азербайҗан теле сүзлегенең I томы 1964 елда басылып чыккан иде. Калган томнарының әлегә күренгәне юк. Башкорт галимнәре аңлатмалы сүзлек эшләүне безнең телчеләр белән бер үк вакытта башлап җибәрделәр, һәм сүзлек әле үткән ел гына нәшриятка тапшырылды.

Сүзлек әзер, ул — халык кулында, сүзлек — хәрәкәттә, ул — халыкка хезмәттә. Академик В. В. Виноградов рус теленең аңлатмалы сүзлеген бәяләп болай дигән: «Туган телнең күп томлы, зур сүзлеген тәмамлау — һәрвакыт аның авторлары һәм төзүчеләре өчен зур вакыйга булганы кебек үк, шул телдә сөйләшүче халык өчен дә, гомумән бөтен җәмгыять өчен дә зур вакыйга булып тора».

Ф. Әмирхан «Тел мәсьәләсенә бер караш» (1908) исемле мәкаләсендә татар әдәби телен үстерү юнәлешендәге әһәмиятле проблемаларның берсе итеп «Мөкәммәл лөгать китабы» булдыру кирәклеген әйтә һәм бу юлда «бик күп, бик күп, бер дә мактау ишетелми торган хезмәтләрне күтәрергә, бик күп иҗтиһадлар сарыф итәргә туры киләчәктер» дип искәртеп киткән иде. Сүзлекчеләр коллективы әнә шундый мәшәкатьле, четерекле, авыр эшне үз җилкәсендә татып, нигездә, аны уңышлы башкарып чыкты.

Бу зур һәм мактаулы хезмәтне төзүдә зур өлеш керткән авторларның исемнәрен атап үтү, һичшиксез, кирәк булыр. Менә алар: И. А. Абдуллин, Г. Х. Ахунҗанов, С. Б. Вахитова, Ф. М. Газизова, Л. Р. Гайнанова, Ф. А. Ганиев, Р. Р. Мингулова, М. Г. Мөхәммәдиев, Р. К. Рәхимова, Ш. С. Ханбикова, Р. Г. Әхмәтҗанов. Күбесенең секторда эшләвенә 2 дистә елдан да артык. Хезмәтне редакцияләү кебек җаваплы эшне Л. Т. Мәхмүтова (фәнни җитәкче), М. Г. Мөхәммәдиев, К. С. Сабиров, Ш. С. Ханбикова башкардылар. Секторның лаборантлары Р. Р. Абдуллина һәм Н. Х. Зарипованың да бу хезмәттә игелекле өлешләре бар.

Хезмәтнең сүз башында әйтелгәнчә, сүзлекнең төп бурычы — «татар әдәби теленең XIX гасырның ахырыннан алып хәзерге көнгә кадәр гомумкулланылышта булган лексик һәм фразеологик байлыгын туплап бирү; сүзләрнең мәгънәләрен һәм мәгънә төсмерләрен ачу, аларга грамматик-стилистик характеристика бирү, кулланылыш үзенчәлекләрен күрсәтү». Шуның белән бергә сүзлектә билгеле бер күләмдә гади сөйләм сүзләре, жаргон сүзләр, этнографик сүзләр, тарихи сүзләр, диалекталь сүзләр, киң кулланылыштагы яңа сүзләр һәм терминнар да урын алган.

Аңлатмалы сүзлек төзүдә иң кыены — сүзләрнең мәгънәләрен, мәгънә төсмерләрен эзлекле, төгәл, тулы итеп ачу. Аңлатма өч төрле юл белән бирелә: тасвирлы аңлатма, синонимик аңлатма һәм икенче сүзгә кайтару. Сүзлектә бу таләп җиренә җиткереп үтәлгән. Мәгънәләр, нигездә, төгәл билгеләнгән. Төзүчеләр аерым сүзләрнең берничә дистә мәгънәсен таба алганнар: **табу** сүзенең 45, **төшү** сүзенең 66, **салу** сүзенең 61 мәгънәсе аерып бирелгән. Сүзләрнең теркәлмәгән мәгънәләре калмаган диярлек. Бик эзләсәң, шулай да кайбер мәгънәләрне күрсәтеп булыр иде әле: **дәрәҗә** — бәйлек сүз, **бастырма** — ашамлык, **мәйдан** — сабантуй (диалектларда), **милек** — бер гаиләнең каралтысы (диалектларда), **остазлык** — «наставничество» мәгънәсендә, **калак** — кашык (диалектларда), **такта** — бик ябык (гади сөйләмдә), **җилем** — җилен (диалектларда), **өстәлмә** — синтаксик термин, **яфрак** — мунча себеркесе (диалектларда), **шәй** — бугай (диалектларда), **урам** — өсте капланган ишек алды (диалектларда), **түңү** — йокыга китү (гади сөйләм) һ. б.

Сүзләрнең мәгънәләрен ачуга бәйле бер чагыштыру үткәреп карыйк. Чагыштыру өчен К. Насыйри, Җ. Вәлиди һәм рецензияләнә торган сүзлекне алыйк, кайбер сүзләргә мөрәҗәгать итик. К. Насыйри, мәсәлән, **тәмле** сүзенә синонимнар гына китереп аңлата: **тәмле — тәгамле — ләзиз — нагыйм.** Җ. Вәлиди мәгънә төсмерләрен аерып күрсәтә: «Тәмле — 1. Тәме бар (нинди булса да). 2. Ашар яки эчәр өчен ләззәтле — вкусный. 3. Гомумән ләззәтле: тәмле йокы «тәмле тел — күңелгә ягымлы, йомшак сүзләр: тәмле тел белән генә әйтәч бәлки тыңлар иде». «Аңлатмалы сүзлек»тә шул ук сүзнең тагын дүртенче мәгънәсе өстәлә һәм шактый фразеология аерып бирелә:

**тәмле корсак, тәмле тамак, тәмле тамаклану, тәмле тел, тәмле телле, тәмле теллелек, тәмле телләнү, тәмле телне бәясезләү.**

Яисә тел сүзен чагыштырып карыйк. К. Насыйрида ул 2 мәгънә белән теркәлә, Җ. Вәлиди бу сүзнең 5 мәгънәсен билгели һәм 52 фразеологик берәмлек һәм составлы термин китерә. «Аңлатмалы сүзлек»тә 13 мәгънә табылган һәм йөзгә якын фразеологик берәмлек һәм составлы термин урнаштырылган. Бу хәл бик табигый да, чөнки К. Насыйри сүзлеге — беренче адым, беренче тәҗрибә. Җ. Вәлиди сүзлеге төзелгән чорда да лексикография фәне, техникасы әле зур үсеш алмаган була. Өстәвенә 50—60 ел эчендә сүзләрнең яңа мәгънәләре дә барлыкка килгән.

Һәр сүзгә бирелгән грамматик һәм лексик характеристика төгәл һәм тулы эшләнгән. Грамматик билгеләр (пометалар) сүз төркемнәренең гамәлдәге классификациясенә нигезләнеп куелган. Сүзлектә исемләшү, сыйфатлашу, рәвешләшү кебек лингвистик терминнарның бирелүе телдә бер сүз төркеменең икенчесенә күчүе, шундый күчеш процессларының бик актив булуы турында сөйли. Грамматик характеристиканың әһәмияте бигрәк тә бер үк сүз берничә сүз төркеме мәгънәсендә, функциясендә кулланылган очракларда ачык күренә. Мәсәлән, **бер** саны сыйфат, алмашлык, исем, рәвеш мәгънәсендә һәм теркәгеч, кисәкчә функцияләрендә кулланыла икән. Яки **кирәк** сүзе: 1—4 мәгънәләрендә ул хәбәрлек сүз буларак тасвирланган; 5— сыйфат, 6, 7— исем мәгънәсендә, 8 — җыючы теркәгеч, 9— кире шарт теркәгечләре функциясендә. Әгәр тиешле грамматик характеристика бирелмәсә, бу сүзләрнең лексик-семантик, морфологик асылын объектив күзаллау кыен булыр иде. Еш кына сүзләр аерым грамматик формаларда теге яки бу сүз төркеменә күчеш алалар. Мондый очракта грамматик характеристика сүзенең лексик-грамматик һәм стилистик үзенчәлеген төгәлрәк, нечкәрәк ачарга ярдәм итә.

Стилистик характеристика теоретик яктан да, сүзлектән файдалану өчен дә бик зарури. Сүзләрнең кулланылыш сфераларына бәйле характеристика бирү зур урын тота. 1. Татар теленең гомумхалык лексикасына мөнәсәбәтле рәвештә җирле сөйләм лексикасы аерымланган. Без бу лексик катламның сүзлектә тиешле чагылыш табуын күрсәтеп үткән идек инде. 2. Татар әдәби теле лексикасына мөнәсәбәттә: а) сөйләү теле һәм гади сөйләм лексикасы; б) сирәгрәк булса да, тупас, жаргон, каргау, тиргәү, кимсетү сүзләре аерып күрсәтелгәннәр; 3. Эмоциональ-экспрессив сүзләргә характеристика бирелгән; 4. Функциональ стильләргә бәйле рәвештә китап теле сүзләре һәм терминологик лексика аерып чыгарылган; 5. Диахроник аспекттагы стилистик характеристика борынгы, тарихи һәм искергән сүзләрне аеруга хезмәт итә.

Күргәнебезчә, стилистик характеристика мәсьәләсе шактый күпьяклы һәм катлаулы эш икән. Әгәр татар тел белемендә лексикология буенча җитди теоретик хезмәтләрнең булмавын исәпкә алсак, төзүчеләрнең бу эштә нинди зур кыенлыклар кичерүе аңлашылса кирәк. Шуңа карамастан сүзлекнең өч томында да сүзләргә бирелгән стилистик характеристика, нигездә, тиешле югарылыкта башкарылган. Төгәлсезлекләр сирәк очрый. Мәсәлән, **бакырту** «кычкырып сугү, битәрләү» мәгънәсендә гади сөйләмгә карый. Анда **күч.** дигән билге генә куелган. **Кадалдыру** фигыленең күчмә (икенче) мәгънәсе **сөйл.** дип, кадалу фигылендә исә шул ук мәгънә **гади с.** дип күрсәтелгән. Соңгысы дөрес булырга тиеш. **Кризис** сүзе төп мәгънәсендә философик түгел, ә экономик термин. **Ыруг** сүзенең икенче мәгънәсендә **зоол.** урынына **биол.** пометасы куелса, төгәлрәк булыр иде, чөнки бу төшенчә хайваннарга гына түгел, үсемлекләр дөньясына да карый һ. б. Сирәк кенә булса да, стилистик характеристикасыз калган сүзләр дә очрый. Мәсәлән, **таб** — искергән сүз, **таңкучат** — этнографик сүз, **тигәнә, дуадык, елдырым, дучмак** һ. б.— диалекталь сүз дип билгеләнү кирәк иде. Стилистик характеристикасыз калган **ахмак, кәмәл, ден, таксист, ташкуран, тизлектә, тәмәйтү, тулыкны, хәтсез** һ. б. сүзләрне дә күрсәтергә мөмкин. Кайбер сүзләрнең искәрмәләре төгәл түгел, мәсәлән, **фломастер** — махсус термин түгел, **чертеж** — сөйләм теле түгел, **тәпәү** — диалекталь түгел, **шунлык белән** — искергән сүз түгел һ. б. **Тилемзәк, теләү, таргыл** һәм тагын кайбер сүзләргә сирәк искәрмәсен куюга караганда искергән дип билгеләү урынлырак булыр иде, чөнки һәрбер сүз борынгы бер мәкаль белән иллюстрацияләнгән.

Тулаем алганда, сүзләргә бирелгән грамматик һәм стилистик характеристика — сүзлекнең фәнни һәм теоретик әһәмиятен күтәрә торган уңышлы якларыннан берсе.

Сүзлектәге иллюстрация материалының муллыгы аеруча куандыра. Бу эшне башкаруга ифрат зур көч, күп вакыт сарыф ителүен махсус искәртеп үтмичә мөмкин түгел. Телнең җәүһәрләре дип йөртелә торган тотрыклы сүзтезмәләрне — фразеологик берәмлекләрнең күпләп бирелүе һәм уңышлы рәвештә эшкәртелүен дә сүзлек төзүчеләрнең тагын бер уңышы дип бәяләргә кирәк.

Моңа кадәр тәрҗемәле яки аңлатмалы сүзлекләрдә булсын, составлы терминнарны, тезмә фигыльләрне һәм фразеологик әйтелмәләрнең бер өлешен баш сүз мәкаләсе эчендә аның аерым мәгънәләре буенча таратып, калган өлешен ромб билгесеннән соң бергә аралаштырып биреп килделәр. Өстәвенә алар «үзәк компонент» принцибы буенча төрле җирдә, еш кына ике, хәтта өч урында теркәләләр иде. Инструкция төзегәндә бу мәсьәлә башкача — фәнни дөрес хәл ителде: составлы лексик берәмлекләр фразеологиядән аерып бирелгәннәр, фразеология ромб билгесеннән соң теркәлгән. Мәсәлән, **бүре җиләге, диңгез чабагы, кытай парусы, кыңгырау чәчәклеләр, саз карчыгасы, су тавыгы, солы чыпчыгы,** чәч гөле һ. б. фразеологиягә хәтле бирелгәннәр. Тюркологик лексикография практикасы өчен моның шулай хәл ителеше бик мөһим. Чөнки төрки телләрдә составлы терминнардан тыш, фразеологик ояга керми торган исем + ярдәмче фигыль (**ярдәм итү, тавыш бирү, эшкә ашыру, искә төшү, каршы чыгу**) һәм фигыль + ярдәмче фигыль (**карап чыгу, чыгып китү, үсеп җитү, кызарып китү** һ. б.) өлешләрендә ясалган тезмә фигыльләр дә бар. Сүзлектә беренче өлгедә ясалган тезмә фигыльләр система буларак теркәлгәннәр. Ә икенче өлгедә ясалганнарын, инструкциядә күрсәтелгәнчә, бик чикләп кенә алу каралган. Тәҗрибә характерындагы бу алым, әзлекле тормышка ашырылмаса да, аналитик характердагы лексик берәмлекләрне тулырак барлау юнәлешендәге уңай бер яңалык дип кабул ителергә тиеш.

Әлбәттә, һәр сүз янында да тезмә һәм фразеологик берәмлекләр булмавы бик табигый. Кайберләре янында тезмә берәмлекләр һәм, киресенчә, фразеология генә булуы мөмкин. Мәсәлән, **күңел** мәкаләсендә ромбтан соң 200 дән артык фразеология бирелеп, тезмәләр бөтенләй юк. Өч томга тупланган барлык шундый лексик фразеологик берәмлекләр саны 6317 һәм 7693 чагыштырмасында. Өченче томда хәтта тезмә лексик берәмлекләр саны фразеологиягә караганда күбрәк: 3501 һәм 2985.

Фразеологик берәмлекләрнең җәяләр эчендә вариант компонентларын бирүне дә уңай дип исәпләргә кирәк. Алар җыйнак һәм ачык күренеп тора, кабатлаудан коткара. Вариантларның кулланылышы да (сирәк очракларны исәпкә алмаганда) мисаллар белән тиешенчә ныгытылган.

Гомумән, теге яки бу сүз кергән фразеологизмнар нигездә теркәлгәннәр. Бик сирәк очракта гына теге яки бу тотрыклы тезмәләрне өстәп булыр иде: **кунак — кунак җыю, кунак ашы, корбан — корбан ашы, котлет — котлет ясау, кочак — кочагы белән, кесмән — кесмән кагу, лапта — лапта сугу, лапта уйнау, мал — мал түгел, панель — панельгә чыгу, пар — пар чыга, пәке — пәкеле уйнау, сер — серләре сыеша, кала — кала алу, тархан — тарханга чыккан** һ. б.

Бик кызык бер хәлне әйтеп үтик: татар теленә аерым сүзләр фразеология аша килеп кергәләр, фразеологияне калькалаштырганда килеп кергәләр икән. Сүзлек шул хәрәкәтне дә чагылдыра. Мәсәлән, **фиаско** сүзе **фиаскога дучар булу** дигән тезмә аша, **тога — кемнең дә булса тогасына төренү** тезмәсе аша килеп кергән. Сүзлек рус теленнән татар теленә калькалашкан фразеологик байлыкны да теркәгән. Әйтик, **тавис каурыйлары таккан карга, чуртан кушуы буенча** һ. б. мисалларның рус теленнән алынганлыгы һәркемгә ачык»: **ворона с павлиньими перьями, по щучьему велению.**

Тулаем алганда, бирелгән фразеологик байлык (**күз** сүзенең фразеологиясен бирү өчен генә дә сүзлекнең зур күләмле 8 бите кирәк булган!) аерым бер сүзлек тәшкил итәрлек һәм киләчәктә андый хезмәт басылып чыгар дип ышанабыз.

Искергән һәм борынгы сүзләрне сайлап алу һәм аңлату принциплары да ныклы бер тәртиптә эшләнә. Мондый сүзләр үзләренең мәгънә төсмерләрен тәгәл ача торган мисаллар белән бирелгәләр, шуңа күрә аларның кулланылышы һәм мәгънәләре дә шик тудырмый, уңай кабул ителә. Зур күпчелегенең сүзлек хәзинәбездә тиешле урын алырга хаклы икәнлегенә ышанасың. Берничә мисал китерик. **Алпар...** Алпарына күрә тулпары (50 б.); **Корапай...** Атның киеге — колан, кәҗәнең киеге — коралай

(156 б.); **Кулавыз...** Кулавызсыз юлга кергән юлдан язар (187 б.); **Китән...** Китән күлмәк киштәдә, киндер күлмәк киртәдә (113 б.) һ. б. Мондый сүзләрне **теркәү халык** тарихын, әдәби тел үсешен өйрәнү өчен дә кирәк.

Сүзлек төзүчеләр кайбер архаик берәмлекләрне теркәүне дә кирәк дип санаганнар. **Ту, тотык, тора, тон, тезе, тимсах, ташбасма, таразы, так, там, шиpт, чам, тәгам, нә, кәлү, күп-тин-күп, көндин-көн** һ. б. сүзләрне шундыйлар рәтенә кертергә була. Бик аз сүзләр генә хәзер инде бөтенләй кулланышта түгел һәм сүзлектә аларның урынсыз булуын да әйтеп узыйк: **тәрәддетләнү** (шикләнү), **тәнәззел итү** (түбәнсенү) һ. б.

Сүзлектә татар халкының мифологиягә, мәҗүсилеккә, дингә мөнәсәбәтле сүзләре (**гуҗ, дөлдел, пот, кук, нух, мәчкәй, убыр, хозыр-ильяс** һ. б.), гореф-гадәтләргә бәйле этнографик лексикасы (**кияү, кода, мәһәр, өчесе, җыен, таба-тапчык, таккаравыл, тамыр** һ. б.), сүзнең тылсымлы көче бар дип уйлауга бәйле эвфемизмнар (**корыботак, пурый, тегe дөнья, ташаяк мунчаласы, җиңел** һ. б.), жаргон сүзләр (**пәнҗеки, фиргавен, чистай малае** һ. б.), гади сөйләм сүзләре (**хөрти, чистый, чукынмыш, чумара, шпана, физмат** һ. б.) урын алуын да дөрес дип бәяләргә кирәк.

Ярдәмлекләр һәм мөстәкыйль сүзләрнең ярдәмлек функциясендәге мәгънәләрен ачудагы мәгълүматның информатив тулылыгын аеруча билгеләп үтәргә кирәк. Алар бик җентекләп өйрәнелеп, мәгънә чикләре ачык билгеләнеп, мисаллар нигезендә аңлатылганнар. Еш кына бу мәгълүматлар дәреслек һәм махсус тикшеренү хезмәтләрендәге белешмәләрне тулыландыралар, ачыклыйлар.

Мөстәкыйль сүзләрнең ярдәмче функцияләрен лексикалаштыру принцибы да игътибарга лаеклы. Фигыльләрдә, мәсәлән, ярдәмче функцияләре гадәттә иң соңгы итеп күрсәтелә һәм шул функциядәге мәгънәләр санап, аңлатып кителә. Һәр мәгънәгә тиешле иллюстрация материалы китерелә. **Китү** фигыленең, мәсәлән, ярдәмче функциясе 21 нче мәгънә булып бирелә. Шунда ул үзе бер сүзлек мәкаләсе тәшкил итеп, 11 мәгънәгә аерып карала.

Сүзлектә тагын бер үзенчәлеккә игътибар итәсең: лексикография практикасында беренче тапкыр буларак аваз ияртемнәре зур урын алганнар. Шулай ук биредә беренче тапкыр образ ияртемнәре дигән сүзләр дә теркәлгән (**җем-җем, ялык-йолык, елтыр-йолтыр** һ. б.).

К. Насыйри хезмәтләрендә, бигрәк тә «Әнмүзәҗ»дә, татар теленең парлы сүзләргә бай булуы турында укырга мөмкин. Сүзлектә парлы сүзләр зур төгәллек белән барланганнар һәм киләчәктә аларны структур-семантик яктан өйрәнү өчен зур материал тупланган.

Сүзләр кайсы хәрефтән күбрәк башлана икән соң? Сүзлек бу сорауга да җавап бирә ала. К хәрефенә 4894 сүз, Т — 3947, С — 1930, Б — 1876, П — 1749, А — 1650, М — 1630, Ч — 1483, И — 1304 сүз теркәлгән. Л, М, Н, О, П, Р, В, Г, Д, Ж, З, Ф, Щ, Ц авазларына башланган сүзләрнең иң зур күпчелеге алынма сүзләр икән, ягъни бу авазлар сүз башында бик сирәк кулланылалар.

Телләрнең сүзлек байлыгы үз сүзләре белән генә түгел, башка телләрдән кергән алынмалар белән дә билгеләнә. Татар теле көнчыгыш телләрдән, рус теленнән, аның аша көнбатыш телләрдән меңләгән сүзләр кабул иткән: **әкият, бүрәнә, чаң, әрдәнә, сәлам, пилмән, сумала, сер, шәм, миләш, поши, бәхет, халык, энҗе, чәй, тәрәзә, дару** һ. б. Алар телебезнең сүзлек составына күптән үтеп кергәннәр һәм аның фонетик системасына җайлашканнар. Сүзлек алынмаларның шушы бай хәзинәсен, татар теленең генетик катламнарын күзалларга мөмкинлек бирә. Алынма сүзләрнең чыганагы да күрсәтелсә, нур өстенә нур булыр иде, әлбәттә.

Яңа алынмалар чыганак телендәгечә дөрес теркәлгәннәр. Бары берничә очракта гына (мәс., **крага** урынына — **краги**, **сардина** урынына **сардин**, **маниока** урынына **маниок**) читкә тайпылу күзәтелә. Аерым алынмаларда басым да куелу хәзерге тел культурасын үзләштерү өчен бик уңай. Моны бәлки һәр сүзгә дә эшләргә кирәк булгандыр.

Сүзлек белән танышып чыкканнан соң, тагын бер нәрсәгә игътибар итәсең. Ул — сүзләрнең төрле вариантларында кулланылышы. Вариантларның бер өлеше гарәп, фарсы, рус телләреннән алынып, язма тел яисә сөйләм теле аша кабул ителүгә бәйле рәвештә төрлечә формалашкан: **кәшмир — кашмир, килки — килька, кәнфит — конфет,**

**кәрәчин — керосин, кәтлит — котлет, кәнител — канитель, карават — кровать** һ. б. Икенче төрләре сүзнең тарихи үсеше-үзгәреше җирлегендә туган: **карындаш — карендәш — кардәш, кыйлану — кылану, меңгерү — мендерү — менгезү.** Өченчеләре орфографик нормалар үзгәрүгә бәйле килеп чыккан: **Киреле-мырлы — кирле-мырлы, кайнана-—-каенана, кашык аяк — кашыгаяк** һ. б. Дүртенче төркем сүзләрнең әдәби һәм диалекталь әйтелеше нигезендә туган. Әйтелгәннәргә мисалларны тагын да дәвам итеп булыр иде.

Әлеге дублетлар яисә вариантлар еш кына яңәшә кулланылалар, телнең мөмкинлекләрен күрсәтеп торалар. Әмма бу сүзлек норматив сүзлек функцияләрен үтәү өчен дә хезмәт итәчәк бит. Теге яки бу вариантның кайсысын язарга, ничек әйтү дөрес булыр дигән сорауга җавап бирү җиңел эш түгел. Бу хәл татар теленең орфографик һәм орфоэпик нормаларының камилләшү процессын дәлилли һәм иң беренче чиратта орфографик сүзлек булмау белән аңлатыла.

Дөрес, вариантларны лексикографияләштерүдә билгеле бер эзлеклелек, принцип та сизелмәнә. Әйтик, телдә бердәйрәк активлыкта кулланыла торган вариантлар рәттән өтер аша гына бирелəләр. Мәсәлән, **консерв, консерва; малай-салай, малай-шалай** һ. б. (Әмма принциптан читләшеп, **туннель,** к. **тоннель,** яки **толпар** һәм **тулпар** кебек бер-берсенә ишарәсез бирелгән вариантлар да очрый.) Ә пассив яки диалекталь, искергән һ. б. вариантлар актив яки әдәби вариантларга җибәреләләр. Мәсәлән, **каторжан** и сөйл. к. **каторжник; колкенеч,** с. сир. к. **колкеле; рәсмият** и. иск. кит. к. **рәсмилек** һ. б. Бирелә дә сирәк кенә булса да, кайбер тайпылчыклар бар. Мәсәлән, **казәки, кәнител, сарыгу, татлану, төптә** (кереш сүз) һ. б. үзләренең әдәби, төп вариантлары **казаки, канитель, сарку, татлылану, төбендә** сүзләренә җибәрелергә тиеш иде. Ләкин алар бер-берсенә ишарәсез, мөстәкыйль аңлатма алганнар.

Сүзлек төзүчеләргә, редакторларга алынма сүзләр орфографиясе турында да уйланырга туры килгән һәм, башлыча, бу мәсьәлә тиешле фәнни дәрәҗәдә хәл ителгән. Ләкин төрле сүзлекләрдә язылыш төрлечә булганда, нишләргә соң? Ягъни кайсысы дөрес: **адәм — әдәм, табиб — табип, самум — сәмум, сәрви — сәрби, сәлам — сәләм, кровать — караватъ, гармонь — гармун, самавыр — самовармы!**

Аңлатмалы сүзлек телебездә совет чорындагы үзгәрешләрне чагылдыруы белән дә әһәмияткә ия. Бу үзгәрешләрнең түбәндәге юнәлешләре билгеләнә: иске сүзләрнең яңа мәгънәләре туа, телнең үз чаралары белән яңа сүзләр ясала, тел алынмалар исәбенә баый. Хәзерге татар телендә СССРда яшәүче барлык халыклар өчен уртак булган һәм политика, промышленность, авыл хуҗалыгы, культура һ. б. өлкәләргә караган зур бер катлам аерылып тора. Бу уртак хәзинә кешеләрнең яңа тарихи гомумилеге — совет халкы барлыкка килү белән бәйле, һәм ул тагын да арта, тулыланa бара.

Һәр әйбер, чагыштырып караганда, ачыграк күренә. «Татарча-русча сүзлек» (1966) белән чагыштырып караганда, сүзлек төзүчеләр бик күп яңа сүзләр теркәгәннәр. Мисал өчен, К хәрефенә — 800, Т — 1700, С — 400, Н — 400, Э — 234, Җ — 252, Х — 115, У — 94, Ә — 69, Ы — 53, Һ — 43 сүз өстәлгән. Күп еллар буе сүзлек төзү эше белән шөгыльләнүче галимнәр бик җентекләп, берәмләп, кадерләп сүзләрне теркәгәндә, кызганычка каршы, бу сүзлектә булган кайбер сүзләр керми калгалаганнар. Алар арасында бик еш кулланылышта йөргәннәре дә бар: **атлас, кадер-хөрмәт, чәүкә, хәрәм, үсмерчак** һ. б. ш. Бу сүзләрнең аңлатмалы сүзлеккә керми калуы, әлешчә, сүзлекнең күләме белән дә бәйледер, күрәсең.

Билгеле булганча, сүзлекләргә иң беренче чиратта әдәби телдә иң актив кулланылышта йөргән сүзләр кертелә. Сүзлек бу таләпкә, нигездә, җавап бирсә дә, кайчак бик тар махсус терминнар да очрап куя (мәсәлән, **лантоза, клемма, легислатура, легистамация, люфтклозет, пальпация, полиспаст, пьекса, пионола** һ. б.), күптән инде кулланылмый торган гарәп-фарсы алынмалары да теркәлә, тар диалектизмнар яисә вариантлар килеп чыга **(кылычбазлык, кырлангыч, кәгъбатулла, кыйхытлык, кәлү, көҗе, күрпә, ләим** һ. б.), кайчак теге яки бу автор телендә генә кулланылышыннан чыгып окказиональ лексика теркәлә: **кыйнашчы, күрәлү** сүзләре — Һ. Такташ, **өешык сүзе** — Ш. Камал, **кәкер-чәкер** — А. Расих җөмләсенә нигезләнеп кенә урнаштырылганнар.

Гомумән алганда, сүзлекне төзүчеләр, редакторлар татар телен тирәннән, һәрьяклап өйрәнгәннәр, тел фактларына хөрмәт һәм җаваплылык белән караганнар, халыкның иксез-чиксез сүз байлыгына карата кайгыртучан булырга тырышканнар. Нәтиҗәдә татар лексикографиясе тарихында тиңе булмаган уникаль хезмәт дөнья күргән. 345 басма табак күләмендәге (2032 бит) сүзлектә 47 мең сүз һәм сүзтезмә тупланып, тәртипкә салынып һәм аңлатылып бирелгән.

Китапның техник эшләнеше дә игътибарны үзенә җәлеп итә. Уку һәм файдалану өчен зарури булган уңайлык таләбе тиешле югарылыкта башкарылган. Бу уңайдан Татарстан китап нәшриятына, аерата аның фәнни-техник редакциясе хезмәткәрләренә рәхмәт сүзен әйтү кирәктер. Гадәти булмаган, техник яктан бик катлаулы шундый хезмәтне китап итеп җыю типография эшчеләреннән дә зур игътибар, түземлек таләп иткәндер. Аларның да бу кыйммәтле сүзлектә зур өлешләре бар.

Редактор һәм корректорларның эшен бәяләп, тагын бер нәрсәне әйтеп үтәсе килә: шундый зур күләмле эштә хаталар очрамый диярлек.

Сүзлек халык кулында, телнең хуҗасы кулында. Ул хәрәкәттә, тел төзелешендә катнаша, тормышның төрле өлкәләрендә хезмәт итүче белгечләргә хезмәт итә, иҗат интеллигенциясе, нәшрият, редакция хезмәткәрләре, укытучылар, радио, телевидение хезмәткәрләренең ихтыяҗларын канәгатьләндерә. Шулар белән бергәттән сүзлек зур фәнни әһәмияткә ия. Анда тупланган бай тел материалы семасиология, фразеология, икетеллелек, алынмалар, тарихи лексикология, этимология, тел һәм сөйләү культурасы, стилистика, сүз ясалышы һ. б. проблемаларны хәл иткәндә нигез булып торачак. Грамматика буенча язылачак фәнни хезмәтләр дә сүзлекне читләтеп уза алмаячаклар: һәр сүз контекст эчендә, билгеле бер төзелмә эчендә бирелә һәм бер сүз белән икенче сүзнең бәйләнеш мөмкинлекләре, ясалыш үзенчәлекләрен сүзлектән бик җиңел табып алырга мөмкин. Бер мөһим фактны билгеләп үтү дә җитә. Сүзлек төзү барышында секторда ике докторлык диссертациясе язылды: татар телендә сүз ясалышын тикшереп — Ф. А. Ганиев, татар теленең фразеологиясе буенча Г. А. Ахунҗанов фәннәр докторы дигән гыйльми дәрәҗә алдылар.

Аңлатмалы сүзлек — халыкның үткән һәм хәзерге бай тарихын чагылдыра торган кыйммәтле хәзинә, тулы бер дөнья. Аны чын мәгънәсендә халык тарихының көзгесе дип бәяләргә була.

Төрки лексикографиясендә яңа зур казаныш булган «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» СССРда яшәүче башка халыкларның сүзлекләрен төзүдә дә үрнәк булыр дип ышанасы килә.

# СЕЗ БИК КАДЕРЛЕ БЕЗГӘ...



Ул менә кырык елдан артык инде балалар әдәбияты өлкәсендә актив иҗат итеп килә. Бала күңеленең нечкә шигъриятен тоеп язылган хикәяләре, повестьлары, пьесалары, шигырьләре белән Әминә Бикчәнтәева күптән нәниләрнең яраткан язучысына әверелде. Ул күпкырлы иҗаты белән татар балалар әдәбиятын үстерүгә, инде берничә буын балаларын матур күңелле чын кешеләр итеп тәрбияләүгә мактаулы өлеш кертте.

Әдибәнең бөтен иҗатын колачлап җентекле анализ ясауны һәм гомуми бәя чыгаруны максат итеп куймастан, аның конкрет бер жанрдагы эшчәнлеге— шигъри әсәрләре турында сөйләшәсе килә.

Әминә Бикчәнтәеваның балалар шагыйре булarak төп көче, үзенчәлеге — бала психологиясенә үтеп керә алуында, балаларча уйлый, күрә-тоя белүендә... Һичшиксез, биредә шагыйрьнең хатын-кыз, ана булуы да, озак еллар тәрбияче-педагог буларак балалар арасында кайнавы да, тормыш тәҗрибәсе дә зур роль уйный торгандыр. Әмма бу — барыннан да элек табигать бүләге, табигать тарафыннан бирелгән сирәк очрый торган сәләт — бала җанына үз булып үтеп керә алу сәләте. Һәм менә шушы үзлекнең шигърият белән кушылуы авторны иҗади ачышларга алып чыга да.

Әминә Бикчәнтәеваның «Бабай һәм малай» шигырендә «ап-ак сакаллы бабай таягына таянып» бәләкәй оныгын мәктәпкә озата килә. Звонокның яңгыравы була,

Йөгереп классына
Керде дә китте малай.
— Әй улым, улым!..— диеп,
Елмаеп калды бабай...

Шушы берничә юлда безнең күз алдыбызда бабай һәм малайның конкрет сурәте җанланып китә. Автор үзенең төп герое — баланың кем булуын яхшы белә: ул гамьсез дә, шаян-шук та, бәхетле дә, азрак кына иркәрәк тә... Шагыйрә аны бабасы күңеле аша билгеле бер контраст, диалектик үсеш каршылыгына куеп, тагын да калку итеп рәсемләүгә ирешә. Бабайга, чыннан да, баш чайкап уйланырга, әлеге сабыйга карап кызыгырга җирлек бар монда. Бәлки шуңадыр ул тиз генә кайтып китәргә ашыкмый:

Сиксән яшьлек бабайның
Малай буласы килә...
Мәктәпләрдә укыйсы,—
Белем аласы килә.

Янәшәдә торган олырак яшьтәге балалар бабайның эчке уй-кичерешләрен әнә шулай күзаллыйлар. Әлбәттә, аның күңел үзгәрешен үзләренчә тотып алып, үзләренчә аңлатулары белән алар хаклы. Әлеге балалардан башкачарак: киңрәк, тирәнрәк фикер йөртүче укучылар да үзләренчә хаклы булачак...

Бабайның оныгын озатып калуы очраклы бер күренеш кенә түгел. Бу — реаль чынбарлык. Бу — буыннар, заманалар очрашуы һәм аларның аерылышулары... Шигырьдә без берьюлы берничә үсеш дәрәҗәсендә торган бала белән очрашабыз: беренчесенең сүз кыска — керде дә китте... Бу штрих аның турында барысын да сөйли. Икенчесе бабайның халәтен күзәтеп, аңа үзенчә аңлатма бирә, ягъни шигырь аның исеменнән тасвирлана. Монысына укучы бала үзе дә кушылырга мөмкин. Инде лирик геройның сүзләренә ул елмаеп куя икән, димәк, тормышны аңлауда тагын да алгарак киткән дигән сүз. Автор, әнә шулай берьюлы берничә төрле балалар психологиясенә үтеп керә һәм алар булып уйлый, фикер йөртә ала.

Бу уңайдан Ә. Бикчәнтәеваның тагын «Камил елкага килде» шигырен күздән кичерик:

**Камил әле бик кечкенә —**
**Үрмәләп йөри иде.**
**Ә менә бүген елкага**
**Ул тәпи-тәпи килде.**

**Әттә-тә, әттә-тә,**
**Камил йөри башлаган.**
**Безнең Камил яңа елны**
**Тәпиләп каршы алган.**

Күрүебезчә, шигырьдә без Камилне канатландырып, үзе дә сабыйларча сөенеп торган икенче бер олырак бала белән дә очрашабыз. Әлбәттә, хикмәт авторның берьюлы берничә геройны күрсәтә алуында гына түгел. Хикмәт — баланың конкрет тормыш күренешеннән шигъри гомумиләштерүгә килүендә. Хикмәт — авторның кечкенә генә тормыш деталеп (тәпи йөрүне) шигъри телгә (Яңа елны тәпиләп каршы алуга) күчерә белүендә.

«Куыш уйнаганда» шигырендә без балалар уенының җанлы картинасы белән очрашабыз:

**Әлдермеш, гөлдермеш,**
**Кылтыр-мылтыр йөгермеш,**
**Ары-бире борылыш.**
**Тота алмыйча егылмыш...**

Китерелгән өзек шулай ук Ә. Бикчәнтәеваның сүз белән шигъри рәсем ясый алу сәләтен бик ачык күрсәтә. Әмма бу читтән карап ясалган рәсем түгел, бу — куышлы уйнаган балаларның рухи халәтен, уй-кичерешләрен гәүдәләндергән күңел сурәте...

Сабыйлык һәм шигърият Ә. Бикчәнтәева иҗатының аерылмас юлдашы. Аның шигырьләрендә табигатьтәге һәрнәрсә җанлана, телгә килә; аларның рәсеме — нәкъ бала күзаллавынча, аларның теле — нәкъ бала сөйләшкәнчә... Биредә без һәрнәрсәгә бала күзе, бала җаны аша карый башлыйбыз, һәрнәрсәне бала күңеле аша үткәреп уйланабыз, сөенәбез... Әлеге шигырьләрдә еш кына табигать белән баланың беренче очрашуы, беренче тапкыр сөйләшергә-аңлашырга омтылуы тасвир ителә. Алар бала күңелендә гомерлек якты эз, шатлык, шигърияткә мәхәббәт хисе уята.

Әнә, яшел чирәмдә «сары күлмәкле» йомры каз бәбкәләре, алар әниләренә ияреп су буена килгәннәр... Алар белән ничек сөйләшмәскә мөмкин?.. Әнә — «ландышлардан уздырып» умырзая калкып чыккан,— аларны ничек күрми үтәсең. Һәрнәрсә сөйләшә, һәрнәрсәнең үз мәгънәсе бар:

**Биек нарат башында**
**Тук-тук итә тукран.**
**Апа әйтә, ул шигырен**
**Өйрәнергә утырган...**

Бала җаны һәм тәне белән табигать эчендә. Ул туктаусыз күзәтә, табигать белән аңлашырга җай эзли. Әнә, «тәпиләре туңса да», урамга песи малае чыккан. Сөйләшми ничек түзсен — бала аның янына килә:

Яз җиттеме дип сорадым
Мин песи баласыннан,—
Ул йөгерде сорарга дип
Үзенең анасыннан...

Әлеге юллар — гади күзәтү генә түгел. Аларда — шагыйрьнең бала психологиясен ни дәрәҗәдә нечкә тоюы.

Табигатьне сөйләштерү, аның белән уртак тел табу ансат эш түгел. Сары эшләпәле көнбагышлар күзләрен җем-җем иттерәп гел кояшка карап торалар, ә балалар белән сөйләшү исләрендә дә юк:

Көнбагышлар, көнбагышлар,
Безгә дә күз салыгыз.
Сезне күрергә килгән ич
Кечкенә дусларыгыз...

Мондый сөйләшү-диалогларны Ә. Бикчәнтәева иҗатында күп табарга мөмкин. Аларның кайберләре бала өчен шигъри танып белү чарасы булса, кайберсе авторга тәрбияви фикер әйтүгә ярдәм итә. Әйтик, колын «син яшь бит, чабып аякларың талмасын» дигән балаларга: «ничек мин зур үсәрмен, көн буена тик ятсам...» дип җавап кайтара. («Колын»). Г. Тукай иҗатында очраган мондый сөйләшүләр традициясен шагыйрә әнә шулай үстерә — шигъри сүзен балаларга аларның үз телендә җиткерүгә ирешә.

Ә. Бикчәнтәева балалар тормышын уен аша күрсәтүгә зур игътибар бирә. Биредә бала психологиясе билгеле бер уен шартларына бәйле тестә, конкрет шөгыль-хәрәкәт, сүз-фикерләү ярдәмендә чагылыш таба. Шуңысы игътибарга лаек, мондый шигырьләрнең күбесендә бала олыларга охшарга, чын тормышка якынаерга тырыша. Уен детальләре еш кына тәрбия элементлары белән үрелеп килә.

Профессия сайлап уйнау — Ә. Бикчәнтәева иҗатында аерым урын алып тора. Әйтергә кирәк, шагыйрә, үскәч мин шундый-шундый кеше булам дип белдергән шигырьләр язу белән артыграк та мавыга кебек.

Хикмәт, әлбәттә, профессияләрнең күплегендә түгел, хикмәт — әлеге шигырьләрнең бер-берсен кабатлауларында, еш кына табышсыз кабатлауларында. Ә бит шигырь һәр очракта индивидуаль бала психологиясе үзенчәлекләрен исәпкә алып иҗат ителсә, аның эстетик кыйммәте дә, тәрбияви көче дә башкача булыр иде. Балалар шагыйрәнең көче дә шунда түгелме соң?.. Бу уңайдан «Язарга өйрәнгәндә» шигырен генә алыйк:

Әлифбаны карадым,
Бар хәрефне таныдым...
Авылга хат языйм әле —
Бабамны бик сагындым.

Өлкәннәргә охшарга тырышып, аларча эре генә итеп сөйләп куйган бу баланы исә башка берничи герой белән дә бутамыйсың — шул кабатланмас җанлыгы белән үзен яраттыра да ул.

Ә. Бикчәнтәева шигъри сүз белән бала тәрбияләүнең төрле алымнарын табарга омтыла. «Әлфия алъяпкычлары» шигырендә ул, әйтик, ак һәм кара алъяпкычның һәркайсының үз вазифасы, үз урыны булуын бәхәс формасында күрсәтеп бирә. Автор кайчакта тәнкыйть-сатирага да күчә. «Илгизәр кесәсе», «Гөлбикә», «Әйтмим» дип әйтмәс идем» шигырьләре шундыйлар.

Конкрет һәм гади итеп фикер йөртә белү Ә. Бикчәнтәевага «бүген», «иртәгә» кебек абстракт төшенчәләрне дә бала күзаллырлык детальләр аша ачу мөмкинлеге бирә.

Бүген мин өйрәндем әнидән
Кулыма тотарга инәне.
Иртәгә мин үзем тегәрмен
Күлмәктән өзелгән төймәне...
(«Бүген һәм иртәгә»).

Бүген абыйсы тырышып дәресен әзерли, иртәгә аңа дәресен «5»легә билгеләндә күңелле булыр: бүген ул гөлләргә су сибә, иртәгә аларның бөресе ачылыр,— гөлләре ямь бирер. «Бүген — иртәгә» шул рәвешчә конкрет мәгънә алып — аздан күпкә, кечкенәдән зурга үсә баручы күренеш-детальләр аша ачыла. Алар «бүген» белән «иртәгә» кебек үк үзара бәйле һәм бер-берсенең дәвамы булып тора. Бу — яшәү бәйләнеше. Тырышканда, кеше иртәгене бүгеннән матуррак итә ала, диган фикер балага әнә шулай җиткерелә.

Ә. Бикчәнтәева балаларча конкрет детальләрне социаль фикер әйтү өчен дә куллана. Ул бала белән күзгә-күз карашып сөйләшергә ярата. Бу очракта шагыйрә балага үзенең фикерен җиткерерлек бирәр шигъри деталь тотып ала:

**Анаң сине сөеп, иркәләп,**
**Күкрәгенә кыскан чагында,**
**Син хәтерлә: партиябезнең**
**Җылысы бар аның канында.**

Инде шагыйрә күмәклек исеменнән, гомумән балалар турында, гомумән балаларга атап яза башладымы — ул көчсез. Шигырь юллары тоныклана, анда фикер яңалыгы да, шигъри очкын да сүнеп кала:

**Ал галстук муеннарда**
**Җилферди җилгә.**
**Үсәбез хезмәт итәргә**
**Без туган илгә...**

Авторның тематик кабатлануы да башлыча шундый шигырьләренә карый. Гомуми тасвир, гомуми сүзләрдән качып, шагыйрә конкрет бала турында яза башлый икән — эш шундук үзгәрә: ул үзенең героена хас детальләрне дә ым-хәрәкәт, сүз һәм фикерләү үзенчәлекләрен дә бик ансат табып ала. Автор шундый әсәрләре белән көчле дә.

Менә аның инде ничә буын балалары күңелдән сөйләп йөргән «Дәү әнием» шигырен искә төшерик. Бала монда әби турындагы әзер сүзләрне тезеп кенә чыкмый. Ул аңа карап үрнәк ала, уйлана, аны ярата һәм аның белән горурлана.

**Өйдә аны һәммәбез**
**Яратабыз, сөябез:**
**Син бик кадерле безгә,—**
**Озак яшә,— диябез.**

Шигырь шушы матур теләкләр белән тәмамлана. Әмма андагы җылылык, үзеңә якын кешене ярату хисе, ул тудырган сөенеч һәм бәхетне тоеп яшәү тойгысы күңелдә югалмый... Шагыйрә иҗат иткән шигъри балачак дөньясы безне әнә шулай гомер буена бәхетле итә.

Шуңа күрә дә бу юбилей көннәрендә нәниләр шигъриятенең әлеге «матур гөлләр үстерүче», «өебезнең нуры»на әверелгән, сабый җанлы, «ак ефәктәй чәчле» «дәү әнисе»— Әминә Бикчәнтәеваның үзенә дә миллионлаган укучылары исеменнән рәхмәтебезне белдереп: «Син бик кадерле безгә,— озак яшә!» диясе килә.

**Равил КУКУШКИН.**

# ХӘКИМҖАН ХАЛИКОВКА 50 ЯШЬ



Хәкимҗан Халиков — балалар шигыре өлкәсендә актив эшләүче шагыйрьләребезнең берсе. Әдәбиятка ул мәктәп, балалар дөньясын яхшы белеп килде: беренче шигырьләрен Арча педучилищесында укыганда ук яза башлаган Хәкимҗан шактый вакыт туган ягында укытучы булып эшли, балалар психологиясен тирәнтен өйрәнә. Ә инде Казанга килеп, тугыз ел буе «Ялкын» журналында (ул анда мәктәпләр бүлеге мөдире булып эшли), аннары җиде ел «Яшь ленинчы» газетасында эшләгәндә ул ныклап иҗат итә башлый. Беренче шигырьләре «Җырчы чишмә» (1963), «Яшьлек таңы» (1964), «Кайнар хисләр» (1966) кебек коллектив җыентыкларда басылган шагыйрьнең 1969 елда «Йолдызлар ничәү» исемле мөстәкыйль китабы дөнья күрә. Нәниләрнең тормышын, аларның уй-хисләрен яхшы аңлаучы Х. Халиков дөньяга алар күзе белән дә, педагог күзе белән дә карый белә, шуңа күрә дә аның шигырьләрен укыганда балалар бакчасы яки ачык класс кебек, шау-шулы, җанлы, кызыклы дөнья белән очрашасың, төрле характерлар, вакыйгалар белән танышасың. «Шук бабай» (1970), «Тынычлык гөле» (1971), «Энәбикә» (1973), «Озын колаклы батыр» (1974), «Октябрятлар шәһәре» (1975), «Эшләпәле дуслар» (1976), «Уйныйсың киләме?» (1980) кебек китаплары әнә шуңа күрә дә укучылар тарафыннан яратып кабул ителде.

Х. Халиков әсәрләре рус һәм илебездә яшәүче башка халыкларга да таныш. Аның 1977 елда Казанда чыккан «Конфетное дерево» исемле русча китабы турында үзәк һәм җирле матбугатта берничә уңай рецензия басылды. Шагыйрьнең кайбер шигырьләре чит телләргә дә тәрҗемә ителгән.

Бу айда 50 яшен тутырган шагыйрьне күп санлы журнал укучыларыбыз исеменнән котлап, аның нәниләр өчен берничә яңа шигырен тәкъдим итәбез.

## Хәкимҗан Халиков

### Рәхим итегез!

Ап-ак кар явып тора,
Миңа эш табып тора.
Эш нәрсә соң миңа ул?—
Физзарядка гына ул.

Иртүк көрәк алам мин,
Якты сукмак салам мин.
Әйдә, рәхим итегез,
Үтегез!

Урамнар көлеп торсын,
Кешеләр йөреп торсын,
Аяклары талмасын,
Юл йөргәндә армасын.

Олыга һәм кечегә —
Юл салам бар кешегә.
Әйдә, рәхим итегез,
Үтегез!

Җилкенгәнгә йөрәгем,
Уйнап тора күрәгем:
Бертуктаусыз кар ата,
Эшен ул да ярата.

Арымасын кулларым,
Чиста булсын юлларым...
Әйдә, рәхим итегез,
Үтегез!

## Кышкы җырчылар

Кышкы юлда җыр ишеттем
Солы чыпчыкларыннан,
Зең-зең итеп сибелде ул
Нәни томшыкларыннан.

Сүзләре дә истә әле:
Сайрадылар «зин-зин...» дип.

Әйтүләре булды микән
«Юлда ешрак йөр син» дип?..

Җыр яңгырый, куган кебек
Кышның кар-бураннарын...
Бер якта торсын ул синең
Көмеш кыңгырауларың!

## Хатлар ташыйм

Апам белән бергә
Хатлар ташыйм, хатлар.
Сөенсеннәр яшьләр,
Сөенсеннәр картлар.
Апам белән бергә
Хатлар ташыйм, хатлар.

Җылы хәбәр кирәк
Бөтен кешегә дә.
Бер хат килсен иде
Безнең күршегә дә.
Җылы хәбәр кирәк
Бөтен кешегә дә.

Күрше әби көн дә
«Уң булсын, ди, юлың».
Дошман аткан аның
Чик саклаган улын...
Күрше әби көн дә
«Уң булсын, ди, юлың».

Языйм микән әллә
Хатны аңа үзем?
Әбекәй хат көтә,
Мөлдерәтеп күзен.
Языйм микән әллә
Хатны аңа үзем?

## Безнең әни кебек икән!

Алып төшкән идем генә
Үрдәкләрне тау астына,
Болыт килә башлады да —
Сыздым тизрәк тал астына.

Әнкә үрдәк, әнкә казлар,
Көткән кебек шуны гына,
Һәркайсы үз бәбкәләрен
Җыеп алды куенына.

Китте яңгыр. Ява, малай,
Нәкъ чиләкләп койган сыман.
Ә юкәдә бер кызылтүш
Кымшанмый да оясыннан.

Китәр иде — куенында
Бар шул аның нәниләре...
Безнең әни кебек икән
Кошларның да әниләре.

# КАНАТЛЫ МАЛАЙЛАР, КАНАТЛЫ ШИГЫРЬЛӘР

«Күңелле сәфәр» (1976) исемле китабыннан соң Шәүкәт Галиевнең балалар өчен татарча китап чыгарганы юк иде. Берничә ел узды. Ләкин шагыйрьнең яңа китапларының булмавы бөтенләй диярлек сизелмәде. Балалар аның элек язган китапларын укый тордылар, чөнки чын шигърият искерүне белми. Чын шигырьнең искесе дә, яңасы да булмый. Ә Ш. Галиевнең шигырьләре нәкъ әнә шундый сыйфатка ия. Инде шушы озын тәнәфестән соң шагыйрьнең яңа китабы дөнья күрде. «Канатлы малай»[1] исемле ул. Шигырьләре дә канатлы малайлар, кызлар турында, балаларыбызның кызыклы, бай дөньяларына багышланган.

Кайда соң ул, нинди соң ул **балалар дөньясы!** Бик күп алар: балалар бакчалары, мәктәпләр үзләре бер дөнья. Футбол, хоккей командалары үзләренә бер дөнья. Тагын бик күп дөньялар... Мин белгән тагын бер кызыклы балалар дөньясы бар. Ул да булса, Шәүкәт Галиевнең балалар шигърияте. Мөмкин булса, шагыйрь иҗатының капкасына мин зур итеп: «Балалар дөньясы» дип язып куяр идем.

Балалар дөньясы дигәннән, безнең балалар поэзиясе, күпме генә алга китмәсен, чын балалар дөньясын күп очракта әле һаман бер читтә калдыра килә. Кайсыбер шагыйрьләрдә ул, иң күп дигәндә, аерым бер баланың дөньясы гына булып кала. Бер баланың дөньясы да бик күп, әлбәттә. Әмма кайбер шагыйрьләр шул бер дөньяга да үтеп керә алмыйча интегәләр. Балалар дөньясыннан башка гына балалар шигыре язу — ул инде балаларны яратмау, хөрмәт итмәү белән бер. Ә фантазиягә, уен-көлкегә, хәрәкәткә бай балалар дөньясы гаҗәп күпкырлы, бер-берсенә һич тә охшамаган, бер-берсен бер генә дә кабатламаган малайларның-кызларның уй-хыяллары, шөгыльләре санап бетергесез. Балалар дөньясында бәйрәмнәр дә, шатлыклар да, борчылулар да — барысы да җитәрлек. Ш. Галиев менә ничә еллар инде әнә шул бәйрәмнәр, шатлыклар һәм борчылулар белән бергә яши.

Дөрес, балалар замана белән бергә үзгәрә тора. Шулай ук шагыйрь дә аларга карап үзгәрә. Бер караганда, ул без белгән элекке Шәүкәт Галиев: шундый ук осталык, тапкырлык, виртуозлык. Икенче караганда, ул инде өр-яңа Шәүкәт Галиев: темалары, күтәрелгән проблемалары, балалар дөньясына карашы яңа. Аның шигырьләрендә темалар җитдиләнә, ә чынында, моңа кадәр балалар әдәбиятында күтәрелмәгән, дөресрәге, балаларныкы исәпләнмәгән проблемалар калкып чыга. Арада тетрәндерә торганнары да еш очрый. Китап битләренә үзеннән-үзе «фаҗига» төшенчәсе килеп керә. Бәлки, балалар шигырендә ул чаклы җитди әйберләр кирәкмидер дә. Ни дисәң дә, алар балалар күңеленә авыр тәэсир итәргә мөмкин. Бик мөмкин. Һәрхәлдә, балалар поэзиясендә мондый җитди темалар әлегә чаклы күренмәде. Ә кирәк иде! «Ялгыш адым», «Әни дим, әчмә инде!», «Куркыныч хәбәр», «Күзгеләр көлеп тора» шигырьләрен генә алыйк. Без трамвайга, машинага тагылып йөрүче малайларны тәнкыйтьләп күп яздык. Мәкаләләр дә, хикәяләр дә, шигырьләр дә... Ләкин алар да «Ярамый!»дан узылмады. «Ялгыш адым» исемле шигыредә исә берничә генә юлда шул шаянлыкның ачы нәтиҗәсе күрсәтелгән. Кайчандыр трамвайга асылынып барган малай култык таягына таянган. Авыр шигырьме? Авырын авыр, әмма күңелгә үтә торган, истә кала торган, сабак бирә торган шигырь.

«Куркыныч хәбәр» шигырендәге бала-

[1] Шәүкәт Галиев. Канатлы малай. Балалар өчен шигырьләр. Казан, 1982 ел.

лар «Эт атучылар килә!» дигән коточкыч хәбәр ишетәләр. Аларның яраткан маэмайлары — Сарбайны атарга киләләр! Малайлар-кызлар күпмедер вакыт эчендә булачак фаҗиганы көтеп яшиләр: куркышалар, борчылалар, елыйлар, дулкынланалар. Кыскасы, тормышта беренче тапкыр батырлыкка «бик зур сынау тоталар». Алар инде Сарбайны яклап калырга — беренче тапкыр зур батырлык эшләргә дә әзер булалар. Бәхеткә каршы, эт атучылар килми кала.

«Көзгеләр көлеп тора» шигырендә автор гаиләдәге мещанлык күренешләренең балалар күңеленә нинди авыр яра салуын сурәтли. Димәк, балалар шигъриятендә дә гомумәдәбият күтәрә торган мөһим проблемаларны, җанны борчыган, дулкынландырган теләсә кайсы мәсьәләне, күренешләрне, вакыйгаларны күтәреп чыгарга мөмкин икән.

Шигырьләрдә без китапның төп герое, малайларның-кызларның яраткан дусты Шәвәли белән кабаттан очрашабыз. Ул хәзер молдаван язучысы С. Вангели хикәяләрендәге Гугуце, В. Драгунский хикәяләрендәге Денис шикелле үк мәгълүм геройга әверелде. Нindирәк соң ул? Үзгәргәнме? Юкмы? Беренче карашка, ул шул ук кебек: шаян, тапкыр, кыен хәлләрдән җиңел генә чыга белә, өстәвенә, тел бистәсе. Ләкин ул инде элекке шикелле генә түгел. Аңа хәзер батырлык сыйфатлары да хас. Минем үземә «Батыр булам» шигыре охшады.

**Мин үскәч һәйкәл булам,**
**Батыр булам,**
**Муса Җәлил янында**
**Басып торам!**

Югыйсә, дүрт юллык гади генә шигырь үзе. Әллә ни шаккатырлык шигъри табышлары да күзгә бәрелеп тормый. Әмма анда баланың күңелендә йөргән, кычкырып әйтелми торган изге бер хыял ярылып ята: «Үскәчтен **«батыр булу!».** Шундый ук хис, теләк «Дөресе» исемле шигырьдә дә бар. Шәвәли шактый үскән, шагыйрьнең үзе төсле үк житдиләнгән, бик күп дөнья күргән. Хәзер ул, шагыйрьнең үзе әйткәнчә, «биш-унбиш арасында яши».

Китапның «Шәвәли сәяхәте» дигән бүлеге географик яктан кызыклы. Ул интернациональ дуслык, тынычлык, туган җиргә, Туган илгә мәхәббәт хисләре белән сугарылган шигырьләрдән гыйбарәт. Менә «Безнең йорт малайлары» исемле шигырь. Ишегалдына Сашалар, Азатлар, Фәритләр җыелган. Аларның әти-әниләре Алжир, Куба кебек илләрдә эшләгәннәр. Малайлар әле генә алар белән бергә шул илләрдән кайтып төшкәннәр икән. Шигырь болай тәмамлана:

**Онытмас дуслар булгач,**
**Хатлар килер кайдан да;**
**Чыкты ишегалдыбыз**
**Халыкара мәйданга!**

«Телләр белүче каләм», «Тыныч диңгез», «Әстерхан карбызлары», «Себер җылысы», «Шундый зур туган җиребез» кебек шигырьләрдә географик киңлек яңа шигъри киңлекләргә юл ачкан. Әгәр җиренә җиткереп язсаң, кайсы тема да балага аңлаешлы һәм кирәкле тема булуын шагыйрь биредә тирәнтен аңлап эш итә. Тема дигәннән, «Халыкара хәлләр» шигырендә шагыйрь шул хакта яза да:

**Мөдир, клубка**
**Юлны киртәләп:**
**— Мондый тема,— ди,—**
**Сезгә иртәрәк!**

**Юкка буталып**
**Йөрмәгез кичен,**
**Кайтып әйтегез —**
**Өлкәннәр кипсен!**

. . . . . . . . .

**Теге якта да**
**Малайлар уйный,**
**Безгә төбәгән**
**Мылтыгын куймый...**

**Иртә дә түгел,**
**Һәм соң да түгел,**
**Аңларга кирәк**
**Миңа нәкъ бүген!**

Шагыйрь үзе генә түгел, лирик герой да яңа темалар даулый. Һәм бик хаклы рәвештә.

Шулай да Ш. Галиев чын мәгънәсендә, туган як шагыйре, балаларыбызның үз шагыйре. Миллилек малайларга түбәтәй кидереп куюда гына чагылмый, билгеле. Түбәтәйләрне кидертсә дә, малайларга түгел, кыярларга кидертә ул. Аның миллилеге шигырьләрнең рухында, тукымасында.

Шагыйрьне социаль үзгәрешләр: табигатьне саклау, авыл-шәһәр, балалар-өлкәннәр проблемалары кызыксындыра. «Колын бара каладан», «Машина ясыйм», «Ат «йөртүче» малай» кебек шигырьләр шул яктан караганда игътибарга лаеклы. Малай машина ясарга ярата. Аңа әтисе дә, әнисе дә машина ясаша. Тик бабасы гына катнашмый, чөнки машина ясый белми. Шуңа күрә дә ул ат кына ясый. Икенче шигырьдә кала буйлап баручы колын сурәтләнгән. Малайларга — тамаша. Алар колынга чит бер планетадан төшкән чит бер җан иясенә караган кебек карап калалар.

Шунысы характерлы, шагыйрь аерым бер темага дип атап язмый. Аның билгеле бер даталарга, бәйрәмнәргә багышлап язылган шигырьләре бөтенләй диярлек юк. Шуңа күрәдерме, аның шигырьләре мәктәп дәреслекләрендә сирәк очрый. Ләкин безнең хөрмәтле дәреслек төзүчеләребез игътибар беләнрәк карасалар, ул шигырьләр үзләренә берьюлы берничә теманы, берничә максатны сыйдырганнарын күрерләр иде. Ш. Галиев шигырьләренең күбесе — **темалар синтезы**. Шул ук «Ат «йөртүче» малай» шигырен генә алыйк. Ул, нигездә, техникадан башканы белмәгән шәһәр малаеның, авылга кунакка кайткач, беренче тапкыр ат белән танышуы хакында. Биредә табигатькә, анда яшәүче җан ияләренә мөнәсәбәт тә, әхлак мәсьәләсе дә, кешелек сыйфатлары тәрбияләү проблемасы да, авыл һәм шәһәр малайлары арасындагы дуслык та, хезмәткә хөрмәт тә бар. Шигырь әлеге проблемаларның барысын берьюлы эченә алган. Бер шигырь өчен күбрәк түгелме соң болар? Күп, әлбәттә. Ләкин алар шигырьдә чәчелеп ятмыйлар, сюжетка зыян китермиләр. Аннары шигырьләрдә тагын бер кызык күренеш еш күзгә чалына: шагыйрьнең күп шигырьләре — **жанрлар синтезы да**. Мәсәлән, шушы ук шигырьдә:

**«Бик гади техника!» — дип,**
**Шәһәр кунагы көлде.**
**«Ат йөртү соң эшме!» — дип**
**Урындык куеп менде...—**

кебек шаян юллар да,

**Әйттек кунак егеткә:**
**— Озак булыр аңлату,**
**Тормоз белү — бер нәрсә,**
**Кирәк атны ярату,—**

шикелле дидактикага тартым урыннар да,

**Әйтү бушка китмәде,**
**Төшендерү ярады —**
**Беренче кат ул атның**
**«Фара»сына карады...—**

дигән лирик строфалар да чагылып китә. Мондый шигырьләрне язу өчен, һичшиксез, оста каләм иясе булу кирәк...

Балалар дөньясы, шул исәптән балалар шигърияте дә җәнлекләрсез, кош-кортларсыз була алмый. Җәнлекләр бит, гомумән, балалар әдәбиятының аерылгысыз бер традицион компоненты. Мультфильмнарны, әкиятләрне, шигырьләрне аларсыз гына күз алдына китереп карыйк әле,— шундый коры, күңелсез булырлар иде. Шуңа күрә яңа китабында да шагыйрь үз иҗатындагы, үз арсеналындагы мәгълүм җәнлекләрдән оста файдалана. Яңа ситуацияләрдә, яңа вакыйгалар, күренешләр фонында, билгеле. Алар шигырьләрдәге балалар дөньясын җылытып, җанландырып, тулыландырып җибәрәләр. Аннары, җәнлекләр бит балаларга гади иптәш кенә түгел. Төрле кыяфәтле, төрле холыклы бу җан ияләре балалар өчен символик мәгънәгә дә ия. Халык иҗатыннан ук килгән ул образлар безнең күңелләргә сеңгән инде. Без, әйтик, бүрене — усал, төлкене — хәйләкәр, куянны куркак дип уйларга өйрәнгәнбез. Әмма әлеге китапта алар башка яклары белән дә ачылып китәләр. Шагыйрь өчен алар сурәт тудыру чыганагы, соклану предметы. Ул җәнлекләрне кызгана, аларга карата шәфкатьле булырга чакыра. Безнең балалар экзотик җәнлекләрне: жирафларны, филләрне, аюларны, ташбакаларны телевизордан, бәхетлерәкләре зоопаркка гына барып күрә ала. Ә китапта безнең, экзотик дигән җәнлекләребез балалар белән бергә уйнап йөриләр, шаяралар, бер-берсенә ярдәм итешәләр. Алар безнең балаларыбыз өчен гадәти колыннар, бозаулар, бәрәннәр, атлар кебек үк якын дусларга әвереләләр. Мондый могҗизаны тылсымлы каләм генә булдыра аладыр, мөгаен...

Ш. Галиевнең Шәвәлие, әйткәнемчә, үтә дә халыкчан, тапкыр, җор телле. Ул тапкырлык, җорлык, шаянлык халык иҗатын-

нән, халыктан һәм, әлбәттә, иң элек шагыйрьнең үзеннән килә. Кайберәүләр әлеге тапкырлыкны бик үк балаларча түгел дияргә дә мөмкиндер. Дисеннәр. Ә бит чынында халыктагы тапкырлыкның нигезе, башлангычы шул ук балаларда. Әгәр игътибар беләнрәк тыңласаң, бала авызыннан очып чыккан канатлы сүзләрне, гыйбарәләрне еш ишетергә туры килә. Бары тик аларга игътибарлы булырга гына, бәя бирә белергә генә кирәк. Шул чагында без балаларның нинди акыл ияләре икәнен тиз аңларбыз. Ш. Галиев балаларның шул үзенчәлекләрен яхшы белә һәм шигырьләрендә оста файдалана.

Ш. Галиевнең бу китабында юмор бармы соң? Шигырьләрендә юмор булмаса, Шәүкәт Галиев буламыни ул. Ш. Галиев юморы, дөресрәге, шаянлыгы «Канатлы малай»да да шул килеш. Ләкин аларның күбесе инде җитдирәк шаянлык. Ул шаянлык артында уйланулар, дулкынланулар, балаларның киләчәге турында борчылулар ята. Чөнки балалар бүген нинди булып үсә, нинди тәрбия ала, нинди уйлар белән яши, киләчәктә дә шундый булачак. Ш. Галиев шаянлыгын **хәрәкәтчән шаянлык** дип атарга да була. Ул сүздән, баланың холкыннан, аның тискәре гадәтләреннән генә түгел, хәрәкәтләреннән дә юмор китереп чыгара. Аның кечкенә геройлары һәрчак хәрәкәттә. Алар уйныйлар, шаяралар, сәяхәт итәләр. Алар — бөек оптимистлар. Джанни Родариның әйтүенә караганда, шаян, күңелле кеше тизрәк үсә икән. Бөек балалар язучысы белми әйтмәс. Ш. Галиев геройлары да, аның меңләгән укучылары да, әлеге шигырьләрне укып, башкалардан тизрәк үсәчәкләр, мөгаен.

Шагыйрь туктаусыз эзләнә, хыяллана, бөтен фантазиясен эшкә җигә. Эзләнү бушка китми. Ул яңадан-яңа мәзәкләр, маҗаралар, кеше ышанмаслык хәлләр уйлап таба. Китаптагы шигырьләрне укыганда шагыйрьнең фантазиясенә, тапкырлыгына гаҗәпкә каласың. Ул гадәти әйберләр хакында көтелмәгән шигырьләр яза. Әйтик, шагыйрьнең элекке китапларында рәхмәтләр хакында берничә шигыре бар иде инде. һәм бик шәп шигырьләр. Әлеге китапны ачып укыйм: тагын рәхмәтләр турында шигырь. Исеме «Тәмле рәхмәт». Моннан соң да Ш. Галиев рәхмәтләр хакында язмас дип кем әйтә ала? Күрәсез, фантазия булганда бер рәхмәт турында мең шигырь язарга мөмкин икән.

Тагын бер гаҗәпләндергән әйбер: шагыйрьнең татар теленә чиксез хөрмәте, мәхәббәте, телне тирәнтен тоюы, тел белән ювелирларча, виртуозларча эш итүе, халыктан килгән йөгерек телдән оста файдалануы. Бу җәһәттән, аның **филологик шигырьләре** махсус бер тикшеренүне таләп итә торган өлкә. Шулай да берничә сүз әйтми булмый. Әлеге шигырьләр шагыйрьнең озын иҗат юлы буйлап сузылган. Без анда төрле каламбурларны, палиндромнарны, шигъри табышмакларны, сүз уйнатуларны күп күрәбез. Инде телне күпме боргаларга мөмкин, аның тагын нинди хикмәтләрен табып була дип уйлыйсың. Ә алар «Канатлы малай»да янә калкып чыккан. «Бабалайка», «Кәли ала иләк», «Бүре эзләү», «Аякъязма», «Надан карга» һ. б. шигырьләр. Алар — шагыйрьнең стихиясе. Алар балаларыбызны туган телне яратырга, аның нечкәлекләрен, серләрен ачарга, телнең нинди олы көч икәнен аңларга өйрәтә, тел белән әллә нинди тылсымнар ясарга мөмкин икәнен күрсәтә. Татар теле укытучылары ул шигырьләрдән дәресләрдә файдаланалар микән, төгәл генә әйтүе кыен. Әмма алар дәресләр өчен — олы хәзинә. Алар ярдәмендә балаларның фантазиясен үстерергә, грамматик уеннар уйлап чыгарырга була. Киләчәктә шагыйрь шундый шигырьләрен бергә туплап, аерым китап итеп чыгарыр әле дигән өмет бар. Татар теле укытучыларына ярдәмлек итеп булса да чыгарырга кирәк аны.

Шәүкәт Галиевнең яңа китабы миндә шундый хисләр уятты. Канатлы шагыйрьнең канатлы малайлар турында язылган канатлы шигырьләрен безнең малайларыбыз, кызларыбыз һәм балачакларыннан аерылмаган өлкән дусларыбыз яратып укырлар дип ышанам. Чөнки һәркемнең канатлы малай буласы килә!

**Роберт МИҢНУЛЛИН.**

# РАВИЛ КУКУШКИН



Равил Кукушкинның аерылып торган сыйфатларыннан берсе — мөгаен, шигъриятне нечкә тоемлавындадыр... Марксистик-ленинчыл эстетика, әдәбият гыйлеме нигезләрен өйрәнүе, психология, логика фәннәре белән ныклап кызыксынуы, фикер һәм хис бердәмлеген тудырган образлы, ассоциатив фикерләү серләрен ачыклау юнәлешендә махсус эзләнүләр алып баруы аның әдәби-эстетик эшчәнлеге өчен тәпле нигез булды. Яшь галимнең шигъри образлар ясалышындагы төп принципларны аңлаткан теоретик монографиясе нәкъ әнә шундый системалы һәм комплекслы характерга ия дә.

Соңгы елларда Равил балалар әдәбияты үсешен өйрәнүдә зур активлык күрсәтә. Балаларга багышланган шигъриятнең матурлыгын һәм үзенчәлеген бөтен нечкәлеге белән анализлап язылган тәнкыйть мәкаләләре, турыдан-туры аның катнашы белән төзелгән «Татар балалар поэзиясе антологиясе», ниһаять, беренчеләрдән булып, татар балалар поэзиясенең фольклордан алып бүгенге көнгәчә үсешен яктырткан «Шигъри бишек», «Канатлы дөнья» китаплары барлыкка килү — әдәби хәрәкәтебездә, һичшиксез, яңа бер адым.

Татар әдәби тәнкыйтендә бүген шактый җанлану сизелә. Ләкин аңа еш кына әле эстетик профессиональ өлгергәнлек җитенкерәп бетми. Әдәбият гыйлеме әзерлекле, сәләтле, яңа кадрларга мохтаҗ. Равил Кукушкин — әдәбиятыбызга зур хезмәт күрсәтүгә әзер булган әнә шундый өметле яшьләрнең берсе.

**Хатип ГОСМАН,**
филология фәннәре докторы, профессор.

# КАВИ ЛАТЫЙПОВ



Кави Латыйповның исеме укучыларга күптән таныш. Егерме елдан артык иҗат гомерендә ул татар, рус, чуваш телләрендә унга якын китап чыгарды. Алар арасында шигырьләр, хикәяләр, очерклар да, балалар өчен язылган әсәрләр дә бар. Прозаик буларак, Чувашстан материалында ул матур булып ачылды: космонавт Николаев һәм Чапаев турындагы повестьлары — укучыны җәлеп итәрлек язылганнар. Кыска хикәяләрендә дә аның үз ачышлары, табышлары бар.

Шигъриятта Кави озак еллар эзләнде. Беренче чор иҗаты беркатлырак тәэсир калдыра. Ә менә соңгы елларда ул поэзиядә үзенчәлекле шагыйрь булып ачылды. Шигырьләренең күбесе профессиональ югарылыкта, поэзиягә яңалык алып килерлек язылганнар. Кавиның үз тавышы көннән-көн ачыла, ныгый бара.

**Илдар ЮЗЕЕВ.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАТ СОЮЗЛАРЫ ПЛЕНУМЫ

29 октябрьда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында ТАССР иҗат союзларының СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган берләштерелгән пленумы булды.

Пленумны ТАССР Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. С. Мөхәммәдиев ачты. Докладлар белән идарә председательләре: Язучылар союзыннан — Г. А. Ахунов, Композиторлар союзыннан — М. З. Яруллин, Художниклар союзыннан — Ә. И. Тумашев, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлегеннән — Р. А. Җиһаншина, РСФСР Архитекторлар союзының Татарстан оешмасыннан — С. С. Айдаров һәм ТАССР Кинематографистлар союзының беренче секретаре И. Н. Алексеев иптәшләр чыкты.

Пленум эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Ю. М. Воронин, культура бүлеге мөдире М. М. Мусин һәм КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Аны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Г. А. Ахунов алып барды.

Партбюроның отчет чорындагы эше турындагы доклад белән партоешма секретаре Р. Мөхәммәдиев чыкты.

Фикер алышуларда язучылар Г. Баширов, М. Садри, И. Юзеев, Л. Ихсанова, Г. Паушкин, М. Скороходов, Р. Фәйзуллин, Р. Кәрами, КПССның Бауман райкомы икенче секретаре Ф. Х. Габидуллин һ. б. катнашты.

Отчет-сайлау җыелышында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин чыгыш ясады.

Җыелышта Татарстан Язучылар союзы башлангыч партия оешмасының 9 кешедән торган яңа бюросы сайланды. Бюро утырышы секретарь итеп яңадан Р. Мөхәммәдиевне сайлады.

## ТЕАТР ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Партбюроның бер еллык эше турындагы отчет докладын партоешма секретаре Татарстанның халык артисты Н. Дунаев ясады.

Фикер алышуларда СССРның халык артисты Ш. Биктимеров, РСФСРның халык артистлары Р. Җиһаншина, М. Сәлимҗанов, РСФСРның атказанган артисткасы Ш. Әсфәндиярова, ТАССРның халык артистлары Г. Камалова, Һ. Солтанов, ТАССРның атказанган артисткасы Ф. Хәмитова, театр директоры Н. Хәйруллин, КПССның Вахитов райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Р. Гыйльмиева иптәшләр катнашты.

Җыелышта партбюроның яңа составы, ә бюро утырышында секретарь итеп ТАССРның халык артисты И. Баһманов сайланды.

## ИҖАТ ЯШЬЛӘРЕ СЕМИНАРЫ

Казанның Яшьләр үзәгендә республика иҗат яшьләренең ике көнлек семинары булды. Ул ВЛКСМ өлкә комитеты, культура работниклары профсоюзы өлкә комитеты, ТАССР Культура министрлыгы һәм республика иҗат союзлары тарафыннан оештырылды. Анда 80 нән артык яшь язучы, рәссам, композитор, кинематографист, архитектор һәм артист катнашты.

Семинарны ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре Б. Д. Леушин ачты. Доклад белән ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. М. Сафин чыкты.

Семинарда катнашучылар кызыклы һәм файдалы лекцияләр тыңладылар, секцияләргә бүленеп, иҗат мәсьәләләре турында фикер алыштылар.

Семинар эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты һәм чыгыш ясады.

## КҮРГӘЗМӘ АЧЫЛДЫ

ТАССР Сынлы сәнгать музеенда мәшһүр рәссам И. И. Шишкинның юбилей күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәне ачуда ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиев, СССРның халык художнигы, СССР Художество академиясе член-корреспонденты Х. А. Якупов, ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе, РСФСРның атказанган художнигы Ә. И. Тумашев, ТАССР Сынлы сәнгать музее директоры, ТАССРның атказанган культура работнигы Ю. И. Петров, халык депутатларының Алабуга шәһәр Советы башкарма комитеты председателе урынбасары Р. И. Миңнуллин чыгыш ясады. Казан шәһәре мәк-

тәп балалары рәссамның портреты янына чәчәкләр куйдылар.

Күргәзмәне ачуда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев катнашты.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

ТАССР Язучылар союзы идарәсенең киңәйтелгән утырышында «Казан утлары» журналының быелгы 1—6 саннарында дөнья күргән әсәрләр турында зур сөйләшү булды.

Сөйләшүдә яшь язучы Ф. Гыйльметдинов — проза, яшь шагыйрә Ф. Низамова — поэзия, филология фәннәре кандидаты Н. Лаисов — әдәби тәнкыйть һәм яшь шагыйрь Р. Юнысов очерк жанры буенча докладлар белән чыктылар.

Докладлар буенча фикер алышуда ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, өлкән әдибебез Нәкый ага Исәнбәт, тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов, Чаллы язучылар оешмасының җаваплы секретаре Разил Вәлиев, шагыйрь Әхмәт Рәшитов һәм «Казан утлары» журналының баш редакторы, шагыйрь Ренат Харис катнашты.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

Башкала язучылары һәм «Новый мир» журналы редакциясе белән Кама автомобиль заводы төзүчеләре арасындагы дуслык Чаллыда бу гигант төзелә башлагач ук урнашкан иде. 1971 елның сентябрендә, мәсәлән, «Новый мир» журналында «Яр Чаллы» дигән яңа рубрика барлыкка килде. Журнал үз коллективы һәм авторлар көче белән Кама автомобиль заводының елъязмасын булдыра башлады. Бу эштә, язучылар һәм журналистлар белән беррәттән, КамАЗның танылган төзүчеләре, төзелеш җитәкчеләре, партия работниклары да актив катнашты, КамАЗга багышлап аерым китаплар, фотоальбомнар чыгарылды.

Шушы матур дуслыкның бер чагылышы буларак, Мәскәүдә, язучыларның А. А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында СССР Язучылар союзы һәм «Новый мир» журналы оештырган кичә булды. Анда КамАЗ хезмәтчәннәре, төзүчеләр һәм Чаллының җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Кичәне «Новый мир» журналының баш редакторы В. Карпов алып барды.

Язучылар белән төзүчеләрнең дусларча хезмәттәшлеге турында СССР Верховный Советы депутаты, «Спецстрой» төзелеш идарәсе бригадиры Р. Ганиев сөйләде.

* * *

Мәскәүдә, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Актерлар йортында, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары — 1961 елда М. С. Щепкин исемендәге театр училищесының татар студиясен тәмамлаучыларның иҗат кичәсе булды. СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган әлеге кичәдә училище ректоры профессор М. Новохижин, академия театрының баш режиссеры, РСФСРның халык артисты М. Сәлимҗанов, ТАССРның халык артисты Н. Дунаев, драматурглар Т. Миңнуллин һәм Р. Батуллин чыгыш ясадылар, аннары студияне тәмамлаучылар катнашында «Ябырылу», «Хуш, Наззыгөл», «Галиябану», «Кичер мине, әнкәй», «Сүнгән йолдызлар», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Агай-эне — ак мыек...» спектакльләреннән өзекләр күрсәтелде.

## ФИЛЬМНАР ФЕСТИВАЛЕ

СССР төзелүнең 60 еллыгына багышлап, республикабыз районнарында бер атна дәвамында кинофестиваль үткәрелде. Татарстан Кинематографистлар союзы, республика Кинофикация дәүләт комитеты, Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт комитеты оештырган бу фестиваль вакытында Алабуга, Чаллы, Түбән Кама, Лениногорск, Әлмәт шәһәрләрендә, шушы төбәкләрнең колхоз-совхозларында Казан кинохроника студиясе һәм телестудия төшергән «Бу — КамАЗ», «Җәлил: көрәш сәхифәләре», «Ренат Ибраһимов жырлый», «Сәйдәшев моңнары» һ. б. документаль фильмнар, Татарстанга багышланган махсус киножурнал, «Хисләрнең яңаруы», «Хәзинә» нәфис фильмнарының татарчалаштырылган вариантларыннан өзекләр күрсәтелде, тамашачылар белән очрашулар үткәрелде.

## ШАГЫЙРЬ ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

Казанның Төзүчеләр культура сараенда шагыйрь Нури Арслановка 70 яшь тулуга багышланган иҗат кичәсе булды.

Аны Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре, тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев ачты. Н. Арслановның тормыш һәм иҗат юлы турында шагыйрь Р. Гатауллин сөйләде.

Юбилярны партия, совет, комсомол органнары һәм республикабыз иҗат союзлары вәкилләре кайнар котлады.

Кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, партиянең Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова катнашты.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталарының концерты булды.

## ШАГЫЙРӘ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

Әдәбиятыбызда якты эз калдырып киткән күренекле шагыйрә Саҗидә Сөләйманованың әсәрләре төрле телләргә тәрҗемә ителде, яратып укыла. Ул 25 ел нефтьчеләр башкаласы — Әлмәттә эшләп, иҗат итеп яшәде. Нефть техникумы укытучысы, КПСС шәһәр комитеты лекторы, журналист һәм язучы буларак та, коммунист С. Сөләйманова һәрвакыт тормышның эчендә кайнады, хезмәт кешеләренең, укучыларның тирән ихтирамын казанды.

Быел халык депутатларының Әлмәт шәһәр башкарма комитеты карары белән Әлмәттәге яңа төзелеп килә торган бер урамга татар совет шагыйрәсе Саҗидә Сөләйманова исеме бирелде.

# РӘССАМ МӘХМҮТ УСМАНОВ

Татарстанның халык художнигы Мәхмүт Усман улы Усманов иҗатын аз гына булса да белгән кешегә рәссамның киң күңелле һәм якты хисләр белән тасвирланган хезмәтләре яхшы таныш. М. Усманов картиналарыннан шатлык та, сагыш та, рәссамның халык тормышы белән һәрвакыт тирән бәйләнештә булуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән бәхет тойгысы да бөркелеп тора. Төсләрне нинди генә күренешкә әйләндермәсен, әйтик: зирәк картның хикәятләрен тыңлаучы балалармы ул, туган җиребез урманнарының мәһабәт тынлыгымы, республикабыз киңлекләрен бизәп, күккә күтәрелгән «кара алтын» манараларымы — барысы да Бөек Ватан сугышының ачы тәҗрибәләрен татыган рәссам сурәтләвендә аеруча зур бәя һәм әһәмияткә ия.

М. Усманов рәссамнарыбыз арасында беренчеләрдән булып нефтьче якташларыбыз янына барып чыкты, бу темага гаять үзенчәлекле, шигъри һәм тантаналы романтик аһәң бирде. Табигать аның иҗатында кеше акылы һәм куллары иҗат иткән күренешләрдән аерып ала алмаслык бербөтен сурәткә әверелә. «Иделдә буровойлар», «Яңа Кама», «Татарстан нефть-химиясе» кебек картиналар яңалыкны иҗат итүче Кеше хезмәтенә гимн булып яңгырый.

Мәхмүт Усмановның туган илебез горурлыгы КамАЗга багышланган «КамАЗда яңа кала» дигән триптихын өч полотнолы сюитага тиңләргә мөмкин.

«КамАЗ»— триптихның төп өлеше. Рәссам, югары бер ноктадан карап, иске Чаллыдан калкып чыккан төзелешләр киңлеген тасвирлый. Бөтен шәһәр кар белән өртелгән һәм менә әкият кебек булып, иртәнге алтынсу-зәңгәр төтеннәре белән күз алдына килеп баса. Түбәләре күккә тигән йортларны, краннарның якты төсләр белән бирелгән силуэтларын, Кама буйларының күз карашы «тота» алмаслык ераклыкка җәелгән киңлекләрен шушы матурлык үз кочагына алган. Картинага карау белән, яшь каланың күңелгә үзенә бер рәхәтлек китерә торган җиңелчә генә шау-шу, гөрелте белән тулганын тоеп аласың: урамнар, иркен проспектлар буйлап кешеләр узып бара, машиналар хәрәкәткә килә — хезмәт көне башлана. Шәһәр пейзажы беренче карашка тыныч кына булып күренсә дә, чынлыкта ул бүгенге көннең тыгыз киеренкелегенә чумган икән! Төгәл ритмик төзелештәге композиция, сурәтләү планнары, тулы яңгырашлы төсләр һәм үзенчәлекле иҗат ысуллары табигый аралашып баруы ярдәме белән, рәссам, әйләнә-тирәбезнең шигъри, лирик төсмердә булуына бәйләп, республикабыз кодрәтенә дан җырлаган.

Әлеге картина язылу рәвеше, ягъни эш техникасы буенча да кызыклы. Мозаикага охшаш киндер өстендә үтә нәфис алтынсу-зәңгәр төсләр балкый. Әйтерсең лә, мозаика шакмакчыкларының төсләр агылышы белән уйный-уйный, оста төрле зурлыктагы сурәтләр тезә. Шуңа күрә дә төсләр хәрәкәтен тыныч-гамьсез килеш, читтә торып күзәтә алмыйсың: киндер хәрәкәткә килә, көчле, якты мохит сине үз артыннан ияртә, күңеленә бетмәс-төкәнмәс дәрт, яшәү дулкыны, куәт тула...

Кама якларындагы хезмәт батырлары, йолдызлары ерак-еraklардан күренерлек биеклеккә күтәрелде. Юл дәвам итә. Мәхмүт Усмановның бу якларга багышланган 30 елдан артык хезмәте шушы күтәрелештә бер этәргеч булды дисәк, һич хата булмас. Аның әсәрләрен инде бүген үк тарихыбызның гасырлар буе кул тимәгән Кама яклары елъязмасы итеп танырга була. Һәм рәссам безгә ачып биргән яңа Кама сурәте — бәхетле иҗатның рухи символы, замандашыбызның батыр хезмәт символы ул.

**Д. САДЫЙКОВА,**
Татарстанның сынлы сәнгать музее фәнни хезмәткәре.


●

**Тышлыкның дүртенче битендә: М. Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет театры солистлары Зөһрә Ильясова һәм Наил Сәрвәров — Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетында.**

Р. Мансуров фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ